КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## Бу санда

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Гөлүсә БАТТАЛ. Сагындырган икән ап-ак карлар... *Шигырь.* ....3
Фирдүс ГЫЙМАЛТДИНОВ. Урда ханы Үзбәк. *Роман.* ....4
Мөхәммәт МИРЗА. Адәм баласы. *Бишьюллыклар.* ....72
Факил САФИН. Күкләр җиргә тоташкан. *Повесть.* ....76
Лилия СӘГЫЙДУЛЛИНА. Алсуланып, янә кояш чыга... *Шигырьләр.* ....122
Шәмсия ҖИҺАНГИРОВА. Мәхәббәт ничәү була? *Хикәя.* ....127
Фәрит ГАБДЕРӘХИМ. Кабатлыйсың бабаң хатасын... *Шигырьләр.* ....145

ЯҢА ИСЕМНӘР

Диана ФӘРХЕТДИНОВА. Язмышның соңгы бүләге. *Хикәя.* ....149

КАРДӘШ ХАЛЫКЛАР ӘДӘБИЯТЫ

Алексей САГАТАЕВ. Минем халкым – калын тайга... *Шигырьләр. (Хакас теленнән Фәнил Гыйләҗев тәрҗемәләре).* ....152

ЮБИЛЕЙЛАР

Нурфия ЙОСЫПОВА. Шигъри сүз кодрәте *(Мөхәммәт Мирза иҗатына бер караш).* ....156

ХӘТЕР

Марс ГАИТОВ. Җыр шигърияте алиһәсе. ....162

МИЛЛӘТТӘШЛӘРЕБЕЗ

Дания ЗАҺИДУЛЛИНА. Татарстаннан читтә – татар галимнәре династияләре. ....170

ИДЕЛ БУЕ БОЛГАР ДӘҮЛӘТЕНДӘ ИСЛАМ ДИНЕН КАБУЛ ИТҮНЕҢ 1100 ЕЛЛЫГЫ

Илдус ЗАҺИДУЛЛИН. Мәхкәмәи шәргыянең XVIII гасыр азагы – XIX йөз уртасында эшчәнлеге. ....176

2023 елда дини бәйрәмнәр һәм истәлекле көннәр. ....183

«Казан утлары» архивыннан. ....184

ГАЗИЗ ТАВЫШЛАР

Рухына, йөгез, бер дога... *(Аяз Гыйләҗевнең тууына – 95 ел).* ....186
Аның моңы безгә шундый таныш... *(Илдар Юзеевнең тууына – 90 ел). Сәхифәне Нәсим АКМАЛ алып бара.* ....187

ШАЯН СӘХИФӘ

Мәңге яшь «Чаян»га – 100 яшь! Сәхифәне *Алмаз ХӘМЗИН әзерләде*....188
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....190

КАЗАН УТЛАРЫ
*№ 1 (1203) 2023*

*БАШ МӨХӘРРИР –*
**Рөстәм Госман улы ГАЛИУЛЛИН**

*ИДАРӘ:*
**Ирада Әюпова**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Искәндәр Гыйләҗев**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Ркаил Зәйдулла**
**Илгиз Зәйниев**
**Илфак Ибраһимов**
**Зиннур Мансуров**
**Ким Миңнуллин**
**Газинур Морат**
**Рүзәл Мөхәммәтшин**
**Айдар Сәлимгәрәев**
**Равил Фәйзуллин**
**Илсур Һадиуллин**
**Данис Шакиров**
**Ленар Шәех**

*Баш мөхәррир урынбасары:* **Вакыйф Нуриев.**
*Җаваплы сәркатип:* **Ландыш Әбүдәрова.**
*Бүлек мөхәррирләре:* **Фәнил Гыйләҗев, Рафис Корбан.**
*Мөхәррирләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Гөлия Сәлахова.**
*Сайт мөхәррире:* **Ләйсән Зарипова.** *SMM-белгеч:* **Алинә Хәбибуллина.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова** (өлкән бухгалтер)**.**
*Машина йөртүче:* **Наил Кадыйров.**

✉✉: Редакция адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Кабул итү бүлмәсе – 222-09-83 (өст.1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Җаваплы сәркатип – 222-05-50 (өст. 1617).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1267), касса – 222-09-84 (өст.1874).*
Сайт: kazanutlary.ru; электрон почта: kazanutlari@yandex.ru

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Гамәлгә куючы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче адресы: 420097, Казан, Академия урамы, 2.
Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 29.12.2022, график буенча 29.12.2022, басылып чыгу вакыты 11.01.2023
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 $^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ О-3845. Тираж 6041.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2020 елның 13 ноябрендә теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-79467.
Индекслар: ПО277 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен),
П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), П2368 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
12+

© «Казан утлары», 2023 ел

## Гөлүсә Баттал

***

Сагындырган икән ап-ак карлар,
Сагындырган икән ап-ак кыш!
Көлә-көлә кар бөртеге саныйм –
Әллә өнем инде, әллә төш?

Сагындырган икән кар көртләре,
Дөнья мәшәкатен күмәрлек...
Югаласы килә ак буранда –
Сагындырган ихлас юләрлек!

Сагындырган икән салкыннар да,
Өшетерлек битем очларын.
Кышкы челләләрдән саклап калыр
Сагындырган җылы учларың.

Сагындырган бәскә чумган дөнья,
Бу карлардан күзләр камаша!
Ак кышларда ак өметләр диеп
Сагынудан йөрәк алдаша...



Фирдүс
Гыймалтдинов

# УРДА ХАНЫ ҮЗБӘК*

РОМАН

## Пролог

1341 елның язы гаҗәеп җылы һәм матур булып килде. Урданың тугызынчы ханы Үзбәк үлем түшәгендә ята иде. Аңа табигатьнең яме инде кирәкмәс. Тик ул барыбер үзен бәхетле тоя. Аңа, Урданың башка шактый ханнарыннан аермалы буларак, бу дөньядан үз үлеме белән китәргә насыйп булыр шикелле. Аллаһы Тәгаләгә догалары, мөселман өммәтенә хезмәте бушка түгел, димәк.

Үзе төзеп чыккан Сарай Әл-Җәдид каласының нәкъ үзәгендә хан йорты Алтынташ. Аның зур гөмбәзендәге кыйгач ай шәһәрнең теләсә кайсы почмагыннан күренеп тора. Тирә-якта ике дистәгә якын мәчет калкып чыккан. Киң мәйданнар сәүдәгәрләр тавышында кайный. Урда башкаласына дөньяның төрле кыйтгаларыннан кәрваннар агыла, аннан ары китәләр. Кайберләре Идел буйлап өскә, рус кенәзлекләренә кузгала. Кайберләре көнбатышка таба юнәлә. Сәүдәгәр биредә үзен бик тыныч хис итә. Үзбәк хан тырышлыгы белән елга-сулар аша кичүләр һәм күперләр көйләнгән, кәрван-сарайлар ерак юлдан ял итәргә мөмкинлек бирә. Урда җирендә аларга беркем дә кагылмаячак, малларын таламаячак. Гадел хан далага тынычлык алып килде, дөньяның нәкъ кендегендә урнашкан дәүләт шуның бәрабәренә чәчәк ата башлады.

Үзбәк хан күзләрен йомып, йокыга талырга маташты. Тик янәдән

* Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе тарафыннан үткәрелгән конкурсның «Роман» номинациясендә икенче урынны алган әсәр.

Фирдүс ГЫЙМАЛТДИНОВ (1980) – *Татарстанның атказанган матбугат һәм массакүләм коммуникацияләре хезмәткәре; «Буа» китабы авторы. Казанда яши.*

саташулы төшләргә генә чумды. Алар һәрвакыт бер үк төрле, аны гомере буе бимазалыйлар...

Имештер, Үзбәкнең яшь чагы. Менә ул атына атланган килеш дала буйлап юырттыра. Уң ягына борылып караса, янәшәдә этисе Тогърулҗа. «Эти, хәлләрең ничек?» – дип сорый ул. Әмма этисе берни дә дәшми. Аның йөзе дә тонык, көч-хәл белән генә шәйләнерлек.

Кинәт офыктан кара болыт килеп чыга, ул тиз арада тирә-юньне каплап ала. Үзбәк күккә карый – һавада яшен ялтыраганы күренә. Янә этисенә борыла һәм имәнеп китә – Тогърулҗа янәшә, ләкин башы юк. Коты алынган Үзбәк аяк астына күз ташлый. Алар инде далада түгел, ә кан диңгезе эчендә. Өстән дә яңгыр урынына кан ява.

Үзбәкнең каршысына өрәкләр очрый. Күбесен яхшы хәтерли ул. Йә үз кулы, йә әмер биреп, гомерләрен өзде ул аларның. Өрәкләр берни әйтми, атын чаптырган җайдакка үпкәле караш белән текәлеп басып кына торалар.

Ниһаять, болытлар тарала, канлы диңгез артта кала. Чалт аяз күктә кояш кыздыра. Үзбәк, еракта басып торган хатын-кызны күреп, аңа таба юнәлә.

Хатын-кыз арты белән басып тора. Килеп җиткәч тә, Үзбәк атыннан сикереп төшеп, аңа якыная. Хатын-кыз борылгач та, бу – әнисе Әрибах икәнлеген аңлый. Ул әнисе каршына тезләнә. Тегесе исә елмаеп, улын аякка бастыра, сөю тулы күзләреннән нур сирпелә. «Улым, безгә биредә күңелсез, без сине көтәбез», – ди Әрибах һәм яктылыкка кереп юк була...

Үзбәк шабыр тиргә батып, уянып китте. Кемдер килеп, иреннәрен чылатты, битен сыпырды. Ханның кулын кымшандырырга да, башын борырга да хәле юк, күзләре генә тирә-якка карарга сәләтле иде.

– Ханның сәгатьләре санаулы. – Хакимнең шәхси табибы Ибраһимның сүзләре Үзбәкнең йөрәгенә кадалды.

– Улым, этиең белән бәхилләш. Ул сиңа хәер-фатихасын бирде. – Яраткан хатыны Тайдуланың тавышы бик салкын һәм төссез иде, әйтерсең, иренең үлем түшәгендә ятуы гадәти бер вакыйга. Дистәләрчә еллар буе яңгыраган җылылык, мәхәббәт тойгылары гүя беркайчан да булмаган.

Улы этисе каршына тезләнде. Тик бу Үзбәк көткән Тәнибәк түгел, Җанибәк иде. «Мин варис итеп Тәнибәкне калдырдым бит!» – дип, яман ачу белән кычкырмакчы иде Үзбәк хан. Ләкин теле тыңламады, сүзләре ишетелмәде. Җанибәк аның гаҗәпләнүен һәм нәфрәтен тойдымы-юкмы – бусы Үзбәккә караңгы калды.

Кинәт Үзбәкнең зиһене ачылды. Ул Тайдуланың мәкерен аңлады. Авызы кипте, йөрәге дөп-дөп тибәргә кереште.

– Тор, улым, этиең сиңа ышанычын белдерде, – диде Тайдула һәм үзе дә хан кырына килде. – Ибраһим табиб, Җанибәк, бөек ханыбыз белән ялгызым гына бәхилләшергә телим, чыгып торсагыз иде...

Тайдула хатын бүлмәдәгеләрнең чыгып китүен башын горур, югары тоткан көе борылып карамый гына көтте, гүя аркасы белән дә аларның һәрбер гамәлен күреп тора, сүзеннән чыкмасларына җаны-тәне белән инанган. Ханбикә телдән язган Үзбәк янына килде. Хакимнең күзләрендә зәһәрлек, рәнҗеш, яман ачу уты яна, соңгы сулышын алырга җыенганда да, ул үзенең яман холкын иярли алмый, хәл керсә, Тайдуланы әллә нишләтергә әзер сыман. Тик хатыны иренең инде берни дә кыла алмаячагын белә, шуңа

аннан тамчы да шүрләми. Элегрәк башын иеп, калтыранып торса, хәзер агарып чыкканчы кысылган юка иреннәре белән чак кына көлемсери дә төсле.

– Синең дә соңгы сулышың чыгар вакыт җитәр икән, Урда ханы Үзбәк... Әле юри генә санап утырдым – егерме биш елдан артык гомерем синең белән үткән. Баялун хатын тәрбияләп үстергән бер мескен җария, кол гына идем бит мин. – Тайдула, түшеннән хач чыгарып, аны күз алдында әйләндергәләде. – Мәрхүм әтием агачтан юнып ясаган моны. Ул мине сарайдагы хорафат-бәлаләрдән, синең яман ачуыңнан саклап торды. Хәрәмдә шушы хачка яшерен урын эзли-эзли җаннар чыга иде. Хәзер инде курыкмыйча тагып йөри алам. Ул булмаса, әти-әниемнең рухы сакламаса, явыз Урда ханының сараенда хәзерге дәрәҗәгә ирешә алган булыр идеммени?! Син мәрхүм булгач та, шул кодрәтемне югалтасы килми. Хакимлек – яман чир икән. Син аны миннән дә яхшырак beләсең, Үзбәгем. Тик... Тәхеткә синнән соң Тәнибәк утырса, хансарайда минем дәрәҗәм бетәчәк, сүзем үтмәячәк. Ана йөрәгенең ничек бәргәләнгәнен белсәң икән! Тәнибәк тә газиз улым, җанымның бер өлеше. Тик тәхет Җанибәккә күбрәк килешә. Монысын да мин ана күңеле белән сизенәм. Ханбикә Тайдула күңеле белән... Васыятеңне үтәрмен – Тәнибәк тәхеткә менәр. Тик озак утыра алмаса, зинһар, рәнҗемә. Сиңа рәхәт – үлдең дә, башка мәшәкатең юк. Ә безгә әле яшисе, Үзбәгем...

Кинәт Үзбәк хан ыңгыраша башлады, соңгы көчләрен җыеп, терсәкләренә таянып, башын күтәрде, Тайдулага кулларын сузды. Тик Тайдула аның кулын алмады, тораташтай басып тора бирде.

– Күпме дошманнарны җиңдең, бөек хан! Күпме көндәшләреңнең башына җиттең. Бер генә көчне буйсындыра алмадың – ул да булса, миңа булган мәхәббәтеңне. Шушындый олы хис белән мине яратуың өчен сиңа зур рәхмәт, җир йөзендәге теләсә кайсы хатын-кызның иң зур хыялы бит бу.

Бәхил бул, Урда ханы Үзбәк, мәңгелектә тыныч йокла!

Үзбәк хан авыр сулыш алды да кисәк кенә тартышып, түшәгенә ауды. Аның күзләре, асылташ сыман катып, түшәмгә текәлгән иде. Тайдула сак кына уң кулы белән сыпырып, аларны мәңгелеккә япты.

– Урдага олы кайгы килде, бөек ханыбыз мәрхүм булды! Хакимебезне җирләр өчен әзерлек эшләрен башлагыз! – дип, ишек катында да ишетелерлек итеп сөрән салды Тайдула хатын һәм җил-җил атлап, бүлмәдән чыгып китте.

Үзбәк хан бакыйлыкка күчкәч тә, Урдада янәдән канкоеш, туганнарның үзара суешы башланды. Ул торгызган хөрлек һәм мәгъруурлык озакка җитмәде. Ахыр чиктә, дәүләт үзе дә таркалып юкка чыкты. Алтынташтан, мәчетләрдән, кәрван-сарайлардан, Сарай әл-Җәдиднең үзеннән таш өемнәреннән ары берни дә калмады. Ләкин Үзбәк ханның исеме мәңгегә тарихка кереп калды. Гасырлар үткәч, аның биләмәләрен Алтын Урда дип атап йөртә башладылар. Үзе хакимлек иткән вакытны исә шул дәүләтнең алтын гасыры буларак бәяләделәр.

Ә кан диңгезе Үзбәк ханның түшенә юкка гына кермәде... Тәхеткә ул шул диңгез аша, кан агызып, йөзләрчә кешенең башын кисеп менеп утырды...

## БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК

### 1

Бәкләр-бәге[1] Ногай үзенең тирмәсеннән чыкты да тирә-юньгә күз салды. Иртәнге һавада тынлык хөкем сөрә иде. Бар җиһан изрәп йоклый. Киң Дунай өстеннән пар күтәрелә. Аның ярында атлар утлап йөри. Чатыр янәшәсендәге озын колга башындагы тугралар шәлперәеп төшкән – җилнең ник бер әсәре булсын!

Ногай – үзенең станында чатыры янәшәсендә берьюлы ике тугра күтәрүче бердәнбер кеше. Башка олысларның бәкләре моңа җөрьәт итми. Нәрсәдән куркалардыр инде?! Ногайның исә, Урданыкыннан кала, үз туграсы да бар. Аны бәкләр-бәге һәрвакыт югарырак күтәрергә куша, Урданыкына тиң түгел ул. Иманы камил, Ногайның моңа тулы хакы бар. Ә нигә тартынып торырга? Ул – Урданың көнбатыш чикләрен саклап, дәүләтне күпсанлы яулардан аралап торучы гаскәр башлыгы түгелмени?! Биредә болгары да, полягы да, литвалары да җитәрлек. Алар Урданы изеп ташларга атлыгып кына тора. Каты куллы Ногай гына һәрвакыт дошманнарның тешләрен сындыра, Карпат тауларыннан ары җибәрми.

Икенче якта рус кенәзлекләре. Алары да акрынлап баш күтәрергә маташа. Ногай баскаклары[2] булмаса, җитәрлек күләмдә ясак түләтәм, димә. Хәер, бәкләр-бәге ул яктан бик хәйләкәр эш итә. Ясакны Урдага җибәреп кенә калмый, үзенә дә мул өлеш чыгарып тора. Моның нәтиҗәсендә байлык белән сандыклары шыплап тулган. Юкса, ничек яшисе? Байлыгың булмаса, бу дөньяда уңышка ирешәм, димә. Гаскәр башлыкларына уч тутырып түли, шуңа аны яугирләр хөрмәт итә. Аларның хөрмәте исә сугыш кырында кылган батырлык белән әйләнеп кайта. Анысын акчага сатып алып булмый.

Үзенең олысына караган вак бәкләргә дә әледән-әле сөяк ташлап тора, алары да моңа чиксез рәхмәтле. Бер сызгыруга гаскәрен дә, мал-туарын да бирәләр. Ногайның бурычлы булып калмаячагын яхшы беләләр. Андый хөрмәткә буш сүз сөйләп кенә ирешәм, димә.

Ахыр чиктә, Сарайның үзендә, хан тирәсендә кайнашучы бәкләр белән әмирләрне дә җайлап-майлап торырга туры килә бит. Андагы күпсанлы тарафдарлары, шымчылары әнә шул алтын-көмеш хисабына хезмәт итәләр үзенә. Алар аркылы Ногай Урданың барлык дәүләт эшләреннән дә хәбәрдар, теләсә кайсы вакытта тыкшына, үзенә файдалы карарны үткәрә ала. Сәргаскәрләр[3] дә, корылтайга чакырулы аксөякләр дә – Ногайның белешләре.

Урда империясенең көнбатышында хакимлек иткән бәкләр-бәге Ногай тормышының бушка үтмәвенә инанды инде. Үзендә Чыңгызлар каны агуын танымасалар да, ул аларның нәселендәге теләсә кайсы ханга караганда булдыклырак. «Сарайда ханнар алмашына тора, Ногай исә мәңгелек», – дип кабатларга ярата иде бәкләр-бәге. Аның олысында яшәгән халык та, үзара сөйләшкәндә, «без Ногай Урдасыннан, ногайлар» дип әйтергә күнекте.

Ханнарны күп күрде бәкләр-бәге Ногай. Башта ике күз, аннан соң,

[1] Бәкләр-бәге – Алтын Урдада олыс җитәкчесе, үз карамагында эчке һәм тышкы сәясәт, икътисад, гаскәр мәсьәләләрен туплаган кеше.
[2] Баскак – Урда ханының яуланган җирләрдәге вәкиле, ясак җыючы аксөяк.
[3] Сәргаскәр – гаскәр берәмлеге башлыгы.

Ширван[4] якларындагы канлы бәрелештә яралангач, сыңар күз белән. Йөзендәге яра аның болай да куркыныч кыяфәтенә тагын да усалрак төсмер салды. Шулай да аңарда хатын-кызларны сокландыра торган чын ирләр матурлыгы бар иде. Озын буйлы, киң сөякле бәкләр-бәгенең буй-сыны төз, өстендәге затлы киемнәре астыннан нык беләкләре кабарып тора, затлы ташлар белән бизәлгән күн кәвеше аягының алыпларныкына тиң икәнлегенә ишарәли. Мыегы исә тар гына, борыны астыннан ике чем-кара су ташкыны төсле төшә дә, ияге астындагы кыска куе сакалга барып тоташа. Чәчләре дә чем-кара, иңнәренә кадәр салынып торалар. Туктаусыз яу, сугышлар, тәхет тирәсендәге гаугаларда катнашуына карамастан, битендә ник бер җыерчык булсын! Моның өстенә, көннәр буе чиксез дала-тауларны кичеп йөрүдән җиз төсенә кергән йөзен дә өстәгәч, егет дими, кем дисең?!

Тәхет тирәсендәге хәлләр тагын тыныч түгел иде. Сарайда янәдән Ногайның күңеленә ошамаган вакыйгалар булып ята. Бүген үк үзен хан дип игълан итеп, Урдадан чыгып китәр иде дә, шиге зур. Бер яктан дошман белән бәргәләшеп, икенче якта аркадашың торуны тою җиңел ул. Урда тарафыннан үзенә яу җибәрүләрен теләми Ногай. Шуңа түзә. Аннан соң, тормышы болай да ханныкыннан ким түгел. Үз олысында гына баш булып яшәп тә, тулаем барлык дәүләт эшләрен дә ничек теләсә, шулай әйләндерә бит!

Тик тәхетне яңартасы бар. Моның өчен кан коймыйча булмый.

Ногай сыңар күзе белән янә бер кат үзенең станын айкап чыкты. Исәпсез сарык, ат көтүләре болында. Биредә тирмәләр генә тупланган. Алар арасында иң купшысы, әлбәттә, Ногайныкы. Аның олысы аша борынгы кәрван юлы уза. Сәүдәгәрләр бу җирләрдән үткән өчен олыс хуҗасына мул итеп өлеш чыгаралар. Көнчыгыштан килгән күз явын алырлык җәймәләр, ефәк тасмалар, тагын әллә ниләр белән бизәлгән иде Ногай тирмәсе. Ханныкы бер читтә торсын.

Юеш борыны белән учына килеп төртелгән маэмае аның уйларын бүлдерде.

– Ә, Ак бүре, син дә уяндыңмыни?! – Ногай тугры дустының башыннан сыйпады. Тегесе, хуҗа күрсәткән назга шатланып, койрыгын болгарга кереште, теле асылынып төште. Тик бәкләр-бәгенең эт белән уйнаклашырга бүген вакыты юк иде.

Ул кире тирмәсенә юнәлде. Бара-барышка:

– Кайсыгыз бар анда, тиз генә бире килегез! – дип, көр тавыш белән кычкырды.

Стан берьюлы хәрәкәткә килде. Әйтерсең, барысы да Ногайның сүзләрен генә көтеп торган, бөтенесе дә шунда ук сикереп тордылар. Тирмә бусагасы янындагы сакчылар гына, берни булмагандай, еракта гы бер ноктага туп-туры текәлеп басып тора бирделәр.

Ногай янына яраннарының берсе йөгереп килде.

– Баш өсте, галиҗәнап бәкләр-бәге, Дунай, Днестр, Тын елгалары хакиме, халкыбызны җәбер-золымнан саклаучы, бөекләрнең бөеге... – дип тезеп китте ул, Ногай каршында бер аякка тезләнеп, башын җиргә кадәр игән килеш.

[4] Ширван – Каспий диңгезенең көнбатыш ярында Дербент шәһәреннән Кура елгасына кадәр җирләр.

– Караны чакырып китерегез! Кичекмәстән! – Ногай яранына борылып та карамады, кызу атлап, тирмәгә кереп югалды.

Ногайның Урда ханнарына охшаш үз тәхете бар. Ул аны Кырым осталарыннан эшләтте. Тәбәнәк кенә тәхетне алтын-көмеш, җиде диңгез артыннан кайтартылган асылташлар белән бизәделәр. Ике култыксасына ике бүре сыны уеп ясалган. Бәкләр-бәге каршына баскан һәрбер кешегә алар, бугазлардай булып, тешләрен ыржайтып карап торалар. Караны, әлбәттә, мондый сыннар белән куркытырлык түгел.

Кара үзе дә баштанаяк кап-кара иде. Ул бусагадан атлап керү белән сүзсез генә тез чүкте. Үзе кап-карадан киенгән, сакал-мыегында да ник бер чаларган бөртек булсын. Билендәге кәкре кылычына кадәр кара төстә. Ногайның иң ышанычлы кешеләренең берсе, ул аның шәхси тән сакчыларын һәм махсус үтерүчеләре төркемен җитәкли. Кара – Ногайның шәүләсе сыман, беркайчан да хуҗасын күз уңыннан югалтмас, шул ук вакытта аяк астында да буталып йөрмәс. Нәкъ менә ул данлыклы төмәнбашын берничә мәртәбә дошман кылычыннан коткарды. Көтмәгәндә килеп чыгып, куркыныч янаган урыннан алып чыгып китүче дә Кара. Гүя ул барысын да күрә, барысын да белә, барысын да ишетә, хәтта кешенең фикерләрен дә укый төсле. Ногай үзе дә кайвакыт Карадан бераз шүрләп куя. Чуерташтай салкын күзләренең ни уйлаганын ничек аңламак кирәк?!

Бәкләр-бәге яранына утырырга ымлады.

– Кара, безгә юлга әзерләнергә кирәк, – диде Ногай, бераз гына уйга батып торгач.

– Хәзердән үк кузгалырга әзермен, галиҗәнап бәкләр-бәгем. – Караның тавышы чак кына ишетелерлек булып чыга, гүя ул һәрвакыт пышылдап кына сөйләшә.

– Үзең белән йөзләп шәп егетне ал. Баштанаяк коралланган булсыннар.

– Егетләр әзер, хакимем.

– Иң шәпләрен, ишеттеңме?! – Карага кабатлап торырга кирәкмәгәнлеген белә, Ногай моны беренче чиратта уйланган гамәленең хак икәнлеген үзенә инандыру өчен әйтте. Дунай буеннан ханнар өстеннән көлеп яту – бер нәрсә, ә инде тәхет тирәсендәге канлы уенда турыдан-туры катнашу – бөтенләй икенче. Аллаһы Тәгалә һаман да яклап тормаска да мөмкин.

– Иң шәпләре, хакимем, – дип пышылдады хуҗасының болай дөрләп кабынуына тамчы да исе китмәгән Кара.

– Башкаларга ауга киттек, диярсең. Мин дә шулай әйтермен. Ләкин чынында юлыбыз ерак булачак, шуңа күрә азык-төлекне мулдан алыгыз. Җыенырга вакыт аз, соңга калганчы, алдан эш итү хәерлерәк. Мине стан читендә көтегез, озакламый сезгә кушылырмын.

– Баш өсте, хакимем. – Кара, башын ия төшеп, тирмәдән тавыш-тынсыз гына чыгып та югалды.

Ул киткәч тә, Ногай янә тирән уйга батты. Күпме җанны койган икән ул бу тормышта? Күпме кешенең башына җиткән? Хәзер башларга торган чираттагы уены да шактый кайгы һәм үлем алып киләчәк. Беренче чиратта гаепсезләрнең гомере киселәчәк. Әмма башкача мөмкин түгел. Хакимлек һәрвакыт корбаннар сорый, даның тутыкмас өчен аны әледән-әле кан белән яхшылап юып тору мәслихәт.

– Кайсыгыз бар анда?! – дигән тавышка тирмәгә шунда ук ике яраны йөгереп керде. – Хәзер үк минем ау киемнәрен һәм коралларымны әзерләгез. Өч атымны да алып килегез. Мин ауга китәм, шактый вакытка югалып торырмын.

Тез чүккән яраннары бәкләр-бәгенең әмерен ишетү белән аны үтәргә ашыкты.

Кара үзенең яугирләре белән стан читендә көтеп тора иде. Ногай, ике атын ияртеп, өченчесенә атланган көе әлеге төркемгә кушылды. Караны бер читкәрәк дәшеп алып, аңа пышылдарга кереште:

– Юлыбыз Сарайга. Минем шымчыларым җиткергәнчә, хан шәһәрдән чыгып китеп, далада стан белән урнашкан. Безгә тиз арада, көненә йөз иллешәр чакрым узып кызу барырга кирәк. Ямчыларга тукталырга ярамый. Кәрван, ямчы юлларыннан ераграк торасы.

Кара, аңладым дип, башын какты. Өч йөздән артык ат берьюлы урыннарыннан кузгалды. Киң дала тәбәнәк малкайларның пошкыруына һәм тоякларның коры җиргә бәрелгән тавышына күмелде. Алар артыннан тузан өере күтәрелде. Станнан йөгерешеп чыккан яланаяклы балалар, җайдаклар артыннан куып карасалар да, тузан басылгач, аларның инде бөтенләй күренмәс булуларын аңладылар...

Бәкләр-бәге Ногай атының бер җайга салып юртаклавына акрынлап күнекте. Башында мең төрле уй, мең төрле сорау. Ул дөрес эшлиме, хаклымы? Ул баскан тайгак, мәкерле сукмакта үзенә каршы тозак корып куймасларммы? Хәзер Урда башында утырган Түлә-Буга хан Ногайны чыннан да нык кыерсытты бит. Үзенең рәтле-юньле сугыш алып барырлык та хәле юк, үзе гомер-гомергә Ногай карамагында булган юнәлешләргә кереп маташа. Анысыннан да бигрәк – Түлә-Буга ризалыгы белән Ногайның ышанычлы кешесе Әхмәт баскакның өстенә яу җибәртү!

Әхмәт инде ничәмә еллар буе русларның Курск дип аталган калалары тирәсендәге җирләрдә баскак булып тора. Шул якларда Урдага гына буйсынган ике бистә дә оештырды. Ул бистәләрдә яшәүчеләр ясактан, башка төр салымнардан азат ителделәр. Рус җирләрендә Яса кануннары хөкем сөргән утраучыклар пәйда булды. Шактый гына рус кешеләре, авыр тормыштан качып, шул бистәләргә агылды. Моны җирле кенәзләр Олег белән Святослав бер дә ошатмаганнар. Олег дигәннәре, яклау сорап, Түлә-Буга хан янына ук барып җиткән. Тегесе, Әхмәтнең бәкләр-бәге Ногай яраны икәнлеген белә торып, бистәләрне тар-мар итәргә ризалыгын биргән. Алай гына да түгел, Олегка ярдәмгә Урдадан гаскәрләр дә ияртеп җибәргән.

Бистәләрне рус кенәзләре кереп талау турындагы хәбәр килгәндә, Әхмәт баскак Ногай янында иде. Чапкынның сөйләгәннәрен икәү бергә тыңладылар. Ногай кичекмәстән үзе янына Олег белән Святославны чакыртса да, тегеләре килмәде. Шуннан соң ачуы кабарган Ногай Тимер бәк җитәкчелегендәге гаскәрне Курск тарафларына җибәрде.

Егерме көн дәвамында Тимер бәк яугирләре әлеге җирләрне пыран-заран китерде. Алар артыннан агач кисәүләре белән мәетләр генә өелеп калды. Олег, гаиләсен җыеп, Түлә-Буга хан янына, ә Святослав исә карурманга кереп качып котылды.

Әлбәттә, Түлә-Буганың мондый гамәлләре Ногайга янау, гайрәтле олыс бәгенең яңагына сугу булды. Янәсе, бәкләр-бәгенең сүзе үтә торган чорлар

узды, яңа вакыт башлана. Тик Ногай гына аның белән килешергә җыенмый. Кылыч белән аңламый икән, башкача, хәйлә белән эш итәчәк. Бу юлы инде Түлә-Буга мәңгелеккә сабак алырлык итеп...

Яугирләре озатуында Ногай төн димәде, көн димәде, атларын туктаусыз чаптырды. Һәрбер җайдакның өч юртагы булганга, аларны алмаш-тилмәш кулландылар. Урда атлары түзем, арый белмәүләре белән данлыклы, хәзер дә алар көндәм генә чакрым арты чакрымны үтә бирделәр.

Эңгер төшкән иде. Алда мәгърур Сарай каласы күренде. Аңа якынлашуларын юлчылар офыкта караеп торган биналар, калкып торган мәчет-чиркәү манараларыннан чамалады. Әле анда, әле монда күккә багана булып төтен күтәрелә. Вакытның соң булуына карамастан, халыкның шау-шуы, нидер кычкырган тавышлар аермачык ишетелә – Сарай һаман да кайнап тора.

Кара бәкләр-бәге Ногайга атларны чаптырмаска тәкъдим итте. Идел аша су кичүеннән соң үзләрен куаламаган хуҗаларына рәхмәтле малкайлар атлап барган шәпкә аяк астындагы үләннәрне эләктергәләп, тамак ялгарга җай тапты.

Шәһәргә җитәрәк Кара җайдаклар төркемен юл читендә ялгызы торган шактый иркен утарга юнәлтте. Биек капка төбенә килеп җитү белән ул өч тапкыр кыска гына итеп сызгырды. Аңа шундук сызгырып җавап кайтардылар, капка шыгырдап ачылды, җайдаклар эчкә узды.

Ишегалды тыштан бик зур тоелса да, икешәр ат иярткән йөз яугир өчен кысан булып чыкты. Кара кискен, ләкин тыныч тавыш белән әмерләр биреп, атларны абзарларга кертергә кушты. Үзе исә Ногай янына ашыкты.

– Хакимем, без килеп җиттек. Иртәнге якка кадәр шушында хәл алырга кирәк булыр.

Ногай, оеган аякларына салмак кына басып, сакчысы күрсәткән ишеккә юнәлде. Монда беркем дә юк, ләкин табын мул корылган. Кечкенә генә бүлмәнең бер читендә ятак та бар. Ул тамак ялгап алырга утыргач та, бусагада янә Кара күренде.

– Хакимем, биредә бернидән дә курыкмаска мөмкин, – диде ул, тез чүгеп. – Мин хәлләрнең ничеклеген белер өчен шәһәргә чыгып китәм, миңа алмашка Наран калачак.

– Яхшы, Кара, мин сине биредә көтәрмен.

Иртәгә Ногайның көне авыр булырга охшаган, шуңа күрә ял итеп алырга кирәк. Бәкләр-бәге Урданың беренче ханы булган Мәңге-Тимернең хәләл җефете Олҗай хатын хозурына барырга җыена. Мәңге-Тимер күптән вафат. Олҗай кырында аларның яше егермедән чак кына арткан уллары Туктай яши. Туктайның хан булырга тулысы белән хакы бар. Әгәр Ногай Түлә-Буганы тәхеттән бәреп төшерә алса, яшь ханзадә – аның урынына менә дигән алмаш. Бәкләр-бәге ханзадә белән таныш, ул ипле, сүз тыңлаучан егеткә охшаган. Аннан соң, Олҗай хатынга ачкыч таба алса, икеләтә җайлы булачак. Ачкыч дигәннән, Ногай ятак түрендәге ике сандыкка күз салды. Анда ханбикәгә дип әзерләнгән бүләкләр, алтын-көмеш, бизәнү әйберләре. Ногай елмаеп куйды. Карт бүрене көчекләр таларга маташса да, беләгендә көче, башында акылы, казнасында малы бар. Ә шушы өч нәрсә белән теләсә нинди явызны авызлыкларга мөмкин. Дунай буенда рәхәт тормыш турында хыялларга төренеп, бәкләр-бәге татлы йокыга талды...

Кара Ногайны уятканда, таң беленеп кенә килә иде. Юлдагы арыганлык үзенекен итте – соңгы вакыттагы борчу-хафаларын да онытып, рәхәтләнеп йоклады бәкләр-бәге. Башка вакыттагы сизгерлеге дә кимегән иде.

– Хакимем, безгә юлга кузгалырга вакыт, – диде сакчысы.

Ногай урыныннан сикереп торды. Кара аңа бер төргәк сузды.

– Бу киемнәрне киеп, йөзеңне капласаң яхшырак булыр, хакимем.

– Сандыкларны ничек алып барабыз?

– Аларын минем ышанычлы кешеләрем икенче капкадан алып кереп, тиешле вакытка китереп җиткерәчәкләр, хакимем.

– Өлгермәсәләр? Тоткарласалар?

Кара кайтарып дәшмәде. Ногай ымлап, аңа чыгарга кушты, үзе гади сәүдәгәр киемнәрен киде. Йөзен күзләре генә күренеп торырлык итеп каплады. Ярымсукыр икәнлегенә игътибар итмәсләр, беткәнме Урдада җыен гарип-гораба?!

Алар килеп кергән вакытта Сарай гөрли иде инде. Шәһәр читеннән үк тезелеп киткән тимерчеләр мичләрен кабызып җибәргән, шалтыр-шолтыр китереп кызган чыбыкларны кыйнап нәрсәдер әмәллиләр. Агач осталарының үз шау-шуы. Күнчеләр исә сабыр, тыныч, ашыкмый гына эшлиләр, остаханәләреннән сасы ис тә килмәсә, сокланырлык манзара булыр иде. Ары киткән саен күренеш үзгәрә барды. Ут очкыны, йомычкалар урынына зәрканчылар, ашчылар күренгәли. Шәһәрнең үзәк бер җирендә исә базар кайный. Биредә әллә нинди сый-нигъмәтләр, кием-салым, чүпрәк-чапрак, терлек, корал табарга мөмкин. Аннан арырак китсәң, коллар сатыла торган мәйданга эләгәсең. Базарда бертуктаусыз алыш-биреш бара, тирә-юнь гөжләп тора. Кара белән Ногайга әйләнеп тә караучы булмады. Мондый халык казанында ике сәүдәгәр кемгә хаҗәт?

Сарайның үзәккә якын бер өлешендә Кара тар тыкрыкка борылып китте. Ногай аңа иярде. Алар, ике дивар арасыннан үтеп, өченчесенә барып төртелделәр. Кара диварны капшады. Икенче мизгелдә андагы яшерен ишек ачылды.

Алар яшеллеккә чумган бакчага үттеләр. Кара ишекне яхшылап япты да Ногайны карашы белән үз артыннан ымлады.

Бакчаның ышык бер почмагында кечкенә алачык. Аны як-яктан үрмә үсемлекләр урап алган. Ногай шунда атлады.

Эчтә караңгы иде. Бәкләр-бәге битенә чорналган кара яулыкны чишеп җибәрде һәм, ниһаять, күкрәк тутырып сулыш алды.

Сыңар күзе акрынлап, алачыктагы саран яктылыкка ияләште. Идәндә матур келәм, уртасында Ногайның ике сандыгы тора. Янәшәдә озын борынлы комган, ике көмеш савыт, җиләк-җимеш. Бик нык эчәсе килсә дә, Ногай бернигә дә кагылмады. Агу салып куймаганнар дип, кем әйтә ала?!

Бәкләр-бәге, ишеккә таба борылып, келәмгә барып утырды. Алай-болай була калса дип, кылычын чыгарып, каршысына салды. Кара монда гынадыр да, дөнья хәлен белеп булмый.

Ишек катында аяк тавышлары ишетелде. Бусагада Олҗай хатын күренде. Шактый картайган, арыган кыяфәтле иде ул. Йөзен җыерчыклар баскан. Ногай, урыныннан сикереп торып, башын иде.

– Ханбикәм, исәнме, – диде ул, күзен келәмнән алмыйча.

– Исәнме, бәкләр-бәге Ногай! Ни йомыш белән? Җитмәсә, кача-поса эш йөртәсең...

Ногай сыңар күзен Олҗай хатынның сагыштан саргайган йөзенә төбәде.

– Олы йомыш белән килдем, хатыннарның затлысы, гыйлемлеләрнең гыйлемлесе, сабырларның сабыры Олҗай ханбикә! Синең ирең Мәңге-Тимер безгә хөр, иректе мәмләкәт төзеп бирде. Мәңге-Тимер кимсетелгәннәрнең яклаучысы, ятимнәрнең әтисе, дәүләтнең терәге, ирнең асылы булды. Без бүген аны сагынып искә алабыз. – Ничек кенә тырышмасын, Олҗай хатынның бер генә кылы да селкенмәде, ул төссез караш белән басып тора бирде. Ногай сандыкларга ымлады. – Сиңа үземнең олыстан кечкенә генә бүләкләр алып килдем, шуларны зурлап кабул итә күр.

– Бүләкләрең өчен рәхмәт, бәкләр-бәге. Ләкин аны миңа чапкын аша да җибәреп була иде. Ничәмә ел эчендә беренче тапкыр мескен Олҗай хатынны искә төшерүеңнең сәбәбен әйт.

– Олҗай хатын! Күреп торасың, мәмләкәтәбез куркыныч астында. Түлә-Буганы хакимлеккә куеп, без нык ялгыштык.

– Аны син түгел, минем ирем билгеләде, бәкләр-бәге, саташа күрмә, үзеңне ханнан да биеккәрәк күтәрмәкче буласың.

– Әйе, бу Мәңге-Тимернең карары иде, ләкин бүген дәүләтебезгә куркыныч яный. Түлә-Буга, аны-моны белештерми сугыш башлый, гаскәр белән идарә итүгә бөтенләй дә сәләтсез. Безне тирә-яктан дошманнар чолгап алган, алар безне юк итәргә генә торалар.

– Син моңа ник хафаланасың?! Үзеңнең олысыңда типтереп яшисең дип сөйлиләр. Ханның карарларын чүпкә дә санамыйсың.

– Мин олыс өчен түгел, Урда өчен борчылам. Бөтен кылган гамәлләрем дә тик шуның хакына. Әмма Түлә-Буга безне упкынга илтә, ханбикәм.

– Мин нәрсә эшләргә тиеш инде?

– Фатихаңны бир, кодрәтлеләрнең кодрәтлесе Олҗай хатын!

– Нинди фатиха, нәрсәгә?

Ногай үзендә булган барлык җылысын, күңеленең әллә кай читләренә китеп югалган ихласлыгын җыеп, бер сулышта әйтеп ташлады:

– Синең улың Туктайны ханлыкка куярга ризалык сорыйм!

Олҗай хатын каушап калды. Дала төлкесеннән барысын да көтте, ләкин мондыйга әзер түгел иде ул. Ногай исә каршындагы ханбикәнең йөрәгендәге боз эрегәнлеген чамалады. Хәзер туктарга ярамый.

– Мәңге-Тимернең дәвамчысы, синең улың – Урда тәхетенә иң кулай кеше. Аңарда синнән һәм мәрхүм ханыбыздан кан белән күчкән олы көч, акыл, мәгърурлык яшеренгән. Әгәр ул ташкынны ачып җибәрсәк, дәүләтебез даны тагын да еракларга таралачак, исеме гасырдан-гасырга күчеп, оныкларыбыз хәтерендә мәңге яшәр. Әлбәттә, янәшәсендәге ханбикә Олҗай хатынны да халык беркайчан да онытмас...

Олҗай хатын икеләнде, ләкин Ногайның сүзләре күңеленә ялкын салды. Аның күзләренә җан керде, аңа инде Туктайны – тәхеттә, үзен хан янәшәсендә күргәндәй тоелды. Бәкләр-бәге әле картаерга өлгермәгән хатынның пыскыган йөрәгенә һава өреп җибәрде.

– Ләкин... Ләкин ханны ханнар гына билгели ала, син моны миннән дә яхшырак беләсең.

– Беләм. Әмма ул тәртипне үзгәртергә дә мөмкин.
– Ничек итеп?!
– Әйтик, тәхеттәге хан кинәт үлеп китсә...
– Үлеп?! Син Түлә-Буганы үтерергә җыендыңмы әллә?! – Олҗай хатын агарынып китте. – Минем улымның куллары белән ханның җанын кыярга телисеңме?!
– Юк, борчылма. Улыңның кулы канга буялмас. Мин барысын да үзем хәл итәм.
Олҗай хатын ни әйтергә дә белми басып тора бирде. Бәкләр-бәге өчен бу мизгел мәңгелек төсле тоелды. Ниләр турында уйлый икән ханбикә? Ногайны тотып, Түлә-Буга кулына тапшырмасмы? Турыдан Туктай янына бармыйча, анасы белән сүз куертып барча эшне дә бозып куймадымы? Икенче яктан, данлыклы төмәнбашының яу кырларында чарланып беткән сизгерлеге тынычландыра. Ана кешегә мөрәҗәгать итеп, дөрес эшләде ул. Олҗай хатын тәкъдим ителгән бәхеттән баш тартмаячак. Кайчандыр хакимлек түрендә булган хатын-кыз өчен купшылык һәм байлык дөньясына кире кайту – әйтеп бетергесез шатлык. Ногай исә Туктай янәшәсендә үзенә бурычлы кешене булдыра. Әгәр Туктай берәр төрле киреләнсә, ул аңа һәрвакыт анасы аша тәэсир итә алачак.
– Бәкләр-бәге, миңа уйларга вакыт бир, – диде салкын тавыш белән Олҗай хатын. – Мин сиңа чапкын җибәреп, үз карарымны җиткерермен.
Ногай башын ия төште.
– Карарың уңай булыр дип өметләнәм, ханбикә! Туктайны исән-имин килеш тәхеткә утыртканнан соң мескен бер бәндәңнең хезмәтләрен дә онытмассың дип ышанам...
– Юлыңда бул, бәкләр-бәге. Күчтәнәчләрең өчен рәхмәт.
Ногай үз олысына шул кичтә үк кузгалды. Ияртеп килгән яугирләренең кирәге чыкмаса да, алар янәшәсендә барыбер тынычрак иде. Бәкләр-бәге белмәсә дә, Кара бу сәер вакыйгаларда һәрбер сугышчысын файдаланды. Ногай Олҗай белән сөйләшкән вакытта алар төрле киемнәр кигән кыяфәттә, коралларын яшереп, очрашу узган бакча янәшәсендә булдылар. Куркыныч хәл чыга калса, йөз хәнҗәр бер сызгыруга хакимнәрен якларга әзер иде.
Озак та үтми, Олҗай хатыннан чапкын килеп төште. Күбеккә баткан атын урамда калдырып, ул бәкләр-бәге Ногай каршында тезен чүкте.
– Олҗай хатын синең тәкъдимеңне өйрәнде, кодрәтле бәкләр-бәге! Курку белмәс көч иясе, көнбатыштагы дала-таулар, елгалар хакиме, ханбикә сиңа үзенең ризалыгын җиткерергә боерды. Син куйган барча таләпләр дә син үз сүзеңдә торган очракта җиренә җиткереп үтәлер, диде. Ханбикә шулай ук парча-ефәкләрнең күңеленә хуш килүен өстәргә кушты.
Ногай чапкынны сыйларга әмер бирде, үзе исә башында туган ниятенең чираттагы өлешен гамәлгә ашырырга кереште. Кичекмәстән үзенә тугры бәкләрне җыярга кирәк иде...

**2**

Киң далада Түлә-Буга станы җәелеп ята. Нәкъ үзәктә хан тирмәсе. Ул купшы, хакимлекне аңлаткан тамгалар белән бизәлгән. Аның янәшәсендәге биек колга башында Урда әләме җилферди. Хан тирмәсен дистәләгән яугир

саклый. Тирмә үзе тәбәнәк кенә киртә белән уратып алынган. Саклану өчен түгел, тирә-юньдә йөгерешеп йөргән бала-чага, кош-корт кереп, ханның кәефен җибәрмәскә корылган ул. Төп тирмәнең уңында тагын берничә дистә купшы чатыр. Аларында ханның хатыннары, бәкләр, корылтай әһелләре, тәхет тирәсендә буталучы күпсанлы әрәмтамаклар яши.

Сул якта кечерәк тирмә – анда үзенең гаиләсе белән Алгуй урнашкан. Ул – Олҗай хатын белән Мәңге-Тимернең олы улы. Алгуйны Түлә-Буга якын итә, шуңа күрә аның дәүләттәге урыны шактый югары. Алгуй барлык эшләрдә дә үз сүзен әйтерлек дәрәҗәгә ия. Үзенең абруе буенча ул бәкләр-бәкләреннән дә, сәргаскәрләрдән дә өстенрәк тора.

Чираттагы тирмә Алгуйга тиң хакимнеке – аның хуҗасы Тогърулҗа. Ул шулай ук туганнары Түлә-Буга һәм Алгуй белән бергә Урданың дәүләт эшләрен киңәшләшеп алып баруда катнаша.

Хакимнәрнең тирмәләреннән арырак башка чатырлар тезелешеп киткән. Биредә нойоннар[5], ханның яраннары урын алган. Станнан еректарак исә башлары исәпләп бетергесез мал көтүләре утлап йөри. Дала тыныч, чикерткәләрнең генә черелдәве ишетелеп тора.

Көннең иң эссе вакыты иде, һәммәсе дә кымыз эчеп хәл алу өчен киез корылмалар ышыгына таралышкан. Бу самими тынлыкны бозып, хан тирмәсе янына тиргә баткан атка атланган чапкын килеп туктады. Ияреннән җәһәт кенә сикереп төшеп, ул кызу адымнар белән яугирләр сагындагы ишеккә юнәлде.

– Юл бирегез, мин ханның чапкыны Айбүләк, – диде ул үзен кырыс караш белән бораулаган сакчыларга. Тегеләре юл бирделәр.

Тирмәгә кергәч тә, Айбүләк тәхетендә черем итеп утырган Түлә-Буга каршында тез чүкте.

– Хакимнәрнең хакиме, чиксез далалар хуҗасы, Күктәге әмерләрне җирдә тормышка ашыручы бөек ханым, мин сиңа Сарайдан кичектергесез хәбәрләр алып килдем, төшке ялыңны бүлгән өчен гафу ит, – диде чапкын башын игән көе.

– Зыян юк. – Түлә-Буга киерелеп куйды. Тәмләп йокы гына төшә башлаган кебек иде, тик Айбүләкнең кыяфәтенә күрә хәбәр чыннан да зур әһәмияткә ия булырга охшаган. – Сөйлә, Айбүләк, барысын да түкми-чәчми сөйлә.

– Бөек ханым, миңа мәгълүм булганча, шушы көннәрдә берничә дистә яугирне ияртеп, Туктай ханзадә Ногай олысына юл тоткан.

Түлә-Буганың йөзе чытылды. Йокысының әсәре дә калмады. Янәдән Ногай! Җәйге ялына да тынычлык бирми, һаман астыртын эшләр белән шөгыльләнә!

– Ногай аны үзе чакырганмы, әллә бу Туктай карарымы?

– Туктай Сарайда синең турыда начар сүзләр тараткан, бөек ханым. Имештер, син аны үтерергә әмер биргәнсең, һаман да эзәрлекләп торасың...

– Булмаган хәл бит бу! – Түлә-Буга шартлар дәрәҗәгә җитте.

– Тагын бер хәбәрем бар, бөек хан, әгәр рөхсәт итсәң...

– Сөйлә.

– Шымчылар җиткергәнчә, күптән түгел Сарайга яшерен рәвештә бәкләр-бәге Ногай үзе килеп киткән.

[5] Нойон – монголларның аксөяк нәселе вәкиле.

– Нинди максат белән?

– Тәгаен генә белүче юк. Ләкин кайбер кешеләр бәкләр-бәге Ногайны Олҗай хатын тарафында күргән, имеш.

– Алай икән... – Түлә-Буга тирән уйга батты. – Сүзең беттеме?

– Тәмам, бөек ханым.

Түлә-Буга, яраннарының берсен чакырып алып, чапкынга ял итәргә урын һәм ризык бирергә кушты, аннан соң үз янына Тогърулҗаны дәштерде.

Тогърулҗа, бусагадан атлап керү белән уң кулын йөрәгенә куеп, чак кына иелә төшеп, хан белән исәнләште.

– Якынрак утыр, Тогърулҗа, – диде гадәттәгедән күпкә борчулы Түлә-Буга.

– Ни булды, ханым?

– Сарайдан яман хәбәрләр бар. Туктай, үзен үтерергә җыеналар дигән хәбәр таратып, Ногай янына качкан. Аңа кадәр Ногай Сарайга килеп, Олҗай хатын белән очрашкан...

Тогърулҗа да тирән уйга батты.

– Фетнә чыгарырга җыеналар дип уйлыйсыңмы?

– Шуңа охшап тора. Минем Туктайга бармак белән тию түгел, янаганым да юк. Дала төлкесе Ногайның миңа каршы башлаган чираттагы әшәке уенына бик тартым бу...

– Олҗай хатын белән ни турында сөйләшкәннәр икән? – Тогърулҗа әле генә ишеткәннәрне башына сыйдырырга маташты. – Сине фетнә аша бәреп төшереп, Туктайны тәхеткә утырту хакында түгелдер бит?

Моның хакында уйласа да, башка кеше авызыннан әлеге сүзләрне ишеткәч, Түлә-Бугага куркыныч булып китте.  Куллары калтырана башлады, авызы кипте. Ул, чак кына түгеп бетерми, чәшкәдәге кымыздан бер йотым эчеп куйды.

– Олҗай хатын андый мәкергә бармас, Түлә-Буга. – Тогърулҗа барысын да бизмәнгә салып үлчәгән кебек бик ышандырып әйтте. – Алгуй – аның олы улы, ул синең уң кулың шикелле. Кече улы өчен олы баласын корбан итмәс. Олҗай хатынның сиңа үпкәләргә бер генә сәбәбе дә юк, шуңа күрә...

– Бу хакта беркемгә дә, шул исәптән Алгуйга да бер сүз дә әйтмә. Миңа уйларга кирәк, – дип, Түлә-Буга сөйләшүнең тәмам булуын аңлатты.

Хан тирмәсеннән чыккач та, Тогърулҗа үз ягына юнәлде. Мондый сөйләшүдән соң төшке ял турында уйларлык та түгел иде. Ләкин ул югалып калуын белгертмәскә тырышты. Тогърулҗага кичекмәстән бу киеренкелектән котылырга кирәк, башындагы уй-фикерләрне яңарту зарур.

Тирмәсе янында аны олы хатыны Баялун белән кече хатыны Әрибах каршылады. Икесе – ике төрле кеше, икесе – ике дөнья. Нык бәдәнле, кырыс холыклы, үз дигәненә ирешүчән, бик хәйләкәр һәм үтә дә акыллы Баялун янәшәсендә талдай нәфис сынлы, куе кара толымлы, карашы белән тәнне чемердәтеп җибәрерлек, төннәрен башны югалтырлык ләззәт бирә белүче Әрибах. Әрибахтан туган уллары Үзбәк тә әнисенә тартым булып үсә. Шундый ук төз буйлы, чем-кара чәчле, анасыннан күчкән чиркәс каны аша киребеткәнлеккә ия егет.

– Үзбәкне чакырыгыз, атларны иярләсен, – диде Тогърулҗа, хатыннарына бер генә караш ташлап.

– Бу эсседә кая бармакчы буласыз тагын?! – Баялун хатын иренең мондый гадәтен күрмәгәнгә, гаҗәпкә калды.

– Далада йөреп керәбез. Үзбәк улым!

Әйтерсең, ун яшьлек Үзбәк шушы чакыруны гына көтеп торган, ул тирмә артыннан йөгереп тә чыкты.

– Әти, әйдә атларыбызның җитезлеген сынап карыйбыз?! – диде ул, һәм үзенең чаптарын эзләргә йөгереп китеп тә барды.

Ике хатын белән Тогърулҗа аның артыннан елмаеп карап калдылар. Аннан соң әти кеше дә аңа иярде.

– Тогърулҗаның йөзеннән нур качкан, – диде Баялун, ирләр күздән югалгач.

– Мин аны-моны сизмәдем кебек...

– Бик киеренке елмайды. Бәла генә килә күрмәсен инде, хан белән икәүдән-икәү генә сөйләштеләр...

Атларын тәмам хәлдән тайганчы куганнан соң, Тогърулҗа да, Үзбәк тә малкайларын тыныч адымга күчерде. Тогърулҗа, бүрдүк алып, андагы кымызны башта ат ялына бераз гына тамызды, аннан соң үзе йотлыгып эчте. Үзбәк бу тамашаны чак кына елмаеп күзәтеп торды.

– Әти, нигә без кымызны ат ялына тамызырга тиеш? – диде ул, Тогърулҗа сусавын баскач та.

– Безнең динебез шуны таләп итә, улым. Мәңге Күк Тәңре.

– Ә мөселманнар ник алай итми?

– Аларның үз дине, балам. – Тогърулҗа, шаккатып, улына текәлде. Тегесенең йөзендә ихлас кызыксыну, күптән бимазалаган сорауларга җавап табу теләге язылган иде. – Безнең дин ата-бабаларыбыздан мирас итеп калдырылган.

– Мөселман дине дә әйбәт шикелле. Аларның Сарайда мәчетләре дә бар. Мин кайвакыт аннан ишетелгән җырларны тыңлап торам.

– Җыр түгел ул, улым, дога. Мөселманнар шулай итеп үзләренең Тәңресенә мөрәҗәгать итә. Аннан соң, бер мөселман гына түгел бит, безнең Сарайда насаралар да үз динен тота ала. Безнең хан барлык диннәрнең дә яклаучысы, берсенә дә артык йә ким игътибар бирми, бу шулай ук бабаларыбыз васыяте.

– Әти, ә ник син хан түгел?!

Тогърулҗа атыннан чак кына егылып төшмәде – мондый сорауны аңа башкалар түгел, ул үзе дә үзенә биргәне юк! Улы үсә төшкән саен төпченүе арта, бар нәрсәгә төшенергә тели.

– Һәркем дә хан була алмый, улым, – диде Тогърулҗа мөмкин кадәр тынычрак тавыш белән. – Мин Түлә-Буга янәшәсендә дәрәҗәле кешемен. Ханыбызга хезмәт итәм. Ә ил белән ул идарә итә. Һәркем үз урынын белеп яшәргә тиеш, тормыш кануннары шундый.

– Димәк, мин дә беркайчан да хан була алмаячакмын... – диде Үзбәк, кәефе кырылып.

Тогърулҗа янә ни әйтергә дә белмәде. Бәхеткә, ерак түгел ул табаннарын ялтыратып чабучы куянны күреп алды. Сүзне икенчегә бору өчен моннан да кулайрак форсат юк иде.

– Үзбәк улым, күрәсеңме, куянны? Әйдә, кем беренче булып аны эләктерә ала?!

Дөньясын онытып, Үзбәк атын куян артыннан чаптырды, күңеленә авыр хисләр тулган Тогърулҗа да аңа иярде.

Алар хан станына кайтып кергәндә, барча халык гөж килә иде. Бер читтә туктаусыз мал чалалар, шунда ук эшкәртәләр. Һәрбер тарафта зур казаннар асылган, алар астында янган ат тизәгеннән тирмәләрне төтен басып киткән.

– Түлә-Буга хан бүген бәйрәм оештырырга карар кылды, – диде Баялун, Тогърулҗа бусагадан атлап керү белән. – Ул сине чакыртып, кеше җибәргән иде инде, аның янына кузгалсаң, яхшырак булыр.

Тогърулҗа кире чыгарга өлгермәде, Баялун, җиңеннән тартып, үзенә борылырга мәҗбүр итте.

– Күңелем сизә, хәлләр хәерлегә бармый. Ханның болай кинәт кәефе үзгәрүе бик сәер, син дә көндез аның яныннан әллә ничек борчулы кайттың. Безгә куркыныч янамыйдыр бит?!

– Тынычлан, хатын, бернинди куркыныч та юк! – Тогърулҗа Баялунның кулын җиңеннән алып ташлады. – Үз эшләреңне кара, дәүләт мәсьәләләренә тыкшынма.

Тогърулҗа киткәч тә, Баялун хатын әле шактый вакыт бусага төбендә басып торды. Аның күзләрендә мөлдерәмә яшь иде. Күңеле алдамаган – Тогърулҗа нидер белә һәм ул аны өйдәгеләргә әйтә алмый. Әйтә алмый икән, димәк, гаиләсенә зыян килергә мөмкин. Бәла ишек какканчы алдан ук әзерлек чараларын күрергә кирәк.

Баялун хезмәтче Болытны чакырып алды.

– Бар, тиз генә яугир Хуланны табып бирегә китерт! Артык сораулар бирмә, ашыга күр!

Болыт, Баялуннан куркып торганга, болай да сораулар бирергә җыенмый иде, ашыга-кабалана станны тутырган халык арасына тиз-тиз кереп тә югалды. Баялун исә сандыгындагы кара көнгә дип җыйган байлыкларын барларга кереште...

Тогърулҗа кергәндә хан үзенең тирмәсендә Алгуй белән сөйләшеп утыра иде.

– Кайда йөрисең син?! – дип, усал караш ташлады аңа Түлә-Буга. – Кайчаннан бирле сине көтәбез бит!

– Галиҗәнап ханым, гафу үтенәм, улым Үзбәк белән далага чыккан идек...

– Йә, ярый, утыр. – Түлә-Буга Тогърулҗага рус җиреннән китерелгән хәмер салынган көмеш савытны тапшырды, өчесе дә сасы сыекчаны эчеп куйдылар, майлы сарык итеннән авыз иттеләр. – Күңелсез, эч поша, шуңа күрә бәйрәм үткәрергә карар кылдым, – дип аңлатты хан, урам яктан дөңгер, думбра тавышлары ишетелгәч. Бавырчылар янә хәмер салдылар, өч хаким шунда ук савытларын бушатты.

Табын янында җитди сүз сөйләшмәделәр. Түлә-Буга чапкын алып килгән хәбәрләрне Алгуйга җиткергәнме-юкмы – анысы Тогърулҗага караңгы калды.

Тәмам кызышып җиткәннәр иде, бусагада Багаууган – Түлә-Буганың ышанычлы багучысы[6] күренде. Багаууганга ничә яшь икәнлеген беркем дә белми. Үзе ул берьюлы ир-атка да, хатын-кызга да охшаган. Өс киемнәре эт талаган төсле, пычракка батып беткән. Чәчләре ике озын толымга салып үрелгән. Муенына төрле рәвештәге тимер кисәкләре, йөри-йөри шомарып беткән сөякләр асылган. Кулында шартлатып тарттырылган дөңгер.

[6] Багучы – шаман.

– Баш өсте, бөек ханым, – диде Багаууган таш шыгырдаган төсле тавыш белән. – Мескен яраныңны ни йомыш белән чакырып китердең?

– Миңа камлап кара, хөрмәтле Багаууган. Минем тирәмдә дошманнар куера төсле...

– Яхшы. Мин камлаган вакытта хәмер эчмәгез, аның исе изге рухларның гайрәтен чигерә.

Багучы, уртагарак килеп, күзләрен йомды. Тогърулҗага ул аягүрә баскан килеш йоклап киткән сыман тоелды. Тик Багаууган йокламый. Ул кинәт күзләрен ачты. Алар әллә учак яктысыннан, әллә башка сәбәптән кып-кызыл булып янып торалар иде. Багучы акрынлап, дөңгеренә суккаларга кереште. Тирмәдә утырган өч кеше, үзләре дә сизмәстән, шул көйгә чайкала башладылар. Дөңгергә Багаууганның тамак төбеннән гырылдап чыккан тавышы өстәлде. Дөңгерен торган саен ешрак каккалап, багучы сәер бию башлады. Ул әле җиргә иелә, әле сикергәли, тагын әллә ниләр кылана. Дөңгере бертуктаусыз дөберди. Тогърулҗа, бу тамашаны күзәтеп, йокымсыраган хәлгә төшүен сизми дә калды. Тәне, аңа буйсынмыйча, елан шикелле як-якка авыша, күз кабаклары үзеннән-үзе йомыла. Ахыр чиктә тирә-юньдә дөңгер белән гырылдаудан башка бүтән аһәңнәр калмады.

Бу күпме дәвам иткәндер – Тогърулҗа белми, ул вакыт исәбен югалтты. Аны Багаууганның яман тавыш белән кычкырып җибәрүе генә сискәндереп аңына китерде. Алгуй белән Түлә-Буга да, әле генә йокыдан уянган кешеләр сыман, күзләрен чекерәйтеп багучыга текәлгән. Тегесе уртада йомарланып яткан, дөңгерен күкрәгенә кысып тоткан. Сәер сүзләр пышылдый-пышылдый, Багаууган сабый сыман кычкырып елап җибәрде. Куркып калган өч ир-ат ни эшләргә дә белми утырган арада, багучы кисәк кенә тынычланды һәм җир идәннән торып басты. Аның күзләре юеш, алар элеккеге халәтенә кайткан.

– Галиҗәнап ханым, минем тәнем бу дөньяда калып, җаным Аскы дөньяга төште, – диде багучы тыныч тавыш белән. – Аскы дөньяның 99 зинданында мәрхүмнәрнең җаннары бикләнгән. Алар көн дә, төн дә зар елыйлар. Күз яшьләре елга булып агып төшә, ул елга Аскы дөньяның хуҗасы Әрлик-хан утырган тимер сарайны әйләндереп алган. Сарайга бары тик упкын аша тарттырылган ат кылы аша гына керергә мөмкин. Капканың үзен котны алырлык куркыныч җанварлар саклый. Мин, алар аша исән-имин үтеп, Әрлик-хан белән сөйләшә алдым.

Багаууган, күргәннәрен исенә төшергән сыман, күзләрен йомып бераз сүзсез торды. Каршындагы өч ир-ат аны тын да алмый тыңлыйлар иде. Багучы дәвам итте:

– Әрлик-хан озын кара чәчле, кара мыекларын колак артларына кыстырып йөри, кара сакалы тезенә җиткән, өстендә җиде аю тиресеннән тегелгән тун. Ул миңа сезнең киләчәгегез турында бәян кылды. – Багучы, сез әзерме дигән сыман, ханнар нәселеннән булган ирләрне күздән кичерде. – Дошманыгыз бик көчле һәм сездән яшьрәктер. Ул сездән хәйләкәррәк һәм мәкерлерәктер. Алда сезне көрәш көтә, әмма сез өчегез дә җиңеләчәксез.

– Кайчан булачак бу хәлләр? – дип сорады калтыранып төшкән Түлә-Буга.

– Анысын Әрлик-хан миңа әйтмәде. Бәлки, иртәгә, бәлки, йөз елдан соң.

Шуннан артыгын мин белмим, галиҗәнап ханым. Миңа китәргә рөхсәт бир, бик нык арыдым... – Багучы, чыннан да, озын юл үткән бәндә сыман хәлсезләнеп калган иде.

Түлә-Буга көмеш тәңкәләр тутырылган кечкенә капчыкны багучыга ташлады, тегесе яшь егетләр җитезлеге белән аны эләктереп тә алды.

– Хәзергә китә аласың. Сарайга кайткач та, беренче эш итеп Әрлик-ханга корбан чалырга кирәк булыр, оныттырма, – диде Түлә-Буга.

Багучы киткәч тә, Түлә-Буга хезмәтчеләрен чакыртып, хәмер салырга боерды.

– Әллә иртәгә, әллә йөз елдан соң булыр диде бит Багаууган. – Хан хәмергә чыланган сакалын сыпырып куйды. Ул шактый кәефле күренә иде. – Бүгеннән үк баш ватмыйк, туганнарым. Ногай белән Туктайның арт сабагын укытырга кирәк анысы. Шуңа күрә озакламый Сарайга кайтып, корылтай җыярбыз. – Аннан хезмәтчегә эндәште. – Бирегә думбрачыларны, биючеләрне, җарияләрне чакыр!

Хан тирмәсе төне буе гөрләп торды. Башкаларында да шау-шулы бәйрәм барды. Киеренкелекне, курку хисен җиңәргә тырышып, Түлә-Буга хәмергә чумды.

Тогърулҗа үз тирмәсенә таң алынганда гына кайтты. Аны борчылып Баялун көтә иде. Тогърулҗа аны үз янына чакырып, багучы әйткәннәрне бәйнә-бәйнә сөйләп бирде. Бәянны тыңлаган саен олы хатынының йөзе карала барды, ул тирән уйга батты.

– Ханзадә Үзбәкне ничек тә булса коткарырга кирәк, – диде, ниһаять, бер фикергә килеп, Баялун.

– Ничек итеп?!

– Кавказ тауларына, чиркәсләргә, Әрибахның туганнары янына җибәрик. Анда ул исән калачак, монда исә язмышы хәл ителгән.

Тогърулҗа җавап бирергә ашыкмады. Баялунны озатып, үз янына Әрибахны чакыртты. Аны сөйгән хатыны белән мавыктыргыч уен көтә иде. Сылу буйлы, татлы күкрәкле Әрибахны туйганчы назлап, арыган Тогърулҗа йокыга талды.

Үзбәкнең Кавказ ягына китүен Түлә-Буга белән килештерделәр. Хан баштарак мондый тәкъдимгә карышты, Тогърулҗаны куркаклыкта гаепләде, ләкин ахыр чиктә күнде.

Ун яшьлек егетне юлга бөтен ыру белән әзерләделәр. Кием-салым, азык-төлек, дәрәҗәле кешеләргә затлы бүләкләр, алтын-көмеш сандыкларга салынды. Үзбәкнең иминлеген, байлыкларның бөтенлеген сакларга йөздән артык тәҗрибәле нүкәр[7] билгеләнде. Аларның башына Алатай белән Нангудай әмирләр куелды. Иптәшкә балачактан ук бергә уйнап үскән Исабәкне – ханзадәдән чак кына олырак малайны да җибәрделәр. Олауга күпсанлы атлар, үгезләр өстәлде. Нәтиҗәдә, уртача бер кәрван килеп чыкты.

Саубуллашыр вакыт җитте. Башта әтисе Тогърулҗа сүз алды:

– Балам, – диде ул, тавышын мөмкин кадәр тынычрак итәргә тырышып. – Син бездән еракка, даладан тауларга китәсең. Безне сагынып, йөрәгең сыкраганда, бер нәрсәне исеңдә тот – чын ир-ат теләсә нинди авырлыкларны җиңәргә, барлык сынауларны да намус белән ерып чыгарга тиеш. Мәңге Күк

[7] Нүкәр – монгол сугышчысы, гадәттә, аксөякләр затыннан.

Тәңре сине дошманнардан саклар, без аңа китергән корбаннар юлыңны ачык итәр. Син әле яшь, ә бу белем эстәр өчен бик кулай чор. Беләгең генә түгел, акылың да ныгысын. Укымышлы кешеләр Урдага бик кирәк. Аларны без читтән чакыртканчы, үзебезнең Чыңгыз нәселеннән үстерү дөресрәк булыр. Ләкин укымышлы булу гына җитми, тәнең дә корычтай ныгысын. Икесе бертигез барганда гына, кеше морадына ирешә ала. Мин сине кире әйләнеп кайтканда, чын ир-егет итеп күрергә өметләнәм. Хыялларың миңа мәгълүм, әгәр Мәңге Күк Тәңре ярдәм итсә, алар чынга ашар. Ләкин ул теләкләреңне беркемгә дә сөйләмә, сак була күр. Хуш, сау бул, сөекле улым Үзбәк!

Аннан чират Әрибахка җитте. Әнисе кулына кечкенә кызын күтәргән. Көнчәага[8] әле берни дә аңламый, авызыннан күбек чыгарып, абыйсына елмаеп, нәни кулларын суза. Үзбәк сеңелкәшенең кулын сак кына учына тотты, аннан әнисенә елышты. Әрибахның күзеннән яшьләр ага иде:

– Улым, син минем туган ягыма, күкне терәп торган тауларга китәсең. Таулар сакчыл һәм шул ук вакытта кыю кешене ярата. Мин синең исән-имин әйләнеп кайтуыңны чын күңелдән көтәчәкмен! Безне онытма, далада сине өзелеп яраткан кешеләрең барлыгын башыңнан чыгарма!

Баялун хатын да берничә сүз кыстырды. Ниһаять, озын кәрван юлга кузгалды. Әтисе атлы җайдаклар белән аларны беренче ямчыларга кадәр озата килде, аннан соң хан станына борылды. Үзбәк ун ел чамасына сузылган сәяхәткә кузгалды...

**3**

Дала буйлап бәкләр-бәге Ногай атын ашыктырмый гына атлатып бара. Аның янәшәсендә оныгы Актаҗи, уллары Тәке белән Җәке, ышанычлысы Кара. Олыс бәген иллеләп җайдактан торган кечкенә генә хәрби төркем озата килә. Ногай сыңар күзе белән офыкны күзәтә, нәрсәдер көтә кебек.

Көнчыгыш тарафында башта тузан өере күренде. Аның эченнән атлы нүкәрләр озатуында Туктай пәйда булды. Ногай, җәһәт кенә ияреннән сикереп төште дә тез чүгеп катып калды. Үзе белән бергә килгән барча кешеләр дә бәкләр-бәгенең гамәлен кабатлады.

Туктай атын Ногайга ике адым кала туктатты. Аннан, җиргә басып, ашыкмый гына төмәнбашы янына килде.

– Тор, бәкләр-бәге Ногай, күрешик, – диде Туктай.

Ногай торып басты, алар Туктай белән кочаклаштылар.

– Караңгы күктәге ут яктысы, өметен җуйганнарның соңгы ышанычы, Урда тәхетенең чын хуҗасы, галиҗәнап Туктай ханзадә, мин сине үз җирләремдә күрүемә чиксез шатмын.

– Синең җирләр – Урда җирләре, бәкләр-бәге, шуны онытып җибәрә күрмә, – Ногайның артык баллы сүзләре Туктайның кырыслыгын киметмәде. Ул ук тарттырылган җәя сыман киеренке халәттә иде.

– Онытмыйм, ханым, онытмыйм, – диярге ашыкты Ногай. – Сине безнең олысның башкаласы Сакчыга чакырырга рөхсәт ит. Синең белән килгән нүкәрләрне дә табында көтәбез.

Туктай үз янәшәсендә торган алып гәүдәле егеткә төртеп күрсәтте:

– Кадак – минем иң ышанычлы кешем, аңа миңа күрсәткән илтифат булсын.

[8] Көнчәага – Үзбәк ханның бертуган сеңлесе, урыс елъязмаларында Кончака исеме белән билгеле.

Кадак, уң кулын күкрәгенә куеп, үзенә сыңар күзен текәгән Ногайга чак кына сизелерлек баш иде.

– Аңладым, бөек ханым, аңладым. Әйдәгез, юлдан алҗыгансыздыр, Сакчыга узыйк. Анда мин безнең уртак эшебезгә тугры булган нойоннарны да җыйдым. Безгә ниятебезне кичекмәстән гамәлгә ашырырга кирәк.

Ногайның Сакчыдагы сарае биек таш дивар белән әйләндереп алынган. Төрле почмаклардан төтен күтәрелә, тирә-юньгә сарык, куй, ат ите исләре кушылган тәмле исләр таралган. Җайдаклар ике якка ачылмалы капка аша иркен ишегалдына керделәр.

Бәкләр-бәге Туктайны үзенең кабул итү бүлмәсенә чакырды. Ул бәйрәмчә бизәлгән, уртасында Ногайның ике бүре башлы затлы тәхете тора.

– Баш өсте, ханзадәм, сине тәхетемдә күрү минем өчен чиксез шатлык булыр иде, – диде Ногай, Туктайны шунда әйдәп. Ләкин Туктай килешмәде.

– Миңа синең олыс тәхете кирәк түгел. Мин бирегә башка максат белән килдем. Шуңа күрә әлегә читтәрәк утырсам да, ярап торыр.

Ногай имәнеп китте. Яшь ханзадә барысын да күрә, барысына да игътибар итә. Бәкләр-бәгенең туграсы Урданыкыннан югарырак торуын да дикъкать белән күзләде. Сакчыдагы сарайның Ногай тамгалары белән генә бизәлгәнлеген дә күрде. Кабул итү бүлмәсендә тәхетне калдыру тагын да зуррак ялгышлык булды бугай. Туктай, Ногай уйлаганча, барысына да килешә торган сарык бәтиенә охшамаган, моңарда юлбарыс чалымнары хәзердән үк шәйләнә. Аңа өмет баглап, ялгышмадымы икән ул? Урда тәхетенә менеп утыргач та, яңа хан кылычын Ногайга каршы күтәрмәсме? Ничек кенә булмасын, чигенергә юл калмаган. Әгәр юлбарыс кирелек күрсәтсә, Ногайга, элеккечә, хәйлә-мәкергә керешергә туры киләчәк. Ә бу эштә бәкләр-бәгенең тәҗрибәсе зур. Нәрсә генә әйтмәсеннәр, Туктай – данлыклы төмәнбашы гомерендә бишенче хан булырга тора бит.

– Мин гомерем буе Урдага хезмәт иттем, сөекле ханым, – дип, сүзен дәвам итте Ногай. – Аның көчле, ныклы, дошманнарны дер селкетеп торучы мәмләкәт булуы өчен җанымны кызганмадым. Бердәм һәм бай Урда – минем тормышымның мәгънәсе. Синең әниең Олҗай хатын миңа мөрәҗәгать итеп, сине тәхеткә утыртырга ярдәм күрсәтүемне сорагач, берсүзсез килештем. Чөнки бүген Урдада тез чүгәрлек хан юк. Тәхетем дә шуның билгесе генә. Син хакимлеккә килгәч, минем күңелем тынычланачак, ата-бабалардан калган хөр дәүләтебез ышанычлы кулларга тапшырылачак. – Аннан Ногай яраннарына борылды. – Минем тәхетне биредән алып чыгып китегез! Мин гади эскәмиядә утырачакмын!

Ногайның озын нотыгына кайтарып, Туктай бер генә сүз дә әйтмәде, бары Кадакка гына тирән мәгънәле караш ташлады.

Кичке якта бәкләр-бәге үзенең сараендагы олы бүлмәгә кунаклар чакырды. Янәшәсенә ул Туктайны утыртты, икенче якта уллары һәм оныклары урын алды. Бер-бер артлы олыс нойоннары килә торды. Алар, Ногай каршында тез чүгеп, аңа тугрылыкка ант эчәләр, затлы-затлы бүләкләр тапшыралар. Туктай бу тамашаны сүзсез генә күзәтеп торды. Исемен төрле сугышларда катнашып, кан белән юган төмәнбашының дәрәҗәсе чиксез, моны бер караштан аңларга мөмкин. Һәрбер нойон артында дистәләрчә мең нүкәр тора. Ногай олысы аның хисабына тагын да

ныгыса, дала бүресенең ханнан да югарырак күтәрелергә бөтен мөмкинлеге дә бар. Аның колакка сыланып кала торган баллы сүзләренә ышанырга ярамый. Ногай бары тик үз җае өчен генә борчыла. Урда дип, төкерек чәчсә дә, Днепр, Днестр, Дунай, Тын елгалары ярларында тыныч кына яшәп ятмакчы. Туктай аның рәхәт картлыгын тәэмин итәргә тиешле бер курчак кына булырга тиеш.

Туктай янәшәсендәге Ногайга дикъкать белән карады. Беләкләре нык, үзенә-үзе ышанычы зур иде бәкләр-бәгенең. Аңа буйсынган олыслардан килгән аксөякләрнең мактауларын җәелеп китеп тыңлый, күкләргә чөеп мактаудан изрәп китә. Мондый кешегә артык ышанып бетәргә ярамас. Әйе, Ногай үз җире өчен җаны-тәне белән янып йөрүче хаким. Әмма ул үз җаен гына кайгыртырга өйрәнгән. Шул ук вакытта бу кадәрле ихтирам яулаган, сүзе үтә торган бәкләр-бәгенең ярдәменнән дә баш тарту зур ялгышлык булыр иде.

Аксөякләр җыелып беткәч, бүлмәгә думбрачылар керде, моңлы көйләр яңгырый башлады. Һәрбер кунак каршына тәбәнәк кенә өстәлләр китерелде, аларга майлы калҗалар, тау-тау итеп ит өелгән табаклар куелды. Бавырчылар чыгып, шунда ук ризыкны туракларга кереште. Чәркәләрдә кымыз, чит-ят илләрдән килгән исерткеч эчемлекләр таратылды. Туктай исерткечкә кагылмады, Ногай күпме генә кыстамасын, шәраблардан авыз итмәде.

Мәҗлес инде гөрли башлаган иде, Ногай үз янына Караны чакырып алды.

– Бавырчылар, думбрачылар, яраннар китсеннәр, сарайда ышанычлы бәндәләр генә калсын. Минем нойоннар белән җитди сөйләшәсем бар, – диде ул, пышылдап.

Артык кешеләр сарайдан чыгарып җибәрелгәч, Ногай торып басты. Корылтайга чакырылган аксөякләр тынып калды, ашау-эчү туктатылды. Барча күзләр дә бәкләр-бәгенә төбәлде.

– Корылтайга җыелган хөрмәтле бәкләр, әмирләр, сәргаскәрләр! Мин сезне бүген бирегә кәеф-сафа корып сыйланырга гына дәшмәдем. – Ногай сыңар күзе белән бүлмәдәгеләрне айкап чыкты. Барысы да, тын да алмый, түмәнбашын тыңлый иде. Аның хакимлеге биредә чиксез, һәм бу Ногайга ышаныч өстәде. – Үзегез беләсез, соңгы вакытта Урданың хәлләре шәптән түгел. Түлә-Буганың акылсыз сәясәте безне авыр хәлгә куйды. Дошманнарыбыз баш калкытты. Хан үзен булдыксыз гаскәр башы итеп күрсәтте. Рус җирләрендә безнең баскаклар мәсхәрәләнде, теләсә кемгә ярлык таратылып, сез өметләнгән ясактан мәхрүм калдыгыз. Аңлашыла ки, мондый гамәлләр Урданың киләчәгенә яный. Минемчә, андый хан дәүләт белән идарә итәргә тиеш түгел!

Бу сүзләр яшен яшьнәгән төсле яңгырады. Нойоннар шаулашырга, кайсы нәрсә кычкырырга керештеләр. Туктай корылтайга җыелганнарның ни әйтергә теләгәнен аңларга тырышса да, шау-шу артык көчле иде. Ниһаять, Ногай уң кулын өскә күтәргәч, җәмәгать тынып калды.

– Бу – корылтай, һәркайсыгызның фикерен тыңлый торган урын. Курпыш бәк, әйдә, син сөйләп кара.

Табындагы бәкләрнең берсе торып басты. Ул инде шактый олы яшьтә, бетәшкәнлеге йөзенә чыккан, таякка таянган. Шулай да карашында яшәү көче һәм зирәклеге тоемлана.

– Түлә-Буга хан Мәңге-Тимер тарафыннан тәхеткә утыртылды, – диде Курпыш бәк. – Ул хакимлекне үз теләге белән бирмәс. Безнең Урда эшләренә тыкшынуыбыз канкоешка китерер. Ә бу бөек Чыңгызхан тарафыннан калдырылган Яса кануннарына каршы килә. Ханны бәкләр түгел, Мәңге Күк Тәңре үзе билгели. Безнең фетнә зур бәлаләр чыгармасмы?

– Курпыш бәк, син утырып тор әле, – диде усал тавыш белән Ногай. – Бердән, Түлә-Буганың китүен без кылыч белән түгел, ә сүз белән сораячакбыз. Ләкин иң үтемле сүз – үткен кылыч ярдәмендә әйтелгәне. Икенчедән, яңа ханыбызның тәнендә Чыңгызлар каны ага, шуңа күрә аны тәхеткә күтәрү Яса кануннарына каршы килми. Өченчедән, без хакимлеккә китерәсе хан Яса кануннары буенча күптән хаким буласы иде, Туктай ханзадә Түлә-Буга һәм аның туганнарының явызлыгы нәтиҗәсендә генә тәхеттән колак какты. Без түгел, ә бәлки Түлә-Буга – ата-бабаларыбыз кануннарын аяк астына салып таптаучы. Без исә, Мәңге Күк Тәңре кушуы буенча гаделлек урнаштыру өчен җыелдык. Һәм, иң мөһимен әйтәсем килә. Мин – бөек Бату хан әманәтен үтәүче бәкләр-бәге. – Бу сүзләрне ишеткәч, Ногай Туктайга карап алды, ләкин тегесенең бер генә дә исе китмәде. – Бату хан миңа Урданы сакларга, гаделлекне якларга кушып калдырды. Бирегә җыелган барчабыз да – аның васыятен үтәүчеләр.

Корылтай шактый озакка сузылды. Бәхәсләр кызганнан-кызды. Кара төндә генә уртак фикергә килделәр. Ногайның сүзе үтте. Күпчелек бәкләр хан тәхетенә Туктайны утыртуны яклап чыктылар.

Мәҗлес янә гөрләде, янә табынга бавырчылар, думбрачылар чакырылды, җарияләр ымсындыргыч биюләрен башлап җибәрде. Бер Туктай гына күңел ачмады. Аны алда зур сынаулар һәм канкоеш көтә, бәйрәм итәргә иртәрәк иде әле...

Таң алдыннан Туктай янына Кадак килеп, колагына пышылдады:

– Берничә бәкнең чапкыннары Сарайга таба чыгып киткән, мондагы вакыйгаларны һичшиксез Түлә-Бугага җиткерәчәкләр, икесен куып тота алмадык...

– Җиткерсеннәр, Түлә-Буга үзен үлем көтәсен белеп торсын, – диде Туктай. Дошман белән ачыктан-ачык каршылыкка керү яшь егеткә тәхет өчен уенда кызык кына өсти иде...

**4**

1291 елны Түлә-Буга Сарайда зур гаскәр туплап, Ногайга каршы кузгалырга әзер иде. Хан нукәрләреннән тыш, иллешәр үгезгә җигелгән киң арбаларга тирмәләр урнаштырылган, кечкенә арбаларга азык-төлек, юл кирәк-яраклары салынган, хезмәтчеләр, яраннар, җарияләр төялгән.

Юлга чыгар алдыннан Тогърулҗа гаиләсе, туганнары белән бәхилләште.

– Күңелем сизә – хәтәр сәфәргә кузгаласыз, – диде соңгы көннәрдә борчылудан төн йокысын югалткан Баялун.

– Хатын, син – иң өлкәне. Әгәр миңа бер-бер хәл була калса, калганнарны яклауны сиңа йөклим, Әрибах белән Көнчәаганы бигрәк тә сакла. Син, Әрибах, олы хатыным Баялунның сүзен тыңла.

Хәрәмендәге һәрбер хатынына, баласына тиешле сүзен табып, мөмкин

булганча юаткач, Тогърулҗа яраннары ярдәмендә хәрби киемнәрен киде, кылычын барлады, җәясенә җитәрлек укларны калчанына салды.

Хан җитәкчелегендәге гаскәрне озатырга барча халык урамга чыкты. Кырыс нүкәрләрне кайсысы кызыксынып, кайсысы кызганып күзләп калды. Ирләренә исән-имин әйләнеп кайтуларын теләүче хатын-кызлар, баласының башы сау булуын Мәңге Күк Тәңредән сораучы аналар Урда гаскәренә юл биреп, Сарайның агач һәм таштан эшләнгән йортларының диварларына елышты. Нүкәрләр төрле олыслардан җыелган, моны төмән башлыгы янәшәсендә баручы гаскәринең кулындагы тугра аңлатып тора. Йөз-битләре дә төрле. Кайберләре кызу кояшта янып, кара-чутыр төскә кергән, кайберләре кырыс салкын кышлы яклардан. Аерым бер дружинада рус кенәзлекләре егетләре атлый – аларның атлары да, кораллары да, төс-кыяфәтләре дә башкаларныкыннан нык аерыла.

Түлә-Буга гаскәре белән Сарайдан чыкканда, Сакчы ягыннан икенче олы гаскәр – Ногай белән Туктай нүкәрләре кузгалды. Бу ике көч очрашкан мәйдан, һичшиксез, мәетләр белән тулачак, кан елга булып агачак...

Бер Ногай гына килеп туган каршылыкны артык күп кан коймыйча хәл итәргә өметләнә. Туктай үз станына килгәч тә, хәйләкәр бәкләр-бәге моның хәстәрен дә күрде. Түлә-Буганың әнисе Җиҗәк хатынга чапкынын җибәреп, солых тәкъдим итте. Имештер, Ногай каты авырый, кан косып, урын өстендә ята. Аңа инде күп калмаган, Бату хан әманәте белән ул низагны туктатырга тели. Әгәр Түлә-Буга, Алгуй, Тогърулҗа очрашып сөйләшергә риза булса, бәкләр-бәге барлык каршылыкларны да юкка чыгарыр иде. Җиҗәк хатын җибәргән шымчылар, чыннан да төмәнбашының бик үк сәламәт түгеллеген, әледән-әле кан косуын расладылар. Кара оештырган күзәтчелек бик төгәл эшли иде – шымчыларны эләктереп, үлем куркынычы һәм алтын чыңлавы астында ул аларны үз ягына аудара торды. Тегеләре, Караның хаиннары үзләрен Урданың теләсә кайсы почмагында табып ботарлавын белгәнгә, Җиҗәк хатын янына кайтып, Ногай җырын җырладылар. Җиҗәк хатын исә улының язмышы өчен борчыла калды. Урданың көнбатышында хакимлек итүче бәкләр-бәгенең дәрәҗәсе дә югары, көче дә хәйран. Бәлки, улы белән очрашсалар, чыннан да уртак тел табарлар, каршылык-низагка нокта куярлар? Бәкләр-бәгенең ни дәрәҗәдә куркыныч кеше икәнлеген Җиҗәк хатын яхшы белә. Аны бары тик юмалап кына җиңәргә мөмкин. Шуңа күрә ул, Сарайда торып та, Түлә-Буганы Ногай белән күрешеп сөйләшергә үгетләүдән туктамады. Ахыр чиктә, Түлә-Буганың да күңеле йомшады кебек...

Ике гаскәр, күз күреме ара калдырып, бер-берсенә кара-каршы урнашты. Ике як та, шымчыларын җибәргәләп, дошман станындагы хәлләрне төп тирмәләргә җиткерә торды. Түлә-Буга да, Ногай да гаскәр башлыкларына ашыкмаска, ләкин теләсә кайсы вакытта һөҗүмгә әзер торырга боерды. Мондый хәл Туктайга бер дә ошамады. Түземлеге беткән ханзадә көннәрнең берендә, тузынып, Ногай тирмәсенә атылып керде.

– Нәрсә көтәбез без, бәкләр-бәге?! Әллә инде картаеп, тешләрең төшеп беттеме, сугышка керергә куркасыңмы?!

Ногай, күзләре акайган, ачуыннан йөзе чытылган егетне утырырга, тынычланырга чакырды, аннан соң Җиҗәк хатын белән бәйләнышлары турында бәйнә-бәйнә сөйләп бирде.

– Бәкләр-бәге, синең тәхетеңә бүре түгел, төлке сыннары куясы булган, – диде Туктай, бераз тынычлана төшеп. – Тик дошманны астыртын юл белән җиңү миңа барыбер ошап бетми...

– Сөекле ханзадәм, тормыш шушы яу кырында гына тәмамланмый ул. Түлә-Буга белән шактый зур көч ияреп килгән. Син хан булгач та, шул гаскәрләрнең төмәнбашлары, нукәрләре ярдәмендә дәүләтебезне саклыйсы, ныгытасы була. Бер тапкыр кара-каршы сугышкан нукәрләр иңгә-иң көрәшә алырмы икән? Андагы бәкләр даладагы кипкән үлән түмгәге шикелле, җил кая иссә, шунда тәгәриләр. Син тәхеткә утыргач та, алар сиңа башларын иячәк. Барысы да булмаса, күбесе. Сабырлык кирәк, ханзадәм, көтә белгәннәргә һәрчак уңыш елмая ул, шуны онытма. Ә хәзер исә иң ышанычлы, иң кансыз егетләреңне әзерлә. Үзеңнең дә кылычың үткен, кулың какшамас булсын. Ханнар башын хан гына кисә ала...

Шымчылардан тыш, чапкыннар да ике стан арасында арлы-бирле йөри бирде. Ниһаять, очрашу хакында килештеләр.

Ике як та гаскәрләрен унар чакрымга чигендерергә тиеш иде. Сөйләшүне кылыч-уклар астында үткәрмәскә сүз куештылар. Түлә-Буга да, Ногай белән Туктай да бу шартны җиренә җиткереп үтәде.

Сөйләшү үткәрү өчен аулак урынны Ногай күрсәтте. Ул урман эчендәге ышык аланны сайлады. Үз ягыннан да, хан тарафдарларыннан да алты кешедән артмаган төркем билгеләнүен таләп итте. Бусы да бәкләр-бәгенең бер хәйләсе иде – Түлә-Буга, Ногайның җаена тәмам күнеп, шымчыларының кисәтүенә дә колак салмады. Әнисе көндәшләре яхшы ният белән йөри дип ышандырды бит, димәк, аңа тулысы белән ышанырга мөмкин. Ул арада урман аланы тирәсен Кара белән Кадак нукәрләре басып алган иде инде.

Атларга атланып, юлга кузгалдылар. Түлә-Буганы Тогърулҗа, Алгуй һәм тагын өч затлы нойон озата китте. Туктайга исә, Ногайдан тыш, Кадак һәм бәкләр-бәгенең өч улы иярде.

Кул сузымы ара калгач, алар туктадылар.

– Атларыгыздан төшеп, бөек хан каршында тез чүгегез! – дип боерды Түлә-Буга, каршындагы бәндәләрнең иярдән төшәргә ашыкмауларына ачуы чыгып.

– Бөек хан?! – Ногай, кемнедер эзләгән төсле, як-ягына каранып алды. – Әлбәттә, минем күзем берәү генә, тик аның белән дә күпне күрәм. Яныбызда бөек ханның әсәре дә юк бит, Түлә-Буга! Өчегезнең кайсысы алдында баш иясе соң?!

Түлә-Буга, тешләрен кысып, билен капшады. Кылычы булса, шушы мизгелдә үк бәкләр-бәгенә ташланасы иде дә, очрашуга коралсыз килергә сүз куештылар шул.

– Бәкләр-бәге Ногай, синең башбаштаклыкка күпме түзәргә була?! – Ханның тавышы калтыранып ук чыкты. – Урда ханын танымыйсың, хакимеңә каршы кылыч күтәрәсең. Ә син, Туктай, ни кыланасың?! Минем хакта нахак гаепләр тараткансың, нигә кирәк булды мондый гамәлең?! Әллә инде син дә дала төлкесенең арбасына утырдыңмы? Аның белән ерак китә алмассың, акылыңа кил, Туктай!

– Түлә-Буга, син алай кызма әле. – Ногай үтә дә тыныч, хәтта елмаебрак та сөйләшә иде. – Әгәр мин Урда ханына каршы кылыч күтәрсәм, моның ни белән бетәсен яхшы беләсең. Әлегә җир йөзендә миннән дә кодрәтлерәк

сәргаскәр юк, моны барысы да таный. Туктайга килгәндә... Туктай ханзадә синең җәбер-золымнардан качып, миннән яклау сорап килде. Башкаларга гаеп сылаганчы, үзеңнең гамәлләреңне үлчәп кара. Без сиңа бу мәсьәләне канкоешсыз хәл итү җаен тәкъдим итәбез.

– Йә, бәкләр-бәге, сайрап кара, тыңлыйк.

– Син үз теләгең белән тәхеттән баш тартасың. Тәхет сиңа болай да таман түгел бит. Урда тарихында гомер булмаган хәл – дәүләт эшләрен өчәүләшеп алып барасыз. Шуңа күрә кем каршына тез чүгәргә дә белми яшәп ятышыбыз. Үз теләгең белән китсәң, сиңа да җиңелрәк булыр. Барчагызга да иминлек вәгъдә итәбез, балда-майда йөзеп, мәмләкәт хисабыннан ашап-эчеп, рәхәтләнеп тормыш алып барырсыз. Кичекмәстән корылтай җыеп, әлеге мәсьәләне уртага салып сөйләшик.

Моны ишеткән Түлә-Буга бөтенләй дә кызарынып-бүртенеп чыкты, бу кадәр мыскыллауны ишетермен дип уйламаган да иде ул.

– Очрашуыбыз юкка булган, бәкләр-бәге, – диде ул, мөлдерәмә яшьле күзләрен каршындагы дошманнарына төбәп. – Мәңге Күк Тәңре, Чыңгызхан Ясасы һәм Урда корылтае тарафыннан бирелгән хакимлекне болай ансат кына тартып алырбыз дип уйласагыз, нык ялгышасыз. – Аннан соң үзе белән килгән тарафдарларына борылды. – Китәбез, биредә сүз куертып торуның башка мәгънәсе юк.

Түлә-Буга атын борды, аңа калганнар да иярде, әмма ерак китә алмадылар – куе куаклык арасыннан килеп чыккан Кара белән Кадак нүкәрләре аларны чолгап алды.

– Нишләвең бу, бәкләр-бәге Ногай?! – Түлә-Буганың куркудан күзләре акаеп чыккан иде, ул, шартлар дәрәҗәгә җитеп, фетнәчеләргә карады. Тик аларда өмет тапмады.

Нүкәрләр тиз арада алты җайдакны иярләреннән сөйрәп төшерде, кулларын артка каерып бәйләде һәм җиргә тезләндерде. Ногай, җәяүле калып, ашыкмый гына мескен бәндәләр янына юнәлде. Килә-килешкә Кара кулыннан үткен кылыч алды.

– Синең өчен соң инде, башкаларга сабак булсын, Түлә-Буга хан, – дип гырылдады ул усал тавыш белән. Күзләре уттай яна, болай да куркыныч йөзен нәфрәт ялмап алган, ямьсез кыяфәттә кыйшайган. – Бәкләр-бәге Ногайга каршы сүз әйтерлек кеше әлегә дөньяга килмәгән. Яхшылык белән моны аңламаганнарны бер генә язмыш көтә.

Ногайның кылычы һавада сызгырып үтте. Бер-бер артлы Мөләгән, Кадан, Көтөгән нойоннарның башлары җиргә тәгәрәде, аларның муеннарыннан чыжлап, кан бәреп чыкты. Ахыр чиктә, тезләнгән килеш тора алмый, башсыз мәетләр җиргә гөрселдәп ауды. Ногай, «күрдегезме инде» дигән караш белән янәшәдәгеләргә текәлде. Тын аланга курку хисенә катыш әчкелтем-баллы кан исе таралган иде. Бәкләр-бәге бигрәк тә Туктайның йөзенә озаграк тукталып карады, ләкин тегесе тораташтай тыныч һәм битараф иде.

– Соңгы сүзеңне әйтергә теләмисеңме, Түлә-Буга хан? – Ногай карашын тезләнгән әсирләргә күчерде.

– Гаиләләребезгә, балаларга тимәгез. Калганы синең хозурыңда, мөртәт Ногай! – Хан түзә алмады, елап җибәрде, тавышы пышылдап кына чыкты.

– Башларына капчык кидерегез! – дип боерды Ногай Карага. Тегесе шунда ук әмерне үтәргә ашыкты.

Ногай, салмак кына атлап, кылычындагы канны чапаны чабуына сөртә-сөртә, Туктайга юнәлде.

– Синең чират, ханзадә. Тәнендә ханнар каны аккан кешеләрнең гомерен син генә өзә аласың.

Гүя, Туктай шуны гына көткән иде. Ул, бер генә дә икеләнми, тезләнгән хакимнәргә якынайды. Түлә-Буганың артыннан килеп, тезен аның аркасына терәде, ике куллап кисәк кенә муенын үзенә таба тартты. Ханның авызыннан «ыһ» итеп соңгы сулышы чыкты, умыртка баганасы шартлап сынды. Җансыз гәүдә җиргә ауды. Тогърулҗа белән Алгуйның сыртларын чәрдәкләгәндә дә, Туктай бер генә мизгелгә дә уйланып, кабаланып тормады. Моны күзәткән Ногайның үзенә дә эсселе-суыклы булып китте – әйтерсең, ханзадәдә кешелекнең әсәре дә юк. Туганнары бит, ә Туктай аларның җаннарын койганда, ник бераз гына уйланып, хискә бирелеп торсын! Хакимлеккә омтылу кешене шулкадәр вәхши затка әйләндерер икән!

Эш тәмам булгач, өч мәетне атларының иярләренә аркылыга салдылар. Ул арада гаскәрләре дә килеп җиткән иде, нүкәрләр хакимнәренә ияределәр. Берничә дистә мең яугир озатуында хан төмәннәре торган урынга юнәлделәр.

Түлә-Буганың сәргаскәрләре аларны тып-тын торган халәттә каршылады. Иярләренә хуҗаларының мәетләре салынган атлар янәшәдән үтеп киткәч тә, барысы да аңлашылды.

– Түлә-Буга хан һәм аның туганнары көтмәгәндә һәлак булды! – дип, көр тавыш белән кычкырды Ногай, Сарай тарафыннан килгән нойоннарга кул сузымы ара калгач. – Телисез икән, сугыша алабыз, әмма безнең каныбыз да, сезнеке дә мәрхүмнәргә булышмас. Урда хансыз калды. Хәзер дәүләтебезне ышанычлы хаким кулына тапшырырга кирәк. Шуңа күрә канкоешсыз гына таралышырга һәм барчабызга да бергә корылтайга җыелырга тәкъдим итәм!

Каршы як дәшмәде, аларның сүзсез торуы – бәкләр-бәгенең фикере белән килешү билгесе иде...

## 5

Урдага яңа хан килде. Бу хәбәр шул ук мизгелдә даланың төрле почмакларына, рус кенәзлекләренә, Кавказ аръягына, Римга һәм Каһирәгә, Болгар һәм Җүкәтауга, Киев һәм Тверьгә, Константинополь һәм Мәккәгә таралды. Бөтен дөнья тын калды. Яңа хан илгә ни алып килер? Рус кенәзләре – үзләренең ярлыклары, Рим папасы католиклар дине таралуы, Каһирә – ислам, Константинополь православ өммәтенең киләчәге өчен борчыла иде. Тәбәнәк атларга атланып йөргән, белемсез, мәдәниятсез дип саналган күчмә халыктан торган Урда, ул чактагы дөньяның нәкъ үзәгендә урнашып, чыннан да Җирнең Кендеге, теләсә кайсы дәүләтнең язмышына кысылырдай, аны үзе кирәк дип тапкан юнәлешкә борып җибәрердәй мәмләкәт булып оешты.

Тик Туктайның уенда әлегә дөнья белән идарә итү кайгысы юк. Ул, Түлә-Буга, Алгуй, Тогърулҗаның җаннарын кыйганнан соң, үзен якламаган

бәкләргә, тәхеткә менеп утырырга хакы булган туганнарына каршы аяусыз көрәш башлады. Олы кешеме ул, әллә инде бишектәге сабыймы – барысы да аның нөкәрләре кылычыннан җан тәслим кылды. Хакимлекне кан коеп яулап алып, тәхеткә менеп утырганда, Урдада дошманнары да, туганнары да санаулы гына калган иде...

Борынгы гадәтләр буенча, үтерелгән ханның һәм аның яраннарының хатыннары Туктайга күчте. Түлә-Буга, Алгуй, Тогърулҗаның хәрәмнәрен ул, үз кулы белән гомерләрен өзгән кеше буларак, шәхсән барып кабул итеп алды.

Тогърулҗа хәрәмендә аның игътибарын башта Баялун хатын җәлеп итте. Яше шактый, Туктай белән бер ятакка ятарлык түгел. Ләкин аннан ниндидер көч сирпелә. Яшь хан, Баялунга якынрак килеп, иягеннән тотып, хатынның күзләрен үзенә каратты.

– Исемең ничек? – диде ул.

– Баялун хатын булам, сөекле ханым.

– Матур исем. Сиңа хәрәмдә тәртип саклап торуны йөклим.

Туктай ары китте. Орчык кебек гәүдәле, төз буй-сынлы хатын каршысына туктады. Бу хатын шунда ук Туктайның гайрәтен уятты.

– Ни атлы буласың?

– Әрибах, – диде кызый, карашын җиргә төбәгән көе.

– Баялун хатын, Әрибахны бүген минем яныма җибәрерсең!

– Баш өсте, сөекле ханым.

Тогърулҗаның йорт-җирен яраннарына тапшыргач, Туктай үзенең сараена юнәлде. Юл буе башыннан Әрибах хатын чыкмады. Ул аңа шунда ук ябырылырга әзер иде, ләкин ханнарга алай килешми, тыелырга туры килде. Төс-кыяфәте, нәфис гәүдәсе генә түгел, Әрибахның чак кына тоемлана торган аерым бер исе егетнең башын әйләндерде. Борыннарны кытыклап, гаурәт җепселләренә үтеп керә торган ис иде ул.

Туктай киткәч тә, Баялун Әрибах янына ашыкты.

– Күңелем сизә, Әрибах хатын, син барчабызны да, шул исәптән улың Үзбәкне дә коткара алачаксың, – диде ул, аларны тыңлап торучылар юклыгына инангач.

– Ничек итеп, Баялун хатын?

– Ятып әйтелгән сүз басып әйтелгәнгә караганда иплерәк үтеп керә. Яшь тай, сине күргәч тә, чак кына кешнәп җибәрмәде. Бүген төнлә барлык чараларыңны да куллан, аның куеныннан чыкмаслык итеп хезмәт күрсәт.

Йөзе чытылып, Әрибах хатын елап җибәрде:

– Баялун хатын, аннан кан исе килә бит! Минем иремнең каны!

– Һай, юләр дә соң үзең! Хатын-кызның язмышы шул инде аның. Балаларың турында уйла, ичмасам. Көнчәаганы үстерәсең бар, Үзбәкне чит җирләрдән кайтарырга кирәк булыр. Ул чакта алар язмышын хәл итәсе кеше синең учларыңда биеп торачак. Бар, борыннарыңны сөрт, чәчләреңне рәткә китер, осталыгың белән шаккаттыр яшь тайны!

Әрибах, мышкылдап, Туктай белән очрашуга әзерләнә башлады.

Ул хан тирмәсенә кергәндә, күктә ай калыккан иде. Туктай түшәгенә сузылып яткан. Ишектән башын иеп кергән хатынны ул сүзсез генә күзләде. Тегесе, карашын күтәрмичә генә, аның каршына килеп басты.

– Чишен, – дип боерды Туктай.

Әрибах өстендәге күлмәген мизгел эчендә салып ташлады һәм анадан тума килеш калды. Хан соклануын яшермәде. Аның ач күзләре хатынның күкрәкләрен, кендеген, аннан түбәнрәк урнашкан уйсулыкны, әйтерсең, кагылмыйча капшыйлар иде. Хан торып басты, чапанын түшәккә ташлады, үзе дә япа-ялангач килеш хатынны тирәли әйләнеп чыкты. Әрибахның озын толымы нәкъ умыртка сөяге буенча төшеп, арткы яктан башланучы ике калкулык арасына кадәр җитә. Хатынның ап-ак тәне һуштан яздыра.

Туктай, Әрибахка якыная төшеп, бармак очлары белән аның арт санына кагылды. Хатынның аркасына, аякларына каз тәне йөгерде. Хан, сылукайны кочаклап алып, муеннарын үбәргә кереште, ике кулы белән ике күкрәген кысып тотты, бөтен барлыгы белән нәзберек гәүдәгә елышты. Борынына баш әйләндергеч ис китереп бәрде. Ул акылдан шаштыра иде. Туктай ләззәт тулы чоңгылга чумды.

Соңгы атналарның киеренкелегеннән соң Әрибах Туктай өчен чынлап торып юаныч чарасына әверелде. Аның тәне генә түгел, авыр уйлар белән бәргәләнгән җаны дә бушанып калды. Кан елгалары, мәрхүмнәрнең җан биргәндә чыккан соңгы гырылдау тавышлары онытылды, башка бер дөньяда калды. Әрибах белән уйнаклашудан тәмам алҗып, ул, ниһаять, күптән хыялланган тәмле йокыга талды...

Уянып киткәндә, хатыны, йомарланып, аның аяк очларында утыра иде. «Әллә бу мине Тогърулҗа өчен үч итеп үтерергә килгәнме?!» – дигән уйдан ханның йөрәге жу итеп куйды.

– Син монда нишләп утырасың? Ник үз тирмәңә китмәдең?! – дип сорады ул, уң кулы белән хәнҗәрен капшап.

– Сөекле ханым, синең белән үткән бу төннән шулкадәр наз алдым ки, син уянгач та, бәлки, дәвамы булыр дип, йокыңны сакладым. Әгәр мин ялгыш гамәл кылсам, зинһар, гафу итә күр...

Әрибахның бу сүзләреннән Туктай тәмам эреп төште, әллә кайдан үзендә яңа көчләр сизеп, ул хатынына омтылды...

Хатыны инде хәрәмгә китәргә җыенганда, Туктай аны бусагада диярлек туктатты.

– Теге хәрәмдәге карчыга... Ни атлы әле ул?

– Кемне әйтәсең, сөекле ханым, Баялун хатыннымы?

– Әйе, нәкъ шулай. Ул миңа бер дә ошамады. Мин аны берәр сәргаскәремә хатынлыкка бирергә телим.

– Сөекле ханым, зинһар алай эшли күрмә! – Әрибах, яклаучысыз калуыннан куркып, елар дәрәҗәгә җитеште. – Ул миңа бөтен эшләремдә булыша, баламны тәрбияли. Әгәр Баялун хатын булмаса, мин синең яныңда болай ачылып ләззәтләнә алмас идем...

– Бала дигәннән... Синең Үзбәк атлы улың бар бит, ник миңа аның турында берни дә әйтмәдең?

– Әйе, сөекле ханым, бар, мин сиңа ул хакта мәгълүм дип уйлаган идем...

– Кайларда ул хәзер?

– Без аны белем эстәргә дип, чит җирләргә җибәрдек...

– Улыңны кайтарасың килмиме?

Әрибах каушап калды, аннан соң бар кыюлыгын җыйды.

– Мин аның белемле кеше булып үсүен телим. Гыйлем ияләре Урдага бик кирәк. Бүген без андыйларны дөнья буйлап җыябыз, үзебезнекеләрне үстерсәк, дәүләтебезгә файда китерерләр иде.

Туктай, китә аласың дип, ишеккә таба ымлады. Аннан соң уйга калды. Үзбәк аңа куркыныч янарлык кеше булмасмы? Кадак әйтүенчә, яше унда гына. Түлә-Буга өстендә болытлар куера башлагач, малайны ашыгыч рәвештә озатканнар. Кадакка кушсаң, аны, әлбәттә, күз ачып йомганчы эзләп табачак. Икенче яктан, ун яшьлек сабый нәрсәсе белән янасын? Аңа зыян салып, Әрибах ләззәтеннән колак какмасмы? Ирен үтерү белән хатын-кыз килешә ала, ә менә баласын югалткач, үзгә рәвешкә керергә мөмкин. Гыйлем белән кызыксынучылар гадәттә гарибрәк, авыру кешеләр була. Андыйлардан яманлык көтү урынсыз. Көне-төне китап өстендә утыралар, башка кайгылары юк. Әлегә ничек барса, шулай дәвам итсен. Вакыты җиткәч борчылыр, бүген Үзбәк кайгысыннан башка да мәшәкате җитәрлек...

Вакыт яраларны оныттырмаса да, төзәтергә сәләтле. Әрибах та акрынлап, Туктайның хәрәмендәге тормышка күнекте. Хан, кунаклар кабул иткәндә, аны һичшиксез үз янына, уң якка утырта торган булды. Моны күргән башка хатыннар Әрибахка ачу һәм нәфрәт сакласа да, бернинди явызлык та кыла алмадылар. Һәр хатынның үз тирмәсе, анда чит-ятлар чакырусыз кереп йөрми, әвнухлар[9] һәм җарияләр генә хезмәт күрсәтә. Баялун хатын Әрибахка кайнар төннәрдә ханның колагына нинди сүзләр пышылдарга кирәклеген өйрәтеп тора. Ханның мәхәббәте түшәктә генә түгел – ул яраткан хатынын алтын-көмеш, затлы бизәнү әйберләренә күмә. Шыплап тулган сандыклардагы байлыклар махсус чапкыннар аша улы Үзбәккә дә җибәрелеп тора. Әрибах инде белә иде – улы чиркәс халкы арасында яшәү белән генә чикләнми, Кавказ таулары аръягына сәяхәт кылырга, андагы гыйлем ияләре белән очрашырга хыяллана. Чиркәсләр арасында беләкләре ныгыгач та, әнисе улына моңа да ризалыгын бирде.

Баялун исә һәрвакыт акыллы киңәшләр белән ярдәм итә. Кан дошманнары дип, ул бер дә Туктайны түгел, ә бәкләр-бәге Ногайны саный. «Туктайга әҗәт кайтару өчен вакыт әлегә җитмәгән, ә менә даладагы карт сасы көзәненең бурычы хакында хәзердән уйлый башларга кирәк», – ди торган иде ул Әрибах белән икәүдән-икәү калган вакытларда.

Туктай Ногайны беренче күрүдән үк ошатмаган иде. Ул аның артык күп көч-кодрәт җыюын, ханның артында мәкерле уеннар алып баруын, бәкләрне үз тирәсенә җыеп, алар арасында Урда хакименнән дә дәрәҗәлерәк кылануын яхшы белә. Ләкин әлегә бәкләр-бәгенә кул күтәрергә ашыкмый, вакыты җитмәгән дип саный. Гәрчә, Баялун хатын әледән-әле Әрибах аша ханга бәкләр-бәгенә карата агулы сүзләрне җиткерә торса да. Имештер, Ногай бишенче ханны үз көенә биетеп торам дип сөйләп йөри, янәсе, аның һәрбер сүзен Туктай карусыз үти, хәтта бәкләр-бәге ханны үзенең учыннан ашатучы яшь айгыр дип тә атаган икән! Яраткан хатынының һәрбер сүзе хан йөрәгенә шырпы булып кадалып барды. Ногайга нәфрәте артканнан-артты. Җитмәсә, тегесе дә чама белми кылана. Туктайның Урдада бердәм акча әйләнешен кертергә җыенуын ишеткәч, үзе тәңкәләр ясата башлаган, аңа үз тамгаларын салган. Хан станына чакырган вакытта да Ногай теләсә килә,

[9] Әвнух – евнух, хәрәмдәге җарияләргә хезмәт күрсәтүче мәхлук.

теләмәсә – юк. Мең төрле сәбәп табып, хаким тарафына аяк та атламый. Әле ул ауда, әле авыру...

Көннәрнең берендә Сарайга Ногайның хатыны Байлак хатын килеп төште. Хан аны, гадәттәгечә, күпсанлы гаиләсе белән бергә каршылады. Ногайдан төрле-төрле бүләкләр тапшыргач та, Байлак хатын сүз сорады.

– Сөйлә, Байлак хатын, – диде Туктай ялкау гына, Ногай җибәргән хәнҗәрне кулында әйләндергәләп.

– Минем хан колагына гына җиткерәсе сүзләрем бар, – диде Байлак хатын. Моны ишеткәч, Баялун аны көлгә әйләндерерлек усал караш белән бүләкләде.

– Ханның үз гаиләсеннән серләре юк, тартынмыйча сөйли аласың.

Байлак хатын уңайсызланды, ләкин фикерләрен туплый алды.

– Синең атаң... – дип башлады ул сүзен. Елмаеп, хәнҗәрне өйрәнеп утырган Туктайның йөзе үзгәрде, ул усал күзләрен Байлакка төбәде.

– Минем әтием данлыклы Мәңге-Тимер. Ул күптән мәрхүм, – дип кырт кисте хан.

– Гафу, сөекле ханым, онытылып киткәнмен. – Ханның Ногайлар йортына мондый мөнәсәбәтен күргән Байлак эшнең хәерлегә бармаганлыгын аңлады. Тик башланган сүзне тәмамлыйсы, ире кушканны үтисе бар иде. – Бәкләр-бәге Ногай синең юлың ачылуга зур шатлыгын белдерә. Ул синең уңышларга, янәшәңдәге дошманнарыңны тар-мар итүгә чиксез шат. Ләкин юлыңда тигәнәкләр очраштыргалый, аларны тамыры белән йолкырга кирәк, сөекле ханым.

– Тигәнәкләрнең исемнәре бардыр бит?

Байлак хатын, ханның кызыксынуын күреп тынычланды һәм бер-бер артлы Туктай тирәсендәге егермеләп аксөякнең исемен атады. Хан дәшми генә тыңлады, аннан соң, сөйләшү тәмам икәнлеген аңлатып, урыныннан торды.

– Бәкләр-бәге Ногайга бүләкләре һәм файдалы мәгълүматы өчен бөек хан исеменнән рәхмәт белдер. Ләкин аңа төшендереп әйт – әгәр ул хан янына килүне кирәк санамый икән, хан үзе килеп төшәргә мөмкин. Ә ул чакта инде сөйләшү башкачарак булачак.

Кичен, Баялун хатыннан күрсәтмәләр алып, Әрибах Туктай янына юнәлде.

– Мин сине чакыртмадым бит, Әрибах хатын, нишләп йөрисең монда? – дип гаҗәпләнде Туктай.

– Сөекле ханым, үзеңнең мескен җарияңне гафу итә күр! Бүгенге сөйләшүдән соң тынычлыгым качты.

– Нинди сөйләшү?

– Байлак хатын турында әйтүем. Син Ногайның фикеренә артык колак саласың бугай. Атап үтелгән бәкләр арасында бер гаепсезләре дә булырга мөмкин. Ә гаепсезләрне үтергән ханны халык яратмый башлый. Гаделсезлектән ераграк тор, зинһар. Сине канечкеч хан иттереп күрсәтеп, Ногай үзеңне көчсезләндерергә маташа шикелле. Әле бәкләргә, әле сәргаскәрләргә каршы котырта. Беләм, син көчле гаскәр төзергә тырышасың, ләкин синең көчең Ногайга кирәк түгел. Ул, дәүләт эшләренә тыкшынып, үзенең генә куәтен арттыру турында уйлый. Әгәр үзем белмәгән мәсьәләгә тыгылам икән, гафу итә күр, сөекле ханым!

– Кадакка әйтермен, ул барысын да җентекләп тикшерер. Ә хәзер күземнән югал!

Гөнаһсыз аксөяк буламыни?! Кайчандыр, кайдадыр, кемгәдер нидер әйткән, рус җиреннән алып кайткан ясакның бер өлешен качырып калган, тагын әллә нәрсәләр... Ногай исемлегендәге кешеләр берәм-берәм суелып торды. Баялун хатынның фаразы дөрес булып чыкты – әмирләр һәм бәкләр, ханның кансызлыгыннан куркып, аңа хезмәт итүләре дөресме икән дип шикләнә башлады, үзләренең иминлеге өчен нык хафага төштеләр. Түземлек касәсен тутырган соңгы тамчы – Туктай хакимлеккә килгәндә, улы Түлә-Буганы ялгыш юлга кертеп җибәргән Җиҗәк хатын булды. Аны үзенең тирмәсендә буып үтерелгән килеш таптылар. Җиҗәк хатынга иң нык теш кайраучы – Ногай. Улының умыртка баганасы сындырылгач та, мескен ана бу фаҗигада беренче чиратта үзен гаепле санады. Ул, Ногай коткысына бирелеп, Түлә-Буганы тыныч кына сөйләшүләр үткәрергә күндерде бит. Тәмам акылдан язар хәлгә җитеп, кайда гына бармасын, ул бәкләр-бәгенең астыртынлыгы хакында зар елап сөйләде. Һәм менә хәзер – кинәт кенә үз йортында сагалап торган үлем...

Әрибах ханыннан сакчыларны арттыруны үтенде, Ногай бuучылары аның янына да киләчәк дип өркетте. Ул арада бер төркем әмирләр Ногай олысына качып киттеләр. Туктай, тегеләрне богаулап, кире кайтаруны таләп итсә дә, бәкләр-бәге ярым сукыр гына түгел, саңгырау да булып кыланды, әмирләрне дә кайтармады, җавап та бирмәде.

**6**

Туктай гаскәр җыярга кереште. Моның белән беррәттән ул Ногай олысына чираттагы чапкынын җибәрде.

Картайган, ләкин күңел көрлеген һәм яшәү ямен югалтмаган Ногай чапкынны Днепр буендагы тирмәсендә кабул итте. Ике бүре башлы тәхетендә ул ятып диярлек утыра, уйлары кайдадыр читтә. Чапкын кереп тез чүккәч тә, бәкләр-бәге аңа игътибар да итмәде.

– Көнбатыш җирләренең ышанычлы бәкләр-бәге, сөекле ханыбызның тугры терәге, мин сиңа Сарайдан хәбәр алып килдем, – диде чапкын, башын күтәрми генә.

– Сөйлә.

– Ханыбыз Туктай сүздә берни дә әйтмәде, сиңа менә боларны тапшырырга боерды.

Ногай йомылып диярлек беткән сыңар күзен кызыксыну белән ачты. Чапкын тирмәдән чыгып китте, аннан соң кечкенә генә сука, бер калчан ук һәм капчыкка салынган бер уч җир алып кереп салды.

– Бу – ханыбызның әмерләре билгесе. Зирәкләрнең зирәге әйткәнчә, син аны һичшиксез аңлаячаксың.

Ногайның баягы битарафлыгы шунда ук юкка чыкты. Ул чапкынны, ял итәргә кушып, чыгарып җибәрде. Тегесе җавап нинди булыр дип сораса да, әлегә әзер түгеллеген әйтте.

Тирмәнең почмагыннан шәүлә сыман Кара күренде.

– Чапкынга бер капчык кирәк булыр. Аның башы сыярлык. Беләсеңме, бу билгеләр нәрсәне аңлатканны?

Беркайчан да сорауларга җавап бирмәгән Кара дәшмәде. Кирәк тапса, хуҗасы барыбер үзе әйтәчәк. Ногай, тәхетеннән төшеп, Туктай күчтәнәчләре янына килде.

– Сука. – Бәкләр-бәге суканың төрәненә бармак очын тидерде, ул шунда ук киселеп китеп канап чыкты. – Туктай, безгә моны җибәреп, «әгәр дә сез җир астына кереп качсагыз, мин сезне шушы сука белән каезлап чыгарачакмын» дип әйтмәкче. – Ногай укларга төртеп күрсәтте. – Бусы «әгәр дә сез күккә күтәрелсәгез, мин сезне шушы уклар белән атып төшерәчәкмен» диюе була. Ә инде бер уч җир... «Кайсы җирдә әйтсәгез, шунда очрашабыз», ди Урда ханы. Күрәсең, яшь тай, тамагы туйгач, үзен айгыр итеп тоя башлагандыр. Хәзер үк чапкын әзерләгез. Бер кулына Туктай илчесенең башын тотып барсын. Ханга болай дип әйтсен: «Ногайның атлары нык сусадылар, шуңа күрә алар Дон елгасыннан су эчәргә тели», дисен. Әгәр ул егет, кем ярдәмендә тәхеткә утырганлыгын онытькан икән, Урданың Дон елгасыннан бу як ярын бүтән үзенеке дип санамасын!

1298 елның кышында Туктай хан җитәкчелегендәге зур гаскәр Ногай олысына, Дон елгасының сул як ярына килеп, станга урнашты. Бәкләр-бәге өчен бу беренче чиратта кисәтү иде. Хан, гаскәрен елганың аргы ягына чыгармыйча, Ногайның баш иеп килүен көтте. Ләкин тегесе Туктай тарафына аяк та атламады. Ике як та бер-берсен күзәтә, каршылыкның ни белән бетәсен, беренче булып, кемнең түземлеге төкәнәсен көтә.

Язга чыккач та, Туктай гаскәре белән Дон елгасы буйлап ары кузгалды, Ногайның станына юл алды. Урда ханы Ногайның бу кадәрле төмәннәргә каршы чыгасына ышанмый, аны яклардай бәкләр юк дип уйлый иде. Тик ул ялгышты. Ногай ягына Таз, Тонгыз, Каҗан, Абаҗан, Каранҗин, Янҗи, Мәнҗи, Сөдөн, Алаҗ, Сөнгәй, Көшөб, Салган, Әшек, Көнҗек, Шобыткай, Терекәрәй, Котлы-Буга, Могылтай бәкләр басты. Алар ярдәмендә тынгысыз бәкләр-бәге исәбе буенча ханнныкыннан чак кына калышкан гаскәр туплады.

Канлы бәрелеш кичектергесез иде. Ике гаскәр кара-каршы тезелде. Ногай яклыларның саны азрак булса да, аларга һөҗүм өчен уңайлы калку җир эләкте.

Хан, төз рәтләрдә торган гаскәре каршына чыгып, дошманына карата нәфрәт уятырлык сүзләр белән ялкынлы чыгыш ясады. Теге яктан Ногайның тавышы ишетелә иде. Ниһаять, Туктай атын бар көченә дошман өстенә юнәлтте. Аның артыннан гаскәре дә иярде. Ногай хан өстенә ыргылды. Ике хаким, җәядән атылган ук очып килерлек арага җиткәч, туктапып калдылар. Хәзер яу кырына сәргаскәрләр хуҗа иде.

Бу сугыш канлы, ләкин Туктай өчен уңышсыз булды. Нүкәрләр исәбе буенча уздырса да, Ногайның хәрби осталыгы өстенрәк чыкты. Берничә поскын оештырып, шулардан яңа көчләрне кертә-кертә, Ногай Туктай яугирләрен кысрыклады. Ахыр чиктә, хан гаскәриләре чигенергә һәм яу кырын ташлап качарга мәҗбүр булдылар.

Ногай качып киткәннәрне куаламаска кушты. Ханга кул күтәрү аның максаты түгел иде. Яралыларга да тидермәде. Бәкләр-бәге Ногайның мәрхәмәтлеге бөтен дөньяга таралсын. Чөнки җаны-тәне белән сизенә – бу әле соңгы бәрелеш түгел. Киребеткән хан һичшиксез яңа гаскәр җыеп

киләчәк. Ул чакта нүкәрләр кем ягында сугышу отышлырак икәнлеген белеп торачак. Ногай, ташлап калдырылган арбалардагы байлыкны җыеп, станына кайтыр юлга чыкты.

**7**

Туган ягындагы бу вакыйгалар хакында Үзбәк хәбәрдар булса да, яңалыкларны соңарып кына ишетә иде. Кавказ аръягына чыгып киткәннән соң ул күп урыннарда булды, күп нәрсәне күрде. Байлыкларын чамалап кына тота, үзен тыйнаклыкка, ризык кадерен белергә өйрәтте. Юлында ул зур шәһәрләрне күреп сокланды. Биек манаралы мәчетләр, купшы сарайлар, олы базарлар – болар барысы да Сарайдагыдан күпкә матуррак, зуррак, килешлерәк булып чыкты. Ул манаралары күккә ашкан гыйбадәтханәләрне, аксөякләрнең бизәкле йортларын, җәмәгать урыннарын кызыксыну белән өйрәнде, кайберләрен рәсемгә төшереп барды.

Аннан да бигрәк Үзбәк мөселман мәдәнияте белән якыннан танышты. Аны моңлы азан тавышы, мәчетләрдәге Коръәннең аһәңле моңнары таң калдыра, тәннәрен чемердәтә иде. Ул, мөселманнарның Изге Китабына төшенә башлап, үзенә бөтенләй үзгә, чисталык, пакьлек, төгәллек дөньясын ачты. Элегрәк үз диннәрендә аңлатып бирә алмаган күпсанлы сорауларга ачыклык кертте. Дөнья гизеп, берничә тел өйрәнеп, үзенә күпсанлы китаплар җыйды, шактый гына гыйлем ияләре белән очрашты. Үзен озата йөрергә куелган Исабәк моңа сәерсенеп караса да, Үзбәкнең эшләренә тыкшынмады, аның тугры юлчысы гына булды.

Күңеленә бигрәк тә Ширван җирләрендә урнашкан суфи5 Пир Хөсәен[10] хәнәкәсе[11] кереп калды. Хәнәкә кәрван юлына салынган, биредә мосафирларга ял итеп алырга бүлмәләр хәстәрен дә күргәннәр. Шушында Үзбәк Габбас хәзрәт белән танышты. Акыл иясенең күңел тынычлыгы аны шаккатырды. Гыйлем әһеле белән озаклап, дин, тормыш хакында сөйләштеләр.

– Сиңа мондый илаһи сабырлык ни бәрабәренә иңде? – дип сорады аксакалның салмак фикер йөртүен кызыксынып тыңлаган ханзадә.

– Мин сабыр, чөнки беркая да ашыкмыйм, дөнья кумыйм. Җан азыгын изге китаптан алам. Ул мине сафландыра.

– Җан азыгы дип кенә яшәп булмый бит, тәнгә дә ризык кирәк...

– Анысын Ходай җитәрлек итеп бирә. Синең күңелең тыныч түгел, чөнки син һаман да каядыр талпынасың, ниндидер үрләр яуларга маташасың.

– Минем хаким буласым килә...

– Хакимлек – Ходай бүләге, аның ләгънәте дә.

Үзбәк хан гаҗәпкә калды.

– Хаким – бар нәрсәгә дә хуҗа, ни теләсә шуны ашый, җаны теләгәнен эшли. Шул да булдымыни ләгънәт?!

– Бер генә хаким дә үз теләгәнен эшли алмый, энем. Ул – үз хакимлегенең колы. Аның һәрбер адымы, һәрбер гамәле халкы һәм биләмәләре язмышын кайгыртып ясала. Бер ялгышлык исә мизгел эчендә барысыннан да мәхрүм итәргә мөмкин. Һәрбер хаким үз җилкәсендә зур йөк йөртә – ул җаваплылык

[10] Пир Хөсәен – XI гасырда Ширванда яшәп, суфичылык тәгълиматына табынган философ.
[11] Хәнәкә – дөнья мәшәкатьләреннән арынып, рухи чисталыкка омтылучы суфиларның яшәү урыны.

дип атала. Тарих битләренә исеме ак яки кара хәрефләр белән язылырмы – монысы да аның кылган эшләренә бәйле. Син хакимлеккә кызыгасың, сизеп торам. Әмма ул бик мәшәкатьле хезмәт. Тәхеткә менү белән кеше үз-үзен югалта, шул тәхетнең колына әйләнеп кала...

Әлеге сүзләр яшь егетне нык тетрәндерде, уйландырды, бераз вакыт үткәч исә, Габбас хәзрәт белән әңгәмә онытылды да диярлек. Аны кабаттан искә төшергәнче, гыйлемле картның хаклы икәнлегенә инанганчы, Үзбәккә әле шактый юллар һәм еллар үтәсе бар иде...

Биек, мәгъруp Кавказ таулары аша чиркәс биләмәләренә кире кайткан вакытта Үзбәк үзенең беренче мәхәббәтен дә очратты. Кумык кызы Нәзифәгә ул бер күрүдә гашыйк булды. Кызны шартын китереп, Исабәкне эти-әниләре янына җибәреп соратып алды. Нәзифә бик чибәр, күндәм, сабыр холыклы кыз иде.

Нәзифә белән Үзбәкнең мәхәббәт җимешләре – туп кебек малай да дөньяга аваз салды. Беренче тапкыр улын кулына алгач та, Үзбәк соклануын яшермәде.

– Миннән соң тәхетне калдырырга варисым туды, Исабәк, – диде ул, күңеле җилкенгән егетләрдә генә була торган чиктән тыш масаю белән.

– Ашыкма әле, Үзбәк ханзадә, юкса бәхет кошын куркытуың бар. Әле үзеңә дә тәхет юк бит... – Исабәк бу мизгелләрдә дә җитдилеген югалтмаган иде.

– Булыр, тәхетем дә булыр, дәүләтем дә. – Үзбәк дустының үзенә ышанмавына күңеленнән үпкәләп куйды. – Ә инде төрле хафалар килмәсен, яман күзләр төшмәсен өчен улыма Тимербәк дигән исем бирәм. Тимердәй нык, Чыңгызлар данына тугры булып үссен!

Исабәк бу хакта башка сүз куертып торырга кирәк тапмады.

Озакламый Әрибахтан хәбәр килеп төште. Ногай белән Туктай арасындагы каршылык ахыр чиккә җиткән, әнисе улына кичекмәстән туган якларына кайтырга җыена башларга куша иде. Башта чиркәсләр янында аерым хәбәр көтеп, аннан мөмкинлек чыкса, Сарайга ук, хан һәм Әрибах янына. Әнисе улына аеруча сак булырга киңәш иткән, Урдадагы хәлләр бик буталчык, юлга ышанычлы нүкәрләрсез кузгалырга ярамый.

Туган ягыннан чыгып киткәненә нәкъ ун ел вакыт үткән, ул инде күз явын алырлык егеткә әверелгән. Беләкләрендәге көче исә башындагы гыйлеме белән бер дәрәҗәгә күтәрелгән. Сарайга кайтып, Туктай хан каршына баруга ул үзен тулысынча әзер итеп тоя иде...

**8**

Туктайга Ногай өстенә янәдән бару өчен гаскәр җыярга ел ярымнан артык вакыт кирәк булды. Ул ара эчендә хәрби гамәлләргә әзерлек белән беррәттән хан барлык хәйләкәрлеген дә эшкә җикте. Нәтиҗәдә, Ногай тарафындагы Мәҗи, Сөдөн, Утраж, Акбуга һәм Тайта бәкләр Туктай ягына качып килде. Үзләре белән алар шактый гына нүкәрләрне дә ияртteләр.

Коралланган кешеләр Сарайга төрле яктан агылды. Идел буйлап болгарлар төште, рус кенәзлекләре шактый гына сугышчы җибәрде. Туктай хәтта Кавказ сыртын саклап торучы көчләрне дә яуга чакырырга мәҗбүр булды. Нәтиҗәдә, исәбе белән моңарчы күрелмәгән гаскәр оешты.

– Болай булгач, Ногайның көннәре санаулы, – диде тулы ышаныч белән Баялун хатын. – Хәзер Туктайның ачуын китереп, теләсә нәрсә сөйләп тору әйбәт булмас. Дала сасы көзәнен җиңеп кайткач, кәефе дә күтәрелер, шунда син аңа улыңны бирегә чакырту турында әйтергә тиешсең, Әрибах.

– Яхшы, Баялун хатын. Ул инде Кавказ аръягыннан кире чиркәсләр тарафына кузгалды.

– Тик, зинһар, ашыкма гына. Улыңа хәзер егерме яшьләр чамасы, аны күргән чапкыннар сүзенә ышансаң, Чыңгызныкы белән синеке кушылган каннан бик чибәр, акыллы һәм шул ук вакытта көчле егет үсеп җиткән. Туктай аңарда үзенә көндәш күрмәсен тагын. Авызын чамалап ачсын, җитезлеге белән мактанмасын.

Яуга китәр алдыннан Туктай хатыннары белән саубуллашты. Алар сөекле ханнарына ихлас күңелдән дошманын җиңеп кайтуын теләделәр.

Дала буйлап олы гаскәр кузгалды. Әйтерсең, анда Урдадагы һәм аңа баш игән күрше-тирә дәүләтләрдәге кулына корал тота алган бөтен кеше тупланган. Аны канлы яулар аша узган нүкәрләр генә түгел, ханның яраннары, багучылар, бавырчылар, думбрачылар, пешекчеләр, тагын әллә кемнәр озата бара. Туктайның төп тирмәсе атлы җайдаклардан арттарак, зур көпчәкле арбага күтәртелгән. Аны сиксән үгез тартып бара. Юлда туктап тормый-нитми, хан шунда ук сәргаскәрләрен, бәкләрне, әмирләрне, кенәзләрне кабул итә, Ногайга каршы бәрелешнең төрле юллары турында киңәшләшә.

Олысына зур яу килүен ишеткән Ногай да гаскәр туплады. Ләкин ул барыбер Туктайныкына караганда ике тапкырга кимрәк нүкәрдән тора иде. Шулай да, мин-минлеге чиктән ашкан бәкләр-бәге борчылмады. Сугышта иң мөһиме сан түгел, ә акыл. Мәкер, хәйлә ягыннан әлегә аңа тиңнәр табылмады, шуңа ул тулысы белән үзенең көченә ышанды.

Туктайга каршы кузгалыр алдыннан Ногай хатыннарын чакырды.

– Зур орышка китәм, биредә сез күз-колак булып торыгыз, алай-болай башка яклардан җәбер-золым чыга калса, шунда ук миңа чапкын җибәрегез, – диде ул, хатыннарын сыңар күзе белән бораулап.

– Бәлки, Туктайга карышырга кирәкмәстер? – дип, тыйнак кына кыстырды Байлак хатын. – Соңгы тапкыр сөйләшкәндә, сиңа бик каты теш кайраганы сизелде...

– Үз эшеңне бел, Байлак хатын, ирләрнекенә тыгылма. Тешен тагын да ныграк кайрыйдыр инде, әле күптән түгел генә арт санына тибеп җибәрдем бит.

– Хәзер үзеңә типмәгәйләре, – диде Хаини хатын. – Безнең шымчылар Туктайның нык әзерләнеп килүен хәбәр итте, башың гына сау булсын инде...

– Кирәк икән, гомеремне саклап калыр өчен вакытлыча Туктайга буйсынырмын. Иелгән башны кылыч кисми, үзен тәхеткә утырткан кешегә кул күтәрмәс, шәт. Йә, ярый, сезнең белән сүз боткасы болгатып, яуга соңга каламмы инде! Югалыгыз күземнән!

Ногай, тирмәсеннән чыгып, тирә-якка күз салды. Биек колга башында бердәнбер үз тамгасы төшерелгән тугра гына җилферди иде. Урданыкын ул Туктай беренче тапкыр гаскәр җыеп килгәч тә алып ташларга кушты. Кем белә, бәлки Ногай үз балаларына аерым мәмләкәт, аерым дәүләт төзеп

калдырыр?! Туктай сөйләшүләр алып барырга ризалашса, Урданы урталай бүлеп, һәрберсе үз ягында тыныч кына хакимлек итә алалар бит. Аларда хан Чыңгызлар нәселеннән булса, бирердә Ногай канынннан хакимнәр куелачак. Бәкләр-бәге фикеренчә, бу әйбәт тәкъдимгә охшый. Дошманнар килә калса, аларга каршы бергәләшеп чыгарга мөмкин. Ләкин Ногай Сарай ханына тез чүгәргә тиеш түгел. Икесе дә бертигез дәрәҗәдә, чын мәгънәсендә хакимнәр булсын! Алай да, Урда туграсын табып алып, аны үзенекеннән озынрак колгага күтәрергә боерып калдырды. Дөнья хәлен белеп булмый...

Хыялларына чумып, картайган, бөкшәйгән Ногай арбага утырган килеш юлга кузгалды. Яшь бара, ул инде хәзер, атка атланып, төмәннәр алдыннан юл күрсәтеп юртаклый алмый. Хәзер дилбегә уллары Җәке, Тәке һәм Турай кулына күчә бара. Башларында акыллары буталып, Ногай мәрхүм булганнан соң сугышып кына бетмәсеннәр инде...

Күпсанлы булуына карамастан, Туктайның төмәннәре бик тиз бара иде. Кыска гына вакыт арасында алар Ногайның «иске олысы» дип йөртелгән җирләргә килеп җиттеләр. Бәкләр-бәгенең хаким дәрәҗәсенә үрмәләве нәкъ менә шушы тарафларда башланды.

Ике гаскәр кара-каршы урнашты. Икесе дә янәдән кемнең беренче булып һөҗүмгә күчүен көтәләр иде. Туктай, олы көчнең үз ягында булуына карамастан, ашыкмаска карар кылды.

Озак та үтми, Урда ханы станына Ногайдан чапкын килеп төште. Ешеш сулап, ул Туктайның тәнсакчылары озатуында төп тирмәгә керде һәм илбашы каршында тез чүкте.

– Ни йомыш белән килдең, илче? – дип сорады Туктай, бөтенләй башка нәрсә турында уйлаган кыяфәт белән. Ногайның тәкъдимен кичекмәстән ишетергә теләсә дә, сер бирмәде.

– Бөек хан, бәкләр-бәге Ногай сине үзенең олысында күрүенә чиксез шатлануын белдерергә һәм сине кайнар сәламләргә боерды, – диде илче, башын күтәрми генә. – Ул сүзен-сүзгә менә боларны җиткерергә кушты: «Синең колың Ногай үз җирләренә Урда ханының килүен белми калды; Ногай олысы һәм аның гаскәрләре тулысы белән илебез ханының милке; синең колың карт һәм авыру кеше, ул бөтен гомерен синең нәселеңә хезмәт итүгә багышлады; әгәр синең каршыңда гаебе бар икән, бу бары тик улларының уйламый эш итүе нәтиҗәсендә килеп чыккан хаталану гына; бәкләр-бәге ханның үзен кичерүенә ихлас күңелдән өмет итә һәм ышана».

– Тәмаммы?

– Тәмам.

– Яхшы, син китә аласың.

– Бәкләр-бәге Ногайга ни дип әйтим, бөек ханым?

– Хан уйлап караячак диген.

Чапкын күздән югалу белән Туктай җитдиләнде һәм янәшәсендәге Кадакка борылды.

– Дала төлкесе картая, һаман бер ялган белән көн күрмәкче. Түлә-Буганы бәреп төшергәндә дә, аның колагын, Җиҗәк хатынны шундый ук сүзләр белән юмалап маташкан иде. Ләкин мин Түлә-Буга түгел. Картлач мәкер әзерли. Хәзер үк гаскәрнең ике канат ягыннан шымчылар җибәрегез, безне камап алырга исәпләре юкмы икән? Ногай станыннан берәр нукәрне урлап

кайтырга кирәк, бәлки ул бәкләр-бәгенең башындагы фикерләреннән хәбәрдардыр. Һәрхәлдә, кул кушырып утырырга ярамый. Гаскәрне кичекмәстән хәрби әзерлек хәленә китерегез!

Туктайның сизгерлеге алдамады. Шымчы елганың өске өлешендә бу як ярга чыгарга әзерләнеп ятучы зур төркемгә тап булды. Нөкәрләрне Ногайның улы Җәке җитәкли иде. Күрәсең, аларга Туктай станына арка яктан китереп бәрергә кушылган. Моны белеп алган хан шунда ук гаскәрен икегә бүлде. Бер өлеше – Җәке ягына, икенчесе Ногай станына ыргылды.

Орыш озак бармады, көчләр тигез түгел иде. Ногайның шактый нөкәрләре Җәке янында калу да Туктайга ярдәм итте. Көтелмәгән һөҗүмнән каушап калган ногайлылар, кайсы кая чабып, киң далада югалды. Туктай исән калган нөкәрләрне үтермәскә кушты – аларның дала даны өчен хезмәт итүләре алда әле.

Караңгы төшкәндә, хан тирмәсе янына утызлап дружиначыдан торган рус кенәзе гаскәриләре килеп туктады. Атлары күбеккә баткан, үзләренең өсте-башы кан. Русларның берсе хан тирмәсенә керергә рөхсәт сорады. Ханның тәнсакчылары шунда ук аның бөтен коралларын җыеп алды. Ләкин үзен Василий дип таныштырган рус егете кулындагы капчыкны бирүдән баш тартты, әлеге әйбер бары тик Туктай күзләре өчен генә дип аңлатты.

Ике учак арасыннан уздырып «чистарткач», Василийны тирмәгә үткәрделәр. Ул Урда ханы алдында тез чүкте, аннан тылмач аша бер әйбер күрсәтергә рөхсәт сорады. Күрсәтсен, дип ымлады Туктай. Дружиначы тураеп басты, йөзенә шатлыклы елмаю чыкты. Яше егермегә дә җитмәгән егет иде ул. Капчыктан горур кыяфәттә кеше башын тартып чыгарды.

Туктай, урыныннан сикереп торып, Василий янына килеп басты. Капчыктагы баш – сыңар күзле данлыклы яугир Ногайныкы иде.

– Бөек хан, мин сиңа дошманыңның башын алып килдем, – диде Василий.

– Минем дошманым икәнлеген кайдан беләүл? – дип сорады Туктай тылмачтан. Тегесе тәрҗемә иткәч, егет әзерлек белән тәмләп сөйләргә кереште.

– Без, аларның гаскәрләре таралашып качкач, бер төркемне куа киттек. Алар арасындагы иң олы яшьтәге кеше, кинәт аты абынып, җиргә мәтәлде. Килеп җиткәч тә, ул, үзен Ногай, ханның бәкләр-бәге булуын әйтә-әйтә, үтермәгез дип ялвара башлады. Безгә күп байлыклар, алтыннар вәгъдә итте. Аның телен тыяр өчен мин башын кисеп, сиңа алып килдем, бөек хан.

Төрле халыклар арасында йөреп, Ногайның теле чарланып беткән иде, русчаны да азмы-күпме сукалый, шуңа егетнең сөйләгәннәрендә хакыйкать бар кебек. Туктай янә Василийның кулындагы бәкләр-бәге башына күз салды. Сыңар күзе, тормыштагы төсле үк акаеп калган. Ул Туктайга текәлгән. Карашы, әйтерсең лә, тезләнеп ялварган кешенеке төсле. Күпме ялварсаң да, Туктай сине коткара алмый инде, даланың данлыклы бүресе Ногай...

Хан күз ачып йомганчы кынысыннан кылычын тартып чыгарды һәм авызын ачып торган Василийның башын кисеп ташлады. Егетнең башы бер читкә тәгәрәп китте, муеныннан шаулап кан бәреп чыкты. Аның тәне әле беравык, берни аңламагандай, чайкалып торды да, җиргә гөрселдәде. Ногайның башы икенче якка тәгәрәде.

Баштанаяк рус гаскәрие канында коенган Туктай кылычын кире кынысына тыкты. Аннан соң тирмәдәге бәкләрне усал караш белән айкап чыкты.

– Хакимне бары тик хаким генә үтерә ала, – диде ул, ниһаять, бераз тынычланып. – Минем дошманым булса да, Ногай үз олысының чын хуҗасы, данлыклы төмәнбашы иде. Мәетен табып алып, хатыннарына илтеп тапшырыгыз, Ногай белән бәхилләшкәндә, ул табынган мөселман дине кануннарын үтәсеннәр. Гаскәрне таратырга әзерләгез, мин үзем Сарайга кузгалам.

1300 елны Ногайның йөрәге тибүдән туктады. Аның белән бергә гүя Ногай олысы да үлде сыман. Туктай Ногайның балаларына әтиләре җирендә хакимлек итәргә ризалык бирсә дә, Җәкедән дә, Тәкедән дә рәт чыкмады. Алар әле үзара, әле бәкләр белән тарткалашып, аталары җыйган хөрлекне тиз арада таратып бетерделәр. Урданың көнбатышында аерым дәүләт дәрәҗәсенә күтәрелергә җитлеккән олыс комсызлык корбанына әйләнеп, озакламый дөнья йөзеннән бөтенләй дә юкка чыкты. Шул ук елны Урда өстенә афәт булып, коточкыч корылык килде. Ханнар багучысы Багаууган моны Мәңге Күк Тәңренең казасы дип аңлатты. Мәңге Күк Тәңре Сарайга ачулы, диде. Бәлки, Ногайның җанын кыйган өчендер? Анысын багучы тәгаен генә әйтеп бирә алмады.

Ногай мәрхүм булу белән Урдада яшәүче бик күп бәкләр һәм әмирләр җиңел сулап куйды. Дәүләт эшләренә читтән торып та тыкшынучы, ханнар белән бәхәсләшә алырлык дәрәҗәдә киребеткән кешедән арынгач, вак-төяк әмирләргә юл ачылды. Аларның берсендә дә Ногайдагы колач, киләчәкне алдан күреп эш итү сәләте юк иде, әлбәттә. Әгәр Ногай гади генә бер чүп кеше булса, ул Урда тарихына ханнар белән беррәттән кереп тә кала алмас иде...

## ИКЕНЧЕ БҮЛЕК

Үзбәк белән Исабәк атларын Сарайга таба чаптырдылар. Авыр йөкләр, Нәзифә белән улы Тимербәк, җарияләр, хезмәтчеләре төялгән арбалар артта калды, ике җайдакны йөзләп ышанычлы нүкәрдән торган хәрби төркем генә озата китте.

Сарайга егермеләп чакрым кала, аларны Туктайның яраннары каршылады. Шәһәр эченнән юл күрсәтеп, ханзадә Үзбәкне төп утарга алып килделәр. Биредә аңа аерым бүлмәләр әзерләнгән иде. Озын юлдан ял итәр өчен барлык мөмкинлекләр дә тудырылган, ризык мулдан. Дистә ел буе чит илләрдә йөргән ханзадә өчен бу җәннәт төсле тоелды. Ләкин үзен чикләүгә ул күнеккән инде, шуңа күрә бавырчыларны тыйнаклыгы белән шаккатырды.

Ханзадәнең тагын бер үзенчәлеген сарайдагылар сәерсенеп кабул итте – ул көн саен берәр китап укымыйча калмый, озаклап уйланып утыра, башкалар төсле җай чыгу белән атына атланып чабарга атлыгып тормый.

Туктай хан аны озак кына кабул итмәде. Түземлеге бетә башлаган Үзбәк Исабәкне чакыртып китерде.

– Исабәк дустым, нигә шушы көнгә кадәр Туктай хан мине каршыларга вакыт таба алмый, биредә берәр төрле мәкер юкмы икән?

– Бернинди дә мәкер юк дип беләм, сөекле ханзадәм. Ханның башы әлегә бүтән мәсьәләләр белән әйләнгән. Белүемчә, Ногай җирләрендә тынычлык юк, аның балаларына Туктай хан олыс белән идарә итү мөмкинлеге бирсә дә, тегеләре үзара сугышып беткәннәр. Ханлыкның көнбатыш чикләрен куркыныч астына куярга ярамый, шуңа күрә аның игътибары әлегә ул тарафларда. Миңа әйтүләренчә, Кавказ таулары тарафында да болганчык хәлләр, Хулагу илханнары дәүләте Урдага тынгылык бирми. Шуңа күрә мондый тоткарлык бары тик хакимнең дәүләт эшләренә баштанаяк чумуы белән генә аңлатыла...

– Минем әлегә кадәр әнием Әрибах хатынны да күрә алганым юк...

– Ханзадә, зинһар, сабыр итегез. Бөек хан кабул итми торып, аның хатыннары янына барып керү зур ялгышлык булачак. Моның өчен башны да салырга мөмкин. Күпкә түзгәнне азга гына түзик.

Исабәкнең акыллы киңәше Үзбәкнең ут эчендә бәргәләнгән җанын тынычландырмады, әлбәттә. Биредәге бар нәрсә дә аның сулышын буа иде. Тар бүлмәләр, купшы булса да, күңелен кайтара. Мул ризык, татлы тоелса да, тамагыннан үтми. Хан белән түгел, әтисенең җанын кыйган кеше белән очрашу көтә бит аны. Әнисенең хәзер шул хаин белән бер ятакта йоклавы гына Үзбәкнең үзен үлемнән саклап кала алырмы икән?!

Ниһаять, Туктай Үзбәкне кабул итү өчен вакыт тапты. Чит җирләрдә йөреп җыйган кайбер байлыкларыннан ханзадә иң матур бизәкле кылычны сайлап алды, аның янына тау җанварлары тиресен эшкәртеп ясалган матур бүрекне өстәде, тагын берничә күз явын алырлык бизәнү әйберләре куйды. Үзе тыйнак, ләкин килешле итеп киенде. Җыйнак сакал-мыегын ияк астыннан тар гына тасма калдырып кыскартып кырды.

Ханның иркен бүлмәсе бусагасыннан атлап керү белән Үзбәк, бүләкләрен алга сузылган ике кулында тоткан көе, башын иеп, карашын аяк астындагы келәмнәргә төбәп, Туктай тарафына атлады, аннан тез чүкте.

– Бөек ханым, синең мескен колың, дөнья читләрен гизеп адашып йөргәннән соң янә хозурыңа әйләнеп кайтты, – диде ул.

Хан, тәхетеннән төшеп, Үзбәк янына килде. Ханзадә тез чүккән көе бүләкләрен ике кулында югарырак күтәреп тора бирде. Туктай озаклап, һәрбер әйберне тикшерде, кылычның үткенлеген бармагы белән сынады, аннан соң яраннарына ымлады. Тегеләре, шунда ук йөгереп килеп, Үзбәкнең бүләкләрен алып, күздән юк булдылар. Аннан соң Туктай ике куллап, Үзбәккә торып басарга булышты.

– Бөек хан синең бүләкләреңне олы рәхмәт хисе белән кабул итеп алды, – диде ул.

Егет карашын ханга күтәрде. Алар күзгә-күз очраштылар. Үзбәкнең куркуы сизелеп тора, ә менә Туктай исә көлемсерәп әйтеп куйды:

– Урда үзенең адашкан углын күрүгә чиксез шат, Үзбәк ханзадә.

Туктай, борылып, тәхетенә таба китте. Ул арада Үзбәк бүлмәдәгеләрне күздән кичерде. Ханның уң ягында ул иң элек әнисе Әрибахны күреп алды. Тегесе шатлыклы елмаю аша күз яшьләрен сөртә иде. Үзбәк чак кына сизелерлек итеп башын какты. Таныш йөзләр арасында Баялун хатын да бар. Аның тораташтай йөзендә егет бернинди хис тә таба алмады. Кайчандыр үзен тәрбияләгән хатын Үзбәккә текәлеп караган, әйтерсең,

ул аны бораулап тишеп өйрәнә, тик бу караштa җылылык та, шатлык та юк сыман.

Ханның аяк очында балалары тезелешеп утырган. Як-якта вәзир, бәкләр-бәкләре, әмирләр урын алган. Алар барысы да Үзбәккә моңарчы күрмәгән җан иясен очраткан төсле зур кызыксыну белән текәлгәннәр.

Туктай хан, тәхетенә менеп кунаклагач та, егеткә үзенең сул кул тарафындагы буш урынны күрсәтте. Егет шунда барып утырды.

Акрынлап тирмәгә бавырчылар кереп тулды. Алар һәрбер кунак каршына кечкенә өстәлләр куеп, майлы ит кисәкләрен туракларга кереште. Аннан соң думбрачылар, биючеләр дә пәйда булды. Хан, үз куллары белән касәгә шәраб салып, аны Үзбәккә сузды. Егет, башын түбән иеп, әлеге касәне кабул итте.

Кич буе Туктай Үзбәктән кай тарафларда булганнарын, ниләр күргәннәрен сораштырды. Кавказ аръягы турында аеруча төпченеп сорады. Күрәсең, чыннан да, андагы тотрыксызлык ханның үзәгенә үткән иде. Үзбәк үзенә бирелгән сорауларга кыска итеп җавап бирергә тырышты. Хакимнән артык сөйләргә ярамаганлыгын, үтә дә акыллы булуның хәерлегә илтмәвен ул яхшы аңлый. Ханга бары тик ул ишетергә теләгән җавапларны гына бирде.

– Мин дөньяның бер кыйтгасында гына булдым, бөек ханым, – диде Үзбәк, хан кулыннан чираттагы касәне алганнан соң. – Ләкин, кая барсам да, анда бөек ханыбыз Туктай исеменнән дер калтырап торалар, сине аеруча ихтирам белән искә алалар.

– Алай икән, – диде Туктай, хәмердән һәм мактаудан исерә төшеп. – Тормышлары ничегрәк?

– Бездәгедән күпкә начар, бөек ханым. Безнең халык асраган мал-туар исәпсез, аларда исә ярым ач, ялангач хәлдә яшәп яталар...

– Анысы ник тагын? Ул якларда безгә караганда күпкә җылырак түгелме? Кышын кар да яумый бит аларда? – Туктай, син мине алдыйсыңмы әллә, дигән кыяфәт белән кашларын җыерды.

– Эш бит һава торышында түгел, бөек ханым. Синең гадел идарә итүең бәрабәренә безнең халыкның тамагы тук. Ә анда кешеләрне изеп, талап яшәү гадәткә кергән.

Туктайның янә авызы ерылды. Үзбәк исә ханны мактаудан, кирәк булса ялганны да кызганмый кыстырып, аның җанына май ягып торудан туктамады. Ханның тәмам йомшавын тоеп алган хатыннары да җанланды. Әрибах, иренең колагына нидер пышылдап, гозерен әйтте.

– Минем яраткан хатыным Әрибах, синең әниең, иртәгә сине үзенең тарафына чакыра. Сагынышкансыздыр, күрешеп сөйләшегез, – диде Туктай, бер кулы белән Әрибахның биленнән кочып алып.

– Рәхмәт сиңа, бөек ханым!

– Сөекле ханым, ханзадә белән миңа да очрашырга рөхсәт итсәң иде, – дип сүзгә кушылды Баялун хатын. – Мин аны бишектә тирбәтеп үстергән кеше бит.

Туктай олы хатынга күзләренең агы белән генә карап алды да каршы килмәвен әйтте.

– Хатыннар белән эшең беткәч, ауга чыгарбыз, ханзадә. Минем улларым белән дә танышырсың. Әзерләнә тор!

Мәҗлес әле бик озак дәвам итте. Ул арада Үзбәк бирегә җыелганнарны дикъкать белән күзәтте. Ханның кече улы Илбасмыш, әле бик яшь булуына карамастан, еракtан кайткан кунакка нәфрәт белән карый. Олы улы Түкәл-Буганың карашы җылырак күренә, гәрчә йөзе кырыс булса да. Түкәл-Буга акылдан күбрәк беләк көченә ышанган ваемсыз бәндәгә охшаган. Мөддәбире[12] Кадак та Үзбәккә очлы карашларын ташлый. Диван әһелләренең дә йөзендә бернинди дустанәлек юк, кинәт юктан бар булган ханзадәгә берсенең дә куанычы күренми. Тәхет тирәсе болай да кысан, анда Туктайга якын торган тагын бер кеше барлыкка килү беркемне дә куандырмады. Алар, яшереп тә тормыйча, Үзбәкне үзләренә тиешле калҗаны ашарга килгән бүре итеп кенә кабул итәләр...

Икенче көнне Үзбәк әнисе Әрибах янына китте. Әрибах хатын аны бәйрәмчә киенеп каршы алды. Бусагадан атлап керү белән ханзадә тез чүкте. Әрибах хатын моны көтмәгән иде, каушап калды, аннан йөгереп килеп, улын торгызып бастырырга ашыкты.

– Ни эшләвең бу, улым, ханзадә бары тик хан алдында гына тез чүгә, – диде ул, кеше-кара күрмиме икән дип, як-ягына каранып.

– Әниләр ханнардан өстенрәк, сөекле анам!

– Анысын кайдан ишеттең тагын?!

– Мөселманнарның Коръән китабында шулай язылган.

Анасы, ни әйтергә дә белми, улын табынга чакырды. Аларга җиләк-җимеш, ширбәт китерделәр. Бераз аңышкач, Әрибах та улын сораштыра башлады, аның тормышы белән кызыксынды.

– Хатының белән минем сөекле оныгым Тимербәк кайчан кайтып җитәчәк? – дип сорады Әрибах хатын, сөйләшә-сөйләшә ике арадагы салкынлык эри төшкәч. Озак еллар күрешмәү барыбер үзенекен итә, якын кешеләр төсле гәпләшү беренче шәпкә үк барып чыкмады.

– Алар бирелән берничә көнлек юлда, Тимербәк бик кечкенә, шуңа күрә арбаларны каты куып булмый.

– Бәхетле бала була күрсен, синең башыңа төшкән бәлаләр аны уратып үтсен иде...

Үзбәк берара уйланып торды. Аннан соң, әнисенә ышанырга мөмкин дигән карарга килеп, үз фикерен җиткерде:

– Минем тирәдә теш кайраучылар күплеген сизенәм. Бер башымны коткару берни түгел, атка атландың да далага чаптың. Хатын, гаилә, балалар белән исә син бәйләп куелган дигән сүз...

Әрибах хатынның йөзеннән елмаюы качты.

– Анысы хак, улым... Дошманнар күп, һәм алар үзләре утырган урынны саклап калу өчен теләсә нинди мәкергә әзер. Бик сак кылан, мактанма, масайма, күренмәскә тырыш. Көчең, осталыгың белән шапырынма, көнчелеккә урын куйма. Мин дәүләт эчендәге мәсьәләләрдән ерак кеше. Синең әле Баялун хатын белән дә очрашасың бар. Ул һәрвакыт та минем киңәшчем, ярдәмчем булды. Аңа ышана аласың. Баялун хатын хан тирәлегендә үзеңне ничек тотарга кирәклеген аңлатыр. – Әрибах хатын көрсенеп куйды. – Тәхет тирәсендәге уйнашлар синең әтиеңең башына җитте бит инде. Безнең гаиләдән ике корбан артык күп булыр... Тукта,

[12] Мөддәбир – Урда ханының беренче ярдәмчесе, баш вәзир дәрәҗәсендәге кеше.

ник моңаеп утырабыз соң әле?! Сине сеңлең Көнчәага көтеп тора бит! Ул инде буй җитте, кайчан ханзадә кайта дип тинтерәтеп бетерде. Үзе сине хәтерләми дә, безнең сөйләгәннән генә белә. Тик үзен яклардай абыйсы барлыгына нык шатланды!

Һәм Әрибах хатын, дөньясын онытып, кечкенә кызын чакырырга ашыкты.

**2**

Үзбәк ханзадә әнисе белән сөйләшкән мәлдә хан үз тирмәсендә бәкләрне һәм әмирләрне кабул итәргә утырган иде. Аңа бер-бер артлы рус җирләрендәге хәлләр турында сөйләделәр, теге яки бу мәсьәләнең язмышы турында сораштырдылар. Тик Туктайның аларда гаме юк иде. Йокымсыраган килеш ул яраннарының сүзен дәшми генә тыңлады, кирәк чакта бер-ике сүз кыстыргалап куйды. Кичәге мәҗлестән чатнап авырткан башына түзәрлек түгел, җитмәсә болары да кигәвен сыман сырып алганнар. Тәмам алҗыгач, хан янәшәсендәге мөдәббиренә иелеп: «Куып чыгар боларны», – дип пышылдады.

Хакименең сүзен ишетү белән Кадак урыныннан сикереп торып, диван әһелләренә тирмәне бушатырга боерды. Бәкләр һәм әмирләр, арт саннары белән ишеккә борылып, башларын игән көе чыгып таю ягын карады.

– Кәефең юк, бөек ханым, – диде Кадак, алар икәүдән-икәү калгач.

– Аның бае кичә кәефем әйбәт иде. – Хан башын тотып карады да шыбырдап аккан тирен сөртеп куйды. – Бар, әйт, шәраб китерсеннәр!

– Алай ашыкма әле, ханым, хәмерле башта аек уйлар булмый...

– Син өйрәтерсең мине тагын!

– Бер генә сүзем бар, сөекле ханым, мине тыңларга вакыт тапсаң, синең өчен дә, нәселең өчен дә файдасы булыр дип уйлыйм...

Әле генә дуларга әзер торган хан шып булып Кадакка текәлде.

– Тагын фетнәме?!

– Юк, сөекле ханым, бернинди фетнә дә юк. – Кадак сүзләрен мөмкин кадәр йомшаграк әйтергә тырыша, бер ялгышлык ычкындырсаң, башыңны да югалтырга мөмкин. – Үзбәк ханзадә кайту белән синең яраннарың арасында тынычлык бетте. Тәхеткә варис итеп билгеләнгән Илбасмыш та нык борчыла. Үзбәк шактый үскән, ныгыган. Син аны теге вакытта исән калдырып, дөрес эшләдеңме икән? Бик күп бәкләр миңа шул сорау белән мөрәҗәгать итә.

– Китап кортыннан нинди зыян килсен? Мин аның тарафыннан үземә карата бернинди куркыныч та сизмәдем.

– Синең игътибарың Әрибах хатынга карата мәхәббәт хисләреннән торган пәрдә белән капланган. Бөек хан, син зур тырышлык белән яулап алган үрләр шул маңка малайга калмасмы? Минемчә, без куеныбызга елан елыштырдык...

Туктай башы авыртуын да онытты, аның яман ачуы кабарды. Тәхет тирәсендәгеләрнең бер-берсенә каршы котыртулары, гайбәт ташулары аны һәрвакыт чыгырыннан чыгара иде. Бигрәк тә ул гайбәтләр ир-атлар авызыннан яңгыраганда.

– Урыныңны бел, мөддәбир Кадак! – дип кычкырды Туктай хан,

билендәге кылычына ябышып. Моны көтмәгән Кадакның ябык битендә елмаюы чалшаеп катып калды, ул шунда ук, тиешле чикне узганлыгын аңлап, билен бөгеп, ишеккә таба арты белән атлады. – Мине туганнарыма каршы тагын бер тапкыр котыртсаң, башыңны колгага менгезеп, бөтен Урда буйлап әйләндереп йөртәчәкмен! Синең ише бер тинтәк бар иде инде, Ногай исемле. Аның аркасында кулымдагы канны юып бетерә алганым юк. Хәзер син аның урынына калдыңмы?! Минем хатыным Әрибах исән чакта Үзбәкнең башыннан бер генә чәч бөртеге дә төшмәячәк, аңладыңмы, сасы көзән?!

– Аңладым, бөек ханым, аңладым!

Хан, усаллыктан шартларга җитешеп, тагын беравык Кадакка карап торды да, тынычланып, яртылаш тартып чыгарган кылычын кире кынысына тыкты.

– Күземнән югал, ябалак шәүләсе! Берәрсенә әйт, миңа шәраб китерсеннәр, русныкын!

– Баш өсте, бөек ханым, баш өсте...

Кадак бусагада юк булгач та, Туктай янә авыр уйларга батты. Мөддәбире, үзе дә аңламастан, авырткан сөяленә басты бит. Үзбәкне кайтарырга рөхсәт иткәч тә, ул уйлар аны бер генә мизгелгә дә калдырмый. Йокысы качты, хәрәменнән хатыннарын һәм җарияләрен чакыртмас булды. Тогърулҗа улын Сарайга китертү Туктайның үз башына үзе сорап алган әҗәлгә әйләнмәсме? Туктай – Тогърулҗаны үтергән бәндә. Үзбәк моны яхшы белә. Ярый, яшь ханзадәнең күңелендә кара уйлар юк диик. Ул кичә бик ачык күренде, ханына үч сакламый шикелле. Ләкин Урданың үзендә күпме бәкләр һәм әмирләр бар, алар арасында Туктайны бәреп төшерергә хыялланучылар да җитәрлек. Кан буенча Үзбәк тәхеткә утырырга тулысынча хаклы. Ханзадә яман кешеләр котыртуына бирешмәсме? Әйе, Туктай, алай-болай була калса дип, улы Илбасмышны варислыкка рәсми рәвештә раслады. Тик Урданың үз кануннары. Анда әле игълан гына җитми, шайтан алгыры, аксөякләр ханны яклап, тавыш бирергә дә тиеш. Шул ук вакытта Туктай Үзбәкне үтертә дә алмый, чөнки Әрибах хатынга улына тимәскә ант эчте. Ханнар әйтелгән сүзенә соңгы сулышка кадәр тугры кала. Багаууган багучыны да чакыртып сорады Туктай. Багучы Үзбәк тарафыннан бернинди дә куркыныч янамавын әйтте. Хатын-кыздан сак булырга кушты. Тик кайсысыннан? Монысын багучы әйтеп бирә алмады...

**3**

Баялун хатын Үзбәк килгән төшкә табыннар әзерләмәгән иде, шактый коры каршылады. Хәер, балачакта да ул аңа артык йомшаклык күрсәтмәде, киресенчә, үтә дә таләпчән булды. Бәлки, Баялун хатынның шундый тәрбиясе ханзадәгә күпсанлы авырлыкларны җиңеп чыгарга ярдәм иткәндер дә.

– Үзеңне хан каршында бик дөрес тоттың, ханзадә, – диде Баялун хатын, егет белән исәнләшеп, аның бүләкләрен кабул итеп алгач та. – Алга таба да шушы рәвешне югалтма. Бәхет көтә белгәннәрне ярата, синең дә вакытың җитәр, тик ашыкма гына.

– Тел төбеңне аңлыйм, хөрмәтле Баялун хатын. Кичәге мәҗлестә карашлары белән мине өзгәләп ташларга ашкынып торучылар шактый иде...

– Янәшәңдә бары тик ышанычлы кешеләрне генә тот, теләсә кемне якын җибәрмә. Гаепсезләр канын койган, көчсезләрнең күз яшен агызган мөртәтләр һичшиксез җәзасын алыр.

– Синең кебек терәгем булганда, моңа шигем юк, хөрмәтле Баялун хатын!

Бу сүзләр хәтта таш йөрәкле Баялунны да йомшатты. Ул күз читеннән ирексездән бәреп чыккан яшен сөртеп куйды.

– Бергә булсак, безгә беркем дә куркыныч түгел. Минем сүземне тыңласаң, уңышка ирешерсең. Сиңа усаллык белән генә түгел, өмет белән караучылар да җитәрлек, мин алар белән һәрвакыт көрешеп торам. Хәзер бар, ял ит. Иртәгә сиңа хан белән ауга чыгасы. Ауда да үзеңне дөрес тотарсың, ялгышлыклар җибәрмәссең дип өметләнәм.

– Яхшы, Баялун хатын...

Үзбәк киткәч тә, хезмәтче кызларының берсе Баялун хатын янына тагын бер кеше килүен хәбәр итте.

– Исемен әйтми, яшерә. Ничек кенә сорап карамадым, булмады, ханбикә мине белә, күргәч тә таныр диде... – Хезмәтче еламсырап аңлаткач, Баялун хатын теге бәндәне үзенә чакырырга боерды.

Ишектә кап-карадан киенгән кеше пәйда булды. Ул бик йомшак адымнар белән атлый, аны ишетү түгел, тоемлап та булмый шикелле, гүя бер шәүлә генә. Баялун хатын тегенең кулларына игътибар итте. Ук, кылыч тотудан сөялләнеп чыккан урыннарын күрде. Аның каршысында, һичшиксез, күп сугышлар үткән яугир басып торуын аңлады.

– Син кем буласың, мин сине белмим, – диде Баялун, чакырылмаган кунак үзеннән шактый ерак арада башын иеп, сындай катып калгач.

Бәндә, башын чак кына күтәреп, кара күзләрен ялтыратты.

– Чиксез ихтирамлы ханбикә Баялун хатын! Син мине белмисең, әмма мин синең хакта бик күп яхшы сүзләр ишеткән кеше. Синең акылың, зирәклегең хакында дастаннар язып булыр иде...

– Артык баллыны яратмыйм, соравыма җавап бир!

– Минем исемем – Кара. Мин...

– ...мәрхүм Ногайның тәнсакчысы, – дип, тегенең җөмләсен тәмамлады Баялун хатын. Аның тавышына гаҗәпләнү катыш курку чыккан иде, әле генә булган горур халәтенең эзе дә калмады. Баялун хатынның хәтта куллары калтырана башлады.

– Әйе, ихтирамлы ханбикәм, – дип, берни булмагандай, элеккечә төссез тавыш белән дәвам итте Кара. – Хезмәтчеңә син мине танырсың дип әйткәндә, ялгышмадым. Таныдың.

– Синең кара даның минекеннән дә ераккарак таралган шул... Мине үтерергә килдеңме?

Кара үпкәләмәде дә, гаҗәпләнмәде дә. Башын чак кына игән көе ханбикәгә карап тора бирде.

– Юк, ихтирамлы ханбикәм. Мин синнән ярдәм сорап килдем.

– Нинди ярдәм?

– Миңа үч алырга булыш.

– Кемнән? Туктайданмы?

Кара җавап бирмәде. Баялун хатын исә тиле сорау биргәнлегенә оялып куйды.

– Ногай миңа дошман иде бит, син моны беләсеңме соң?

– Әлбәттә, ихтирамлы ханбикәм.

– Шулай булгач, ник миңа килдең?

Кара янә сорауны җавапсыз калдырды.

– Син үзең сакларга тиешле Ногайны үтерүгә юл куйган кеше бит, Кара. Нигә син аның гомерен өзәргә ирек бирдең?

– Бәкләр-бәге мине үзенең улы Җәке белән җибәрде. Аны сакларга кушты.

– Ник Җәкегә хезмәт итеп, хуҗаңның башын кискән кешеләрдән үч алмыйсың? Ник миңа килдең?

– Бәкләр-бәге Ногайның уллары көчсез һәм холыксыз, ихтирамлы ханбикәм. Аларда әтиләре истәлеге кайгысы юк, уйларында мал бүлешү генә. Үзара талашып, сугышып беттеләр. Мин гомер буе Ногайга хезмәт иттем, хәзер миңа үземә тиң хуҗа кирәк. Һәм мин ул хуҗага ихлас күңелдән бирелеп, кушылганның барысын да үтәргә әзер.

Баялун хатын янә уйга калды. Туры килүен әйт әле син! Башта Үзбәк кайтып төште, аның артыннан Ногайның тәнсакчысы килеп керә. Кара начар кешегә охшамаган. Гомере буе кеше үтереп йөреп каешлангандыр анысы, тик ул, чыннан да, хуҗасына эт шикелле тугры булды. Урданың үзендә аның төсле оста шымчы, җан кыючы юктыр. Беркайчан да кеше арасында буталмый, аның йөзен күрүчеләр дә сирәк. Дөрес булса, чыраен күрсә, шул Ногай күргән, диләр, Кара һәрвакыт битен, күзләре генә күренеп торырлык итеп, кара чүпрәк белән урап йөргән. Мондый тәҗрибәле сугышчы Үзбәк өчен бик кыйммәтле иңдәш булыр иде.

– Ничә кешең бар? – дип сорады Баялун хатын.

– Минем белән без утызау.

– Кайда тукталдыгыз?

– Моннан егерме чакрым арасы.

– Ике көннән килерсең, мин сиңа карарымны җиткерермен.

Кара сүзсез генә уң кулын күкрәгенә куеп, башын иде һәм шәүлә төсле юк булды. Ул киткәч тә, тирмәдә әле бик озак курку һәм үлем исе эленеп торды төсле. Баялун хатын, әле генә булган очрашуны аңларга тырышып, арлы-бирле йөренергә кереште. Мөгаен, аның каршында бая гына басып торган бәндә тавыш-тынсыз гына кереп, Җиҗәк хатынны да буып ташлагандыр. Җиҗәк хатын, Туктай хакимлеккә килгәч тә, Ногай алдады дип кычкырып йөрде бит. Тәмам акылыннан шашты, базарга чыгып ук Ногайга ләгънәтләр укый иде. Аннан соң аның җансыз гәүдәсен тирмәсендә табып алдылар. Аны Мәңге Күк Тәңре янына шушы ук Кара озатмаганмы?! Күпме кешенең башына җиткәнлеген кем әйтә ала?!

Баялун хатынны уйларыннан аерып, бүлмәдә ханның шәхси бавырчысы Тугал пәйда булды.

– Гафу итәрсез, бөек ханбикә, кисәтмичә килдем, – диде ул, тез чүгеп.

– Син тагын ни эш кырып йөрисең биредә?

– Хәбәрем бар сиңа, бөек ханбикә.

– Булса сөйлә, вакытым тар! – Ханбикә Тугал янына ук килде, аны тез чүккән җирдән торгызды. Бавырчыны ул инде күптән хан янында үзенең колаклары һәм күзләре иткән иде. Баялун хатын шымчыларга акчасын кызганмады, Тугал исә аларның иң күп белгәне, Туктайга иң якыны. Бавырчы ханны ашата, аның колагы хәтта мөддәбиргә мәгълүм булмаганны

дә ишетә. Тугал беркайчан да буш сүз белән йөрмәс, чөнки бу тирмәгә еш чабуын күрсәләр, башын кисеп ташларга да күп сорамаслар.

– Бүген хан киңәшчеләрен куып чыгаргач, Кадак белән икәүдән-икәү калдылар, – дип пышылдады Тугал. – Кадак мөддәбир ханны Үзбәк ханзадәгә каршы котырта башлады. Яшьли үтермичә ялгыштык, ди.

– Ә хан ни диде? – Бер көн эчендә бу кадәр вакыйга хәтта сарай тарткалашларына күнеккән Баялун хатын өчен дә күпкәрәк китте.

– Хан Кадак мөддәбиргә җикеренде, чак кына кылычын тартып чыгармады. Әрибах исән чакта Үзбәккә кагылмаячагын әйтте.

– Шуннан?!

– Ханнан чыккач, Кадак мөддәбир үз-үзенә: «Алайса Әрибахтан башларга кирәк», – диде дә китеп барды. Миңа бөек ханыбызны сыйлыйсы бар иде, аның артыннан иярә алмадым.

Баялун хатын ишетелгәннән куырылып килде.

– Ә хан аннан соң үзен ничек тотты?

– Бик озак уйланып утырды, күп шәраб эчте. Хәзер йоклый.

Баялун хатын янә тынычланды. Каушап, куркып калуын бавырчыга күрсәтергә ярамый иде. Ул, ашыкмый гына сандыгы янына барып, аннан алдан әзерләп куелган төенчекне алды һәм Тугалга ташлады. Тугал һавада әйләнеп очкан төенчекне күнегелгән хәрәкәт белән ике куллап тотып алды, янә тез чүкте.

– Бер генә сүзең дә файдалы түгел, юк-бар гайбәт өчен акча туздырып ятам! Югал күземнән!

Бавырчы, ханбикәгә арты белән борылмый гына, ишеккә юнәлде. Баялунның андый сүзләренә күнеккән, шуңа шелтәсенә игътибар итмәде. Файдасы булмаса, шулай уч тутырып түләмәс иде ханбикә...

Баялун хатын, ашык-пошык җыенып, хезмәтчеләре озатуында Әрибах тирмәсенә йөгерде. Кергәч тә, андагы кыз-кыркынга тиз арада чыгып китәргә боерды. Әрибах борчуга калды – Баялун хатынның йөзеннән үк ниндидер афәт килүе тоемланды.

– Ни булды, Баялун хатын?!

– Әлегә берни дә булмады. Ләкин булырга тора. – Әрибахка үзе белгәннәрне сөйләгәч, олы ханбикә янә әмер бирү рәвешендәге мөрәҗәгатькә күчте. – Кадак – хәзер безнең җан дошманыбыз. Мин сөйләгәннәрне ханга әйтә күрмә, ләкин атлаган саен мөддәбирне яманла. Алай карамады, болай дәшмәде, сүзне тыңламады, диген. Кыскасы, көн саен тамчылап тамызып торырга кирәк. Үзең дә сак бул, явыз Кадак сиңа да зыян салырга мөмкин!

– Туктай ханның ике атналап мине чакырганы юк, бәлки, үземә аның янына барыргадыр?!

– Бүген йөри күрмә. Ул исерек, җитмәсә, Кадак та ачуын чыгарган. Аудан кайткач, менә дигән мөмкинлек туачак.

## 4

Туктай хан ауга зур әзерлек белән чыкты. Барлыгы йөзгә якын мәргән җыелды. Ханның янәшәсендә бер яктан Кадак мөддәбир барса, икенче яктан уллары Түкәл-Буга һәм Илбасмыш. Шулай ук бирегә бәкләр-бәкләре, тәхет янәшәсенә якын аксөякләр, сәргаскәрләр дә чакырылды. Бу төркемне

кулларына лачыннар тоткан, этләр иярткән кешеләр озата бара. Утызлап арба да кушылган. Аларында бавырчылар, хезмәтчеләр. Мәргәннәр аудан кайткан төшкә алар, стан корып, хуҗаларны табын җәеп көтәргә тиеш.

– Нәрсә, ханзадә, син ауга чыгарга әзерме? – дип, күз кысты Үзбәккә Туктай хан.

– Бөек ханым, синең белән җир читенә барып җитәргә дә ризамын!

Күңеле булган хан янәшәсендәге Кадакка борылды.

– Менә, бөек мөддәбир, ничек сөйләшергә кирәклегенә Үзбәк ханзадәдән өйрәнә аласың!

– Тел белән әйтелгән бер нәрсә, ир башка сыйфатлары белән танылырга тиеш, – диде ачуыннан бүртенеп чыккан Кадак.

– Ауга керешкәч тә, карап карарбыз, – дип елмайды хан һәм мәргәннәргә кузгалырга әмер бирде.

Ул елны Урда җиренә корылык килгән иде, шуңа күрә киек җанварларны табу җиңел эш булып чыкмады, аларны эзләп, Сарайдан дистәләрчә чакрымнарга китәргә туры килде. Озак вакыт йөри торгач, ниһаять, ярдәмчеләр мәргәннәргә хәбәр салды – алар утызлап баштан торган болан көтүенә тап булган.

Җайдаклар күрсәтелгән тарафка юртты. Көтү күренгәч тә, мәргәннәр ярымай рәвешендә таралышып, боланнарны үзенә күрә камалышка алды. Кыргый хайваннар кызу йөгерсә дә, аучыларның ышанычлы атлары да бирешми иде.

Беренче булып, хан уктан атты. Бер дәү болан йөгереп барган җирдән абынып мәтәлеп китте. Мәргәннәр, аны җирдә аунап яткан көе калдырып, ары чаптылар. Икенче боланны Түкәл-Буга екты. Аның йөзендә бер генә кыл да селкенмәде, әйтерсең, ул көн дә кабатлый торган гамәлен бүген дә башкарды. Өченче җәнлекнең сыртына Илбасмыш угы кадалды. Борын асты кипмәгән малайның шатлыгы чиксез иде.

– Тел белән боланны үтереп кара, таулар аръягы кунагы! – дип кычкырды ул Үзбәккә.

Әллә атта тиз юртаклау, әллә ау тәэсир итте, Үзбәкнең саруы кайнап чыкты. Гомумән, аның холкында, ни кызганыч, кызып китүчәнлек бар, ул бу авыр сыйфатын берничек тә авызлыклый алмый.

Күз кырые белән ул Кадакның җәя тартканын күрде, аннан тиз генә үзенекенә ук салды. Берьюлы диярлек ике ук сызгырып чыкты. Ләкин Кадакныкы соңарды. Үзбәк ул төбәгән боланга алданрак тидерде.

– Болан Үзбәк ханзадәнеке! – дип шәрран ярды ерак түгел юртучы Исабәк. Кадакның йөзе кара янып чыкты.

Үзбәкнең бу алымны тагын бер кат кабатлыйсы килсә дә, ул тыелып калды. Теләгенә иреште – аны үртәгән Илбасмыш та тынып калды, Кадакның да борынына чиертте. Ни булса шул булыр, үзен түбәнсетү белән ул һич килешмәячәк.

Аудан соң күчмә станга кайткач, хан аеруча зур осталык күрсәткән яраннарын мактады. Улыннан соң игътибары Үзбәккә күчте.

– Ханзадә, булдырдың! Ә мин сине китаптан ары берни белми дип уйлаган идем, – диде ул, ихлас күңелдән елмаеп.

– Очраклы гына килеп чыкты, минем хөрмәтле Кадак мөддәбирнең

өлешенә кирәсем килмәгән иде, – дип акланды Үзбәк. Бу – үзенә күрә гафу үтенү кебегрәк булса да, ул Кадакның йөзеннән аңлады – тегесе гафуны кабул итеп алмады.

Ауга чыккан башка ир-атлар бу тирәдә сүз куертып тормады, шау-гөр килешеп кичке мәҗлескә әзерләнә башладылар. Боланнарны ярдәмчеләр инде ыстанга алып кайтып, түшкәләрен эшкәртергә өлгергән. Дарга асылган һәрбер түшкә янына килеп, хан аларны тикшереп, бәяләп чыкты.

– Кемнең боланы иң симезе соң? – дип сорады ул хезмәтчеләре башлыгыннан.

– Бөек ханым, иң симезе син еккан болан. Аннан ары Үзбәк ханзадәнеке тора, – диде тегесе.

Туктай хан янә артында басып торган Кадакка борылды:

– Күрдеңме, Кадак, ханзадә синең борын төбеннән майлы калҗаны алган да киткән.

– Ярый ла, сөекле ханыбыз күз төшергән малга кул сузмаган, минеке кызганыч түгел, – диде Кадак, әлеге төртмәле сүзгә, әйтерсең, җавабын алдан әзерләп куйган төсле.

Үзбәккә, моны ишеткәч, янә эсселе-суыклы булып китте. Тәхет тирәсе бик авыр урын икән. Һәрбер сүзеңне үлчәп әйтергә, һәрбер адымыңны уйлап эшләргә кирәк. Кылыч белән булмаса, тел белән егып салырга әзер торучылар бихисап. Берәүләре икенчесен яманлый, ханга ялагайлана, хан моны рәхәтләнеп тыңлый. Авыр дөньяга эләкте ул, биредә бар нәрсә дә агулы, усал, мәрхәмәтсез.

Кичке мәҗлес кара төнгә кадәр дәвам итте. Хан мәргәннәрне туктаусыз хәмер белән сыйлады, төп тирмәдә думбра тавышлары тынып тормады. Кайсыдыр бәк, җаен табып, барлык ирләргә дә җитәрлек җарияләр төяп килгән булып чыкты. Табын чыр-чу, чикләрне белми торган күңел ачу мәйданына әверелде.

Бу тамашадан алҗып, Үзбәк тирмәдән урам якка чыкты. Далага төн иңгән. Нәзек юрган булып ябылган ап-ак кар ай һәм йолдызлар балкышында җемелдәп тора. Бүреләр улый, атлар пошкыра. Ханзадә тирмә янәшәсендә торган арбага менеп утырып, затлы җәнлек тиреләреннән тегелгән тунына төренде. Каршысына хан улы Илбасмыш килеп җиткәнлеген сизми дә калды. Тегесе, яше уннан чак кына узып баручы малай, ике кулын бөерләренә төртеп, Үзбәккә текәлде.

– Нигә барысы да сине ханзадә ди, син минем әтинең улы түгел бит, – диде ул, кереш сүзләргә вакыт әрәм итмичә.

Үзбәк аптырап калды.

– Соң... Миндә дә, синдәге кебек үк, Чыңгыз каны ага... Без икебез дә хан нәселеннән.

– Синең әтиең беркайчан да хан булмаган. – Илбасмыш карга төкереп куйды. – Әтидән соң тәхет миңа калачак, шуңа күрә үз урыныңны белергә өйрән.

– Миңа беркемнең дә урыны кирәкми, яшь ханзадә. Барысы да Мәңге Күк Тәңре кулында.

– Мәңге Күк Тәңре минем әтине сайлап алган, аның үлеменнән соң чират миндә. Синең әтиеңнең билен минем әти сындырган, анысы да Мәңге Күк Тәңре әмере буенча кылынган гамәл!

Бу мизгелдә Үзбәк, сикереп торып, чаманы югалткан маңка малайга нык кына итеп тондырасы иде дә, тыелырга көч тапты. Дәшмәвең хәерлерәк.

– Син хаклы, яшь ханзадә... – дияргә генә калды аңа. – Тик абыең Түкәл-Буганы нишләтерсең, ул синнән олырак бит...

– Түкәл-Бугага арт саны астында – ат, кулында кылыч булса, шуннан артыгы кирәкми. Аның өчен Урданың берәр олысы да күтәрә алмаслык йөк булыр. Исән-сау булсаң, Илбасмыш хан каршында тезләнер вакытларың алда әле. Минем юлны аркылы чыга күрмә, мин сиңа куркак Кадак түгел. Үзеңнең килмешәк икәнлегеңне беркайчан да онытма.

Илбасмыш, кырт итеп борылып, кире Туктай хан тирмәсенә кереп югалды. Үзбәкне рәнҗеш һәм ятимлек тойгысы биләп алды. Шушы да булдымы туган җир?! Шушы да булдымы якыннары һәм туганнары?! Ник бу якка янәдән әйләнеп кайтты соң ул?! Кимсетелеп, мыскыл ителеп яшәү өченме? Аның китаплары, аның белемнәре боларның берсенә дә кирәкми. Көч-куәте бары тик дошман җыюга гына сәбәпче. Бер әнисенең ханга пышылдаган сүзләре генә Үзбәкне үлемнән саклап кала алырмы?!

Уйларына чумып, Үзбәк йокыга китеп бара иде, аны Исабәк аңга китерде.

– Йокларга ярамый, хан сине югалтты, мәҗлестә кәеф-сафа корырга чакыра, – дип, үзе белән тирмәгә дәште.

**5**

Сарайның коллар базары күпсанлы халыкның туктаусыз сөйләшү-кычкырышуыннан гөжли иде. Урдага якын-тирә дәүләтләрдән куып китерелгән мескен бәндәләр арасында кем генә юк! Тәннәренең, чәчләренең, күзләренең төсләре, киемнәре, килеш-килбәтләре җирнең әллә нинди кыйтгаларыннан җыелуына ишарәли. Хуҗалары, акыра-бакыра, тере тауарны һәрьяклап мактый. Менә бу ир-ат эшкә талымсыз, урта яшьләрдәге хатын-кыз – оста тегүче, араларында данлыклы бавырчы, ат караучы, бала тәрбияләүче бар. Кемгә кем хаҗәт – сайлап ал, акчаңны гына түлә!

Әлеге базар уртасында хан йорты тамгасы салынган арба күренгәч, аңа баш иеп, юл бирделәр. Арба өсте ябулы, төрле төстәге тукыма кисәкләре, затлы җәнлекләрнең койрыклары белән бизәлгән. Ул, базарның урта бер җиренә җиткәч туктап калды. Шул мизгелдә үк аны ике дистәгә якын нүкәр уратып алды, каяндыр пәйда булган җарияләр төркеме дә аларга кушылды. Нүкәрләр тирә-юньне күзәтсә, җарияләр, башларын ия төшеп, арба ишеге төбенә тезелештеләр.

Ниһаять, озакка сузылган көттерүдән соң, арбадан Баялун хатын төште. Як-яктагы халыкка борылып та карап тормый, ул ышанычлы нык адымнар белән алга атлады. Нүкәрләр, аңа юл ачып, халыкны кысрыклады, ханбикә артыннан җарияләр иярде.

Сәүдәгәрләр арасыннан берсе, ханбикәне күрү белән, ярдәмчеләренә усал итеп әмер бирде дә симез йөзенә киң елмаю тарттырып, Баялун хатын каршына йөгерде. Берничә адым кала ул тез чүкте һәм башын түбән иде.

– Аяк асларыңдагы җиргә дә тиңләшергә хакы булмаган колың Сәргәлән сине ихлас сәламли, юмартлардан-юмарт ханбикәм Баялун хатын! – диде ул, сүзләрен җырдай сузып.

– Тор, Сәргәлән, әллә кай төшләреңә салкын тимәсен.

Сәргәлән сәүдәгәр торып басты.

– Ни йомыш белән килдең, сөекле ханбикәм?

– Сөекле дип атарга әле ярый син бар... – Ханбикә Сәргәлән сәүдәгәрнең биләмәсен күздән кичерде. – Башкалардан акылы белән аерылып торырлык берәр кечкенә кызың юкмы?

Сәргәлән уйга калды, аннан соң янә йөзе елмаюдан балкыды.

– Акылын белмим, ләкин киребеткән кыз бар, – диде ул, ханбикәнең гозеренә җавап таба алуына шатланып.

Баялун хатын сәүдәгәргә үтергеч караш ташлады.

– Минем кебек киребеткән димәкче буласыңмы?!

– Юк ла инде, сөекле ханбикәм, син нәрсә?! Синең килелекне үз җилкәмдә тоюдан мине Мәңге Күк Тәңре саклап калды... – Сәргәлән, телемне тыя алмадым инде дигән булып, уч төбе белән авызына суккалады да житдиләнде. – Акыллы кызга охшаган. Яхшы тәрбия бирсәң, ут чыгарырдай килен үстерергә мөмкин.

– Кай тарафлардан үзе?

– Рус олысыннан.

– Һөнәрләре бармы?

– Ууу, һөнәрләре бик күп. Акыра, бакыра, сугыша, тибенә, тырнаша һәм менә – тешләшә. – Сүзләренең хаклыгын раслап, Сәргәлән ханбикәгә күптән түгел яраланган бармагын күрсәтте. Ханбикә елмаеп куйды.

– Телеңне тешләсә, әйбәтрәк булыр иде, карт төлке.

– Синең мине кызганып әйтелгән сүзләрең йөрәгемә май булып ятты, сөекле ханбикәм...

– Ярый, телеңә салынып торма, күрсәт шул кызыңны.

Сәргәлән ханбикәне үзе белән ияртеп, коллар тотылган бинага алып керде. Бичара кызчык читлектә бер ялгызы утыра. Арыган, талчыккан, кул-аяклары тырналып беткән, пычранган чәчләре чәбәләнгән. Күзләре генә очкыннар ата-ата җемелдәп тора. Карап торышка ун яшьләр чамасы. Сәүдәгәр белән ханбикә кергәндә, ул эченнән генә ниндидер рус җырын җырлый иде, затлы киемнәр кигән Баялунны күргәч, кисәк кенә тынып калды.

– Күпме тора бу кызың?

Сәргәлән бәясен әйткәч, ханбикә аңа «акылдан шашма» инде дигән караш ташлады. Тегесе шунда ук колның хакын ике тапкырга киметте. Баялун хатын артындагы хезмәтчесенә борылып карамый гына тиешле акчаны санап, сәүдәгәргә бирергә боерды. Үзе исә, елмаеп, читлеккә иелде.

– Исәнме, кызыкай, – диде ул, тавышына үзенә хас булмаган җылылык өстәп. – Синең иза чигүләрең тәмам. Бүгеннән син минем канат астына күчәсең. Сәргәлән сәүдәгәр, ач читлекне!

Читлек ачылу белән Баялун хатын иелгән килеш уң кулын сузды. Кызый башта ни эшләргә дә белмәде, аннан соң сак кына торып басып, ханбикәнең кулына кечкенә учын салды. Алар коллар тотылган зинданнан шулай икәү бергә кулга-кул тотынышып чыгып киттеләр. Тирә-юньгә җыелган халык өчен бик сәер тамаша иде бу. Үтә дә купшы киенгән озын буйлы мәһабәт гәүдәле ханбикә янәшәсендә карлы җиргә ялан аяклары белән сак кына басып баручы, телгәләнеп беткән күлмәк кигән нәни кызчык...

Хансарайга алып кайткач та, Баялун хатын баланы юындырырга, ашатырга, юньле киемнәр бирергә кушты. Чәчләрен ике толымга үреп, ханбикә хозурына килеп басканда, ул инде бөтенләй башка кешегә охшап калды.

– Мин сине тәрбиягә алам, – диде Баялун хатын, кызчык каршына чүмәшеп утырып. Тылмач барысын да тәрҗемә итә торды. – Син минем балам булачаксың. Минем сүзне тыңласаң, тормышыңда барысы да әйбәт булыр. Исемең ничек синең?

– Настя, – диде кызчык, башына ишелеп төшкән көтелмәгән бәхеттән дөньясын онытып.

– Моннан соң синең исемең Тайдула булыр! Исеңдә калдыр – Тай-ду-ла!

Кызчык, куркынып, таныш булмаган сүзне кабатлады да, эченә җыелган хисләргә түзә алмыйча, кычкырып елап җибәрде. Баялун хатын аны күкрәгенә кысты.

– Бер дә борчылма, Тайдула, минем янымда син бернидән дә курыкма, мин синең яклаучың да, саклаучың да...

Баялун хатын, кырыслыгын онытып, рус җирләреннән куып китерелгән ятим кызга кушылып, үзе дә үксеми булдыра алмады...

Тайдуланы ышанычлы тәрбиячеләргә тапшырып, Баялун хатын кызга телне, гореф-гадәтләрне, динне өйрәтергә боерды. Бу очрашу ханбикәне нык тетрәндерде. Ул үзе авыр тормыш узды, аның терәк булырдай кешеләре юк. Бәлки, Тайдуланы Мәңге Күк Тәңре аңа олыгаеп барган көннәрендә юаныч итеп җибәргәндер? Һәрхәлдә, ул баланы җәберләргә ирек бирмәячәк. Тәнендә җаны булганда, җил-давыллардан аралап яшәячәк. Ханнарга тиң килен итеп үстерәчәк.

Хисләнеп китеп, ул тирмәсенә тавыш-тынсыз гына килеп кергән шәүләне абайламый да калды. Күргәч тә, һушы китте, коты алынды. Берничә мизгелдән генә ул тирмә бусагасы янында башын иеп торган шәүләнең Кара икәнлеген абайлады. Киң итеп сулыш алып, бераз тынычлангач, Баялун нүкәргә эндәште.

– Болай кисәтми-нитми йөрсәң, син мине теләмәсәң дә үтерәчәксең, Кара, – диде ул, йөзенә гадәти кырыслык битлеген киеп.

– Гафу ит, ханбикәм, минем сине куркытасым килмәде...

– Синең кул астында күпме кеше диден әле?

– Нәкъ утыз хәнҗәр сиңа хезмәт итәргә әзер, ханбикәм.

– Үзбәк ханзадәне беләсеңме?

– Ишетеп кенә.

– Озакламый сез аның карамагына күчәрсез. Ханзадәнең гомере өчен син башың белән җавап бирәсең, Кара!

– Аңладым, ханбикәм.

– Синең үч алу турындагы гозереңә килгәндә, мин сүз бирәм – андый мөмкинлек чыгу белән барысын да оештырам. Тик минем әмердән узып, берниндәи гамәл дә кыла күрмә. Бәлки, озак көтәргә туры килер, ләкин һәр нәрсәнең үз вакыты.

– Аңладым, ханбикәм.

Баялун хатын, сандыгын ачып, берничә төенчек чыгарды һәм Карага сузды.

– Әлегә алып торыгыз. Сарайда болганып йөрмәгез, артык игътибар җәлеп итмәгез. Иртәгә мин Үзбәк ханзадә белән сөйләшермен, аннан соң сез аның утарына кереп урнашырсыз.

Кара, барысына да төшенүенә ишарәләп, башын иде һәм тирмәдән чыгып, юк булды.

**6**

Нәзифә белән Тимербәк килү, аларны башта хан, аннары туганнары белән таныштыру мәшәкатьләре Үзбәкне авыр уйлардан аралап торды. Хан үзе оештырган мәҗлесләргә чакырды, бәкләр, әмирләр, тәхет тирәсендә чуалучы әрәмтамаклар да аңа хөрмәт-илтифат күрсәткән төсле тоелды. Гомумән, ханзадәгә яңа урында төпләнәсе, тормышны җайлыйсы бар, ә бу шактый вакыт һәм көч таләп итә иде.

Баялун хатын аша Кара белән танышкач, Үзбәк башта борчуга калды. Әтисенең үлемен күргән канечкечеләрнең берсе шушы кеше бит. Ул үтерешне оештыруда да Кара турыдан-туры катнашкан. Бусы һәркемгә көн кебек ачык. Бөтен астыртын пычрак эшләрен Ногай Кара куллары белән башкарып килде. Хәзер аны үз янәшәсенә якын җибәреп, дөрес эшлиме? Тик Баялун хатын аны Караның тугрылыгына инандырды.

– Гомере буе карусыз хезмәттә булган эт, хуҗасын югалткач, кая барырга белми. Аңа яңа хаким кирәк, – диде Баялун хатын. – Кара Ногайга намус белән хезмәт итте. Үзе күренми торып, гамәлләре хакында даны таралды. Сарайда аның йөзен танучы кеше юк. Ногай олысында да сирәк кеше күзенә чалынгандыр, анда да битен күрсәтмичә. Андый бәндә сиңа бик файдалы булыр. Беренче очрашуда ук ант эчтер. Каны белән ант итсен. Аның осталыгы зур, антыннан соң курыкмый ышана аласың.

– Исабәк ни дияр бит...

Баялунның йөзенә «Син әллә юләр инде?!» дигән кыяфәт чыкты. Үзе тәрбияләп үстергән Үзбәкнең беркатлы булуына нык хәтере калды.

– Исабәкнең үз урыны, Кара белән икесен бергә бутама!

– Тик Исабәк һәрвакыт янәшәмдә...

– Исабәк каны Чыңгызларныкы белән катнаш. Ул Урданың аксөякләре нәселенә карый. Кайсы аксөякнең хакимлеккә омтылмавын күргәнең бар?! Янындагы ышанычлы дип санаган кешеләре күпме ханны суеп үтергәнен беләсеңме?! – Баялун, чыгырыннан тәмам чыгасын тоеп, тукталып, киң итеп сулыш алды һәм тынычланып дәвам итте. – Беркемгә дә ышанма. Кара бары тик синең тәнсакчың гына. Син Исабәккә берни дә аңлатырга тиеш түгел, хәтта ул сораса да. Серләреңне эчеңдә бикләп сакла.

– Миңа бу авыр булыр...

Баялун, янә ачуы кабарып, Үзбәккә якынлашты. Аның күзләре ут булып яна иде.

– Тәхеткә менәсең килсә, минем сүземне тыңлап, барысына да түзәчәксең, – диде Баялун хатын. Пышылдап әйткән бу сүзләр белән Үзбәк башын иеп килеште. Баялун янә тыныч, хәтта салкын халәткә кайтты. – Нәзифә хатының бик чибәр, ләкин сай акыллы кешегә тартым.

Бу сүзләрдән инде Үзбәкнең өянәге кузгалды.

– Минем хатыныма тел-теш тидерәсе булма, Баялун хатын, – диде ул,

бар нәфрәтен җыеп. Нәзберек, каршы дәшмәс Нәзифәсен кыерсытуларын күз алдына китереп, ул аны нык кызганып куйды.

– Карале, нинди гарьчел, – дип, тел шартлатты Баялун, йомшый төшеп. – Мин тел-теш тидермим, теләсәң нишлә, синең хатының. Тик ул дәүләт эшләрендә киңәшче-терәк булырлык кызга охшамаган. Күче белән бала табып, шулар белән әүмәкләшеп йөрүдән артык китмәячәк. Тимербәк тә шундый булып үсәчәк...

– Баялун хатын!

– Чү, чү, тынычлан. – Баялун елмаеп куйды. – Синең тормышыңда ул хатыннан кала башкалары да булыр, ләкин анысын вакыт күрсәтер. Нәзифә ахирәт буларак миңа килеште, мин хәзер хатын-кыз фикерен түгел, тәхет әһеле уйларын гына җиткерәм. Минем әйткәннәрне аңа сөйләп, хәтерен калдыра күрмә. Кызулыгыңны, үпкәли торган гадәтеңне ташла. Ауда вакытта Кадакның боланын екканыңны сөйләделәр, бер мәңгелек дошманың өстәлде дигән сүз. Шуңа Кара һәм аның кешеләре сиңа бик кирәк, ханзадәм. Һәм, әлбәттә, үз-үзеңне кулда тота белү мөһим...

Баялун хатыннан чыккач, Үзбәкнең янә йокысы качты. Үзенә аксөякләр каныгуы җитмәгән, хәзер инде Баялун хатын Нәзифәсеннән җитешсезлек тапкан. Интегеп йөри торгач, ул әнисе Әрибах белән сөйләшеп карады. Тегесе улын булдыра алганча тынычландырды. Баялун хатын Нәзифәнең дәүләт эшләреннән ерак торуына гына борчыла. Яшь кызны ул дусиптәше итеп кабул иткән, төрле мәсьәләләргә сөйләштереп, кылларын тартып караган, әмма тегесенең гаиләдән ары гаме юклыгы ачыкланган. Һичшиксез, ханзадәнең хәрәмендә аның эшләренә тыкшынмый, катлаулы вакытта башын бушатырлык хатын да кирәк, һәм Нәзифә бу яктан бик тә урынлы. Тимербәкне исә Баялун да, Әрибах та оныклары буларак кабул иткән, Үзбәк югында алар олы хатыннарның тирмәләрендә еш кунак булалар, Баялун Тимербәк белән дөньясын онытып уйный, күңел ача икән. Хатыны белән дә сөйләшкәннән соң, әнисе сүзләренең хаклыгына тәмам инанып, Үзбәк бу хакта бүтән сүз кузгатмады.

**7**

Урда өчен ул елларның җәйләре, аннан соң кышлары үтә дә авыр килде. Даланы шартлатып киптергән корылыкны ачы салкыннар алмаштырды. Ач бүреләр Сарай янәшәсендә үк өерләре белән йөри, атларны, каладан ераккарак киткән кешеләрне ботарлыйлар. Корылык һәм салкыннар үзе белән ачлыкны да ияртте. Гаиләләрен туйдыра алмаган кешеләр, чарасызлыктан, балаларын кол базарында сатып җибәрергә мәҗбүр булдылар. Туктай хан өчен үтә дә киеренке чор иде бу. Ничек яшәргә? Хан тирмәсендә, киңәшмә арты киңәшмә җыеп, баш ваттылар. Мондый шартларда рус олысын да артык талап булмый, баскаклар тиешле күләмдәге ясакны берничек тә җыя алмый, алырга әйбер юк. Русларның ачлыктан кырылып бетүе Урда өчен дә файдага түгеллеген аңлаган Туктай хан анда артык кырыс кыланмаска боерды.

Кыш ничек үтә салкыннары белән килсә, яз да көтмәгәндә башланды. Тиз арада җылытып җибәреп, болай да җирне чак кына каплап яткан кар тиз арада эреп тә бетте, дала янәдән корылыкка керде. Дым санаулы көннәр эчендә юкка чыкты, яңгырлар яумады.

Җәйләү урынына гадәттәгедән алданрак кузгалырга кирәк иде. Туктай хан халыкка әзерләнергә кушты, үзе исә тирмәсенә бәкләр-бәкләрен, сәргаскәрләрне, хисапчыларны, яраннарын олы корылтайга җыйды. Түрдә тәхеттә утырган хакимнең йөзе кара иде. Ул Үзбәкнең тез чүгеп сәламләвенә дә, башкаларның илтифат күрсәтүенә дә игътибар итмәде. Ханзадә исә, үз урынына барып утыргач, тирмәне күздән кичерде. Корылтай, димәк, җәйләүгә кузгалыр алдыннан соңгысы.

– Хәлләребез әйбәт түгел, – диде, ниһаять, Туктай хан, яраннарына карамыйча гына. – Җанисәп алгач, күпме халкыбызны югалтуыбызны тәгаен аңларбыз. Далада ат, сарык сөякләре генә аунап ятмый, ул мәетләр белән дә тулган. Бу яклардан китеп, җәйләү өчен Биштау янындагы үзәнгә төшәбез. Анда беренче мәлгә җитәрлек үлән дә, шифалы чишмәләрдә сихәтле сулар да бар. Аннары күз күрер. – Хан, башын күтәреп, ишек катындагы яранына кулы белән ымлады. – Багаууганны чакырыгыз!

Үле тынлыкта тирмәгә башына болан мөгезләре кигән Багаууган керде. Ул, иелмичә, исәнләшмичә, ханга ихтирамын күрсәтеп тормыйча, Туктайга туп-туры карап, ышанычлы адымнар белән атлады. Тәхеткә бер адым кала багучы башын чак кына иде, ләкин күзләре каш астыннан хакимгә текәлгән килеш кала бирде.

– Сөйлә, Багаууган багучы, минем әмеремне үтәдеңме, мин сораган йоланы башкардыңмы? – дип сорады Туктай хан арыган тавыш белән.

– Синең кушуың буенча мин үзем белән бергә тагын сигез иң көчле багучыны алдым, – диде Багаууган, чак кына гырылдап. – Без тугызау иң биек тау башына менеп, тугызыбыз тугыз тарафка юнәлдек. Тугызыбыз тугыз сорау бирде. Мин барлык җавапларны да туплап, изге рухларның безгә ни әйтергә теләвен аңладым.

– Сузма, әйт, изге рухлар ни диделәр?!

– Мәңге Күк Тәңре безгә ачулы. Ул безнең түземлекне һәм көчебезне сыный. Ул өч коры җәй һәм өч салкын кыш әзерләгән. Бер җәй белән бер кышны җиңдек, алда тагын икешәр калды...

Туктай күзләрен йомды. Аннан битен кулы белән сыпырды. Тәхетендә тураеп утырды.

– Мәңге Күк Тәңре миңа ни өчен ачулы?!

– Сиңа түгел, бөек хан. Халыкка. Ул халыкка син дә, мин дә керәм, Урдадагы һәркем дә. Безнең барыбызның да Мәңге Күк Тәңре алдында гөнаһларыбыз бар. Шулардан арынсак, ул безне кичерәчәк.

– Һәм корылык белән салкыннар бетәчәкме?

– Тагын ике елдан. Төзәлмәсәк, бөтенләй бетмәскә мөмкин. Бу – Мәңге Күк Тәңре кисәтүе. Аны аңламасак, җәзасы алда булачак, моннан да куркынычы. – Туктай сүзсез калды. Йөзләренә куркулары чыккан яраннары ягына ул борылмады да. Беркемнән дә киңәш тә сорап тормады. Уң кулын күтәреп:

– Казначы! – дип кенә кычкырды.

– Мин монда, бөек ханым! – дип, тегесе хан каршына егылды.

– Тугыз багучыны мул итеп бүләкләгез, көмештән кала һәрберсенә берничә баш терлек бирегез.

– Баш өсте, бөек ханым!

Багаууган чыгып киткәч, Туктай торып басты.

– Тыңлагыз һәм минем сүзләрне барлык олысларга да җиткерегез! Хан сүз тота! Бүгеннән һәм алдагы ике елда Яса кануннарын үтәүне тикшереп тору өчен һәрбер олыста өч йөзәр нүкәрдән торган төркемнәр оештырырга. Ул төркемнәр башына Ясага тугрылыклы Чыңгыз нәселе дәвамчыларын куярга. Яса кануннарын бозган кешеләрне, хөкем чыгарып тормыйча, көнесәгате белән утарның үзәк мәйданында барча халык каршында мыскыллы үлем җәзасына дучар итәргә. Хан сүзе тәмам.

Кырыс карар кабул итүенә канәгать калып, Туктай тәхеткә утырды. Үзбәкнең башына куркыныч уй йөгерде – ханның бу әмерен үтәп, күпме гаепсез кешенең җанын алырлар икән? Хан гадел хөкемгә, мәхлукларга үз-үзләрен якларга да урын калдырмады бит. Бер атка мескеннең кулларын, икенчесенә аякларын бәйлиләр дә, атларны чаптырып, тәнен икегә өздереп, дала буйлап җибәрләр. Болай да ачлыктан кырылган Урдага күпме күз яше түгелергә тора! Ләкин Үзбәк дәшмәде.

Туктай хан тәхетендә чак кына яткан көе янә уйга калды. Аннары күзләрен ачты.

– Мисырдан килгән илчеләребезне чакыр! – диде ул.

Әле кичә генә ерак араларны узып, Сарайга кайтып төшкән илчеләр бик йончыган иде. Тирмәгә атлап керү белән, алар, беренче эш итеп, хан каршына тезләнде.

– Бөек ханнарның иң бөеге, дөньяның кендеген тотып торучы илбашы, далалар, таулар, елгалар, Күк һәм Җир хуҗасы Туктай хакимебез! Синең әмерең белән фәкыйрьләрең, ерак араларны үтеп, кире каршыңа кайтып егылды, – диде илчелек башлыгы Оюун бәк. – Мисыр солтаны Әл-Мәлик Ән-Насыйр Насыйретдин Мөхәммәд бине Калаун сиңа баш ияргә, синең көчеңә, зирәклегеңә соклануын җиткерүебезне сорады. Сиңа һәм синең дәүләтеңә озын гомер һәм иминлек теләде. Ул сине, аралар ерак булса да, туганы төсле якын күрүен белдерә һәм сиңа безнең арттан менә шушы бүләкләрне җибәрде.

Тирмәгә бер-бер артлы Мисыр күчтәнәчләре керә торды. Хан, тәхетеннән төшеп, андагы коралларны, балдак-беләзекләрне, келәмнәрне, күн эшләнмәләрен кызыксынып өйрәнде, соңыннан китерелгән көмеш тәлинкәләрдәге моңарчы күрелмәгән киптерелгән җимешләрдән авыз итте. Аннары җимешләр белән тирмәдәге башкаларны да сыйларга боерып, тәхеттә урын алды.

– Мисыр солтаны Иран илханы Газанга каршы Урда белән берләшеп эш итү турында ниләр уйлый? Ул безгә Кавказ тавы артындагы Арран һәм Азәрбайҗан җирләрен, Ширванны бирергә ризамы?

Оюун бәк каушап калды, як-ягына каранды. Киңәшмәдәгеләрнең илчеләрдә кайгылары юк төсле иде. Кайсы мәрҗән төсле хиссез күз белән текәлгән, кайсы киптерелгән җимеш ашауга кереп чумган.

– Иран илханы Газан белән Мисыр солтаны Әл-Мәлик Ән-Насыйр сугыш хәлендә, бөек ханым. Ләкин әлегә ул берләшеп, Газанга каршы көрәшү турында берни дә әйтмәде...

– Аңлатыйм, бөек ханым, – дип, ышанычлы илчесе Оюун бәкне яклар өчен Кадак мөддәбир сүзгә кушылды. Ханнан рөхсәт алгач, ул бәйнә-бәйнә аңлатырга кереште. – Мисыр солтаны Әл-Мәлик Ән-Насыйр синең көчең-

кодрәтеңнән курка, шуңа күрә берләшергә ашыкмый. Әгәр бергәләп Иран илханнарын сытып ташласагыз, безнең дәүләт белән Мисыр арасы бик якыная, без күршеләр булачакбыз. Синең киң колачлы хан булуың бөтен дөньяга мәгълүм. Иран илханнарыннан соң мәмлүкләр Мисыры да Урдага кушылырга мөмкин, шуңа куркак Әл-Мәлик Ән-Насыйр солтан һаман җавап бирми суза...

Хан күңеленә бу сүзләр хуш килде.

– Миңа Мисыр кирәк түгел, Мисыр солтаны тыныч була ала. Урдага Ширван, Арран белән Азәрбайҗан гына кирәк, бу – гадел таләп. Заманында бөек Чыңгыз хан ул җирләрне Бату хан олысына кушкан иде. Иран илханнары аларны явызларча талап алды. – Туктай хан Оюун бәккә борылды. – Ханның рәхмәте сиңа чиксез, Оюун бәк. Мин теләгән җавапны ала алмасаң да, Әл-Мәлик Ән-Насыйр хакында бик файдалы мәгълүмат туплагансың. Казначыдан тиешле хакын алырсың.

Илчеләр чыгып югалгач та, Туктай янә йокымсыраган төсле булды. Кинәт кабат уяулык халәтенә күчеп, чираттагы мәсьәләгә күчте.

– Тоңгыз бәк белән Таз бәкне чакырыгыз! – диде Туктай.

Хаким хозурына кайчандыр Туктай ханга каршы бәкләр-бәге Ногай ягында сугышкан аксөякләр басты. Алар башларын түбән игән, кулларында бүләкләр. Туктайның ул бүләкләргә әллә ни исе китмәде, ул янә йокымсыраган кыяфәт алды.

– Сөйләгез, – диде ул ялкау гына.

Тоңгыз бәк барысын да бәйнә-бәйнә сөйләргә кереште. Ногайның үлеменнән соң аның олысы ике улы Җәке һәм Тәке кулына калды. Ләкин, Урданың көнбатыш чикләрен ныгытасы урынга, тегеләре үзара тарткалаша башлаган. Бигрәк тә Җәкедән күп явызлык күрәләр. Тәке Туктай ханга тугры булса, Җәке әтисе җырын җырлауны дәвам итә, үзен Урдадан аерым дәүләттә хан итеп күрмәкче була. Тәке каршы төшкәч, Җәке аны мәкерле рәвештә үтереп ташлый. Олыска берүзе хуҗа булып калгач та, Җәке бәкләрне кысрыклый башлый, аларның шактые аның кылычыннан җан тәслим кыла. Олыстагы халыкның игътибарын бу мәгънәсез канкоештан читкә юнәлтү өчен, Җәке көнбатыштагы Молдавия җирләренә гаскәр җибәрә. Төмәннәр башына Тоңгыз бәк белән Таз бәкне куя. Бу – олы ихтирам билгесе буларак түгел, ә ике нойонны юмалап, соңыннан үтереп ташлау өчен эшләнә. Тоңгыз бәк белән Таз бәк, Молдавиягә таба барыр урынга, төмәннәрен Җәкегә каршы боралар һәм тегене тар-мар итәләр. Җәке исән кала, аланнар янына кача, һәм андагы әмирләрнең гаскәрләре ярдәмендә баш күтәргән бәкләрнең төмәннәрен куып тарата.

– Урданың бердәнбер ханы, бүген көнбатыштагы фәкыйрьләреңнең игътибары сиңа юнәлгән. Алар синнән яклау көтәләр, – диде бәянын тәмамлаган Тоңгыз бәк.

– Гаскәр җыярга кирәкме, бәкләрем-нойоннарым? – дип мөрәҗәгать итте тирмәдә утыручыларга Туктай хан. – Ногай олысында тынычлык урнашырмы, әллә сыңар күзле бүре безне үлгән көе дә мыскыллап ятачакмы? Ике улы башлырак булыр, Сарайга йөз тотар дип уйлаган идем, ялгышканмын. Мондый золымны җирдә яткырсак, Мәңге Күк Тәңре безне кичермәс...

Кайсыдыр бәкнең:

– Бөек ханым, корылык һәм ачлык шартларында сугышка керү бик үк дөрес булмас... – дигән сүзләрен ханның тәхеткә шап итеп йодрык белән сугуы бүлдерде.

Хан торып басты. Йөзе усал, күзләре яна, ачуы яман иде бу мизгелдә аның.

– Хан сөйли! – диде ул корычтай тавыш белән. – Әмеремне тыңлагыз. Бүгеннән үк Ногай олысына барып, Җәкене хакимлектән алып ташлау өчен гаскәр тупларга! Ачлык аларда да, бездә дә, ике як та бер үк шартларга куелган. Җәкене исән килеш хан станына алып килеп, Яса кануннарын бозганы өчен хөкем итәргә. Әлеге бурычны үтәү өчен мин гаскәремнең башына сөекле улым Түкәл-Буганы куям! – Туктайның улы шунда ук сикереп торды һәм әтисенә рәхмәтле кыяфәт белән баш иде. – Гадел, ләкин кырыс, кыю, ләкин сак бул, улым, яулап алынганнан соң Днестр елгасыннан ары җирләргә сине хуҗа итеп билгелим, безне көнбатыштагы дошманнардан саклап торырсың. Гаскәрнең уң канаты башына – туганым Бүрлекне, сул канатына туганым Сарай-Буганы билгелим. – Ханның туганнары да рәхмәтле рәвештә тораташтай катып калдылар. – Ногай көчеге юк ителгәннән соң Бүрлек сәргаскәргә – Тын ярындагы биләмәләрне, Сарай-Буга сәргаскәргә Җаек буендагыларын тапшырам, сез шул җирләр белән идарә итегез. Ханның сүзе тәмам!

Туктай урынына утырды. Тоңгыз белән Таз бәкләр хан әмерен авызларын ачып тыңлап тордылар. Яклау сорап килгәннәр иде, нәтиҗәдә гомер-гомергә үзләре баш булып торган олыслар күз ачып йомганчы ханның якын туганнарына тапшырылды да куйды. Хәзер алар шул бәкләр астындагы гади йомышчыларга гына әйләнеп калачаклар. Туктай ханның Ногай олысын җимереп, бүлгәләп-таркатып бетерү теләге бик зур икәнлегенә беркемнең дә шиге калмады...

Тоңгыз белән Таз бәк абына-сөртенә, хан тирмәсеннән чыгып киткәч, бавырчылар чакыртылды, хан яраннарына кымыз салынган чәркәләрне өләшә башлады. Һәрбер нойоны, аның каршына килеп, тезләнеп, хакимнәре кулыннан эчемлек алып эчә торды. Үзбәк ханзадәгә дә чират җитте. Җай чыгып, ул Туктай ханга сүз катарга җөрьәт итте:

– Бөек ханым Туктай, ялгыш сүз әйтсәм, кичерә күр, ләкин яшьлегем, тәҗрибәсезлегем мине сиңа дәшәргә мәҗбүр итә...

– Әйтеп кара, Үзбәк ханзадә...

– Мин гаскәр белән бергә Ногай олысына барырга теләр идем, зинһар, үтенечемне кире какма...

Хан уйга калды. Үзбәк, димәк, әтисе каны коелган җирләрне күрергә тели. Соң, барсын, күрсен, ник каршы килергә? Ханзадә эчтән бер дә кара күңелле кешегә охшамаган.

– Сарай-Буга сәргаскәр! – дип дәште туганын Туктай хан. Тегесе килгәч тә, әмер бирде. – Үзбәк ханзадәне меңбашы итеп ал, меңлек белән тәэмин ит. Сугышта үзенең ирлеген күрсәтсен!

– Ләкин, бөек ханым... – дип кушылмакчы булды Кадак мөддәбир, тик хан, уң кулын күтәреп, тегенең авызын япты.

– Хан үз сүзен әйтте.

Үзбәк күзләрен ханга күтәрде. Тегесе инде елмаеп, думбрачыларга борылган иде. Аннан соң бөтен кыяфәтенә нәфрәте чыккан Кадакка бакты. Алар сүзсез генә карашып тордылар. Җиңү янә Үзбәк ягында иде...

Кичен Әрибах хатын улын үз янына чакырды.

– Олы яуга китәсең, улым, сине Мәңге Күк Тәңре үзе сакласын, ак юл үзеңә, – диде ул борчулы кыяфәт белән. – Әтиеңнән калган хәрби кирәк-яраклар сине саклар дип өметләнәм. Хәзер алар – синеке.

Үзбәк бер читтәрәк өелеп торган кораллар янына килде. Әтисенең җәясе. Зур һәм шул ук вакытта бик җиңел. Саргаеп чыгып, затлы таш төсенә кергән, ике очына ике мөгез кидерелгән. Тәтесе шул мөгезләр астына кереп югала. Тәте үзе исә, шартлап кипкән сеңердән ясалып, коры урында әйбәт сакланган, тагын да ныгый төшкән, аны көч-хәл белән тарта алды. Әтисенең калчаны өсте ябулы иде. Калчан эчендә берничә төрле укларга тап булды. Берсе ерактан ук дошманны бәреп ега торган җиңел, тишекле сөяк җилдә сызгырырлык итеп урнаштырылган; икенчеләре авыр очлы, көндәшнең өстендәге тимер кыякны[13] тишеп керерлек. Ике төрле кылыч – асылташлар белән бизәлгән тоткалы, берсе туры хәнҗәрле, икенчесе кыйгач ай рәвешендә. Туры хәнҗәрнең уртасында уйсулык бар – кан агып чыгар өчен махсус шулай эшләнгән. Әтисеннән Үзбәккә аның калканы да мирас итеп күчте. Кат-кат тирене өсле-өсле ябыштырып ясалган әлеге калкан бер үк вакытта артык авыр да түгел, таш кебек нык та иде. Аның тышкы ягына нәсел тамгалары төшерелгән. Ләкин иң таң калдырганы – Тогърулҗаның сугыш чукмары. Тоткасы филнең казык тешеннән ясалып, төп өлеше тимердән иде. Тимер түмгәгенең дүрт ягыннан очламнар калкып чыккан. Мондый чукмар бер сугуда көндәшеңнең башын ярырлык.

– Тогърулҗа синең бу коралларны сугышта куллануыңны күреп, шатланып ятачак, – дип мышкылдады Әрибах хатын. – Башың гына сау була күрсен.

– Әтиемнең дә, синең дә исемеңә тап төшермәм, сөекле әнием! Минем җиңү белән кайтуымны көт, даным еракларга таралыр.

Әни кеше, тыела алмый елап җибәреп, улын кочаклады. Бердәнбер ир баласын соңгы тапкыр күрү хакындагы уйларын куаларга маташса да, алар һаман да әйләнеп кайта тордылар...

Сарай халкы ике төркемгә бүленде. Хан тирмәсе, аның якыннары, хатын-кызлар, балалар, сакчылар, хезмәтчеләр, бавырчылар, башка яраннар төялгән арбалар Биштау ягына кузгалды. Түкәл-Буга ханзадә җитәкчелегендәге зур гаскәр исә, туганнары белән саубуллашып, Ногай олысына таба юл алды. Сарай-Буга сәргаскәр кул астындагы канатта меңбашы Үзбәк ханзадә дә бар. Аның меңе башлыча Иделнең өске ягыннан, Болгарстан һәм рус олысларыннан килгән сугышчылардан тора иде.

Үзбәк ханзадә беренче көннәрдән үк, юлда булуына карамастан, үзенең йөзбашлары белән якыннан танышу, аралашу өчен вакыт тапты. Рус дружиналары җитәкчеләре Иван белән Игорьны бик төпле һәм булдыклы кешеләргә охшатты. Болгар олысыннан нүкәрләр ияртеп килгән Аршак бәк исә күңеленә аеруча хуш килде. Хәрби булуына карамастан, үтә дә укымышлы, җаена карап биш вакыт намазын калдырмый. Ул ханзадәгә

[13] Кыяк-кольчуга.

үзенең туган ягының матурлыгы, андагы мәчетләр, мәдрәсәләр турында озаклап сөйләде. Урданың төньягындагы соңгы терәк булган бу төбәкне Үзбәк ханның һичшиксез күреп кайтасы килде.

Нукәрләр арасында да Үзбәк ханзадәнең тиз арада дәрәҗәсе күтәрелде. Кешеләрне тыңлый, аңлый белә. Дөрес, сүзенә каршы төшсәң, ут кебек кабынып китә. Бусын да ошатты яугирләр – аксөякнең йөрәге мукләнмәгән, чын ихлас сугышчы, димәк.

Акрынлап, Ногай олысы эченә керә барган саен әледән-әле Түкәл-Буга гаскәре һөҗүмнәргә дә очрап торды. Ләкин тауларда сугышырга өйрәнгән аланнар өчен дала ят җир иде. Хан гаскәренең хәрби киемнәре нукәрләрне уклардан бик яхшылап саклый һәм шул ук вакытта җиңел дә. Кораллары да күпкә шәбрәк. Берьюлы атылган укларның очламнарындагы махсус тишекләргә эләккән җилдә алар аланнар өстенә сызгырып, өннәрен алып килеп кадала. Күпчелек нукәрләр үтә кызуга да күнеккән. Һәм, әлбәттә, теләсә нинди авырлыкка түзем кечкенә атлары аларны далада теләсә кайсы афәттән коткарып бара.

Җәкенең язмышы хәл ителгән иде. Үзбәк өчен бу хәрби сәфәр дала шартларында сугыш алып бару осталыгына өйрәнү урыны булды. Чапкыннар аңа хатыны Нәзифәдән шатлыклы хәбәр дә алып килде – ул гаскәр белән кузгалып өч ай вакыт үткәч, Биштау итәгендәге тирмәдә нәни кызы аваз салган. Нәзифә иреннән аңа Иткөҗек дип исем кушарга рөхсәт сораган, нарасыйның әтисенә ике тамчы судай охшаган булуын да әйткән. Чапкынны юмарт бүләкләп, ханзадә хатынының тәкъдиме белән килеште.

Түкәл-Буга да, Сарай-Буга да яхшы җитәкчеләр булып чыкты. Алар Үзбәкне кимсетмәде, кыерсытмады, яу кырындагы аның меңнәре күрсәткән батырлыкларны мактадылар. Гомумән, гаскәриләр кырыс, ләкин гадел иде. Алар тәхет тирәсендәгеләр төсле кырлы-мырлы сөйләшми, тиешсез урында төрттерми, сүзгә бәйләнми. Яуда, ниһаять, Үзбәк ханзадә күңеленә берникадәр тынычлык тапты...

**8**

Төн уртасы иде инде. Туктай хан, назлы уеннан алҗып, Әрибахны ияртеп, тирмәсеннән урамга чыкты. Тышта рәхәт. Биштау өстендә тулы ай балкый. Күккә йолдызлар сибелгән. Җылы, шул ук вакытта һава бик чиста, көндезге ябышкак эсселек чигенгән. Биштау итәге яшел үләнгә, шифалы суларга да бай. Чишмәләрнең кайберләре тозлы, аларны атлар да чамалап эчә. Кешеләр дә ул суларны төрле сырхаулар вакытында кулланырга өйрәнде. Берсе күз авыруларыннан, икенчеләре эч авыртканда, өченчеләре хәл киткәндә ярдәм итә.

– Карале, сөекле ханым, нинди матур тулган ай! – диде Әрибах хатын, иренә елыша төшеп. – Шушы таулар артында, кайдадыр еракта минем улым синең данлыклы балаң Түкәл-Буга җитәкчелегендә дошманнарыңны айкап йөри. Исән-сау гына булсыннар инде...

Туктай көрсенеп куйды.

– Дошманмы, әллә миңа буйсынып яшәргә тиешле яраныммы – белгән юк... – диде ул.

– Сине саткан кеше дошман ул, сөекле ханым. Әтиләре дошман булса да,

балаларын кичердең, нәселенә тимәдең. Ә алар синең яхшылыкка яманлык белән җавап кайтарды. Зинһар, үзеңне битәрләмә, син барысын да дөрес эшләдең, гадел ханым!

– Җәкегә кичерү юк. Ләкин мин үлгәч, халык минем турында ни сөйләр икән? Гомере буе үз җирләрендә сугышып йөреп, дәүләтне ныгыта, зурайта алмады, диячәкләр бит. Минем күңелне шул борчый...

– Әле барысы да алда, сөекле ханым! Син көчле, булдыклы, егетләрдәй япь-яшь! Ногай олысына тәртип керткәч, илебез тынычланыр, афәтләр китәр, син, яңа көчләр җыеп, мәмләкәтебезне тагын да киңәйтерсең, моңа һич кенә дә шигем юк! – диде Әрибах, иренең киеренкелеген киметергә тырышып.

– Әлегә исә мин ата-бабаларымнан калган малны да арттыра алмыйм... – Туктай кинәт ачылып китүенә оялып куйды, кабат кырыс тавышка күчте. – Ярый, Әрибах, бар, сине тирмәңә озатсыннар! Бүгенгә мин нык арыдым.

Туктай тирмәсенә ялгызы гына кереп китте. Йокы төшмәде. Ногай олысыннан килгән хәбәрләр аны шатландыра иде. Улы Түкәл-Буга үзен чын гаскәрбаш итеп таныта. Үзбәк ханзадә турында да ул мактау сүзләре генә җиткерә. Түкәл-Буганы Туктай үзенчә ярата. Көчле, ышанычлы ул. Башы гына юк. Ни кызганыч, аны варис иттереп калдырып булмаячак. Илбасмыш мәкергә хирыс, кеше белән курыкмый сөйләшә белә. Түкәл-Бугадан аермалы буларак, танавы кипмәс борын тәхет турында хыяллана. Илбасмышның тәрбиячесе Кадак мөддәбир тиешле сүзләрен таба. Хәзер инде улы әтисеннән бигрәк остазына колак сала шикелле.

Хәер, Әрибах дөрес әйтә. Туктай әле яшь, тәхетне беркемгә дә ансат кына бирергә җыенмый. Ногай олысын өч кисәккә бүлеп, дөрес эшли Туктай. Түкәл-Буганы Урданың көнбатыш чикләренә үк олактыруы да урынлы. Сарайдан ерак торыр, Илбасмыш белән Кадакның кәефен кырмас. Ә Түкәл-Буга исә Урданың иминлеген дошманнардан соңгы тамчы канына кадәр саклаячак. Моңа шиге юк ханның.

Мисыр белән әлегә кадәр уртак тел таба алмау да борчый Туктайны. Кадак хаклыдыр – куркадыр Туктайдан Әл-Мәлик Ән-Насыйр солтан. Куркуы әйбәт. Тик Иран илханнарының мин-минлегенә чик куярга кирәк бит. Ә моны Туктай ялгызы гына башкарып чыга алмаячак – Кавказ тауларының аръягында сугыш алып бару җиңел гамәл түгел... Авыр уйларына арыганлык өстәлеп, Туктай, ниһаять, изрәп йоклап китте...

Биштау итәге бирегә җәйләүгә килгән барлык Урда халкын үзгәртеп куйды шикелле. Ачлыктан үлгәннәрнең сөякләре аунап ятмый, даладагыдай өтеп ала торган эсселек тә юк. Баялун белән Әрибах бигрәк тә Үзбәкнең кызчыгы нәкъ менә бирегә дөньяга килүгә шатланды. Бу якның һавасы да, суы да шифалы, ана сөте дә үзәннең барлык байлыгын үзенә туплаган. Ике хатын көннәр буе сабый белән маташып, дөньяларын оныта торган булды. Нәзифә моңа карышмады, хан хатыннарының мондый илтифат күрсәтүенә шатланды гына. Дөрес, тегеләре атлаган саен акыл өйрәтергә ярата, ләкин табигате белән сабыр кыз моңа гына түзде. Яңа туган баласы, олы хатыннар җәмгыятендә иренең еракта яуда йөрүе хакындагы уйлар онытыла иде.

Иртән торып, Баялун хатын янә Нәзифә тирмәсенә юнәлде. Анда ул хуҗаларча, кисәтми-нитми килеп керергә гадәтләнгән. Тик бүген

озак утырырга насыйп булмады. Урам яктан хатын-кызларның чыр-чу кычкырышкан тавышлары ишетелде. Баялун хатын үз тирмәсенә ашыкты.

Гауга, чыннан да, аның ягында булып чыкты. Ишек төбендә аны елап, шешенеп беткән, куллары канга кадәр тырналган олы яшьтәге Сарнай хатын каршылады.

– Сарнай хатын, нигә сөрән ярасың?! – дип килә-килешкә җикеренде аңа Баялун хатын, тавышка халык көтүе җыелудан куркып.

– Тайдула, – диде тегесе, мышкылдап.

Баялунның йөрәге табан астына төшеп китте.

– Ни булды Тайдулага?! Нишләттең аны?

– Мин түгел, ул мине... – Сарнай тагын мышкылдады, ике кулындагы тырналган эзләрне күрсәтте.

– Әйдә, монда түгел, тирмәгә кергәч сөйләрсең.

Эчкә үткәч тә, Сарнай хатын барысын да аңлатты. Иртән ул тәрбиядәге кызларның, шул исәптән Тайдуланың да урын-җирләрен җыештырып йөргән. Тайдуланың әйберләре арасыннан агачтан юнып ясалган хач килеп чыккан. Кыз баладан, бу нәрсә дип сорагач, тегесе, аны-моны белештерми карчыкка ташланган һәм сугыша-тырнаша тәрене тартып та алган.

– Тайдула үзе кайда?!

– Уртак тирмәдә...

Баялун хатын, җил-җил атлап, асрамалар тирмәсенә китте. Керә-керешкә бала-чагага урамга чыгарга кушты. Тайдула тирмәнең ерак читенә поскан иде.

– Чык, Тайдула, курыкма, – дип дәште аны Баялун, елмаерга маташып. Тегесе тыңламады. Баялун сак кына бала янына килде, каршысына чүмәшеп утырды. Тайдула бер кулын, чытырдатып кысып тоткан килеш, күкрәгенә яшергән. – Йә, миңа гына күрсәт әле, нәрсә ул синең кулыңда?

Тайдула усал күзләрен Баялун хатыннан алмады, аннан соң, бирешеп, уң кулын алга сузды. Акрын гына кечкенә учын ачты. Анда агачтан юнып ясалган кечкенә генә хач күренде. Ул гади киндер бауга беркетелгән иде.

– Миңа моны тотып карарга ярыймы? – дип сорады Баялун хатын йомшак тавыш белән. Тайдула башын какты.

Баялун хатын, менә-менә ватылып китәргә әзер әйберне алган сыман, тәрегә үрелде. Агач кисәге вакыт үтү белән шомарып беткән, шактый гына пычрак та каплап алган үзен. Баялун хатын хачны озак кына әйләндергәләп карады, аннан кире Тайдулага сузды.

– Кем бирде сиңа моны?

– Әнием...

Баялун хатын кинәт күңеле тулып киткәнен, күкрәген сагыш кысып алуын, күзләре яшьләнүен тойды. Ул, тыела алмыйча, кызыйны кочаклап алды. Яшьләре баланың чәчләре буйлап йөгерештеләр.

– Яхшылап яшереп куй, сакла син аны, яме, кызым, – дип пышылдады Баялун. – Башка беркемгә дә күрсәтмә. Хәтта миңа да. Авыр чакларыңда, ялгызың калгач кына, аны алып, әниеңнең, якыннарыңның, туган ягыңның төсен исеңә төшер...

Тайдула дәшми утырды, аннары Баялунның куеныннан аерылып, тәрене мендәрләр астына яшерде.

– Мин зур үскәч, Сарнай төсле кол булачакмынмы? – диде ул, кинәт зур күзләрен Баялунга төбәп.

Баялун хатын янә ни әйтергә белми каушап калды.

– Нигә кол булырга тиеш ди син?!

– Син мине акчага сатып алдың бит...

– Сатып алмадым, сине коткарып калыр өчен бирдем мин ул алтыннарны.

– Ә нигә син мине коткардың? Кол итәр өченме?

– Юк, Тайдула. Мин сине ханбикә итәргә дип алып кайттым.

Кыз куркуын яшермәде.

– Туктай ханның ханбикәсеме?! – диде ул, шаккатып.

– Юк ла инде, юләр. Беркемгә дә бу хакта сөйлисе булма. Бу безнең икебез арасындагы сер булыр. Әгәр минем сүземне тыңласаң, син яшь, чибәр хан янәшәсендә урын алып, аның яраткан хатыны булып утырачаксың. Тик моның өчен минем һәр сүземне карусыз үтәргә һәм түзәргә кирәк. Аңладыңмы?!

Тайдула янә моңсуланды.

– Алар минем әтием белән абыемны үтерделәр, әниемне миннән аерып сатып җибәрделәр...

– Үткәннәр белән яшәргә ярамый, балам. Алга атларга, яшәргә омтылырга кирәк. Синең гаиләңне кыерсыткан кешеләр, һичшиксез, үз җәзасын алыр. Минем сүзне тыңласаң, бәлки, вакыт узгач, әниеңне дә исән-имин килеш эзләп таба алырсың. Ә моның өчен хакимлек һәм байлык кирәк.

Тирмәдән чыккач та, Баялун Сарнай белән очрашты.

– Ни күргәнеңне оныт, Сарнай хатын, авызыңнан бер генә сүз чыкса, аны мәңгегә ябармын, – диде ханбикә һәм тиз генә атлап китеп тә барды.

Кичен Туктай хан якыннарын мәҗлескә чакырды. Гадәттәгечә, түрдәге урыннар гаиләсенә бирелде, бәкләр, дәүләт хезмәткәрләре, дәрәҗәсенә карап, тирмәнең төрле почмакларына урнашты. Гадәттә, мондый табынга җыелган кешеләр биш йөздән дә ким булмый, бу юлы, сугыш бару сәбәпле, халык азрак иде. Шулай да, тирмәдә шактый күңелле, ул шау-гөр килеп торды, хан кергәч кенә, барысы да тын калып, кайсы уң тезен чүкте, кайсы, ихтирам билгесе итеп, башын иеп, уң кулын күкрәгенә куйды.

Тәхеткә менгәч тә, хан җәмәгатькә борылды.

– Хан сөйли! – диде ул тантаналы кыяфәт белән. – Барыгыз да белеп торыгыз. – Ногай олысын акылга утыртырга дип җибәрелгән туганнарыбыздан бары тик шатлыклы хәбәрләр генә килеп тора. Озакламый Урданың көнбатыш өлешендә тулысынча тәртип урнаштырачакбыз. Безнең яугирләребез хөрмәтенә табында кымыз белән шәраб мулдан аксын, бавырчылар сый-нигъмәтләрне кызганмасын! Озакламый безнең сугышчылар, җиңү белән кайтып, сатлыкҗан Җәкене ике айгырга бәйләп җанын алачакбыз! Мин аеруча улым Түкәл-Буга белән сөекле хатыным Әрибахның улы Үзбәк ханзадәнең батырлыклары белән горурланам! Безнең нәселебезнең киләчәге бар!

Тирмәдәгеләр, шау-гөр килеп, ханның бу сүзләрен шатланып кабул итте, аннары берәм-берәм, баш иеп, хаким кулыннан кымыз тулы чәркәләрне алды. Озакка сузылган бу тамаша думбрачылар тавышына күмелде. Тирмәдә бәйрәм рухы урнашты – корылык һәм хорафатлар аркасында ханның күптән инде мондый мәҗлесләр үткәргәне юк иде. Бәйрәм тансыклаган аксөякләр

тәмам исерешеп беттеләр. Бер Кадакның гына кәефе күтәрелмәде, йөзенә елмаю иңмәде.

Баштарак күңеле күтәренке булса да, кичкә таба Туктай да арыды. Ул салмыш яраннарының әле берсенә, әле икенчесенә караш ташлап дәшми утырды да, Кадакка мөрәҗәгать итте:

– Кайтсыннар, җитәр! – диде.

– Бөек ханыбыз мәҗлес тәмамланганын игълан итте, таралышыгыз! – дип шунда ук шәрран ярды Кадак.

Думбрачылар тынып калды, тирмәдә ыгы-зыгы башланды. Кадак халык арасында боргаланган арада, каршына Әрибах хатын килеп чыкты. Ханбикәне күргәч, мөддәбир елмаерга маташты һәм, кулын күкрәгенә куеп, башын ия төште.

– Бөек ханбикә, мескен мөддәбир сине күрүенә чиксез шат.

Әрибах хатынның йөзенә шунда ук салкынлык йөгерде, ул башын югары күтәреп, Кадакка текәлде.

– Сүзең булса – сөйлә, Кадак.

– Бүген ханыбыз авызыннан Үзбәк ханзадәгә әйтелгән сүзләрдә синең дә өлешең бик зур, бөек ханбикә!

– Хан мактавына ирешү һәркемгә зур бәхет, моның өчен бик күп көч түгәргә туры килә.

– Хакимнәрнең мактавыннан да, тиргәвеннән дә куркырга кирәк, бөек ханбикә.

– Бу нәрсә, янаумы?!

– Юк, бу тормыш кануны.

– Мине кичен хан үз янында көтә, мөддәбир. Сүзең бетсә, китәм.

– Баш өсте, бөек ханбикә, – дип, Кадак түбәнрәк иелгән төсле булды һәм Әрибах хатынга юл бирде.

Кешеләр чыгып беткәч, Кадак хан тарафына килде.

– Чыгышыгыз кыска, әмма үтемле булды, бөек ханым! – диде ул ялагайланып.

– Беләм, – дип ялкау гына җавап кайтарды Туктай.

– Түкәл-Буга белән Үзбәкне тиңләштерү генә мәҗлестәгеләрнең йөрәгенә шырпы төсле кадалды, гадел ханым.

Туктайның ачуы чыкты. Ул, тәхеттән сикереп торып, мөддәбиренең якасыннан эләктереп алды.

– Син бер әйткәнне аңламадыңмы, койрыксыз эт?! Мине янәдән Әрибахның улына каршы котыртмакчы буласыңмы?!

Кадак калтыранып төште. Ханның йөзе нәфрәттән чытылып килгән иде. Ул кинәт агарып чыккан иреннәре белән:

– Юк, бөек хан, гафу ит, сүзем ул хакта түгел иде, – дия генә алды.

Хан вәзирен төртеп җибәрде.

– Тагын бу хакта сүз кузгалтсаң, башсыз эткә әйләнәчәксең. Синең урынга атлыгып торучылар Урдада бетмәгән. Югал күземнән!

Кадак, хәлсезләнгән аякларын көчкә сөйрәп, тирмәдән чыкты. Күз аллары әлҗе-мөлҗе килде. Хан белән сөйләшүдән мәгънә юк, чөнки Әрибах хатын төннәрен аның миен чайкый, улына карата теләктәшлек уята. Ничек дигән иде әле теге вакытта Туктай? «Әрибах хатын исән чакта Үзбәккә

беркем дә кагылмаячак», – дидеме? Кадакка янә хәл керде. Үткәннәрдән кинәт калкып чыккан ханзададән котылу юлын ул хәзер тәгаен белә. Мәкерле фикерен тормышка ашыруны башында әйләндереп, мөддәбир үз тирмәсенә юнәлде.

**9**

Үзбәк Түкәл-Буга гаскәре белән бер елдан артык сәфәрдә булды. Ногай олысы тулысы белән тар-мар ителде. Туктай хан әмере белән аны өч кисәккә бүлделәр. Ногай турында истәлекләрдән ары бернәрсә дә калмады. Бу җирләр инде беркайчан да сыңар күзле илбашчылары ирешкән югарылыкка күтәрелә алмаячак...

Җәке барыбер качып котылды, аны Болгария тарафында сыену тапкан, диделәр. Ногайның кече улы Турай әле бер яктан, әле икенча яктан олысбәкләрне котыртып карарга маташса да, уңышка ирешә алмады. Урда тарихындагы ногайлар сәхифәсе тулысы белән ябылды, дәүләтнең көнбатышында акрынлап тынычлыкка охшаш халәт урнашты.

Үзбәк ханзадә кире Сарайга кузгалды. Көннәр салкынайта, хан хәзер кышлыкка шунда кайткан. Улы Тимербәк, нәни кызы Иткөҗөк, хатыны Нәзифәне, әнисе Әрибахны күрергә ашыкты ул. Тик хыялларының берсе дә тормышка ашмады...

Бишатау якларыннан Сарайга кайткач та, Әрибах кинәт бик нык авырып китте. Иртәдән генә очып йөргән шат күңелле хатын егып салган төсле түшәккә ятты. Баялун хатын кергәндә, ул инде кызышып чыккан, саташа, күзләре акайган, шабыр тиргә баткан иде. Баялун Әрибах тирәсендә кайнашкан җарияләр аша ханбикәгә бер генә караш ташлады. Өмет юк иде Әрибахта. Янәшәсендәге тәбәнәк өстәлдә суынып беткән сарык ите кисәкләре. Берсен алып чыгып, Баялун хатын урамдагы этка ташлады. Тегесе, койрыгын болгап рәхмәтен белдерде, итне кабып йотты, һәм йөгереп китеп тә барды. Йөз адым чамасы үткәч, кинәт арт аяклары абынды, аннан җиргә барып төште. Моңсу гына чинап куйды да яткан җирдә катып калды. Баялунга башка дәлилләр кирәк түгел иде – Әрибахка кемдер агу ашаткан.

Әрибах хатын үлем белән озак тартыша алмады. Тәненә сеңгән агу аны тиз арада кимереп бетерде. Коры сөяккә калып, ул озакламый җан бирде...

Өч көн, өч төн дәвамында Әрибахның тирмәсе янында туганнары, якыннары, җарияләре елашты. Өченче көнне тирмәгә Туктай хан үзе килде. Әрибахны затлы тукымаларга төрделәр, аннан соң көмеш кисәкләре, асылташлар белән бизәлгән кабык эченә салдылар. Хан хатыны янына алтын-көмеш тәңкәләр, кыйммәтле бизәнү әйберләрен куйды. Сарайдан ерак түгел урнашкан каберлектә шул ук көнне Әрибах хатын соңгы сыену урынын тапты. Аны искә алу табыны таңга кадәр дәвам итте, кымыз, шәраб елгадай акты. Ул табында иң күп хәмер эчкән кеше – беркем белән дә сөйләшми утыручы тирән кайгылы Туктай хан иде...

Аршак бәккә үзе җитәкләгән меңне калдырып, атларын күпме генә кумасын, Үзбәк ханзадә әнисен җирләргә кайтып өлгерә алмады. Бары тик беренче кар каплап киткән каберен генә күрсәттеләр. Әнисе белән озак еллар аерылып торып, артык якынлык тоелмаса да, Үзбәкнең җаны бәргәләнде, ул кайгыдан ни эшләргә белмәде. Нәзифәсен кочканда да,

Тимербәкне сөйгәндә дә, беренче тапкыр кулына алып, Иткөҗөкне назлаганда да, ханзадәнең күзеннән ачы яшьләре китмәде.

Баялун хатын белән берничә көннән соң гына очраша алды.

– Син минем әнинең нидән үлгәнен беләсеңме? – дип сорады ул туптурыдан.

Баялун хатынның йөзе таш кебек хиссез калды.

– Ханзадә, хәзер сиңа үлгән кеше турында уйлау дөрес булмас. Сабырлыгыңны бер йодрыкка җый да түзем бул. Үзеңә дә, гаиләңә дә сак кыланырга кирәк. Нидән генә үлмәсен, Әрибах хатын китү белән син бик көчле яклаучысыз калдың. Минем сиңа киңәшем – белмәгәнне ашамагыз, күп сөйләшмәгез, алдыгызны-артыгызны карап йөрегез. Карага әйт – аеруча игътибарлы булсын. Сәер сый-нигъмәтләрне кабул итмә, хәтта хан мәҗлесләрендә дә авыз итүдән ерак тор. Бераз вакыттан соң, җаен туры китереп, Туктайдан үзеңне Хәрәземгә күчерү турында сора. Анда минем ышанычлы кешем, синең туганың Котлы Тимер бәкләр-бәге вазифасында хезмәт итә. Дәүләтнең көньяк кыйтгасында сиңа тынычрак булыр. Котлы Тимер үзеңә идарәгә олысындагы берәр шәһәрне табар, бер дә борчылма. Шунда вакыт җиткәнне көтеп, тик кенә утыр. Сарайга әледән-әле килгәләп йөр, бөтенләй борынын чөерде, димәсеннәр. Кыскасы, сиңа хан һәм аның яраннары күзе алдыннан югалып торырга кирәк. Кайтыр вакыт җиткәч тә, мин сине үзем чакырырмын.

Әнисенең көтелмәгән үлеменнән болай да югалып калган Үзбәк Баялун хатынның киңәшен тыңлады. Хан белән сөйләшү җае шактый вакыттан соң гына чыкты. Туктай каршы килмәде. Әрибах үлеменнән соң аның бу дөньяда гүя гаме калмаган иде. Язга чыгуны да көтеп тормый, Үзбәк ханзадә, гаиләсен, яраннарын төяп, Исабәк һәм Кара нүкәрләре озатуында Үргәнечкә юл алды.

## 10

Үзбәк ханзадәнең килүе хакында Котлы Тимер алдан кисәтелгән иде. Ул туганының кәрванын Үргәнечкә җитәрәк каршылады. Егермеләп нүкәр озатуында килеп, ул тиз генә атыннан сикереп төште, ханзадә алдында уң тезен чүгеп, башын түбән иде. Юлдашлары да аның гамәлен кабатладылар.

– Сөекле ханзадәм, сине Хәрәзем җирендә сәламли алуыма чиксез шатмын! – диде Котлы Тимер.

Үзбәк, шулай ук иярдән төшеп, Котлы Тимерне ике куллап тезләнгән җирдән күтәрде.

– Котлы Тимер, синең хакта мин бик күп яхшы сүзләр ишеттем, хәзер инде якыннан таныша алуым миңа олы бәхет, – диде ханзадә, Хәрәзем әмиренә елмаеп.

– Минем олысым тулысы белән синең хозурыңда, ханзадәм. Биредә син үз өеңдә, янәшәңдә дусларың гына булачак, аларның барысына да син тулысынча ышана һәм таяна аласың. Кәрваныңны минем кешеләр озата кайтыр, хәзер исә мин сине үзем белән Хәрәземнең йөзек кашы Үргәнечкә чакырам.

Котлы Тимер чаптарларына Исабәк белән Караның җайдаклары да кушылды, барысы бергә eрактан таш манаралары белән балкып торган калага таба юнәлделәр.

Күпме йөреп тә, Үзбәкнең бу кадәрле матур һәм мәгъруур шәһәрне күргәне юк иде. Күккә ашкан мәчет манаралары, таштан нык итеп салынган йортлар һәм сарайлар, халык белән шыгрым тулы урамнар. Үргәнечнең үзенә генә хас аһәңе бар. Анда кешеләрнең төрле телләрдә сөйләшүе дә, атлар кешнәве, терлекләр тавышы да, һәр тарафтан кинәт яңгырап алган азан тавышлары да бергә кушылган. Шушы аһәңгә изрәп, олы мәйданнарны, тар урамнарны, мал тулы базарларны басып алган халык диңгезе, әйтерсең, тын гына тибрәлә.

Котлы Тимер Үзбәк ханны үзенең сараена дәште. Биредә аларны Үргәнечнең олы ихтирамга ия кешеләре, казыйлар, имамнар көтеп торалар иде. Алар Сарайдан килгән ханзадә каршында башларын иде, аны мактаулы сүзләр белән сәламләде. Сарайның бизәлешен, андагы халыкның төрле төсләрдәге киемнәрен, купшылык һәм матурлыкны күреп, Үзбәк шаккатты. Биредә шулкадәр якты, чиста, күңелгә рәхәт иде. Җыелган аксөякләр дә Сарайдагыларга бер дә охшамаган. Сөйләшү рәвеше дә күңелгә ятышлы. Тыныч, мыскыллаусыз, төртмәләрсез әңгәмә алып баралар. Бер-берсен дикъкать белән тыңлыйлар, сорауларны тыйнак кына итеп бирәләр. Күтәрелгән мәсьәләләр дә һаман да тормыш мәшәкатьләре турында гына түгел – дөньяның мәгънәсенә төшенү, кешенең дөньядагы максаты, омтылышлары хакында фәлсәфи фикер алышуларга кереп китәләр. Үзбәк Котлы Тимер тирәсендәгеләрнең бик укымышлы булуларына гаҗәпләнүен яшермәде.

Илаһи мәсьәләләр белән беррәттән, дөньяви сорауларны да онытмыйлар. Беренче очрашуда ук ханзадә Хәрәземдә киң колач белән төзелешләр алып барылуын аңлады. Ком чүле арасында җимешләрне су белән тәэмин итүче арыклар казыла, аларның озынлыгы дистәләрчә чакрымнарга сузыла икән. Шул арыклар тирәсендә яңа калалар калкып чыга – бу якларга Урданың төрле кыйтгаларыннан халык агыла, биредәге муллык һәм тынычлык аларны үзенә тарта.

Үргәнечтә Котлы Тимер Үзбәккә, аның гаиләсенә, Исабәккә, ханзадә белән бергә ияреп килгән башка күпсанлы нукәрләр һәм хезмәтчеләргә рәхәтләнеп яшәү өчен барча мөмкинлекләрне дә тудырды. Үзбзәк гаиләсенә аерым сарай бүлеп бирелде.

Котлы Тимер Үзбәк белән шактый вакытын үткәрә торган булды. Ул аны олысы буйлап йөртә, зур һәм кечкенә калалар белән таныштыра, төзелеш, хуҗалык эшләренә чумдыра. Биредәге ташчыларның осталыгы ханзадәне сокландырды. Күчмә рәвештә яшәүче төп Урда белән чагыштырганда, биредә утрак тормыш өстенлек итә, гадәткә әйләнгән.

– Котлы Тимер, кайчан да булса Урдада да шушындый тәртипкә күчәрбезме икән? – дип сорады ул, чираттагы сәяхәтләренең берсеннән кайтып килгәндә.

– Хәрәзем дә буш урында таштан калкып чыкмаган, моңа ирешер өчен гасырлар кирәк булган, – дип, сүзен башлады олыс бәге. – Безнең олысның төп көче – динебездә. Ислам дине безне тырышлыкка, чисталыкка өйрәтә. Син күргән корылмалар барысы да кеше кулы белән генә түгел, Аллаһы Тәгалә рәхмәте ярдәмендә торгызылган.

– Урдада Яса кануннары...

– Яса кануннары Коръәнгә каршы килми.

– Әмма Урдада мөселманнар да, христианнар да, яһүдиләр дә ят дин әһелләре буларак кабул ителә.

– Урданың яртысын мөселманнар тәшкил итә дисәм, ялгышмам. Ислам Ногай олысында да, Идел буендагы болгарларда да, Кавказ итәгендәге халыкларда да, Кырымда да киң таралган.

– Әмма Чыңгыз нәселе Мәңге Күк Тәңрегә табына.

– Алар арасында да төрле дингә керүчеләр бар. Урдага бердәм дәүләт дине кирәк. Андый дин итеп, мин үзем бары тик исламны гына күрәм.

– Нигә исламны?

– Чөнки ул халыкны берләштерерлек көчкә ия.

– Христианнар дине берләштермимени?

– Күпмедер дәрәҗәдә берләштерә. Ләкин ислам диненең аңа караганда тәэсире көчлерәк. Христианнар, берәр гөнаһ кылса, чиркәүгә барып, атакайдан ярлыкау ала. Исламда кичерүче бер Аллаһы Тәгалә генә. Кеше үзенең гөнаһысы гафу кылынганмы-юкмы икәнлеген үлгәч, Ходай тарафына җавап тотарга баргач кына белә. Шуңа да мөселман бәндәсе кырын адымнар ясаудан куркып яши, Аллаһы Тәгалә хөкеме аны төрле кыек эшләрдән ерак тота.

Алар дин турында еш сөйләшә башладылар. Үзбәкнең шик белдергән сорауларына Котлы Тимер үзенең фикерләрен җиткерә торды. Акрынлап, ханзадә олысбәк белән бергә мәчет бусагасын да атлап керә башлады. Анда ул, читкәрәк утырып, җәмәгатьнең намаз укуларын күзәтте, мәртәбәле имамнарның вәгазьләрен тыңлады. Тик шулай да Мәңге Күк Тәңредән ваз кичү әтисе Тогърулҗа, әнисе Әрибах хәтеренә хыянәт төсле тоелды.

Егетнең икеләнүен яхшы аңлаган Котлы Тимер бер көнне аны Үргәнеч читендәрәк урнашкан кечкенә генә алачыкка алып килде. Алачык ишегенә озын чират булып халык тезелгән иде. Олысбәкне күргәч тә, һәммәсе, башларын ия төшеп, юл бирделәр.

Котлы Тимер, Үзбәкне ияртеп, алачыкка үтте. Чалт кояштан кинәт караңгы бүлмәдә Үзбәкнең күзләре чекерәеп калды, ярымкараңгылыкка күнеккәч кенә, ул идәндәге келәмдә утырган ап-ак сакаллы, башына чалма кигән агайны абайлап алды. Агай килеп кергән кешеләрне сәламләргә ашыкмады, ничек тыныч кына утырса, шул килеш калды.

– Әссәламегаләйкем, Ногъманетдин имам хәзрәтләре, – дип, Үзбәкне шаккатырып, Котлы Тимер агай алдында баш иде.

– Вәгаләйкемәссәлам, Котлы Тимер, – диде тегесе, ханзадәне зур кызыксыну белән күзәтеп. – Кемне ияртеп кердең тагын?

Агайның аларны утырган килеш каршылавы, баш ими сәламләве, дорфа соравы ханзадәнең ачуын кабартты, ләкин ул дәшмәде. Агай исә тегенең шартлар дәрәҗәгә җитүен тойды сыман.

– Бигрәк усал кеше икән, син булмасаң, кылычын тартып чыгарып, мине урталай ярып ташлар иде, – диде имам тыныч тавыш белән. Үзбәккә уңайсыз булып китте.

– Бу – безнең олысның мәртәбәле акыл иясе имам Ногъманетдин Әл-Хәрәзми, – дип таныштырды Котлы Тимер. – Мөхтәрәм хәзрәт, сиңа усал күренгән кеше минем якын туганым, мәрхүм Тогърулҗа углы Үзбәк ханзадә.

– Чыңгызлар нәселеннән, димәк... – Ногъманетдин имам күзләрен йомды, дәшми торды. – Миңа ник алып килдең аны? Ул мөселман түгел бит.

– Син аның белән әледән-әле очрашып, изге динебез турында аңлатмалы әңгәмәләр оештыра алмассыңмы икән, хөрмәтле имам хәзрәт?

Үзбәк янә шаккатты. Котлы Тимердән бу хакта сорамаган иде ләбаса!

– Безнең динебез аңа нигә кирәк? Аның дине – канлы кылыч.

– Үзбәк ханзадә ислам белән нык кызыксына, – диде сабыр гына Котлы Тимер. – Сораулары бик күп. Ни кызганыч, мин фәкыйреңнең аларга җавап бирерлек гыйлемем юк...

Имам янә Үзбәккә текәлеп карады.

– Үзенең теләге бармы соң?

– Бар, имам хәзрәт.

– Мин синнән түгел, ханзададән сорыйм, – дип тыныч кына бүлдерде Котлы Тимерне имам. – Минем белән сөйләшергә теләгең һәм түземлегең бармы?

Үзбәк ни әйтергә дә белмәде. Әлеге имам аңа нык киребеткән төсле тоелды. Үзеннән югарырак торган кешеләргә холкын күрсәтеп маташа. Ә нәрсә, аның белән бәхәсләшү Үргәнечтәге күңелсез көннәренә бераз кызык өстәр, бәлки?!

– Теләгем дә, түземлегем дә бар, имам! – дип әйткәнен Үзбәк сизми дә калды.

– Яхшы алайса. Айга бер тапкыр өйләдән соң мин сине үземдә көтәм. Бу алачыкның бусагасын атлап кергәч тә, үзеңнең ханзадә икәнлегеңне онытасың. Бирегә кылыч тагып кермисең. Калганын тора-бара җайлаштырырбыз.

Ни гаҗәп, үзсүзле имам белән сирәк очрашуларны ханзадә көтеп ала торган булды. Ногъманетдин хәзрәт аңа гади бер кешегә караган мөнәсәбәттә иде. Имам янына көннәр буе халык агыла, киңәш сорый, догасыннан шифа-тынычлык таба. Үзбәк тә шул халык ташкынының бер өлешенә әверелде. Дөрес, сөйләшүләре җиңел генә бармады. Икесе ике дөнья кешесе бит. Үзбәкнең үз карашлары, үз уйлары. Имам исә акрынлап үз фәлсәфәсен алга сөрә. Ул ханзадәне Коръән укырга өйрәтә башлады. Анда язылганнарның мәгънәсен зур сабырлык белән аңлатты.

– Имам хәзрәт, ислам дине  дәүләт өчен иң уңайлы дин булып чыгамы? – дип сорады бервакыт Үзбәк.

Ногъманетдин хәзрәт көрсенеп куйды.

– Ислам дине – Аллаһы Тәгалә тарафыннан кеше өчен иңдерелгән. Аның дәүләт идарәсенә бер генә дә катнашы юк, энем.

– Ләкин мөселманнар бердәм, шуңа аларның дәүләтләре дә көчле түгелмени? Мисырны гына алыйк...

– Ялгышасың, энем. Бер генә диндә дә тулы бердәмлек юк. Шушы ук Коръән китабында язылган сүзләрне һәркем үзенә җайлы булганча кабул итә. Динне уң якка да, сул якка да борырга мөмкин. Исламга килсәк, без, мәсәлән, сөнниләр, бездән арырак шигыйлар яшәп ята. Икесе дә бер үк Аллаһы Тәгаләгә табына. Христиан диненә килсәк, руслар православиедә, аларның митрополитын Константинопольдән билгелиләр. Шул ук вакытта католиклар бар, аларның үзәге Рим каласында. Гомумән, син динне хакимлек өчен кулланырга мөмкин дип, нык ялгышасың. Дин ул күңел тынычлыгы, пакь, ихлас тормыш өчен җибәрелгән. Дөньяны дәүләтләргә, байларга һәм ярлыларга, аксөяк һәм кара халыкка бүлгәләүне исә җирдә уйлап тапканнар.

Күреп торам – синең күңелең хакимлек теләге белән яна. Ул теләк сине эчеңнән ашый, көчсезләндерә, акылыңны югалтуга сәбәпче булып тора. Шуңа күрә ачуыңны тыя алмыйсың, тиз кызып китәсең. Ачу – упкынга илтә торган хис. Динне идарә максатында кулланырга исәпләсәң, арты хәерле булмаячак. Аллага ышану ханнар өчен уйлап табылган камчы түгел...

Айлар арты айлар, еллар арты еллар үтте. Котлы Тимер Үзбәкне Үргәнечтән ерак түгел урнашкан Яңа Шәһәр белән идарә итәргә җибәрде. Биредә ханзадә зур төзелеш эшләре башлап җибәрде. Калада һөнәрчелек, сәүдә үсеш алды. Кызу канлы ханзадә гадел булырга тырышты, үзенә ышанып тапшырылган каланы матурайтырга, зурайтырга омтылды. Ул мәшәкатьләрдән аерылып торып, Ногъманетдин имам янына ай саен барып кайтырга да онытмады.

Әледән-әле Сарайга да килеп китә иде. Ул чакларда Баялун хатын белән һичшиксез очрашалар, озаклап сөйләшәләр. Ләкин Баялун хан тәхете турында бер генә сүз дә кузгатмады. Мөгаен, Үзбәккә Урда хакиме булу насыйп түгелдер. Вакыт артык күп узды – гаиләсен, якыннарын җыеп, Сарайдан чыгып киткәнгә дә хәтсез. Вакыт белән бергә өмете дә сүрелә барды.

Урдадагы хәлләрне ул Сарайда чакта гына белешә дә, Хәрәземгә килеп ирешкән аерым хәбәрләр аша чамалап тора. Күпсанлы яңалыклардан хәтеренә аеруча Илбасмышның фаҗигале үлеме кереп калды. Имеш-мимешләргә ышансаң, хәрби һөҗүмнәрнең берсе вакытында аны билгесез кешеләр юл чатырында суеп чыкканнар. Бу вакыйга бөтен Урданы тетрәндерде – бертуганнарын, хәтта балаларын да аямаган Туктайның бердәнбер варисы нәкъ менә Илбасмыш иде. Инде өзеләм дип торган хан нәселенә турыдан-туры катнашы булган бер генә инсан – Илбасмышның бишектәге баласы калды. Үзбәк әлеге фаҗигагә бәйле бер нәрсәгә игътибар итте – ханзадә үтерелгән вакыт Караны Баялун хатын чакыртып алу белән тәңгәл килде. Берара югалып торып, кире Яңа шәһәргә кайткан нүкәргә ул артык сораулар биреп тормады. Караның йөзе, һәрвакыттагыча, хиссез, җаваплары кыска иде. Шулай да, Үзбәк эчке тоемлау белән сизенде – Илбасмышның үлеме очраклы түгел. Ул Туктайның хәрби һөҗүмнәрдә уң кулы, ышанычлы сәргаскәре иде, каршы якта да дошманнары җитәрлектер. Урда кавеме җинаятьне нәкъ менә тыштан кергән залимнәргә сылтады. Тик Үзбәк яхшы белә иде – Урданың үзендә Туктайга каршы теш кайраучылар күбрәк, һәм алар һәммәсе дә үч алу теләге белән янып яши...

Аны корылтайларга чакырмадылар, Туктай ханзадәне хәрби һөҗүмнәргә җәлеп итмәде. Үзбәкне тәмам оныттылар, аннан өметләрен өзделәр шикелле. Икенче яктан, кан дошманы Кадак та тынычланды бугай, ул инде ханзадәдә тәхеткә куркыныч янаучы кешене күрми иде. Әмма көтә белгәннәргә уңыш иртәме-соңмы елмая. Үзбәкнең дә югарыга күтәрелер көннәре әле алда иде...

*(Дәвамы киләсе санда).*



# Мөхәммәт Мирза

## АДӘМ БАЛАСЫ

***

«Сүз куертып кына
Май төшмәс» дигәнне
Адәм баласының
Туа-тумышыннан
Аңлыйсы килмәде.

***

Хуплап әйтелгән сүз
Үстерә бер башка...
Адәм баласының
Гел шуны көткәне
Бер төртелә ташка.

***

Сүз атып – имгәткән,
Сүз катып – тилерткән.
Адәм баласының
Шуңар битарафын
Чукрак, телсез иткән...

***

Әче сүз – төчкертә,
Төче сүз – укшыта...
Адәм баласының
Сүздә талымсызы
Су эчеп, ут йота...

***

Дәшми калалганы
Һәрчакта яраган...
Адәм баласының
Күң(е)ле төпкеленә
Кем төшеп караган?

***

Сүз – бөек могҗиза,
Тыңлый, әйтә белсәң...
Адәм баласының
Өмете учагын
Тын өреп тергезсәң.

***

Хәбәрнең чыны бар,
Күбрәк – шыр ялганы...
Адәм баласының
Инкарь иткән саен
Шуңар ышанганы.

***

Табаны астында
Эзләп табыласы
Адәм баласына
«Түмгәк» дип, шуңарга
Йөз кат абынасы.

---

Мөхәммәт МИРЗА (1953) – *шагыйрь; Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Биш томлык «Сайланма әсәрләр», «Киек каз юлында», «Тере су», һ.б. күпсанлы китаплар авторы. Казанда яши.*

***

Ярәшеп табылган,
Ярәшеп барылган.
Адәм баласының
Талымсызлары гел
Ябышып тагылган.

***

Җиргә киләсе бар,
Җирдә каласы бар.
Адәм баласының
Соңгы сәгатендә
Күккә багасы бар.

***

Офыктан-офыкка
Үр-таулар арасын
Адәм баласына
Тәкъдире сандыгын
Күтәреп барасы.

***

Мал таба, майтара –
Бөтәя тырышып.
Адәм баласының
Шул мәлдән башлана
Бер-берсен кырышы.

***

Бөресендә көйде
Җиләк аланнарда.
Адәм баласына
Нинди кыш киләсен
Калды фаразларга.

***

Чүплектә көн итә:
Танымаслык йөзе...
Адәм баласының
Язы үтмәс борын
Килеп баскан көзе...

***

Сорау-җаваплары
Акланудан тора...
Адәм баласы үз
Гаепсез-гаебен
Кирәгенчә кора.

***

Җирдә тамырланып,
Җирдә яфрак яра...
Адәм баласының
Нәсел агачында
Гом(е)ре кабатлана.

***

Муза кыл тартканда
Туплар тын торадыр.
Адәм баласыннан
Күкләрдә шул хакта
Күбрәк соралыр...

***

Шатлыгын, кайгысын
Бер җепкә беркеткән
Адәм баласының
Күңеле көй йөрткәне
Картлыгын өркеткән.

***

Нәфсе – күз атканын
Кулы җәһәт алыр...
Адәм баласының
Әҗәткә батканы
Кабалада калыр.

***

Күтәралгән кадәр
Иңенә аласы...
Адәм баласының
Гомерлек нияте:
Кайдан ни табасы...

***

Алып кайтармаган –
Күзгә карап бурлык...
Адәм баласының
Оныкларына ук
Мирас булыр хурлык.

***

Күк – бар уй-гамәлен
Белүче, күрүче...
Адәм баласының
Тәүбә итми торып
Үтмәс үкенече.

***

Мәмләкәтләренең
Кануны, йоласы...
Адәм баласына
Карусыз ярашып,
Тормышын корасы...

***

Уртак теле, дине,
Бердәй йолалары
Адәм баласының
Талымсызлыгыннан
Йолкып йолыр әле!..

***

...Таш-кыяларга да
Күперләрен аскан...
Адәм баласының
Уе җиткән җиргә
Аяклары баскан.

***

Сан өчен туган бар,
Кан өчен туган бар...
Адәм баласының
Кансыз, сансызлары
Туганын куганнар.

***

Кояш белән тора,
Кояш белән ята...
Адәм баласының
Якты көне генә
Гом(е)рен озайта.

***

Кем өчен бил бөгә,
Җигелә кем өчен?
Адәм баласының
Гом(е)ре җитәрме
Җавап тотар өчен?

***

Нидән өлгертсә дә
Көн иткән йортларын.
Адәм баласы үз
Түренә элдерткән
Табынган потларын.

***

Саулык сатылмый
Әмма кыйммәт тора.
Адәм баласының
Таякка калганы
Чатта сорап тора.

***

Уйнаш уйларында
Утырганда кызып,
Адәм баласының
Иңендә фәрештә
«Юк» дип, куйды сызып...

***

Соранып тапканы
Иң түбән мескенлек.
Адәм баласының
Шуңармы әйткәне:
«Дөнья дип, өч көнлек.»

***

Китаплы кавемне
Гел кисәтеп торган...
Адәм баласының
Имгә килмәгәнен
Таш яудырып кырган.

***

Барлап тора барын,
Күреп тора күбен.
Адәм баласының
Түренә менгереп
Таратканын чүбен.

***

Җанисәп ала ил
Ун елдан – ун елга
Адәм баласының
Юкса бар исәбе
Бер Аллаһ кулында.

***

Ишеткән – уйланыр,
Сабакланыр – күргән.
Адәм баласының
Битараф калганын
Куе томан үргән.

***

Өлкәне – үткәрер,
Кечесе – юл сабыр.
Адәм баласының
Әдәп-тәрбиясен
Күреп Күк сокланыр.

***

Күп күргән – күп йөргән,
Хак-дөресен әйтер...
Адәм баласының
Күңеле офыкларын
Чакрымнар киңәйтер.

***

Шайтан, җен – туганнар,
Уртак ниятләре:
Адәм баласының
Җан түренә үтеп
Гомер итмәкләре.

***

Гамәле теркәлә
Үткән һәр көнендә
Адәм баласының
Гомере-тәкъдире
Күкләр хөкемендә.

***

Үткәнен сүткәндә
Килерен гоманлар
Адәм баласының
Тибелеп, сибелеп
Йөререн кем аңлар?

***

Каек көймәсендә
Дәрьяларны кичкән...
Адәм баласының
Теләк-ниятендә
Җил дә уңай искән.

***

«Белмим» дигәндә һич
Авыртмас беләге...
Адәм баласының
җаваплылыклардан
качуда теләге.

***

Тулышып тәгәри
Йөзеннән яшьләре.
Адәм баласының
Кайгыдан, шатлыктан
Тора бар яшәре.

***

Сораганга бирер,
Табын булыр тулы...
Адәм баласына:
«Бүлешергә», – дисәң,
Җыерылыр кулы.

***

Өммәтен, милләтен
Санга сукмадыисә,
Адәм баласының
Иманы-имәнен
Иблис чабып кисә.

***

Тарлыкка күнеккән,
Юклыкка ярашкан, –
Адәм баласының
«Ярар» диячәге
Ярты күз караштан.

***

Ишетүдән күрү –
Бермә-бер үтемле.
Адәм баласының
Күргән саен үсә
Авызында теле.

***

Хәтта гөманламас
Табар һәлакәтен.
Адәм баласының
Югалтуы булыр
Вакыт бәрәкәтен...

***


Барып күрүе бар,
Күреп кайтуы бар.
Адәм баласының
Күреп – күралмаслык
Күңеле кайтуы бар.

***

Төрлелек – гап-гади.
Табигый күренеш.
Адәм баласының
Катлауландырганы
Кырдым ди бик зур эш...

**Редакциядән:**

*Бу айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*



Факил
Сафин

# КҮКЛӘР ҖИРГӘ ТОТАШКАН

ПОВЕСТЬ*

1

Язу өстәлемдә бер дәфтәр пәйда булды. Тышы таушалган калын дәфтәр. Иске кәгазьләр арасында актарынганда табып алганмынмы (бу көннәрдә архивны тәртипкә китереп маташкан идем), әллә өйдәгеләрнең берсе, каяндыр табып алып, күрсен дигәндәй, күз алдыма китереп куйганмы, һич әйтә алмыйм. Урта җиреннәнрәк: күр, укы, уйлан, дигәндәй, киереп ачып та куелган әле. Баштарак моңа әллә ни әһәмият бирмәдем, шулай да ачык дәфтәр күземә чалынган саен нигәдер күңелнең кузгалганын тоя башладым. Байтак ятты ул өстәл читендә игътибар көтеп. Һәрнәрсәнең кайчан да булса үз вакыты суга. Берсендә, дәфтәрне үз алдымарак шудырып, ачык биттәге язуга күз салдым. Битнең өске ягына, ачык итеп «Коры Әлфир...» дигән сүзләр язылган. Шушы ике сүз кайчаннан бирле мыштым-өнсез генә мине күзәтеп, тынычлыгымны алып тордылар түгелме соң?!

Соңгы айларда язу өстәле янына утырырга туры килмәде дисәм дә була. Дөресен генә әйткәндә, күңел җилкенеп алган чаклар, кулның каләмгә үрелергә чамалаган мизгелләре булгалый булуын, әмма, йөрәксенеп, берәр яңа әсәргә тотынырга тәвәккәллек җитеп бетми иде. Элеккеге язучылар әйтмешли, кулдан каләм төште. Сәбәбе дә җитди – син язганнар бүген кемгә кирәк? Бу сорау соңгы елларда каләм әһелләре арасында еш ишетелә. Без, язучылар, үзара сөйләшкәндә дә, үзалдыбызга уйланып утырганда да, шушы сорауга җавап эзләп гасабиланабыз. Безнең язганнарны укучы булырмы? Бүген бераз бардыр да, ә киләчәктә ни көтә? Моннан берничә ел гына элек, татар телендә укытуга игътибар артып, ниндидер күтәрелеш булыр дип адарынып йөргән көннәр бар иде. Милләтнең киләчәгенә ышаныч арткан

* Журнал варианты

Факил САФИН (1954) – *язучы, Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты, «Соңгы көз», «Гөлҗиһан», «Саташып аткан таң» һ.б. китаплар авторы. Чаллыда яши.*

чак иде бу. Әмма уйламаганда-көтмәгәндә, татар өстенә яшен тавы ишелде – туган телне мәктәпләрдән кысып чыгару башланды. Прокурор күзәтүе астында газиз ана телебезне расписаниеләрдән алып ташладылар, татар телен дәүләт теле буларак сүздә түгел, гамәлдә кулланылышка кертүне чын күңеленнән кайгырткан мәгариф министрын эшеннән алдылар. Меңләгән татар теле укытучылары эшсез калды. Әлбәттә, беренче чиратта татар теле дип янып-көеп йөргән, үз эшендә зур уңышларга ирешкән оста һәм тәҗрибәле педагоглар эштән кыскартылды. Чөнки алар бу хикмәтләргә теш-тырнаклары белән каршы иде, фикерләрен кычкырып әйтүдән дә курыкмадылар. Бездә сүзен дәлилләп, рәсми даирәләрнең өйрәткәннәренә каршы фикерне башкалар ишетелерлек итеп әйтүчене өнәмиләр. Алар бүгенге җәмгыятьтә иң куркыныч кешеләр... Билгеле, прокуратура күзәтүендә барган әлеге эшне мәктәп директорлары канун таләпләренә китереп башкардылар – кыскартуга эләккән укытучыларга ашханәдә савыт-саба юучы, ишегалды себерүче, сантехник, җыештыручы хезмәтләре тәкъдим ителде. Ә-ә, син риза түгелмени?! Риза булмасаң – бигайбә, рәхим ит, хезмәт кенәгәңне тотасың да башка эш эзләргә китәсең... Мәскәүнең бу кыланмышына ризасызлык күрсәткән директорлар да булгалады, әмма андыйларны прокуратурага чакыртып, артка юл юклыгын аңлаткан «әңгәмәләр» үткәрделәр. Бу «аңлату» эшләреннән соң бер генә мәктәп директорының да татар теле ягына борылып карыйсы килми иде инде.

Җәмәгатьчелек тә, җитәкчеләр дә, укытучы халкы да татар телен яклау мәсьәләсендә чарасызлар иде. «Тотса мәскәүләр якаң...» Һи, анаң башы, барысы да уңай барганда кәпрәеп йөрүчеләр күп ул, якаңнан борып алсалар, сулышың буыла башласа, ни кылырсың? Татар үзен-үзе яклар хәлдә түгел икәнлеген күрсәтте. Татар – чарасыз милләт... Моны «күрделәр», инде һич тә шикләнмичә, богауны көннән-көн ныграк кысуны дәвам итә киләләр.

Көчсезлекнең сурәте шул: бичара кавем гаеплеләрне үз араларыннан эзли башлады. Таптылар – бәтәч, монда төп гаеп язучыларда икән бит! Алар нишләп сөрән салмыйлар, нишләп мәйданнарга атылмыйлар, нишләп... Нишләп?... Каләм әһелләренә чиләкләп түгел, тонналап пычрак ату башланды. Эшнең башында, әлбәттә, үзләрен «тәтәйдән дә тәтәй» санаган аерым җәмәгать «эшлеклеләре», үзләрен «кәттәдән кәттә» итеп күрсәтү юлында күзе-башы тонган журналистлар, үзләрен «милләт каһарманнары» дип санаучы бушкуыклар тора иде. Алар сайлап-сайлап талантлы, гамьле, туган тел, милләт өчен биниһая эшләр башкарган әдипләрне нәҗескә буярга тотындылар. Үз гомерендә җүнле-башлы эш күрсәтмәгән җилкуар-шантрапага, чын әдәби әсәр тудыра алмаган графоманнарга шул гына кирәк иде, язучылар җыела калса, иң беренчеләрдән булып шушы алабайлар трибунага үрмәлиләр, уңга-сулга интервьюлар тараталар, үзләрендә булмаган акылны башкаларга өйрәтеп азапланалар, алар кулы белән милләтнең фәһемле улларына, кызларына яла ягыла, ачыктан-ачык та, астыртын да гамәлләр кылына, кычкырып-шаулап, яннан үтеп киткән чакларында киерелгән күкрәкләренең җиле тиеп, аң-зиһен томаланган сыман хис итәсең үзеңне. Боларга нидер аңлату, иблиси кыйблаларыннан ваз кичтерү, шушы кара эшләренә киткән җегәр-энергияне файдалы гамәлләргә бору турында сүз кузгату мөмкин эш түгел. Кайчакта, кайбер каты колаклы,

күрә караучы бәндәләргә ачу килеп: «Тыңлый, ләкин ишетми», – дибез, болар исә тыңламыйлар да, ишетмиләр дә, алар белән аңлашырга тырышу – иң зур җүләрлек. Күзләрендә коточкыч мәкер, көнчелек, хөсетлек чагыла. Болар – милләтнең яшәеш, туган тел мәсьәләсендә Мәскәү тегермәненә су коючылар, милләтнең тамырына балта чабучылар. Берчакны, үземә тилереп ябышкан берәүне кызык иттем: бер чарада тегенең әйткән сүзләрен тыңлап тордым да, берничә минуттан, сүз алып, шул ук фикерләрне, сүзгә сүз кабатлап, милләт өчен ниләр эшләргә кирәклеген сөйли башладым. Теге иптәшнең тыңларга түземлеге җитмәде, минем авыздан яңгыраган үзенең фикерләренә үзе үк җилләнеп каршы төшә башлады. Әйткән һәр сүземнән (чынлыкта, әле биш минут кына үзе үк сөйләгән нәмәрсәләр) хата-кимчелек табып, тагын да катырак сүгенергә кereште. Бу адәмгә милләт кирәкми, бары үзен күрсәтер өчен гауга чыгару һәм аны башкаларның аның кыдрачлануын күрүләре кирәк икән бит! Тыңлаучылар, моны тиз сизеп алдылар, теге бушбугазның кыланмышыннан астан гына көлеп утыра башладылар. Менә ничек бит – ул үзен «көрәшче» итеп күрсәтү хакына башкаларны таптар, изәр, хәтта шул юлда милләтеннән дә ваз чигәр. «Милләт бетте, милләт юк ул!» – дип сөрән салучылар шундыйлар бит инде... Әмма иң аянычы – күз алдыбызда мең еллар буена сакланып кала алган, иң авыр чорларны да исән-имин үтәргә насыйп булган, дөньядагы иң камил телләр рәтендә саналган бөек Татар теле, изге Туган телебез, газиз Ана телебез юкка чыгуга таба бара. Ул көннән-көн зәгыйфьләнә, көчен җуя, аңа ихтыяҗ югала, татар үз теленнән үзе ваз кичеп бара. Тел – иң зур байлыгыбыз, буыннан-буынга килгән бөек мирас! Зур өметләр баглап көтеп алган яңа гасыр аңа җеназа укырга җыена.

Шундый вазгыятьтә күңелне иҗатка дәртләндереп кара инде син!.. Язучыларның күбесе шушы хәлдә. Шулай да үзара очрашканда, бөтенләй үк өметсезлеккә бирелмәвебезне сиздерергә тырышабыз, бер-беребезне дәртләндерергә омтылабыз, бу кыргыйлыкка кайчан да булса чик куелачак, иҗат тукталырга тиеш түгел, дигән булабыз. Кайсы дәвердә, кайсы язучыга җиңел булган? Үрнәк дисәң, ерак барасы түгел – Тукай, Бабич, Җәлил, Алиш, Туфан... Татар халкы талантларны биреп тора, ачы язмыш җилләре аларны халык бәгыреннән суырып алып китә тора...

Язу өстәленә сирәк килүнең, бәлки, сәбәбе шулдыр. Бәлки алай ук та түгелдер. Күңелдә берәр әсәр ярала башласа, берзаман ул «тишелеп» чыкмый калмый инде, нигә анда дөньясы ишелеп төшми. «Шагыйрь күңелендә кар яумый да, кыш булмый...» Язучы – халыкның намусы, бу сүзләрне төрлечә боргалап әйтәләр, әмма асылы бер – әдип белән намус төшенчәләре аерылгысыз, чишелмәскә тиешле бер төен.

Язучыны иҗатка «камчылап» торган нәрсә – ул хәтер. Хәтер уянмыйча, каләм эш башламый. Хәтта бүгенге нәрсәләр хакында язарга алынсаң да, алай гына да түгел, нәкъ шушы мизгелдә булган хәлләргә таянып әсәр язарга тотынсаң да, сакта хәтер тора. Хәтер – күңел сагы. Тәҗрибәле каләм ияләре моны яхшы беләләр – күңел тарихы булмаган язучыдан рәтле әсәр көтмә!

Хәтер җилләре исә дә, җанга кагылып куя, шул арада нindидер уйлар теңкәгә тия башлый, зур ниятләр белән нидер язып атмакчы буласың, аннан мең төрле мәшәкать, вак-төяк ыгы-зыгылар белән «гаҗәеп иҗади

ният» дигәнең онытыла, вакыт тузаннары астында күмелә, «кирәксенмисең икән, бигайбә» диптер инде, яңадан искә дә төшеп тормаска мөмкиннәр җилкенеп алган мизгелләр. Югыйсә, бар эшеңне кырык якка ташлап, канатланып, дәртләнеп эшкә башлыйсы гына да, һич тә син теләгәнчә генә барып чыкмый бит ул. Күпме кеше: «аны эшлим, моны эшлим» дип очынып йөри дә, кабына башлауга ук сүнгән мотор шикелле, «тых-пых» килә дә бетә... Иҗатта да шулай.

...Ачык дәфтәрдәге бу ике сүз мине сәер хәлгә куйды. Беркөнне, түзмәдем, сак кына дәфтәргә үрелдем, кулга алдым. Саллы гына тоела бу. Үзеннән җылылык, нур бөркелгән сыман. Тәк, «Коры Әлфир» дигән... Ни өчен, кайчан теркәп куйганмын бу сүзләрне, ни дә булса язарыма азык булыр сыман тоелды микән ул чакта, кайчан язганмын, ни уйлап язган – исемә төшми генә – дәфтәрне актарганда чамалап алдым – монда язылганнарга ун-унбиш еллап вакыт үткәндер, теркәлгән язмалар шуңа ишарә ясыйлар. Дәфтәрне саксыз гына өстәлгә ташлаган идем, үҗәтләнгән шикелле, атналар буе үзенә җәлеп итәргә маташкан теге бите ачылып китте. Аннан миңа чекерәеп ике сүз карап тора...

«Коры Әлфир...»

Әйе, безнең авылда Әлфир дигән кеше бар иде. Хәзерге чор күзлегеннән караганда, гади генә бер абзый иде. Аның турында ни-нәрсә язарга була соң? Берара читтә, зимагурлыкта йөргән, аннан ни сәбәп беләндер авылга кайтып төпләнгән. Бүтән авылдан чыкмады да кебек. Ничектер сәеррәк, аңлашылып бетмәгән бер абзый иде ул. Кушаматы Коры иде, әтисеннән, бабасыннан калган кушамат, ягъни борынгыдан килә. Иң сәере шул – аны ни өчен дәфтәремә теркәп куйдым соң әле? Әллә берәр әсәремә персонаж буларак кертеп җибәрергә әзерләндемме? – Инде хәзер төгәл генә әйтә алмыйм.

Хәтер җиле искән-искән дә, адәм баласының тормышындагы бик күп нәрсәләрне оныттырган сыман ул чагындагы уй-ниятне дә себереп кенә алып киткән икән.

Дәфтәрне ябып, өстәл читенәрәк шудырып куйдым.

Икенче көнне өстәл янына килсәм, дәфтәр тагын, ачылган хәлдә, өстәл уртасына күчкән. «Коры Әлфир...» дигән сүзләр «бездән котылыр чараң юк!» дигәндәй, чәчрәп күземә кереп торалар. Кайчандыр үзем укыткан авылда фатир хуҗасы Гафиятулла бабайның карчыгы әйтмешли, бер-бер хикмәте бардыр инде моның...

## 2

Шәһәр һавасы тәмам туйдырса, туган авылыма кайтып киләм.

Авылга кайткан һәр кешене зират каршы ала. Олы юл буенда ул.

Авыл, моннан йөз еллар элек, якын-тирәдә иң зурлардан булып, волость үзәге саналган. Шуңадыр инде зираты да зур, керсәң, урап чыкмалы түгел. Хәер, өстәрәк «Иске зират» та булган. Анысын сөреп, юкка чыгарып бетергәннәр. Мин белгәндә, басу өстендә ваткаланып беткән ташлар аунап ята иде әле. Олылардан ишеткәнем булды, элек, имеш, иске зиратны «Чирмеш зираты» дип йөрткәннәр. Зур булганмы, кечкенә каберлек булганмы анда, кызыксынып, сораштырып калмаганмын. Хәер, ул чакта

ук белүчеләр дә булмагандыр инде. Көннәрдән бер көнне, могҗиза булып, барлык әрвахлар күтәрелеп чыгып, «өстә калганнарга» үз күңел тарихларын сөйләп бирсәләр, акылдан язарлык хәл булыр иде ул...

Гадәткә кергәнчә, авылга үзем генә кайтып киләмме, гаилә беләнме, юлдан үткән-сүткәнне тын гына күзәтеп утырган каберстанга керми китмим. Анда минем әби-бабайларым күмелгән, әткәй, әнкәй җирләнгән, монда «күченгән» туган-тумачаның исәбе-саны да юктыр. Нәселебез тармаклы, нәсел очларының күбесен ныклап белеп тә бетермим инде. Шушында ук ике Фәйрүзә апам җирләнгән. Берсе – тугыз айлыкта оҗмах кошы булган, икенчесе – туганнан туган апам, утыз яшендә якты дөнья белән хушлашты. Һәммәсе дога көтә...

Зират зур булгангадыр инде, вафат булганнарны күмү-урнаштыруның борыңгыдан килгән үз тәртибе бар. Әгәр кем дә булса, бакыйлыкка күчкән туган-тумачаларының каберләрен тапмый йөрсә, аңа шундук авыл кешеләре ярдәмгә килеп, «эһ» дигәнче аңлатып бирәләр: «Ә-ә, син, туган, Вәч-вәч Вәли оныгы буласыңмыни?! Аларның йортлары Кызылъяр урамында иде бит әле. Син, туган, бер дә аптырама, кәберстанга кергәч, Әлмәт ягына табан йөз илле адымлап барып, Үмер урамы кулыннан эзлә әби-бабаңнарны. Ул урамда яшәүчеләр бакыйлыкка күчкәч, шунда җирләнә, сезнең урам әрвахлары анда...» – дип, «төгәл адресны» күрсәтәләр. Вафат булганнар, исән чакларында кайда яшәүләренә карап, зиратта Югары оч, Түбән оч, Базар урамы, Кызылъяр урамы, Тавык урамы, Алачык урамы, Кәнсә урамы дигән биләмәләргә мәңгелек «пропискага» керәләр. Билгеле, авыл советындагы шнур кенәгәсендә мондый урамнар күрсәтелмәгән, бер генә җирдә дә әлеге урамнарның булуы хакында мәгълүмат табылмас, әмма халык авылны шул рәвешле бүлеп куйган, зират мәсьәләсендә бу бүленеш, язылмаган канун рәвешендә, бәлки инде ике-өч йөз еллар дәвамындадыр, яшәвен дәвам итә. Мин белгәндә, шушы язылмаган канунны Корыныкылар гына бозды. Коры Әлфир, соңгы сәгатьләре якынлашканын сизеп, вафаты алдыннан балаларына әйтеп калдырган икән: «Тавык урамында яшәп изаландым, күзем йомылгач, мине Базар урамыныкылар тирәсенә күмегез», – дигән ди. Базар урамында элек-электән хәллерәк кешеләр яши иде.

**3**

Язу өстәле янына утыргач, ихтыяри-мәҗбүри дигәндәй, вафатыннан соң Тавык урамыннан китеп, Базар урамына елышкан Әлфир абый турындагы истәлекләремне барларга тотындым. Күңелне бер кузгатып кына җибәр, аның төпкеленнән әллә нәрсәләр өскә калкып чыга, һушлар китмәле. Истәлекләр янына кайчандыр, кемнәндер ишеткәннәре дә өстәлә бит әле аның, уйлап чыгарасы да юк.

Аларның нәселе, дәфтәргә язылганча, Коры кушаматлы иде. Әлеге ләкаб бабайларыннан ук килә булса кирәк. Әлфир абзыйның атасы яки бабасы турында сүз чыкса, Коры кушаматын кыстырмый калмыйлар иде. Әмма бу нәсел тарихын күрсәтми, аларның холкын билгели торган ләкаб иде булса кирәк. Коры кушаматында вәкарьлек тә, тәкәбберлек тә, минминлек тә, башкаларны санга сугып бетермәү дә, үзен күрсәтү теләге дә бар сыман тоела. Әлфир абыйга да ят түгел иде бу сыйфатлар, кешеләр

арасында берәр бәхәс яки ызгыш-фәлән чыкса, сүз куертып тормыйча, теш арасыннан бер-ике сүз саркытып чыгара иде дә, бәхәскә нокта куеп, важный кыяфәттә китеп бара иде. Әйттем – бетте! Ни дисең инде, әти-бабаларыннан килгән коры холык! Аның кем беләндер иркенләп, авылдагыча әйтсәк, җәелеп сөйләшеп торганын күргәнем булмады. Ул, берьяктан караганда, үз дөньясында гына яшәүче сәер адәм иде кебек, икенче яктан, аның белмәгәне-кызыксынмаганы юк, ни хакында сөйләшсәләр, шул хакта, тавышын бөереннән чыгарыбрак, аңа игътибар итәләрме, юкмы, сүз кыстырмый калмый иде. Шунысы кызык: Коры Әлфир кибет тирәсендә аерым игътибарга, хәтта ихтирамга дисәм дә, дөрес булыр, ия иде, чөнки мин белә-белгәннән бирле, ул, кибеттә, потребкооперация хисап-сайлау җыены тарафыннан сайланып куелган ревкомиссия рәисе булып йөрде. Әлеге вазифаны ул зур җаваплылык белән башкарып килде һәм, авылдашлар уйлавынча, алыштыргысыз булып санала иде.

Әлфир абыйга кагылышлы хатирәләр минем күңелдә беренче сыйныфта укыган чыктан беркетелеп калган икән.

***

...Мәктәптән кайткач, миңа дүрт яшьлек сеңлемне карау эше йөкләнә.

Шулай беркөнне, сеңлем белән өстәл астында «өйле» уйнаган булып мәш киләбез, әнкәй казан астына ягып җибәрергә әзерләнә – олы пычак белән сап-сары сөян пүләненнән чыра телә.

Йөгереп диярлек алтынчы сыйныфта укучы Гамил абый кайтып керде. Көч-хәл белән генә тын ала, үзе нидер әйтергә азаплана, әмма артык кабаланудан, ни сөйләгәнен аңлап бетереп булмый.

Гамил абыйның болай «гөрс» кайтып керүе безне уеннан, әнкәйне эштән аерды. Нәрсәдер булган чакта бала-чага зурлар яныннан китми, колагын шомрайтып тыңларга әзерләнә бит инде, сеңлем Рәмүзә белән икәүләшеп өстәл астындагы «өебезне» калдырып, шыпырт кына сәке өстенә үрмәләдек. Әнкәй эшеннән бүленеп, Гамил абыйга карап торды да бераздан йомшак кына әйтеп куйды:

– Ул кадәр ни булды? Башың-күзең тонган...

Безнең өйдә балалар арасында иң йөремсәк кеше Гамил абый иде. Өлкәнрәк абый-апаларның алай килəп сарып йөрергә вакытлары да булмагандыр, укудан соң, өйгә кайтып капкалап алалар да, һәркайсы үзенә тәгаенләнгән вазифаларга керешәләр, Кем Тауасты чишмәсенә суга дип ашыга, кемдер, абзарга чыгып (аны абзар диюче юк иде бугай бездә, лапас дип сөйләшә идек), мал асларын чистарта, кемдер утын ярып алып керә. Хәер, ярырлык утын сирәк була, җәй көне, уттай кызу эш өстендә утын әзерләтеп йөриләр, ди, колхозда! – Гадәттә, әткәй кыш уртасында бригадирдан ат сорап, айга бер-ике мәртәбә ерак булмаган Имәнлек урманыннан коры-сары төяп алып кайта иде. Башкасына рөхсәт юк, урманчы (лесник) тотса, башың бетә, хәзер суд юлын таптата башлыйлар. Монысын мин әткәй белән әнкәйнең сөйләшүләреннән еш ишетәм, шуңа күрә бәләкәйдән «суд» сүзе, иң куркыныч нәрсәне аңлаткан төшенчә буларак, җаныма сеңеп калды.

Гамил абый, ниһаять, тынычлана төште, сүзләре аңлашыла башлады:

– Коры йөри!..Мәгъфүрҗаннардан чыгып килгәнен күрдем.

Әнкәй сабыр тавыш белән Гамил абыйны бүлдерәсе итте:

– Ни сөйләп маташасың соң син, Аллаһ колы?! Нинди Коры ул тагын?

– Соң инде... Корыны да белмәскә! Теге, радио тикшереп йөри торган абый инде. Тавык урамында яшиләр алар.

– Шулай диләр аны баштук. Әлфир абыең радио тикшерергә чыккан инде алайса. – Әнкәй кабалана башлады. – Тиз генә өйне җыештырып алыйк.

– И, ул Корыны... Гел иснәнеп йөри инде, име, әнкәй?

– Кем әйтте алай дип? – Әнкәйнең тавышы ачу төсмерле иде.

Гамил моны сизенеп, хәлне йомшартырга теләде.

– Кем әйтте дип... Мәгъфүрҗанның атасы инде. Әхмәй абзый...

– Кем ни әйтмәс? Син кабатлама, бигрәк тә ләкаб белән эндәшмә кешегә.

– Ләкаб? Нәрсә ул? – диде Гамил абый, аптырый төшеп.

Бу сүзне минем дә ишеткәнем юк иде.

– Менә әйттең бит әле Әлфир абыеңны Коры дип. Шул була инде ләкаб.

– Кушаматны әйтәсең икән. Аны бөтен авыл шулай ди бит. Коры булгач, Коры инде.

Әнкәй чын-чынлап ачуланды.

– Башкалар дисеннәр, ә син әйтмә! Олыны олы, кечене кече итә белергә өйрән, син бәләкәй малай түгел – алтынчы сыйныфта укыйсың.

Гамил абый тынычланырга уйламый, тагын сәерсенеп сорау бирде:

– Сыйныф ни дигән сүз ул, әнкәй?

– И балакайлар... Мәктәбен әйтер идем, туган телне бозып бетерәләр, татарча дәреслекләрегезне ачып карасам, шаклар катам – яртысы русча, чиреге чит телчә, калган чиреге татар теле... Шул булдымы туган тел, газиз ана теле? Сез бергә укыган төркемегезне класс дип йөрисез, без аны сыйныф ди идек элек.

Мин инде бераз исәүрәк, әнкәйнең бик күп еллар элек укытучы булып эшләгәнен ишеткәнем бар иде. Шуңа күрә ул күрше-тирәдәге апалар сыман өтек-төтек сөйләшми, ничектер йомшак, матуррак сөйләшә, безне дә сеңлем белән әйткән сүзнең тәмен белергә өйрәтә. «Бер-берегезгә телегез тәмле, йөзегез ямьле булсын, – ди ул, бер-бер ямьсезрәк сүз ычкындырсак. – Алтыдагы – алтмышта, кечкенәдән матур сөйләшергә өйрәнеп үсәргә кирәк!»

– Әлфир абыең – колхозның радиоузелы мөдире. Шуңа өйдән өйгә кереп, йорт борынча радиоларны тикшереп чыга ул. Гел йөреп тора.

Әнкәй «гел йөреп тора» дисә дә, нигәдер мин ул «Әлфир абый» дигән кешене бер дә күргәнем юк иде моңарчы. Искә алмадым микән, тышта уйнап йөргән чакка туры килдеме аның безгә керүе – бу абыйны минем белгәнем-күргәнем юк иде.

– Нигә тикшерә соң ул? – диде Гамил абый бирешәсе килмичә.

– Анысын үзеннән сорарсың. Хәзер исә идәнне себереп чык, күрәсең бит, бәрәннәрнең «шомырты» белән тулган өй. Ә син, улым Сәяр,  – дип, миңа эндәште әнкәй, – сәкедәге мендәрләрне әйбәтләп өеп куй.

Гадәттәгечә, сеңлем Рәмүзәгә өйдә эш табылмады. Ул соры песи баласы белән уйнап утыруын белә. Рәхәт бәләкәй кешегә. Нишләсә дә ачуланмыйлар, эш килеп чыкса, аңа кушып та карамыйлар.

Өйне рәткә кертеп бетерүгә, ишекне шакыдылар.

Әнкәй йөгереп диярлек барып, ишекне ачып җибәрде.

– Керегез, кер... Әлфир икән әле, – дигән булды аның нишләп йөрүеннән бөтенләй бихәбәр шикелле.

Безнең ишекне моңарчы бригадир Рәис абый гына болай шакып керә иде. Тик ул иртүк шакый ишекне. Ул чакта инде барысы да уянып, һәммәсе аяк өстендә була. Без Рәмүзә белән җылы юрган астында. Рәмүзә йокы бүсә, мин шыпырт кына өйдәгеләрнең ни эшләгәнен күзәтеп ятам. Җылы юрган астыннан бер дә чыгасы килми. Шул чакта сак кына ишек шакыйлар. Ул арада, «керегез!» дигән сүзне көтмичә, ишек ачылып китә, «исәннәрмесегед!» дип, яшькелт төстәге олы кожан кигән берәү килеп керә. Шушы була инде ул бригадир Рәис абый. Үзе юкта аны Тәвәй Рәисе дип тә җибәрәләр, әмма үзенә алай әйтүче юк, әткәй: «Рәис энекәш» дип кенә тора. Рәис абый исә куеныннан калын дәфтәр чыгарып, әткәйгә эш куша.

– Бүген, Хәбирҗан абзый, фирмедә буласың. Балта, пычкы ал. Түбә ныгытасы бар, Ысмай абзый белә, агач ярдырып, түбәне такта белән яптырып кую мәслихәт. – Ул, җавап көтмәстән, дәфтәрен ачып, карандаш белән ниндидер билге сала. – Нәрәт бирелде, абзый, әйбәт кенә эшләргә язсын, – дип, җиңел адымнар белән чыгып та китә.

Әткәй, «ярар, ярар», – дип, аны озатырга чыга. Ишегалдында ни турындадыр бераз сөйләшеп торалар әле. Тик мин аларның ни сөйләшкәннәрен ишетмим, тыңлап ятарга теләк тә юк, күзләрне тагын йокы эләктереп ала да керфекләрне йомдырып куя.

Инде Әлфир абыйга кайтыйк.

...Ишекне каерып ачып, өйгә таныш булмаган абый килеп керде. Озын буйлы (бездә аны «дастыен» диләр), төскә чибәр, әмма ачык йөзле түгел сыман. Нигәдер сөмсере коелган шикелле иде аның. Кәефсез генә:

– Исәнмесез... – диде.

Безнең авылда болай сөйләшмиләр. Әнә бригадир Рәис абый ничек матур, ягымлы итеп әйтә: «Исәннәрмесегед» – ди. Вәт бу безнеңчә. Ә болай төксе генә «исәнмесез» дию колакка ятып бетми. – Йә, ни эшләр майтарып ятасыз монда? – диде ул, сытык чырай белән. – Тикшерергә чыксам, бөтенесе тәртиптә, понимаешь, чыгып китүгә бөтенегез радио тирәсендә бөтерелә башлый, – дип, бер сүз көтмәстән, аяк киемен сала башлады. Ул безнең өйгә килеп кергән мәлдән үзен хуҗа, каршы килмәслек абруй иясе итеп тота иде булса кирәк.

Чыннан да, бу абыйны беренче күрүем иде. Мине иң нык гаҗәпләндергәне – Әлфир абыйның елтыр соргылт ботинкалары булды. Өр-яңа, күз явын алырлык итеп ялтырап торалар. Ул ботинкасы өстеннән кара кәлүш (безнеңчә эрҗинкә) кигән. Килеп керүгә, беренче эш итеп, аерым бер вәкарьлек белән димме, шул кәлүшләрен салып куйды. Аннан бернинди чакыру көтмәстән, түргә атлады. Түр диварда безнең өйнең иң кадерле әйбере – кара эшләпәле радио эленеп тора иде.

Ул радио дигән нәмәрсәне дөньяның серле бер хикмәте итеп саный идем. Эшләпә артында кечкенә йодрык кадәрле бер тартмасы бар. Күпме генә әйләндереп-тулгандырып карасам да, аңлый алмыйм, сөйләүчеләре кайда утыралар – шушы сергә һич төшенә алмый изаланам. Әткәй, ай саен диярлек радионы эленгән җиреннән алып, шул кара каты кәгазьдән

эшләнгән «эшләпәне» дымсу чүпрәк белән сак кына кагылып сөртеп ала. Миңа җай чыга, тәвәккәлләп, күптән кызыксындырган сорауны биреп ташлыйм:

– Әткәй, бу радионың кешеләре кайда соң? Нишләп алар безне күрәләр, без аларны күрмибез?

Әткәй көлемсерәп, чүпрәк белән маңгаемны сөртеп алгандай итә.

– Һе, «безне күрәләр», дисеңме? Каян алып әйтәсең?

– Күрмәсәләр, шулай бөтен кеше җыелгач кына җырлый башламаслар иде алар. Бер дә син өйдә булмаганда җырламый бит ул.

Әткәй көлеп җибәрде.

– И бала, бала! Соң, кич бөтен кеше эштән кайткач, ашагач, өй эшләрен бетергәч кенә, концерт башлана. Программа диләр, ишетә торгансыңдыр инде, шулай көйләнгән ул радио. Бер дә безне күзәтеп утырмый.

Мин исә андагы абый-апаларның җырлауларына мөкиббән, барлык кешене булмаса, һич югы мине күрмәүләренә ышанасым килми.

Тагын да үҗәтләнеп, сораштыруны дәвам итәм:

– Кешеләре кайда соң бу радионың? Кайда утыралар, кая басып җырлыйлар?

Әткәй эшләпәне борып, арттагы шул йодрык кадәр нәрсәне күрсәтә.

– Шушында инде аның хикмәте, улым. Шушыннан сөйли дә, җырлый да инде ул.

Берсендә сүзгә әнкәй дә кушылды.

– Килде бит заманалар, концерт карыйм дигән булып, салкын клубка барып катып утырасы да юк. Иренмә, тыңла гына – Рәшит Ваһапов та өйгә үзе килеп керә, Усман Әлмиев тә, Мәрьям Рахманкулова да, Зифа Басыйрова да. Рәхәтлән тыңлап. Җырлары йөрәккә май булып ята.

– Әле тагын бер шәп җырчы ишетелгәли башлады, – диде әткәй, горурланган сыман. – Илһам Шакиров, безнең Сарман ягыннан икән.

– Кара әле, сорыйсым килеп йөри идем, Мәхтүрә сөйләп торган иде беркөнне. Аны, көнләшеп, Рәшит Ваһапов парахудтан суга ыргыткан, ди бит. Көч-хәл белән тартып алганнар. Судан алгач, ике бидрә су чыккан үзеннән. Бичаракаем, ничек үлми калган диген?..

– Мәхтүрәгә куш җыен юк-бар белән авыз чайкарга.

– Алай димә, аның өч малае Казанда укый. Шулардан чыккан сүздер, үзе әйтмәсә дә, әйбәт беләм, малайлары сөйләнгәннәрдер бу кайтуда. Һәдиягә шулай дип әйткән идем, ул бөтенләй башкача сүз йөртә.

– Һәдиянең Казанда кеме бар? – диде әткәй, әнкәйне үртәгәндәй.

– Абыйсы Казанда эшли. Хәрби заводта. Анда бөтен хәбәр иң беренче булып килеп ишетелә икән. Һәдия әйтә: Рәшит Ваһапов Илһам Шакировка кырын күз белән дә карамаган, тегесе яшьлек җүләрлеге белән, Рәшит Ваһаповка өч тапкыр пычак белән кадаган икән. Әтисе сугыштан нимес пычагы алып кайтып, чормага яшереп куйган икән, ди. Шуны табып алган, ди... Берәрсе котырткандыр дип әйтәләр, ди. Тик торганнан кеше кадәр кеше алагаемга кем китереп кадасын инде, җә? Рәшит Ваһаповның ике банка каны аккан. Күргән кешеләр булган. Рәшит Ваһапов бик әйбәт кеше икән, каны чаптырып агып тора, ди, үзе һаман: «Илһам Шакировка тимәгез, әле яшьлеге белән генә шулай кылана, вакытлар үткәч, аңлар әле», – ди икән, ди.

Кемгә ышанырга да белмәссең, андый җирдә шулайдыр инде, әртистләрдә ул акча, ул ашау-эчү, ди. Барлыкка чыдый алмыйлар, юклыкка түзә кеше. Әле үткән атнада гына булган хәлләр, ди.

– И карчык, карчык! Син бит бераз сабак алган кеше, мөгаллимә булып та эшләдең. Радио сөйләп тора, бу көннәрдә Рәшит Ваһапов Казакъстанда, чирәм җир күтәрүчеләр янында концерт куеп йөри, Илһам Шакиров Үзбәкстанда, Ташкентта концерт куя икән. Алар бит бер-берсе белән очрашып, иркенләп сөйләшеп тә утыра алмыйлардыр.

Минем исә аларның сүзләре колакка керде дә чыгып та китте. Ничек тә радиога кереп оялаган кешеләрне күрәсе килә. Әткәйне тинтерәтүне дәвам итәм.

– Әйт инде, әткәй, бәләкәй генә савытка ул кешеләр ничек сыялар, ә?

Әткәй миннән котылу өчен нидер уйлап чыгарып сөйли башлады.

– Менә, улым, шул җырчыларны Мәскәүгә алып барып, бәләкәй ишләрен ясаталар. Чынлыкта алар зур гәүдәле, чибәр кешеләр бит инде. Ә ишләре бәләкәй генә, энә күзе чаклы гына икән. Заводта һәр ясалган радиога шул бәләкәй ишләрне урнаштыралар икән. Шулар сөйли дә, җырлый да. Һәр радиода бар алар. Мин Нәби бабайларның читәнгә чыгарып элгән эшләпәле радиоларын күз алдына китердем.

– Ә радио ватылса? Кешеләре нишли? Кая китәләр алар?

Әткәй бу сорауны көтмәгән иде булса кирәк, аптырабрак калды.

– Ватылса дип инде. Аның кешеләре дә ватыла инде, радиодан төшеп, коелып бетәләр. Ватылгач, нишләргә соң? – дип, үзе миңа сорау бирә башлады.

Мин «белмим шул» дигәндәй, иңнәремне җыерып куйдым. Нигәдер әткәйнең сүзләре мине бик үк ышандырып бетермәде. Монда ниндидер башка сер булырга тиеш. Онытмасам, мәктәптә укучы абыйлардан сорап карармын әле.

Бу сорау әлегә һавада эленеп тора, Әлфир абый радио тирәсендә булаша. Аннан сорасаң, шәп булыр иде дә, бер дә күтәрелеп карамый, төксе кыяфәттә нидер чокчына.

– Апа, карагыз, – диде ул, озын отвёрткасын колак артына кыстырып. – Менә бу ике тишекле әйбер – розетка дип атала. Розеткага радионың вилкасы кертеп куела. «Папка-мамка» диләр аны, ну бусы сезгә аңлашылмый.

– Бу кадәр нәмәне ничек аңламак кирәк? – диде әнкәй, Әлфир абыйның җаена торырга теләп. – Ярый әле, син бар, ничекләр башың җитә?..

Әлфир абыйның йөзе бераз ачыла төште.

– Аңламыйлар шул! – диде ул, тавышын күтәреп. – Узелның көче җитми, кайберәүләр җай таптылар – радионың тавышы ишетелми дип, вилканы авызга тыгып юешлиләр дә, розеткага тыгып куялар. Шуннан шул... Бу өйдә радио кычкырып сөйли башлый, ә күршеләр колакларын куеп тыңларга тиешләрме? Әле Миңнегалим абзыйлардан бик ачуым килеп чыкты. Бөтен семьялары белән төкерәләр вилкага, чёрт возьми! Тутыгып, розеткага сылашып, катып калган вилкасы, көч-хәл белән тартып алдым. Йолкып кына алыр идең, закун кушмый. Мине шундук җавапка тартачаклар. Совет өендә радио сөйләп, җырлап торырга тиеш. Аннан... Заманасы нинди бит, андый-мондый хәл була калса...

– Була күрмәсен инде, Әлфир энем...

– Булсын димим. Ну бездән тормый анысы. Радио һәр өйдә эшләп торырга тиеш. Миннән шуны таләп итәләр. Безне дә тикшереп торалар, әллә син... Үз эшемне беләм, шуңа күрә минем белән бәхәскә кереп маташмасыннар. Миңнегалим абзый: «Кем син безнең өйгә кереп актарынырга?» – дигән була. Кычкырып әйттем: «Мин радиоузел начальнигы булам!» – дидем. Алай-болай эшкә аяк чалып маташсалар, районга барып, судка бирәм. Белсеннәр кемнең кем икәнен!

– Кара син аны... Кара син аны, – дип, ни дияргә белми, бер үк сүзләрне такмаклап тора башлады әнкәй. – Бик куркынычка китә түгелме соң, Әлфир энем. Сугыш алды елларында төрле гаепләүләр белән ярты авылны алып киттеләр бит. Хәзер дә шул хәл килеп чыкмаса ярар иде, дим. Миңнегалимнең аяксыздан күтсез җиде бала. Аны алып китсәләр, нишләрләр?

– Китәсе килмәсә, төкермәсеннәр вилкага! Әйткәнне аңласыннар! Бөтенләй санга сукмаган булалар. Әйтмәгәч тә...

– Балалы өйдә ни булмас инде. Кайбер чакларда бигрәк ишетелми радиосы, бик тыңлыйсы килә, бер дә ишетелми бит. Аптыраганнан...

– Аптыраганнан? Менә үзең әйтеп торасың, апа – сездә дә бар андый хәл. Тик монда һушлы кеше маташа – вилканы да, розетканы да чистартып торасыз. Имеш, Әлфир сизми! Бер чакрымнан беләм мин кемнең ни кыланганын. Эндәшми йөри дигәч тә, барысын да күрәм, барысын да беләм. Яшереп маташасы юк. Сез дә төкерәсез вилкага.

Әнкәй югалып калды.

– Төкерә дип... Болай, су белән генә чылатып...

Әлфир абый кабынып китте.

– Вәт, кешеләрдәге наданлык! Су да шул юешлек бит инде. Шулай ук бөтен линиянең җегәрен суыра торган нәрсә. Юк, су да ярамый! Соңгы тапкыр әйтәм, апа, тагын бер кабатланса, акт язмыйча булмас. Колхозга кертеп бирәм, Вәдүтов теләсә ни эшләтсен. Колагыгызга киртләп куегыз! Имеш, мине алдыйлар, розетка-вилканы чистартып торалар... Тагын өч-дүрт мәртәбә наждак кәгазе белән ышкылагач, вилкагызның контакты югала, аннан шытыр да мытыр. Капут радио дигән сүз.

Әнкәй хәлнең шактый катлаулану ихтималы барлыгын сизеп алды. Колак бар бит, мин инде уңны-сулны аерам, ни дисәң дә, мәктәп укучысы! Кайчакларда әткәй белән әнкәй сөйләшкәнне читтән генә тыңлаштырып утырам, шуңа күрә белеп сөйлим. Сугыштан кайткач, бригадир итеп куйганнар аны, эшенә тел-теш тидерерлек булмаса да, колхозга яңа партком секретаре – Гашимов килгәч, әткәй белән борчаклары пешми башлаган. Турырак әйтә торган кеше шул ул. Бригадирлыктан да алдылар үзен, шуннан бирле җүнле-башлы эшкә дә кушмыйлар. Инде Әлфир дә утка май өстәсә... Юкәдә икән чикләвек диярсең, әнкәйнең күзләреннән ярым курку, ярым чарасызлык чагылып үтте. Бу Әлфирне тынычландырып, җайлап-майлап дигәндәй чыгарып җибәрсәң дә ярар иде дә... Хәбирҗан ни әйтер икән соң?

Шулай да әнкәй ныклы карарга килеп, Әлфир абыйга эндәште:

– Кем, Әлфир энем, көне буе өйдән өйгә йөреп ачыгып та беткәнсеңдер

инде, чәйләп алсаң, дим. Мичтән яңа гына көлчә дә чыгарган идем. Каз мае белән майлап...

Әлфир абый ничектер йомшабрак китте.

– Чәй дип... Көлчә дип... Тамак ачты инде анысы. Өч йөз йортны урап чыкканчы атна үтә. Узелда да эш бетәсе түгел... – Сүзен өзеп, бераз тын торгач, бала-чага ишетмәсен дигәндәй, әкрен генә әйтеп куйды: – Баш авыртып тора, апа, Хәбирҗан абзыйның запаска калдырган нәмәсе юкмы? – Күзләрендә ялвару, тәкатьсезлек очкыннары чагылып үтте. Шул сүзләрдән соң тирән сулыш алды да бер мәлгә әнкәйнең йөзенә текәлеп катып калды.

Әнкәй «нәмә» сүзен аңлап ук җиткермәде сыман.

– Ул «нәмә» ни-нәрсә була соң әле, Әлфир энем?

Тегесе, «шуны да аңламагач» дигәндәй, муенын боргалап алды.

– Соң, апа, белмәгән кебек... Ни инде, бер яртысы юкмы Хәбирҗан абзыйның, дим. Кара көнгә саклап тота торганы. Кеше белән эш итү бер дә җиңел түгел, нервылар бетә...

Әнкәйнең зиһене ныклап эшли башлады бугай: «Берәр җамаяк тотса, кантурга кереп әләкләшеп йөрмәс бит инде», дип уйлагандыр инде үзенчә.

– Аллага шөкер, Хәбирҗан абыең аның ишене тотмый үзе... Сугыштан кайткан көннән намазга басты. Шулай да кирәге чыкса дип, бер шешә алып куйган иде. Кискән ишек бит, төрле кеше килеп керә. Әйдә, ачуланмас әле, бик арып, йончып та киткәнсеңдер кешедән кешегә йөреп... – дип, шкаф артыннан чүлли тартып чыгарды. – Менә шушы нәмә...

Әлфир абыйның йөзенә кызыллык йөгерде. Кабат кыстаганны көтмәстән, өстәл янына утырып, көлчәгә үрелде.

– Һем...һем-м... Көлчәне минем Фәрдия тәмле пешерә, иркенләп ашарга гына вакыт юк. Узелда көн үтә. Районнан шалтыратып, белешеп кенә торалар. Эшлиме авылда радио, юкмы, мәсәлән. Эшләмәсә, ни өчен эшләми? Җавап бир син аларга. Хан заманындагы аппаратураларны көн саен эшләтеп кара! Лампалары яна да чыга, ярый минем элекке заводта эшләгән дуслар бар, шулар җибәреп торалар. Башка авылларда хәл ничек? дип сора. Әйтәм: айлар буе лампа таба алмый изалараналар. Әгәр торым-торым һәр йортны тикшереп чыкмасаң, ишетер идегезме радионы? Юк, җырын да тыңлый алмас идегез, соңгы хәбәрләрне дә. Ни булмас дөньяда? Америка атом бомбасы дип ажгыра. Безнекеләр дә ясады аны ясавын. Ни килеп чыгар? Юк, радиосыз булмый! Менә апа, ышансаң ышан, өч йөз йортлы авылда чәй эчәргә өч кенә өйдә эндәшәләр миңа. Сөләйман картның карчыгы Закирәтти, Бану әби һәм сез... Бетте, шуның белән вәссәлам. Санламаган булалар. Имеш, корыны бушка аударып йөри. – Кулына чүллине алып, капкачын теше белән каерып ачты да, буш стаканга коеп, маңгаена чыккан тирен сөртеп алды. – Фу, чёрт, баш авыртуга чыдап булмый иде, әйбәт булды әле, – дип, стаканны авызына каплап та куйды. – Көлчә кисәген иснәп, өстәлгә куйгач, иркен тын алып, ачылып сөйли башлады.

– Апа, сезнең олы малай белән бер класста укыдым бит мин.

– Истә, энем, истә, – диде әнкәй гадәттәгечә йомшак тавыш белән.

– Истә булмаска, Һади белән гел бергә булдык инде. Безне физикадан Мохат абый укытты бит. Мохат абый дип йөрттек инде, югыйсә мулла кушкан исеме Муллахмәт диләр иде. Мулла дигәнне килештермиләр

бит, апа, шуңа кыскарткannар исемен. Ну Мохат абый шәп укытучы иде! Җидене тәмамлагач, алдынгы укучылар дип, Һади белән икебезгә юллама биреп, ФЗУга озатты. Колхозда чиләнәсе идек югыйсә. Һади Казанга китте, күрдем, газеталарда басып чыгардылар сурәтен. «Булачак инженер», дип.

Әнкәй олы абый турында сүз кузгалгач, шкаф башыннан ак чүпрәккә төрелгән әйбер алып, сәкегә куйды, сынаган төсле Әлфир абыйга караш ташлады. Аннан, тәвәккәлләп, төргәкне сүтеп, аннан матур итеп эшләнгән зур гына шакмаклы бер нәрсәне кулына алды һәм тегенең янына килеп басты.

– Һади димәктән, энем, җәй көне посылка белән шушы әйберне җибәргән иде. «Шушының белән эш итегез, «эшләпә» радио вакыты түгел», дип язган...

Әлфир абый әнкәй кулындагы саллы гына шакмаклы нәмәрсәне күргәч, тончыга язып, урыныннан сикереп торды.

– Юк, юк! – диде ул, буыла төшеп. – Якын да китермәгез, чыгарып ташлагыз моны! Ике каналлы радио бит бу! Шәһәрдә ярый ул, анда рәхәт, көне-төне сөйли радио, радиостанцияләрнең куәте дә башка. Авылда колхоз төзегән узел гына, аппаратурасының җегәре ташка үлчим. – Әлфир абый бераз басыла төште. – Алып куй, апа, бу приёмникны, тагын унбиш елсыз кирәге булмаячак әле мондый радиоларның. Моны эшләтергә уйласагыз, ярты авылны радиодан мәхрүм итәсез, аңлыйсызмы? Аннан Әлфир җавап бирә, аннан сораячаклар! Ярый инде, үз кешеләр дип әйтимме, конфисковать итмим, яшереп куегыз, күземә күрсәтәсе булмагыз яңадан! Кара инде Һадины, халык дошманнары да болай эшләмәс, белә бит ул бездәге хәлләрне.

Әнкәй, бүләккә җибәрелгән радионы җәһәт кенә чүпрәгенә төреп, кире шкаф өстенә алып куйды. Әлфир абый, стаканын тагын авыз янына китерде. «Голт»лап эчеп куйгач, ике каналлы радионы онытып, бая өзелгән сүзен дәвам итте:

– Мин Свердлауда, военный завод каршындагы ФЗУга эләктем. Яхшы укыдым, апа, укуны бетергәч, ябык шәһәргә җибәрделәр. Әйтергә ярамый, сер! Анда белгечлеккә кабат сынау үткәрделәр, баш бар бит миндә, шундук сизделәр, дүртенче разряд биреп, контролёр итеп куйдылар. Радиоприборлар эшли торган секретный завод! Миннән дә принципиаль, грамотный контролёр юк иде. Ике ел эшләүгә, бер бүлмә бирде завод. Тулай торак түгел инде, үзеңнеке. – Әлфир абыйның теле ачылды, аны тыңлыйлармы, юкмы, сөйләвен белә. – Йөргән кызым да бар иде, марҗа булса да, күземә генә карап тора иде, мине хөрмәт итте. Хөрмәт итмәслек түгел, ул чагында бишенче разряд бирделәр миңа, техникум тәмамладым. Өйгә, әнкәй карчыкка акча җибәреп торам. Ун еллап эшләдем заводта, почёт бар, завод директорына кадәр кул биреп күрешә иде. Күрешми ни, мин эшләгән сменада бер генә рекламация булмады. Уйлап кара! Әгәр ныклы контрольдә тотмасам, тәртип шундук югала. Күрше сменада ай саен булып торды рекламация. Ягъни сыйфат бозылып, кайдандыр жалоба килә дигән сүз заводка. Куркыныч нәрсә ул. Секретный булгач, әйтеп бетереп булмый, Гагарин мин тикшергән приборларга карап менеп төште космоска. Әйтергә генә ярамый... Секрет!.. Шулай канатланып йөргәндә, базарга чыктым.

Берәү татарчалап эндәшә миңа: «Үләм, Әлфир түгелме соң?» Һушка килгәнче, гаҗәп чибәр кыз каршыма килеп басты. Үзен күрүдән түгел, татарча эндәшүен ишетеп, җиргә кадакланган сыман басып торам. Гел урысчага күчеп бара идем бит. Карасам, үзебездән ике класс түбән укыган Фәрдия. Үзе чибәр, үзе тал чыбыгыдай нечкә гәүдәле. Бер кашык су белән йотып җибәр! Сөйләшеп киттек, баксаң, бер урыс егете моны алдап, бала ясаган да юкка чыккан. Хәзер тулай торактан куалар, базар тирәсендә берәр таныш кеше очрамасмы дип аптырап йөрүе икән. Озак уйлап торыш юк, алып кайттым үземә баласы белән. Өйләнештек, Фәрдиянең эшкә чыгар вакыты җитте, эшкә чыкмасаң, бездә закон катгый, заводтан куып кына җибәрәләр. Баланы куяр урын юк, яслегә чират. Монда минем авторитет та ярдәм итә алмый. Кайтып киттек авылга. Фәрдия сыер саварга керде, баланы карарга әнкәй бар, үземне тузып-таралып беткән радиоузелга мөдир итеп куйды колхоз. Ике ай дигәндә, аякка бастырдым узелны. Куна-төнә шунда ятам хәзер, иртәнге биштә башкорт радиосын кушам, аннан Казан, кичке унга кадәр Мәскәү. Арт борырга да хәл юк. Җитмәсә туктаусыз шикаять килә – имеш, радио җүнләп сөйләми, ишетелми, кыштыр да мыштыр... Шулай булмый, мин дигәнчә генә булса, бер дә кыштырдамас, шытырдамас иде. Тыңламыйлар... Шуңа тикшереп йөрергә туры килә. Әле өйдә шатлык бит, апа – малай туды! И, башлы нәрсә инде, хәзер үк сизеп торам, мине уздырачак ул. Шул Фәрдия дип, институтка керә алмыйча калдым, завод юллама биргән иде... Малайга кала инде анысы. Үкенмим, Фәрдия нык әйбәт минем, эшчән дә, сабыр да. Ир-атка сабыр хатын кирәк аңа. Юкка-барга чәпчи торган булса, яшәп булмый. Минем холык...

Коры димәкче иде бугай, тынып калды. Әлфир абый белән беренче танышуым шулай булды.

**4**

Авылда Әлфир абыйның аерым токкан урыны бар иде. Сала торган гадәте булгач, үзен артык санлап яшәделәр дип әйтеп булмый. Бер яктан, аны хөрмәт итәләр кебек, икенче яктан, аңа көлебрәк карыйлар иде бугай. Очрашып, аның каршында дөнья хәлләре хакында авыз ачма инде, аның белмәгәне юк, шундук бәхәскә кереп китә. Техника мәсьәләсендә дә төшеп калганнардан түгел, ул җан өрмәсә, колхоздагы күпме машина-трактор вакытыннан алда металлоломга озатылыр иде. Шул салу дигән нәрсә булмаса, алтын бәясенә йөрер иде бәлки. Ә бер гаебеңне күрсәләр, аны купайтып, үзеңне икенче сортлы бәндәгә әйләндереп куярга күп сорамыйлар авылда. Әлфир абыйның җитмәгән ягы шул – кайчан күрмә, кызмача иде.

Радиоузел үзара янәшә урнашкан өч кибет каршында иде. Безнең авыл кешесе кибет, магазин дигән сүзләрне сирәк куллана иде – без «ләфкә» дип сөйләшергә күнеккән. Кибетләрне сатучыларының исеме белән «Фәриха ләфкәсе», «Сәлимә ләфкәсе», «Нәҗми ләфкәсе» дип йөртәләр иде. Авылыбыз борынгыдан базар токкан, инкыйлабка кадәр елга ике мәртәбә ярминкә үткәрелә торган булган. Әле мин бәләкәй чакларда тирә-як халкы базарга җыела иде, якын-тирәдәге авылларны әйтәсе дә юк, әллә кайлардан килә торган булганнар монда. Базар урамы белән Колхоз урамы кисешкән

урындагы зур мәйдан гөр килеп тора иде. Бер рәт прилавкалар тезелеп киткән, аларның саны илледән дә ким булмагандыр. Прилавкаларда төрле товар, көнкүреш кирәк-яраклары сатыла. Мәйданны урталай бүлеп, вак-төяк сатучылар өчен озын буйга өсте каплаулы урыннар әзерләнгән. Анда, кара -каршы рәтләргә басып, өендә кем ни-нәрсә җитештерә – шуларны саталар. Бер өлешендә – бәйләм әйберләр, бер өлешендә – яшелчә, тозлы кыяр, тозлы кәбестә, алма саталар, югары башта ит сатучылар урын ала. Мәйданның уң яктагы түрендә мал сату урыны. Сыер, сарык, кәҗә асраучылар хәйран җыела монда. Сатучылардан да уздырып, «штатлы» маклерлар кайнаша, базарга керү юлында чабата сатучылар: тау кадәр өелгән сары юкәдән эшләнгән «продукцияләренә» багынып, салкын үтмәсенгә урында таптанып торалар. Араларында картлар да, хатын-кызлар да, үсмерләр дә бар. Соңгы чабата сатучыны, инде базарларны куып тараткач, алтмыш беренче елның февраль аенда күрдем. Базар мәйданы каршында Юныс бабай бер өем чабатасы янында ялгызы бөкшәеп басып тора иде. Янына килүче дә, чабатасын алучы да юк... Күрәсең, ул елларда халыкның тормышы бераз рәтләнә башлап, чабатага ихтыяҗ калмагандыр инде.

Ул чакта «член» дигән сүз модада иде. Колхоз члены, партия, комсомол, «ДОСААФ», «Белем» җәмгыяте, «Ирекле янгын сүндерүчеләр» җәмгыяте, «Суда батучыларны коткаручылар» җәмгыяте, «Китап укучылар» җәмгыяте членнары... Санасаң, күп инде алар. Тагын берсен атап әйтмичә булмый – авыл халкының күбесе, кагыйдә буларак, потребкооперация (ягъни кулланучылар, сатып алучылар) җәмгыятендә дә член булып тора иде. Потребкооперация җәмгыятенең уставы буенча, кибеткә кайткан товарны сатуда хилафлыклар килеп чыкмасын өчен ревизия комиссиясе төзелә, аның рәисе була. Кануни мәсьәләләрдә аз-маз уңны-сулны аера диптер инде, озак еллар дәвамында Әлфир абыйны шуның рәисе итеп сайлап куялар иде. Ул, намуслы рәвештә, шактый еллар тынгысыз җәмәгать эшен тартты. Бигрәк тә Фәриха апаның үзегенә үтте булса кирәк. Кайчан кибеткә кермә, Фәриха апа янында пышын-пышын килеп торучы өч хатын-кыз була иде. Аның икесе укытучылар – Кайдафә һәм Сәрмия апалар, өченчесе – элек сельпода бухгалтер булып эшләгән Нурия апа. Сүз уңаеннан әйтеп китим инде, безнең авыл революциягә кадәр волость үзәге булган, районнар оеша башлагач, Калинин районына кергән. Илленче еллар ахырында, Хрущёв реформасы башлану безнең авылга нык зыян сала. Калинин районы бетерелеп, авыл Мөслим районына кушыла. Шуннан башлана инде авылның тамырына балта чабу. Участок больницасы, ветлечебница, сельпо, май заводы, ашханә кебек оешма-учреждениеләрне сүтеп-туздырып, биналарын, кирәк-яракларын район үзәгенә алып китәләр. Шул елларда гөрләп торган базар да тарала. Алдан әйткән апалар өчесе бергә сирәк туры киләләр, ә аерым-аерым, дежурга билгеләнгән сыман, һәрчак Фәриха апа «ләфкә»сендә булалар иде – сатучы апаны бер дә ялгызын калдырмаска сүз биргәннәр, диярсең. Фәриха апа прилавканың товарлар ягында, тегеләре сатып алучылар ягыннан, үрелеп бер-берсенә башларын терәп диярлек, и пышылдашалар, и пышылдашалар. Кибеткә берәрсе килеп керсә, сүз кырт өзелә. Андый чакта сердәшләр кергән сатып алучыга ризасызлык күрсәтеп, «йөрисез эч пошырып, сүз бүлдереп» дигәндәй, төксе караш

ташлап, читкәрәк китеп торалар. Фәриха апа алыш-бирешне тәгәлләгәч, тагын чыш-пыш башлана. Нинди уртак гамьнәре, серләре, бетмәгән сүзләре булгандыр – белмәссең. Кибеткә, эре атлап, Әлфир абый килеп керсә, Фәриха апаның йөзенә кызыллык йөгерә. Сердәшләренә күз карашы белән «читкәрәк китеп торыгыз» дигәнне аңлатып ала да теш арасыннан гына:

– Коры килә инде, тагын ни дип җанга төшәр, – дип, үзалдына каргана башлый.

Чыннан да Әлфир абый монда да үзен хуҗаларча тота иде. Ул чактагы тәртип буенча һәр атнаның чәршәмбесендә өйләдән соң сәгать өчләр тирәсендә товарны кибеткә райпо машинасында китерәләр. Халык, товар кайтканны көтеп, кибет тирәсендә бөтерелә.

Машина кибет каршына килеп туктауга, товаровед кабина ишеген ачып җибәрә дә күзе белән Әлфир абыйны, ягъни ревкомиссия рәисен эзли башлый. Әлфир абый, ерак түгел урнашкан радиоузелыннан чыгып, вәкарь атлап, ашыкмыйча гына, аның янына килеп баса. Халык тын калып, бу күренешне күзәтә. Әлфир абый кабинадан төшми утырган товароведка кырын карап алгач:

– Счёт-фактураны бир, – ди кырыс тавыш белән.

Товаровед ашыгып, аңа ниндидер кәгазьләр суза. Халык өчен шушы «счёт-фактура» дигән сүздән дә хикмәтле сүз юк иде. Чөнки анда кибеткә кайтарылган һәр товар, бәясен, санын күрсәтеп язылган була.

Кайчакларда товаровед, өтәләнгән кыяфәт белән Әлфир абыйны читкәрәк алып китеп, нидер аңлатып маташа башлый. Бу сөйләшүләр бер дә гади бармый, еш кына Әлфир абый тавыш күтәреп, ни-нәрсәдәндер ризасызлык күрсәтә, товаровед бер арада кулына сонган счёт-фактураны киредән үзенә тоттырырга тырыша. Тегесе алмый, һаман нидер аңлата, хәтта ялвара да бугай әле. Бу сөйләшүләрнең серен соңрак аңладым мин. Кайчакта райпога кайткан сирәк товарны районда ук алып калалар да сатучыга товар урынына акчасын гына биреп китәләр икән. Башка авылларда шома гына барган бу эш Әлфир абыйга килеп терәлгәч, бик катлаулыга әйләнеп куя. Ул риза түгел! Әйбәт товар авыл кибетенә дә кайтырга тиеш, монда да кешеләр яши, яхшы кием-салым алырга колхозчының да хакы бар!

Елга бер мәртәбә кооперация җәмгыятенең хисап җыелышы була. Анда райпо вәкиле дә килә. Сатучылар чыгышыннан соң, сүз Әлфир абыйга бирелә. Үз дәрәҗәсен белеп кенә, урыныннан күтәрелгән абзый куен кесәсеннән сары тышлы бер кенәгә чыгара. Трибуна артына килеп баскач, кенәгәне баш өстенә күтәреп:

– Җәмәгать, минем кулда җәмгыятьнең уставы! – ди ныклы тавыш белән. – Монда закон язылган. Кем уставны боза, уголовный эшкә кадәр ачыла. Бездә булгалый закон бозулар! – дип, күзләрен чекерәйтеп, вәкилгә карап ала. Вәкил, муенын җыерып, читкә борыла. – Ни өчен магазинга кайткан товар счёт-фактура белән туры килми? Ни өчен товарга кул сузасыз? Авыл халкына кирәкми дисезме ул кием-салым? Бу хәл елдан-ел кабатлана. Әгәр быел да шушы нәрсә дәвам итсә, прокуратурага барам, фактлар бар, җитәрлек! – Чыгыш ясаучы кенәгәсен баш өстенә күтәрә. – Уставта язылган: «сатучы кибеткә кайткан товарны ревкомиссия белән берлектә кабул итеп алырга тиеш» диелгән. Минем теләсә кайчан кибеткә кереп,

эш барышы белән танышырга хокукым бар! Шуңа күрә кырын карамагыз, иптәш вәкил, законга язылганны эшлим, үзем уйлап чыгармыйм. Ә болай сатучылар әйбәт эшлиләр. Кышкы суыкларда магазин җылытылмый, аларга да салкын тия, авырыйлар, шулай да эшләрен дәвам итәләр. Алдагы җәйдә мич чыгарып, кибетне җылыту ягын уйларга кирәк. Адәм тәганәсе, илдә социализм төзелеп бетеп килә, ә кибет сап-салкын, чыдамалы түгел. Вәкил иптәш, килгәнсең икән, бер файдаң булсын, мич чыгарыйк кибеткә. – Клубка җыелган халык, Әлфир абыйны хуплап, шаулашып ала. Алдагы елга вәкилнең дә, сатучыларның да аны җәмгыятьнең рәисе итеп сайлатасылары килми, әмма авыл халкы яклый, башка кандидатураларны күрсәтеп тә тормыйча, рәислеккә аны сайлап куялар. Мондый чакларда Әлфир абый тантана итә, өенә ул бер башка үсеп кайта.

Әгәр Әлфир абый товар кайткан көнне ни сәбәп беләндер «урында» булмаса, кибеткә икенче көнне килеп кереп, барлык кайткан товарны счёт-фактура белән чагыштырып карап чыга. Билгеле, күп нәрсәдән җилләр очкан була, әмма Әлфир абый һәр нәрсәнең очына чыгарга тырышып, сатучының җелегенә төшә. «Монда язылган костюм-чалбар кемгә сатылды?» «Бу ботинканы кем алды?» «Ни өчен счёт-фактурадагы бушлатның хакы күрсәтелмәгән?» Гыйльмановка (райпо рәисе) шалтыратам, закон бозу алардан башлана»...

Товар кайткан чагында сатучы иркен эш йөртә. Әлфир абый ни сораса да сатучы, күзләрен зур итеп ачып, гөнаһсыз тавыш белән: «Сорама, Әлфир, кем алып киткәнен әйтә алмыйм. Олы юл буенда бит авыл, кемнәр генә кереп чыкмый, аларның адресларын язып бармыйм бит. Закон кушмый», – дип котыла. Бу сүзләр Әлфир абыйны янә чыгырдан чыгара.

– Ни өчен башка як кешесенә сатылды бу әйбер? Әнә Мирхафизан инде ике ай ботинка эзли, таба алмый. Кайтканын көтеп йөри, очраган саен сораштыра. Ни әйтим аңа, Фәриха кайткан товарны читкә аткарып ята димме? Исемлек бар, кемгә ни кирәген алдан яздырып куялар, минем эш аларны кием-салым белән тәэмин итү. – Чыннан да ревкомиссия рәислеген шул дәрәҗәдә үзенең эше дип саный иде. – Беләсең, белә торып башка кешегә шудыргансың! Алдашуга остардың син, күп товар астан китә, эләктерсәм, чамала, мәрхәмәт көтмә! Җавап бирәсең булмагае...

Җавап бирү дигәннән, безнең өйгә кагылышлы бер вакыйга искә төште. Бишенче сыйныфка барыр алдыннан, әткәй елмаеп кайтып керде. Кулында сары кыштырдык кәгазьгә төрелгән нидер бар.

Төргәкне чишеп җибәрсә – күзнең явын алырлык костюм! Чалбары да бар. Сыек яшел төстә, киеп караттылар, миңа тап-таман, үлчәп теккән кебек. Миңа куаныч, әнкәй елмаеп өстемдәге костюмны сыйпап алды. Әткәй сөйләнә:

– Сарык суеп, Бакалы базарында сатып кайттым, ләфкәләрендә малайга ярашлы кием табып булмады. Нишләргә дип, аптырап йөри идем. Үсеп килә улым, тишек-ертык белән йөртәсе түгел. Язган булгач, кичә үзебезгә кайткан булган костюм. Фәрихага рәхмәт инде, астан гына чыгарып бирде.

Әмма костюм вакыйгасы болай гына тәмамланмады.

... Икенче көнне әнкәй, төш җитәрәк, мине әйбәтләп юындырып, өскә

үтүкләнгән ап-ак күлмәк, яңа костюм, чалбар, аякка Бакалы универмагыннан алган шәп ботинка кидереп, әткәйне каршы алырга җибәрде.

– Бар улым, әткәңне каршы ал. Бүген осталар кәнсәләр түбәсен ябалар, әткәң дә шунда. Күрсен әле улының ничек үскәнен! – диде.

Әнкәйнең кыланмышын аңлыйм. Сөенеченнән шулай итә ул. Үткән ел, печәнгә төшкәч, көтмәгәндә, әткәй нык кына авырып китте. Карамалы участок больницасына илткәннәр иде, андагы табиб эшне тиз тоткан:

– Күп булса ай ярым яшәр, каты сырхау эләккән абзыйга, – дигән.

Район больницасында да дәвалау чарасын тапмадылар.

Авылда сүз чыкты, Хәбирҗан абзыйга озак калмаган, сәгате сукканны гына көтеп ята икән, дип сөйләнүләр ишетелгәләде. Әткәйнең яшьтәшенең хатыны Әлфәрия апа урамда мине күргәч, башымнан сыйпап:

– Бигрәк иртә атасыз каласың шул, бала... Әле әткәеңнең бик кирәк чагы бит.. – дип киткәне истә.

Ятып калганчы, атып кал, дигәндәй, әнкәй миннән Сарапулда яшәүче олы апага хат яздырды. Апа атна эчендә кайтып та җитте, әткәйне алып китеп, Сарапулдагы «мыеклы врач» дип даны таралган хатын-кыз табибка алып кергән. Әткәй кайткач, сөйләде, чыннан да мыеклы икән ул табиб – Анна Павловна. Мыегы Будённыйныкыннан чак кына кайтышрак икән. Табиб апа үзе дә фронт юлларын үткән, хәтта әткәй белән бер кавалерия бригадасында хезмәт иткәннәр булып чыккан. Моны белеп алгач, «Мыеклы апа» эшкә җиң сызганып тотынган. «Фронттагы хәлләрне беләм, сугышта алган «болячкаларың» азып киткән, сине болай гына, ниндидер әгъзаңны аерып дәвалап булмый, комплекслы дәва кирәк булачак, – дигән. Өстәп тә куйган: – Хәзерге укып кайткан табиблар «тар белгечләр», кеше организмын бербөтен итеп карау юк, «кай төшең авырта?» дип сорыйлар да, даруларга керешәләр. Элек безне комплекслы дәваларга өйрәтә иделәр», – дигән. Үзем дәвалыйм сине, – дип, ай ярым хастаханәдә яткырган. «Янымнан китмәде, тәки аякка бастырды, алтын куллы табиб, – дип сөйләде әткәй кайткач, сөенечен яшермичә.

Мине күргәч, әткәйнең йөзе кояштай балкып китте. Кече улының сау-сәламәт, матур булып үсеп килүенә куанып, күзләреннән горурлык чаткылары сирпелде. Әнкәсен әйт инде, ничек килешле итеп киендергән бит!

Кайтып киләбез. Әмма кызыклы булды минем бу сәфәр! Иң элек каршыга Ирсай абзый очрады. Әткәй култык астына балтасын кыстырган, кояш кыздырганлыктан, маңгаена тир бәреп чыккан, кәпәчен өскәрәк шудырып куйган.

Ирсай абзый салмыш иде. Бу эссе көндә нишләп аракы эчеп йөргәндер, үзе генә белә.

Ирсай абзый болай тыныч кеше инде ул, әмма салып алса, кешегә бәйләнергә ярата. Кемгә бәйләнергә белми йөргән чагы туры килгәндер инде, әткәйне күргәч, кулын кулына шапылдатып, безнең каршыга килеп басты.

– Син, нәрсә, мулла малае, атаң кәсебенә керештеңме? Сабыйларга исем кушып йөргән буласың икән... Мулла булмакчымы әллә?

Әткәйнең аның белән сөйләшеп торасы килми иде.

– Сорап килсәләр, куям шул, Аллаһ разый булсын инде. Кирәк дип тапсаң, үзеңә дә исем куям, – диде эткәй, бер дә исе китмәгән кыяфәт белән.

– Миңа исем кушасы юк, исемем бар – Ирсай мин, Ир-сай!

– Ирсай исем түгел бит ул, энем, кушамат кына.

– Әле син мине мыскыл итеп торасыңмыни? Мулланы да, Алланы да шулай итәм, – дип, ачы итеп сүгенде дә, күз ачып йомганчы, Ирсай абзый эткәйнең ияк астына китереп сылады.

Эткәй безнең чандыр гәүдәле, әмма көч дигәндә, сөбханалла, кемгә дә бирешә торганнардан түгел. Әмма аның кем беләндер, ни өчендер бәйләнешеп алган, тарткалашкан чагын хәтерләмим. Ирсай эткәйгә караганда шактый яшь кеше, картлар әйтмешли, «җилле» чагы, эткәйнең ияк астына ару гына эләккәндер, тик эткәй хәтта селкенмәде дә. Бу кыланмышын килештермәвен яшермичә, ләкин тыныч булырга тырышып, сүз башлады:

– Бәй, Ирсай, сиңа бит атаң Сөнәгать дип исем куштырган, менә шулай йөри торгач, исемеңне җуеп, Ирсайга әйләнгәнсең. Мә, улым, балтаны тотып тор әле, – дип, миңа балтасын бирде. Үзе сөйләнүен дәвам итте. – Башкасына түзәргә була, иманга кагылгач, сабыр сына икән ул. – Эткәй җиңен сызганган хәрәкәт ясап алды. – Аны, энем, алай сукмыйлар бит, менә болай сугалар, – дип, сул яклап, Ирсайның үзеннән дә җиллерәк итеп тегенең ияк астына китереп тондырды. Ирсай, һөҗүмне уң яктан көтеп, үзенчә әзерләнеп тә торган сыман иде, эткәйнең сулагай икәнен искәргәне булмагандыр инде, сул яктан тукмак кадәр йодрык килеп төшкәч, дуга ясап һавага күтәрелде дә Шәрифҗан бабайларның койма буендагы кычыткан арасына барып төште.

Кешегә сугу әйбәт түгел, әмма Ирсай үзе башламаса... Эткәйнең көченә сокланып тордым.

Ирсай кычыткан арасына чүгәләп, үкерергә тотынды:

– Үтердең, дерә дә нык итеп юри суктың, минем бүсерем барын бөтен кеше белә, белә торып суктың, үтердең, үтердең... Менә үлеп барам... – дип, Ирсай аяк өстенә яртылаш басты да кире кычыткан арасына тәгәрәде.

– Үлмисең, атың коргыры нәрсә, җан чытырман арасында ул, – дип, эткәй аның ягына борылып та карамый юлын дәвам итте. Үзендә куәт сизеп, сөенеп атлагандай тоелды ул миңа. Шушы мизгелдән аның бөтен авыруларына да нокта куелганын аңладым.

Кибет тирәсенә җиткәндә, безне ерактан күреп, Әлфир абый көтеп алды. Минем өс-башны күздән кичереп чыккач, эткәйдән сораштыра башлады.

– Малаеңа шәп костюм алгансың, Хәбирҗан абзый. Кайчан алдың?

– Кичә инде, Әлфир энем. Товар кайтты бит... Бәхете бар икән малайның...

– Беләм лә. Шуңа соравым. Тикшереп карыйк әле, нинди хәлләр бар микән монда? Әйдә, керик магазинга, беләсе килә, хәрәмләшү булмады микән? Кичә Кәнсәләр урамындагы электр чыбыкларын тарттырып йөрдем, товарны кабул итәргә вакытым булмады. Аз гына җил чыкса да, чыбыклар бер-берсенә тиеп, кыска ялганыш барлыкка килә, подстанция бөтен авылны аера да куя. Теңкәгә тигән иде. Шуңа товар кайтканын белсәм дә, эшне

калдырып булмады. Фәриха миннән башка товар кабул итсә, бер-бер хәл булмый калмый. Тикшерәсем килә.

Без кергәндә, сатучы апа Әнсәрия апа белән кызып пышылдашалар иде, кереп килүче Әлфир белән эткәйне күргәч, Фәриха апа Әнсәрия апага каш сикертеп алды. Әнсәрия апа, елан сыман боргаланып, тавыш-тынсыз кибеттән чыгып китте.

Әлфир абый, гадәттәгечә, тавышын каяндыр эчтән чыгарып, коры гына сатучыга дәште:

– Кая, кичәге товарның счёт-фактурасын бир әле. Мин хәзер электрик та бит, эш муеннан, кайткан товарны кабул итүдә катнашмадым.

Кулына кирәкле кәгазьләрне алгач, ашыкмыйча күз йөртеп чыкты да эткәйгә сорау бирде:

– Хәбирҗан абзый, малаеңа алган костюмга ничә сум түләдең?

– Утыз җиде сум да сиксән бер тиен.

Әлфир абый кашын җыерып, дәшми генә шактый вакыт кәгазьгә карап торды. Сатучы комачтай кызарып, эткәйгә нидер аңлатмакчы булып, күз кыскалап алды, башын боргалады, эткәй исә «бернәрсә дә аңламыйм», дигәндәй, иңсәләрен сикертеп кенә куйды да, Әлфир абыйга карап, авызын ачып тик тора.

Ниһаять, Әлфир абый телгә килде.

– Свидетельләрең бармы, Хәбирҗан абзый?.. Син костюм алганны, акча түләгәнеңне кемнәр күрде?

– Кемнәр дип инде, Зәйнәп белән бергә сайладык кәчтүнне. Ул малае белән кергән иде, кәчтүнне малаена кидертеп тә карадык әле. Икесе бер буйда сыман күренделәр. Шулай булды шул, кәчтүн малайга таман гына булды. Рәхмәт инде Фәрихага...

Фәриха апа, ризасызлык сиздереп, арлы-бирле йөренергә тотынды.

– Җанга төшә инде бу Коры. Төшләргә керә шушы кыланмышы... – дип сөйләнгәне колакка чалынды.

Әлфир абый аны тыңлап та тормады. Үзенекен тәкрарлавын дәвам итте:

– Шаһит икәү кирәк, абзый. Тагын кем бар иде?

– Кем барые дип... Өлфәт бар иде. Җитмәгән сиксән тиенне аннан алып тордым.

Фәриха апаның йөзе кара коелды.

– Әйбәт кешеләр икән шаһитларың. Алар булганны булмады димәсләр. Димәк, ничә сум түләдең инде костюмга.

– Әйтәм бит, утыз җиде сум сиксән бер тиен.

Әлфир абый счёт-фактураны сатучының борын төбенә китереп терәде:

– Ыклап кара әле, костюм ничә сум тора дип язылган?

Фәриха апа эндәшмәде. Яшьле күзләрен читкә борып, нидер мыгырдангандай гына булды. Әлфир абый, тавышын әкренәйтеп, сөйли бирде:

– Вәт, абзый, кешегә чыгарып йөрмә инде, башка алай кыланмас Фәриха. Син алган костюм егерме биш сум тора, дип язылган. Калган сумманы каян алгандыр, үзе белә. – дип, башын сатучы ягына кагып алды. – Узган ел Хәйдәр абзыйның бушлаты белән яна язган идең бит инде, һаман нәфсеңә булышасың, ә?.. Унике сум сиксән бер тиенне кайтарып бир! Ярты костюм

акчасын артык алгансың бит, оят кирәк! Прокурорга хәбәр итсәм, башың себер китәчәк! Ничекләр кулың бара шушы абзыйны таларга? Сугышларны үтеп кайткан, колхозда көн-төн эшли, көч-хәл белән тормыш алып баралар. Юк, башың киткәндер синең.

– Гафу ит, Хәбирҗан абый, – диде Фәриха апа, күтәрелеп карамыйча. – Ут юк иде бит кичә, эңгер-меңгердә шәйләп бетермәгәнмендер инде, кешегә чыгарма инде, зинһар!

Ут булмауда төп гаепле кеше Әлфир абый, әлбәттә. Фәриха апа кирәкле төймәгә басканын яхшы аңлый иде. Чөнки Әлфир абый, багана башына менеп, электр чыбыкларын кирәгенчә тарттыру эшен тәмамлагач, шул очта яшәүче Гатифә апаның яңа өенә электр үткәреп, алардан шактый «салып» та чыккан иде.

Фәриха ападан артык алынган акчаны алып, әткәй кесәсенә салып куйды. Сатучының куллары калтыраганын шәйләп алдым.

Кибет төбенә чыккач, каршыга Әнсәрия апа килеп басты.

– Инде дә матур да костюм алгансың инде, Хәбирҗан абзый! Малаең мондый костюмга лаек микән соң? Бик кыйммәткә төшә бу бала сиңа, Хәбирҗан абзый. Артык ирәйтмисезме үзен? Кызганам, баларына артык акча түккән ата-ананы...

Әткәй артык сүз катып тормады.

– Баланы алып кайтканда, синнән киңәш сорамадык, Әнсәрия сеңлем, үстерүен дә ничек тә үзебез үстерербез... Моңарчы кешедән ким-хур булмады балаларым. Балалы кешеләрне түгел, баласыз кешеләрне кызганырга кирәк, – диде.

Әнсәрия апаның баласы юк иде...

Кайтышлый Өлфәт абыйларга кереп, бурычны түләп чыктык.

Кайткач әткәй шаярткан төсле, кесәсеннән бер уч акча алып, өстәлгә ташлады. Әнкәй аптырый төшеп, бер акчага, бер әткәйгә карап тора.

– Әлфир табып биргән акчалар бу, карчык, – дип, кибеттәге хәлне сөйләп бирде.

– И, бу Әлфиргә Аллаһның рәхмәтләре яусын инде, – дип кенә әйтә алды әнкәй, гаҗәпләнүен җиңә алмыйча. – Исеңдәме, теге чакта бер чүп өчен мине бик нык ачуланган идең. Йөзе белән кайтты бит.

Үткән-беткән дигәндәй, әткәй кулын селтәп куйды.

–Таптың искә алыр нәрсә! – диде дә сүзне Әнсәрия апага борды:

– Кара әле, карчык, бу Әнсәриянең безгә ни үче бар икән соң? Очраган саен төртелми калмый.

– Синең партком Гашимовка ярап бетмәгәнеңне белә бит ул. Гашимов синең дини йолаларны үтәп йөрүеңне килештерми. Әнсәрия Гашимов җырын җырлый инде. Үткән ел Рәилә кызымны район смотр концертына барырга машинага утыргач куып төшергән бит. «Синең урынга Хөршидә бара», – дип әйткән. Рәилә кебек мандолинада оста уйнаучы мәктәптә юк югыйсә. Смотрга дигәч, Фәриханың кызын алганнар. Ул кыз, ике ел түгәрәккә йөреп, мандолинадан бер көй дә чыгара алмаган. Күмәкләп чыккач, тотып утырган инде мандолинасын. Аның каравы мактау кәгазе алып кайтты районнан. Иң оста уйнаучы саналган безнең Рәиләгә шымытыр башы... Балаларны рәнҗетеп, ни күрер икән ул?

– Иблискә юл бирермен, дигән Аллаһы Тәгалә. Бу дөньяда чуртым да күрмиләр алар, теге дөньядагысын бер Аллаһ белә....

– Әлфиргә рәхмәт әйттеңме соң, күпме акчаны кайтарып биргән бит, – дип, әнкәй өстәл өстендәге акчаларны җыештыра башлады.

– Әйтмичә! Кичә бурычка кергән идем, бүген табышлы булып кайттым менә. Бер карасаң, Әлфир булмаса нишләр идек? Сатучыларда нәфес бер булмаса, бер уйнап ала бит ул. Кулларыннан тотып тормасаң, ни генә кыланмаслар иде алар?..

Әнкәй ул сүзләргә җавап кайтармады. Аны әткәйнең Әнсәрия апага әйткән сүзләре бимазалый икән.

– Әнсәриягә каты кагылгансың, атасы. Бала булу-булмау – Ходай эше. Йөрәгенә хәнҗәр булып кадалгандыр сүзләрең.

Әткәй эндәшмәде. Артыграк җибәргәнен таный иде ул.

Уйлап куям, ул чакларда, ягъни халык кием-салым таба алмыйча тилмергән елларда, Әлфир абый авыл кешеләренең чын яклаучысына әйләнгән икән бит. Сатучыларны да гаепләргә җыенмыйм. Ялгышлыклар киткәндер, әмма булса да, безнең авыл кибетләрендә хилафлыклар сирәк булгандыр. Әлфир абыйның  катылыгы, бердән, халыкка файдалы булса, сатучыларның үзләрен дә күп күңелсезлекләрдән коткарып калгандыр ул. Нәфес чүпрә кебек, ирек куйсаң, кабара башлый. Төртеп чыккач, соң була.

**5**

Икенче юлы Әлфир абый белән очрашуның сәбәпчесе Гамил абый иде дисәм, дөрес булыр.

Берзаман мин Түбән оч малайлары белән дуслашып киттем. Авыл зур, һәр очта бала-чага бер өер. Безнең урамда да җитәрлек алар. Тик күбесе кызлар. Малайлар да бар барын. Әмма кайчак шулай була бит – уйнарга, аралашырга якыннан дус-иптәш табылмый, аларныерактанрак эзләргә туры килә. Һәр урамның үз атаманы, бөтен бала-чага аның тирәсендә бөтерелә. Башка урамга барып чыксаң, күз ачып йомганчы сине «плингә» алып куюлары бар. Сугыш беткәнгә егерме елдан артып барса да, сугыш культы көчле иде. Сугыш турында фильм күрсәтсәләр, мөкиббән китәбез. Гадәттә, фильмда каты сугышлар барып, ахырда, безнекеләр җиңә, немесләр җиңелә, күпләп пленга төшә. Сорау алу күренешләре дә истә калырлык була. Немец генералы башта кәпрәя, тәкәббер кылана, аннан, сорау алу барышында, совет кешеләренә карата үзләре кылган явызлыклары фаш ителгәч, башларын түбән иеп, ерткыч күзләрен аска төбәп, шиңеп бетеп утыралар. Фашистта кешелек сыйфатлары юк, беркайчан да тәүбә итми, аны көч белән генә буйсындырып була. Күп фильмнарның эчендә шул фикер ята иде. Шул фильмнарны карый торгач, бала-чага сугышлы уйнарга һәвәсләнеп китте дә инде. Үз урамыңда уйнап йөрү ярый ул. Хәтта атаман Мәгъфүрҗан булып, килешмәгән нәрсәләргә котыртып торса да. Әйтик, караңгы төшкәч,  Гали бабайларның бакчасыннан кыяр чәлдереп чыгу, Мөгаллимә әбинең тәрәзәсенә борчак атып, аны кат-кат ишегалдына чыгарга мәҗбүр итү...

Әйткәнемчә, башка урам малайларының күзенә чалынсаң, сине шундук «плингә» алып, үзләренең атаманнары янына алып киләләр. Син немец,

алар кызыллар; сорау алулар, җәзалау элементлары; аяк-кулларны бәйләп берәр келәткә ябып тотулар – кинодагыдан ким кыланмыйлар. Бер генә юл кала, ниндидер җегәр күрсәтеп, әсирлектән котылу җаен табу. Бәхет елмаеп, чыгып сыза алсаң, сөенеч; ябып куйган келәттән чыгып ычкынмасаң, шактый кыенлыклар кичерергә туры килә. Безнең урамга килеп чыккан малайларны да шундый ук язмыш көтә.

Түбән очтагы Рафикъ исемле малай белән дуслашып киттем, ул урамның атаманы иде, кай ягым белән аңа ошаганмындыр, үз дус-ишләренә миңа җил-яңгыр тидермәскә кушты. Рафикъ уйлап тапкан уеннар башкачарак – көчкә, осталыкка, җитезлеккә сынаулардан торганга, бу уеннар исә Мәгъфүрҗан «җитәкчелегендә» кыяр урлап, ялгыз карчыкларны куркытып йөрүдән яхшырак иде, миңа килеште – күбрәк Түбән оч малайлары белән уйный башладым.

Шулай беркөнне Түбән очтагы малайлар белән дөньяларны онытып, чын сабан туендагы шикелле көрәшеп ятканда, әткәйнең эштән кайтканын шәйләп алдым. Караңгы төшеп килә икән инде. Уенны ташлап, әткәй янынннан теркелдәп кайтам шулай, нидер сөйләнәм үземчә, әткәй, көлемсерәп, минем такылдаганны тыңлап атлаган була. Кибетләр тирәсенә җитәрәк, бер төркем кеше күзгә ташланды. Әткәйне күреп, бер малай:

– Әнә Гамилнең атасы кайтып бара! – дип сөрән салды. Кешеләр арасыннан берсе аерылып чыгып, әткәйнең каршысына килә башлады. Бу – участковый Нариман иде. Милиция киеме шактый таушалган, үзе дә көне-төне мотоциклда йөргәнгәдер инде, каралып, тузанга батып беткән. Участковыйны авылдагы һәркем яхшы белә, үзенең дә белмәгән кешесе юктыр.

– Абзый, синең белән сөйләшәсе бар иде, – диде Нариман абзый, безгә якынлашып бетмәстән.

– Ни булды? – диде әткәй, барган җиреннән шып туктап. Участковый белән сөйләшүнең бер дә җүнлегә булмавын чамалый инде ул. Милициягә сәлам бирмә, ул бирсә дә син алма...

– Күңелсезлек килеп чыкты бит әле. Малаең...

– Ни булган минем малайга, – диде әткәй, ачулана төшеп.

– Велосипед урлаган ул... – диде Нариман абый, ачык итеп.

– Кем әйтте? Кайда соң ул үзе? – диде әткәй, хәлнең мөшкел икәнен сизенеп. – Гамил шук бала, әмма да тик беркайчан да кеше әйберенә кызыга торган малай түгел.

– Күрүчеләр бар. Шуны ачыклап йөрим дә инде. Малаеңнан сорау алып тора идем әле, өегезгә кеше йөгертмәкче идем, ярый үзең килеп чыктың.

– Ничек сорау аласың? Ул бит мәктәп укучысы, башта ата-анасын чакыртырга иде. Мин бернәрсә белмим, авылны шаулатырга өлгергәнсең, – диде әткәй, кызып китеп. – Сталин заманы түгел бит, теләсә кемне теләсә кайда эләктереп, сорау ала башларга!

– Кызма, абзый, малаеңнан сорашмый булмый. Каян алган, ни өчен алган? Шуткы түгел, велосипед бит. Мондый очракта тимерне кызуында сугарга кирәк. Әйдә, малаең янына барыйк әле.

Әткәй ирексездән кибет ягына атлады. Җыелган кешеләр, малай-шалай безгә юл биреп, алга үткәрделәр. Гамил абыйны, качып китмәсен дигәндәй, кибет диварына кысрыклап, Әнсәрия апа басып тора.

– Совет укучысы, совет укучысы... Пионер.. – дип сөйләнгәне ишетелә. Мәктәптә пионервожатый булып эшли ул. Гамил абыйны да, Нариман абзый кушуы буенча, монда ул алып килгән икән.

Гамил абый әткәйне күргәч, өмет тулы күзләрен киң ачып, кычкырып сөйләнә башлады.

– Тимәдем мин бәчәйгә (велосипедны малайлар шулай дип кенә йөртәләр иде). Күрүен күрдем, тимәдем түлке! Янында карап тордым да китеп бардым.

Гамил абый бер дә коелып төшәргә уйламый, Нариман абзыйның күзенә туры карап сөйли.

Гамил абыйның үз-үзен тотышын, ышанычлы итеп сөйләгәнен ишеткәч, әткәй иркен сулыш алды.

– Кем нәмәрсәсе ул, бәчәй дигәне.

– Алма бакчасы каравылчысы Миръякутныкы.

– Әлмәт Миръякутмы? Көндез эшкә барганда күреп калдым, исереп, кибет төбендә утыра иде каравылчы Гиздуш белән. Шуның билсәпитен урлаганнармы? Соң, аның үзен милициягә алып китәргә кирәк, алма бакчасын каравыллыйсы урынга, эчеп-исереп йөргәне өчен. Минем малайның урлаганын кем күргән?

– Нәҗми әйтте. «Велосипед янында Хәбирҗан малае гына йөрде, ул гына чәлдергән булырга тиеш», ди.

– Баканың да койрыгы булырга тиеш. Ә син, Әнсәрия, малай артыннан йөгергәнче, миңа килеп әйтергә идең. Кайда эшләгәнне беләсең бит, Түбән очтан көнгә биш урыйсың. Балалар бакчасы төзибез, бура күтәргәнне озаклап карап торган идең бүген.

Әнсәрия апа ни әйтергә белми, бер Нариман абыйга, бер әткәйгә карап, эндәшмичә тик тора. Шулай да, уяулыгын югалтмый, карчыга сыман, Гамил абыйны саклавын белә.

– Аның гаебе юк, – диде Нариман абый. – Мин куштым, ул үтәде. Шулай булырга тиеш, чөнки мин милиция, власть кешесе.

– Власть кешесе дип. Тик торганнан балага бәйләнмиләр инде. Әйтеп тора бит, мин алмадым, ди.

– Малаеңа артык ышанасың, абзый. Бала-чага кызыккан булырга может.

– Гамил андый бала түгел, – диде әткәй өздереп. – Миръякут үзе кайда? Аннан сораучы бармы?

– Ул бакчага китте, җәяүләп. Велосипедны табу минем эш, – диде Нариман абый үҗәтләнеп. – Карак башта тана ул – алмадым, күрмәдем, белмәдем. Ныклап тикшерә башлагач, очы чыга аннан...

Әлфир абыйның озын гәүдәсе күренде.

– Нәрсә бар, ник шаулашасыз? – диде ул килгән шәпкә.

Нариман аны күргәч, ничектер, арткарак чигенде.

– Менә бу малай велосипед чәлдергән, – диде ул. Тавышы ышанычсыз яңгырады, Әлфир белән сүз алышып бер дә торасы килми иде аның. – Кибет төбеннән алып киткән.

Әлфир абый, тикшерүне җәһәт кенә үз кулына алып, бер-бер артлы сораулар биреп ташлады.

– Кемнекен? Кайчан? Кем күргән?

– Нәҗми әйтте, – диде Нариман абый, аягын аерыбрак басып. Болай торса, башкалар күзенә шәбрәк күренгән сыман тоела иде аңа. – Мирьякутның велосипедын алган да яшереп куйган менә. Әйтми кая куйганын. Сәгать буе тарткалаша минем белән, тел чарлап маташа. Каты чикләвек... Югыйсә әллә кайчан кайтып китәсе идем Карамалыга, хатын мунча ягып калды, – диде участковый, зарланып. – Точно беләм, кибет тирәсендә шушы малай гына йөргән, ул алмыйча, кем алсын? Факт, велосипед анда! – дип, Гамил абый ягына бармак төртеп күрсәтте.

– Кибет тирәсендә йөрүчеләр күп ул, – диде Әлфир абый, нинең нәрсә икәнен аңлап. – Радиоузел тәрәзәсеннән миңа барысы да күренеп тора. Әйе, Мирьякут килде Нәҗми янына. Ярты капчык алма кертте ул аңа, велосипедының багажнигына бәйләгән иде, сүтә алмый шактый маташты, карап тордым. Колхоз малын тарата ул адәм. Шактый торып чыкты Нәҗми кибетендә. Эчеп чыкты, аягында көч-хәл белән басып тора иде.

– Аның эчүен тикшермибез, кирәк булса, иптәшләр суды карар. Велосипедын урлау хакында эш карала, – диде Нариман, сабырсызланып.

– Менә син факт дисең дә... – Әлфир абый күзен кыса төшеп, Нариманга карап алды. – Фактлар киресен сөйли бит. Әйе, Хәбирҗан абзыйның малае кибет янына килеп, велосипедка карап торды. Рулендәге шылтыраткычы белән уйнап та алды. Әмма да ләкин велосипедка кагылмады. Бераз торды да каршыдагы китапханәгә кереп китте, китап алып кайтып киткәнен күреп калдым. Кибет ягына күз дә салмады башка. Шаһит була алам!

– Кая киткән соң алайса ул велосипед, җен алып китмәгәндер бит, чёрт возьми! – диде Нариман, Гамилгә карата кузгалып килгән эшнең җимерелүен өнәмичә. Күпме вакыт әрәм китте, – диде ул, сызланып. – Инде әйт, велосипед кайда, беләсең икән, әйт тә куй, җәфалама мине.

Җил исеп китте. Кичке салкынча җил җыелган кешеләрнең аяк астына каз мамыгы, саргылт яфраклар китереп ташлады. Көн ныклап сүрәнләнә башлаган иде.

Әлфир абый мыскыллы карашын Нариманга төбәде.

– Мирьякут кибеттән чыккач, Мосаллия апаларга кереп китте. Әнә ул йорт, – дип, йөз адымнар чамасындагы тәбәнәк кенә салам түбәле өйгә күрсәтте. – Белмим, Мосаллия апаларда ни эшләгәндер, озак торды ул анда. Ике сәгатьләп булыр. Шыр исереп чыкты. Бал коя бит Мосаллия апа, балы шәп аның, – дип, авыз тирәсен сыпырып алды Әлфир абый. – Мирьякут Мосаллия ападан велосипедсыз гына чыкты. Шуннан соң шул... Әнә теге элекке базардан калган ит чаба торган бүкән төбенә утырып йоклап алды. Аякка баскач, кичкә табан инде бу, як-ягына каранды да авыл советына кереп китте. Димәк, шунда «велосипедны урлаганнар» дип сөрән салган. Анда секретарь булып тити баш Мәрдилә эшли бит, Фәриха кызы, тизрәк сиңа шалтыраткан. Сиңа шул гына кирәк, матаеңа атланып...

Нариман, «җитте» дигәнне белдереп, кулын селкеп алды.

– Миңа ни, хәбәр килде, чарасын күрергә тиешмен. Совет милициясен диванага чыгарма син, яме! Велосипед шутка түгел. Техника урлау көн саен булмый бездә. Шәһәр түгел бит бу. Авыл советы миңа түгел, районга ук хәбәр салган, эчке эшләр бүлегендә регистрациягә алынган эш турында сүз бара. Миннән бастырып сораячаклар. – Өнәмичә, Гамил абый ягына карап

алды. – Шикләнерлек тә бит, малай үткен күренә, үкереп елар инде дигән идем, кая ул, күзен тасрайтып, минем белән бермә-бер телләшә. Урламаса соң, белгәнен әйтсен, телләшмәсен. Әнсәрия дә үгетләп карады, аптырап бетте. Нишләргә белгән юк...

Ул арада Әнсәрия апа, эшнең ни белән бетәсен аңлап, халык арасыннан чыгып, тиз адымнар белән өенә кайтып китте.

– Каракның бүреге яна, диярлек булды бу, – диде Әлфир абый, Әнсәрия апа ягына карап. – Мәктәп укучысын яклыйсы урында, милиция юлында йөртә, җүләр. Күреп тордым, малайны Нариман каршына ул китереп бастырды. – Әлфир абый эшкә ачыклык кертүен дәвам итте. – Кибеттә бикләнеп эчеп утырды Мирьякут. Нәҗми белән бергә шешә бушаттылар, белгәнгә сөйлим. Ярты капчык алма хисабына сыйлагандыр инде Нәҗми, югыйсә саран нәрсә ул, кешенекен эчә, үзенекен чыгарырга ашыкмый. Исерек Нәҗми сүзе белән йөрсәң, башың бетәр, иптәш участковый. – Әлфир абый Нариман абзыйны пешекли башлады. – Яшь балага карак исемен якмакчы булдың, ә?

– Минем эш – тикшерү, – диде Нариман абзый, соргылт сумкасын актарган булып.

– Тизәккә буялсаң, юып алырга була ул, тик сасысы килүдән туктамый аның. Шунысын уйларга кирәк: син бит, үзең әйтмешли, власть кешесе, гражданнарның иминлеге өчен җавап бирүче, димәк. Эшләмәгәнне эшләде дип, укучы баланы халык алдына чыгарып, бурлыкта гаепләү яхшы түгел. Үзеңнең башың себер китәр. Яла ягасың син бу балага, яла ягасың! Законный түгел!

«Себер китү» сүзен ишеткәч, Нариман бер тынга исәңгерәп торды. Бу Әлфиргә ышаныч юк, прокурор белән куркытырга оста, бер заман куркытып кына калмас, жалу да язар. Йөр аннан акланып...

Әлфир абый исә үзенекен тукый:

– Яла ягу әйбәт нәрсә түгел. Аерым статьясы бар.

Нариман бу тирәдән тизрәк китү ягын чамалый иде. Чыннан да эш прокурорга барып җитсә, баштан сыйпамаслар. Мунчаны әйбәт кертерләр анда, хатын мунчасы түгел ул. Җиңелгәнен сиздерәсе дә килми.

– Алайса, кем урлаган соң велосипедны? – диде ул хәлсезрәк тавыш белән. – Табарга кирәк бит инде аны, канса да канис.

– Әйтәм бит, Мосаллия түтигә керде велосипедын өстерәп, түти өеннән җәяү чыгып китте. Велосипед, димәк, Мосаллия түтинең ишегалдында. Әйдә, барып карыйк, тучны беләм, анда ул. Ә малайны җибәр, Хәбирҗан абзыйдан гафу үтен.

Нариман ялгышын таныйсы килми иде.

– Гафу үтенмим. Эштә мин. Тикшерү бара. Һәр информациянең төбенә төшү – бурычым! Баш ярылып, күз чыкмаган. Малаена контрольне көчәйтсен, сабак булыр. Йөрмәсен трай тибеп.

– Трай тибеп түгел, китапханәгә килә ул. Укырга ярата, димәк, – дип, каршы төште Әлфир абый. – Кеше булырга тырыша. Укыган балада өмет бар.

– Һе... – диде Нариман, авызын кыйшатып. – Китап укып кына кеше булсаң... Дүрт бала үстердем, өйгә китап кермәде, дәреслекләрдән башкасы

дим. Бушка вакыт исраф итү генә бит ул. Әнә үсеп җитеп киләләр, берсе дә дурак түгел. Малайлар милициягә керәбез диләр, кыз бүген-иртәгә кияүгә чыгасы. Китап ник кирәк аларга, әйт? Миңа, мәсәлән, аның кирәге юк. Караклар, хулиганнар белән эш итәм, китап кайгысы юк миндә.

Нариман белән Әлфир сөйләшә-сөйләшә, Мосаллия түтиләргә табан киттеләр.

– Әйдә, улым, кайтыйк инде, әнкәң көтә торгандыр, – дип, әткәй Гамил абыйны җитәкләп алды. Улының шундый кыен чакта да югалып калмавына, җебеп төшмәвенә күңеле булган иде әткәйнең. Шулай да иң зур рәхмәте – Әлфир абыйга иде.

**6**

Кояш чыкмый да, батмый да, аның үз юлы.

Җирнең без белгән халәте ниндидер серле очраклылыкка бәйле. Җир дигәнебез кайчандыр, ничектер шушы галәм ноктасына урнашып калган да чыршыдагы мөһер сыман әйләнеп-тулганып тик тора. Ахыры ничек булыр, кешелекнең җавабы бар да, юк та. Без әле мәңгелектә түгел һәм анда беркайчан да булмабыз да кебек. Без мәңгелеккә бер якынаябыз, бер аннан ераклашабыз. Дин галимнәре «очраклылык» дигәнне яратмыйлар, Җирне илаһи канун яшәтә, ул канунның серен бер Аллаһ кына белә, диләр. Җир яралган икән, анда без булганбыз икән, димәк, кемгәдер, ни өчендер бу бик кирәк. Котылгысыз дәрәҗәдә кирәк.

Уйласаң да, гомер үтә, уйламасаң да... Уйласаң, гомер тизрәк үтә, чөнки тизрәк картаясың.

Заманалар үзгәргән саен Әлфир абыйга эш артып кына барган шикелле.

Үткәннәрне тарих итеп сөйли башласаң, кызык хәлләр җитәрлек ул. Авылны гына алыйк – кайчандыр куыклы лампа белән көн күргән авыл илленче елларда электр дигән хикмәтле нигъмәтне дә «татып» карады. Авылда генератор, трансформатор, электр баганасы (анысын авыл буйлап һәр алтмыш метр саен утыртып чыктылар), электр чыбыгы, розетка, вилка, патрон, предохранитель (саклагыч) кебек яңа атамалар барлыкка килде. Башта иске НАТИ хәрәкәткә китергән генераторны соңрак кабинасыз «Владимерец» тракторы әйләндерә иде, соңыннан аерым рамага утыртылган дизель двигателен эшкә җиктеләр. Шул ук елларда безнең яклардагы Сөн, Ык елгаларын буып, колхозара электр станцияләре төзеп куйдылар. Колакка «Чуракай ГЭСы», «Мәлкән ГЭСы» дигән сүзләр керә башлады. Шунысы кызык: Әлфир абыйның классташы Һади абыем Мәлкән ГЭСын электромеханик буларак, беренче хутка җибәрүче иде.

Кыш көннәрендә генератордан ут алсак, җәен Чуракай ГЭСы хутка җибәрелә иде. Аны яз ахырында тирә-як авыллардан колхозчылар җыелып, сафка бастыралар, октябрьнең соңгы атнасында корыч колонналарга урнаштырылган калын тактадан эшләнгән буучы блокларны җай белән генә сүтеп алалар. Дизель белән эшли торган генератордан, соңрак Чуракай ГЭСыннан ут алган йортларны тикшереп йөри башлады абзабыз. Генераторның да, ГЭСның да җегәрләре аз, ихтыяҗны канәгатьләндерә алмый иде. Өйләргә электр уты иртәнге алтыдан кичке тугызга кадәр генә бирелә, һәр йортка кырыклы бер генә лампа куярга рөхсәт итәләр, әгәр дә

инде, нәфесеңә булышып, йөзле лампа куясың икән, ишекне Әлфир абый шакымыйча калмый.

Өйгә керсә, хуҗа белән сөйләшүе төксе була аның.

– Нәмәгә дип йөзле лампа куйдың? Генератор янып чыксын, дисеңме? Яз башында ай ярым утсыз утырганны оныттыгызмы? Хәзер үк алыштыр, а то... – Әлфир абыйның йотып калынган сүзләренең нindiрәк икәнен хуҗа белә инде. «Генератор белән андый-мондый хәл булса, прокурорга язып бирәм» – янавы инде аның. Җәй көннәрендә, ут Чуракай ГЭСыннан килгәндә, кайберәүләр зуррак лампа да куярга җөрьәт итәләр, хәтта электр плитәсендә аш пешерергә азапланучылар да табыла. Андыйларга Әлфир абый бигрәк тузына. Чөнки бер йортта электр плитәсен розеткага тоташтыруга, бөтен авыл чүгеп куйгандай була, көчәнеш кимеп, утның януы сүрәнләнә дә куя. Андый чакларда Әлфир абыйның күзен дә ачырмыйлар: «Йөргән буласың, бер файдаң юк, ике көннең берендә тычкан утында утырабыз. Плитә яндыручыларның эзенә төшә алмыйсың, әллә төшәсең килмиме?..» – Бусы инде Әлфир абыйны гаепләүгә охшый. «Имеш, кайберәүләргә кереп, йөз грамм саласың да, тегеләр, өрекми-нитми электр белән эш итәләр. Ашаган авыз ояла, ди. Кайберәүләргә күз йомасың, чамала, үзеңә прокурор юлында йөрергә калмасын. Хәзер кеше грамотный, яза белүчеләр күп...»

Ил мантыган саен көнкүреш тә үзгәрә торды. Озакламый радиодан яңгыраган, газеталардан укыган «Зәй ГРЭСы», «Уруссу ГРЭСы» дигән сүзләргә дә күнегеп беттек. Хәтеремдә, мин, яшүсмер малай, Аяз Гыйләҗевнең «Зәй энҗеләре» дигән китабын укып, шактый хисләнеп йөргән идем. Хәзер әдипнең ул китабын сирәк искә алалар, күпләр инде бөтенләй хәтерләмиләрдер дә. Мин исә аны бик яратып укыдым, андагы тормышчан вакыйгалар арасында йөрдем, җанга ятышлы персонаж-геройларны үз иттем. Безнең буын йотлыгып укыган «Матур туганда», «Намус», «Язгы җилләр», «Саф күңел» кебек калын романнардан соң үзебезнең чор турында язылган әсәр җаныма яңа сулыш, чып-чын саф җил сыман тоелган иде.

Зәй ГРЭСының безнең авылга тәэсире шул булды – авылга яңа баганалар утыртып чыктылар, басу-кырлар аша куәтле электрүткәргечләре сузылды. Йортларга гына түгел, урамнарга да электр утлары эленде. Элек кичке сәгать тугыз тулуга йокларга яткан авыл соңрак ятарга өйрәнде, урамнар төннәрен дә яп-якты, җиргә төшкән шырпы бөртеген дә табып була башлады. Радиоузелның элекке роле кимеде, аннан һәр көнне кич бригадир колхозчыларга нәрәт әйтә дә, шуның белән бетте, узелны алдагы көнгә кадәр бикләп куялар. Шәп радиоалгычлар, телевизорлар килеп керде йортларга.

Аннан безнең як кешеләренә Зәй ГРЭСының да кирәге калмады, ут Түбән Кама ГЭСыннан килә башлады. ГЭС үзе Чаллы тирәсендә урнашкан булса да, беренче төзүчеләр Түбән Камадан килеп эшләүчеләр булгангадыр инде (алар арасында минем Рәис җизни дә бар иде) ут станциясен Түбән Каманыкы дип йөртәләр. Халык заманча яшәүгә ияләште, чыра, керосин лампасы астында көн күрүләрне онытып та куйдылар. Кеше яхшыга тиз ияләшә бит ул.

Әгәр Әлфир абыйга эш бетеп китте, дисез икән, ялгышасыз, эш-

мәшәкатьләр артты гына. Электротехник белемле, армиядә элемтәче һөнәрен үзләштергән абзыйга гозере төшмәгән кеше сирәктер. Кемнең радиосы эшләми башлый, кемнеңдер телевизоры ватыла. Йортларга электр энергиясен чутлый торган санагыч (счётчик) дигән нәрсә куеп чыктылар, безнең авылда контролёр эзләп йөрисе юк – бу эшне, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте белән контролёр булып туган Әлфир абыйга тапшырдылар. Җитмәсә, колхозга яңа техника кайта, аларда приборлар катлаулана, электр чылбырының төбенә сызым-схеманы укып кына төшенеп була, барысына да Әлфир абый кирәк. Сәрхушләнеп йөрсә дә, аны сәрхуш ясаучылар да авыл кешеләре инде, гозере төшкән һәр кеше абзыйның «тамагын чылатмый» җибәрми. Саранлансаң, икенче тапкыр янына барасы түгел...

Әлфир абый партия члены иде. Әле заводта эшләгәндә үк кабул иткәннәр аны. Пролетариат вәкиле! Еллык хисап җыелышында сүз алмыйча калмый Әлфир абый. Кайчан карама, килешле киенә иде ул. Хатыны Фәрдия апа бик уңган булып чыкты, иренә юылмаган күлмәк кидертмәде, костюм-чалбары да һәрвакыт пөхтә, үтүкләнгән булыр, аягында – елтырап торган ботинка. Үзе дә ыспайлыкны ярата, килеш-кыяфәтен чамалап, һәрвакыт кеше алдында үзен көяз тота торган Әлфир абый, сүз сөйләргә трибуна артына чыгып баскач, беренче чиратта колхоз белгечләре пошалана башлый. Чөнки ул аларның һәрберсенең эшеннән гаеп табып чыга иде.

– Быел сүз алмам дигән идем, тыңлап тордым да, иптәш Гашимов, барысын да әйтеп бетермәде ул, мин өстәсен дигәндер инде, докладны тулыландырасы килеп китте. Шәп булды доклад, иң мөһиме – критика бар. Дөрес, әмма алай түгел! Менә зоотехник Шәмсетдиновны алыйк. Фермада йөри инде ул, әйеме. Күрмиме – андагы электр двигательләренең ата-анасы юк бит. Күпме исраф ителә энергия. Санап чыктым, фермаларда егерме җиде двигатель эшли, барысының да җегәрләре тиешеннән дүрт-биш мәртәбә артык. Артык электр энергиясе бит ул, колхоз аңа акча түли. Димәк, кирәкмәгән чыгымнар барлыкка килә. Колхоз түли бит аны. Безнең акча сарыф ителә. Моны баш экономист Фәйзетдин дә күрергә тиеш! Кәнсәдә чалбар төбе шомартып утырып кына булмый ул, йөрергә кирәк, күрергә, тиешле нәтиҗә ясарга. Экономия экономияле булырга тиеш! Ишетмәдегезме иптәш Брежневның сүзләрен? Санап чыгардым, шушы биш айда гына да колхоз двигательләр аркасында килеп чыккан артык энергия өчен айга мең биш йөз сум акча артык түләгән. Баш бетмәле цифрлар бит бу! Бер «Москвич»лык акча! Елга унике колхозчыга машина алып бирер иде колхоз. Ун елда машинасыз колхозчы калмас иде, менә бит чутлый белсәң, ничек килеп чыга. Фәйзетдин утыра тәмәке төтененә уралып. Агай-эне күкрәкләрен җилгә куеп, матай белән чапмаслар иде, ялтырап торган «Москвич»та җилдерерләр иде. Кая монда экономия? Кем җавап тота?!

Гашимовның йөзенә кызыллык йөгерә. Гаепләү җитди, партия чакыруын аяк астына салып таптау дип тә аңларга була моны. Районнан килгән вәкилгә табан иелеп, нидер аңлата башлый, пеләш башында эре тир тамчылары пәйдә була.

Райком вәкиле исә Әлфир абыйның сүзләрен күңеленә салып куйган икән, җыелыштагыларга күз ташлап:

– Җитди мәсьәлә бу, кем дә булса аңлата алырмы? – дип, кулындагы карандашы белән шык-шык итеп өстәлгә бәргәләп ала.

Әлфир сүзен тәмамламас борын, зоотехник Шәмсетдин күтәрелә.

– Ни бит, иптәш райком вәкиле, әгәр тиешле җегәрлектәге двигательләр куйсак, өч көннән артыкка чыдамыйлар. Трансформатор көчәнешне тигез бирми (бусы Әлфир абзыйны гаепләү), обмоткалар яна да чыга, яна да чыга. Бөтен нәрсә электрдан тора бит, тирес чыгару, саву агрегатлары, су эчертү җайланмалары. Двигательләр эшләмәсә, фермада афәт башлана. Катастрофа! Аптыраганнан эшләнгән нәрсә.

Урыныннан сикереп торып, Фәйзетдин сүз ала:

– Әлфир ачыш ясамый монда, иптәш вәкил. Җегәрле двигательләр куелмаса, югалтулар коточкыч булачак. Мең биш йөз генә түгел, ун меңнәрчә сум югалтачакбыз. Шуннан уйлыйсың инде, һәр медальнең ике ягы бар, дигәндәй. Трансформаторы да көйсезләнә, моны Әлфир яхшы белә, ни өчен яңасын кайтартып куймый? Ул чыбыкларны әйтерием, Бану кортканың бауга элгән ыштан балаклары кебек асылынып торалар. Җил чыкса, замыкание, кыска ялганыш. Двигательләргә тимәскә инде, акыл белән эш итәргә кирәк. Монда чыгып, тел чарлау бер нәрсә, тормыш икенчене күрсәтә. Әлфирне партия җәзасына тартырга кирәк дип саныйм!

Әлфир бу сүзләргә артык колак салып тормый, баш инженерга гаепләү ташлый:

– Кыш көннәрендә күрә торгансыздыр, машиналарны өстерәтеп кабызалар. Тәгәрмәчләр кыймылдап та карамыйлар, бүкән сыман өстерәлеп кенә баралар. Арт күпергә негрол салынган. Салкында ул каткан сумалага әйләнә. Ә бит кышка негролга бер стакан солярка өстәсәң, күпме ватылу-җимерүдән котылып була. Әйтеп тә карадым, санламыйлар.

Баш инженер Хәйретдин күтәрелә.

– Негрол – негрол инде ул, салкында куера, җылыда суга әйләнә. Солярка салып карадык. Машина хутка киткәч, май кыза да, басым артып, солярка клапанны бәреп, тышка чыгып бетә. Барыбер ката арткүпер. Әкият сөйли Әлфир, баш катыра.

– Синең үзеңнең арткүпереңне катырырга кирәк! – дип җикеренә Гашимов. – Кышка керсәк, машина ремонтлаудан бушамый шофёрлар. Җаен табарга кирәк, баш инженер бит син!

– Двигательләр чыдамый, ремонт ясап кына чыгалар, тагын мотор шакылдый. Иске запчастьләр куялар, – дип, гаепләү актын дәвам итә Әлфир абый. – Иске клапаннарга протирка ясаган булалар да, яңа прокладка тыгып, моторны кире җыялар. И вәссәлам! Шатун втулкалары җыйганда ук шыкылдап тора, рульдә люфт – бәрелеп үлмәле. Ничек йөрсен ул машина? Баш инженер запчасть юллыйм дип, көн саен юлга чыгып китә. Колхоз акчасын бирә, итен, балын кыстыра. Яңа запчастьләр кая китә торгандыр?

Бу сүзләрдән соң Хәйретдин урынына сеңеп бетә.

– Инде агроном Фәндәскә килик. Күрше «Правда» колхозы агрономы Хәсән Гәрәев иптәш һәр гектардан егерме биш центнер уңыш алды. Күз күрмәгән уңыш! Безнең колхозда унтугыз тирәсе. Аерма алты центнер. Колхозның өч мең гектар чамасы чәчүлек җире бар, һәр гектарны алтыга

тапкырласак, күпме ашлык алып җиткермәгән булып чыгабыз?.. Шул шул, – ди Әлфир абый, канәгать рәвештә. – Исәпләсәң, һуш китә...

Агроном Фәндәс, түзеп утыра торганнардан түгел, башына килгән сүзләрне ычкындыра:

– Безнең колхоз җиренә яңгыр яумады дияргә була, ел коры килде...

Халык «коры» сүзен ишетүгә дәррәү көлеп җибәрде. Хәтта моңарчы сүзгә кушылмаган кырыс холыклы колхоз рәисе Вәдүтовның да йөзендә елмаю чагыла.

Әлфир сүз җебен югалтмаска тырыша.

– Сынықка сылтау табыла ул. Ышанмыйм, унбиш чакрым арада зур үзгәрешләр булмагандыр. Инде әйтәсе килгән төп сүзгә күчәм. Кайчан Тавык урамын рәткә китерергә уйлыйсыз, иптәш Гашимов? Ул урамда да колхозчылар яши, һәр йортта дүрт-биш бала. Җәй көннәрендә кайбер чокырлар аша трактор үтә башласа, түбәсе күренми...

Гашимов сорауга җавап бирүне артык саный булса кирәк.

– Бу сорауга авыл советы рәисе җавап бирсен. Партия комитеты секретаре юл төзеп йөрми.

– Юл да төземәгәч, партия нигә кирәк соң ул? Без коммунизмга кайсы юлдан барырга тиеш? – дип үҗәтләнә Әлфир.

Эш уеннан үтеп баруын күреп, Вәдүтов җыелыш дилбегәсен үз кулына ала.

– Күп сөйлисең, Әлфир, сүз боткасы тамак туйдырмый, утырып тор әле. Тавык урамына быел тотынмакчы идек, ишеткәнсездер, Хәйретдин ел коры килде ди (халык тагын күңелле гөжләп ала), хикмәт диме ни дисең – Тавык урамында җәй буе юеш булды. Саз, боламык. Сазлык өстенә күпме ком салсак та, юкка чыга бара. Таш җәяргә кирәк анда башта, аннан соң гына ком. Үткән ел булмады, быел карарбыз, – дип, җыелышны тизрәк төгәлләтү ягын карый.

Әлфир яшәгән Тавык урамын рәткә китертмәвенең сәбәбе бар – үзенчә бу күп күрүче, күп белүче эшем иясеннән үч алуы иде авыл җитәкчеләренең.

**7**

«Ачык дәфтәр» җибәрми мине.

Өстәл янына атна чамасы килергә туры килмәде. Килеп утырсам, һаман да шул биткә төртелдем: «Коры Әлфир»...

Тагын ни саклый хәтер аның турында?

Искә төште! Гыйбрәтле вакыйга бу – үзем күргән түгел, кемнәндер ишеткән идем. Сүз Әлфир абый турында баргач, монысын да теркәп куярга кирәк. Һичшиксез кирәк! Алайса Әлфир абый турында язганнарым тулы булмас.

...Моннан күп еллар элек сугыш яралары ачылып, Вәдүтовны Казанга хастаханәгә салдылар. Печән өсте иде, Вәдүтов башта карышты, әмма, яраларның болай гына төзәлмәсен чамалагач, дәваланырга ризалашты тагын. Аның урынына Гашимов калды.

Озак кына ятты Вәдүтов хастаханәдә.

Бер көнне Гашимовны прокурорга чакырттылар. Гашимов бу як кешесе булмаса да, «Солют» колхозында күп еллар эшли, тәҗрибәле җитәкче буларак сан алган иде. Шулай да Вәдүтов урынына калып торган ике

ай эчендә үзен прокурор юлларын таптармын дип уйламагандыр. Хәер, дөнья булгач, төрле хәл була, колхозда һәрчак эшләр тигез генә бармый, прокурорга кереп чыгулар да булгалый торгандыр инде. Гашимовның эче поша башлады. Иң беренче килгән уй – Вәдүтов чагында гел уңай яктан телгә алынган колхозны тарта алмады дигән исем-даны таралмасмы? Нәрсә булыр? Райком белән дә бозылышканы юк (прокурор партком секретарен райкомны узып чакыртып алмый бит инде), эштә дә зур хилафлыклар юк сыман. Көтмәгәндә булган чакыру Гашимовның уйларын чуалтып җибәрде.

Прокурор таныш кеше, Гашимовны елмаеп каршы алды. Каршысына урын күрсәтте:

– Утырыгыз, иптәш Гашимов, кайткач мактанып сөйләрсең: бүген прокурор утыртты әле, диярсең.

Чәчләренә чал кергән прокурорның болай сөйләшүен ишетеп, Гашимовның эченә җылы йөгерде.

– Бездә бер жалоба бар, иптәш Гашимов, – диде прокурор, чакыртуның сәбәбен аңлатуны озакка сузмыйча. – Габдуллин Әлфир язган. Беләсеңдер, сезнең партия члены.

– Юкны бар итеп йөрүче бер кеше инде, – диде Гашимов, йөзен чытып. – Кулымнан килсә, партиягә якын да китермәс идем. Хәрби заводта эшләгән чагында алганнар...

– Нindiрәк кеше инде бу член? – диде прокурор. Нигәдер бу сүзләрне җитди итеп әйтте ул. Хәтта тавышыннан салкынлык бөркелде.

– Ниндирәк дип... Башы бар, акылы юк, дигәндәй. Салырга ярата инде. Электр эшләренә хирыс. Бер карасаң эшләгән эше юк, икенче яктан алсаң, аңа йомыш төшми торган көн булмый. Бөтен нәрсә электрга корылган бит колхозда.

– Колхоз электригы бардыр бит.

– Бар ла... – диде Гашимов ачулырак тавыш белән. – Анысының акылы бар, башы юк. Нечкәрәк эш килеп чыкса, Әлфиргә дәшәбез. Башка чара юк бит. Яшьләрне укытып кайтарабыз, бераз тәҗрибә туплыйлар да шәһәр ягына сыптыралар. Райком тынгы бирми: яңа төзелешләргә кеше сорап, көн саен разнарядка килеп тора, җибәрми кая барасың? Тыеп булмый, комсомол төзелешенә аяк чалучы исеме тагып куярга да күп сорамыйлар. Булыр-булмас, тулыр-тулмаслар кулына калып бара инде колхоз.

– Әйе, проблемалар бар... – диде прокурор аның белән килешкәндәй. – Илдә грандиоз төзелешләр башланды, тыныч тормышка куанып эшләргә дә эшләргә.

– Анысы шулай да... Эшче кулларга кайда да кытлык хәзер...

Прокурор сүзне кабат Әлфиргә борды.

– Гаиләсе бармы соң аның? Үзен чамаларга була инде. Димәк, башлы, сәләтле кеше, үзен реализовать итә алмаган мәхлук, шуңа һәр нәрсәдә эшем бар дип, бөтен җиргә борын төртә, һәр нәрсәдән гаеп эзли, үзен бу авыл өчен гаять кирәкле, мөһим кеше итеп күрәсе килә. Авыл масштабындагы гений.

– Өстенә бастыгыз, үзен күрсәтәсе килә инде. Ни генә уйлап тапмый, ничек кенә безнең башны катырмый... Бер сәрхуш шунда. Хатыны, балалары бар. Хатыны сыер сава, карусыз, өченче елны күкрәгенә медаль тактык. Вәдүтов берсенә сүз әйттерми бит, һәммәсен яклый, югыйсә минем кулымда булса...

– Кулымда булса, дисең инде. Ач күзеңне, дөнья бу, дигәндәй, колхоз синең кулда инде хәзер, иптәш Гашимов. Вакытлы гына булса да. Үзеңне күрсәтергә барлык мөмкинлекләр бар. Әмма шикаять сиңа карата язылган. Мин эшләгәндә, Вәдүтов өстеннән килгән шикаятьне хәтерләмим.

Гашимов прокурорга карап, урынында кыймшанып алды.

– Ниндирәк шикаять язган соң ул?

– Мәгез, укып карагыз, – диде прокурор һәм өстәл өстендә яткан бер кәгазьне сузды.

Гашимов ашыгып укырга кереште. Тигез хәрефләр белән дәфтәр битен тутырып язган шикаятьтә Әлфир авыл зираты хакында язган иде.

«Иптәш прокурор!

Мин – «Солют» колхозы члены, авыл активисты, булган җитешсезлекләр белән, партия кушканча (мин партия члены), армый-талмый көрәшүче Шакирҗан улы Әлфир Габдуллин. Озак уйлаганнан соң бик четерекле нәрсә турында Сезгә мөрәҗәгать итәргә булдым. Мине генә түгел, бөтен авылны борчыган хәл турында язам. Моны Гашимов өстеннән үч алу максатыннан шикаять дип уйламасагыз иде. Без үзебезнең рәисебез Вәдүтовны хөрмәт итәбез, аның тизрәк сәламәтләнеп чыгуын телибез. Вәдүтов булдыклы, нык куллы җитәкче. Колхозда да, районда да абруе зур. Ул җитәкчелек иткән унбиш ел эчендә авылда зур үзгәрешләр булды, мин моны, таныклыгы булган электротехник буларак, белеп әйтәм. Яңарды авыл, ферма, техника паркы карап туйгысыз. Кешеләргә игътибарлы, хәтта миңа да. Сүзләремә колак салырга теләмәүче наданнар җитәрлек авылда. Шунысы хак, авыл, колхоз тагын да матурайсын, бөтәйсен, алга китсен дип тырышам. Җитешсезлек күрсәм, әйтми кала алмыйм, кем булуына карамастан, кычкырып әйтеп бирәм, гаепләрен төзәтсеннәр, эшкә зыян китермәсеннәр, дигән уйдан эшлим моны. Кемгәдер начар булсын дип йөрмим.

Сүзем шул турыда: иптәш Вәдүтов хастаханәгә киткәч, аның урынына Гашимов калды. Беренче көннәреннән үк кысага сыймый торган эшләр кыла башлады. Мисалга – авыл зираты өстенә печән эскертләре куйдыртырга тотынды. Бу хилаф эшне туктатуда ярдәм сорыйм. Авыл борынгы, зират зур безнең. Киртәләп алынган, капкасы чылбырлап йозакка бикләнә. Шуңа күрә фермаларга якын булсын дип, иптәш Гашимов зират уртасына печән эскертләре өйдертүне уйлап тапты. Әйтеп карадым, тыңламыйлар, трактор-машинада яшьләр эшли, өлкәннәр сүзен колакка да элмиләр. Гашимов әйткән закон чутлана. Бу хәлгә авыл картлары борчыла. Өстеннән машина, трактор, арбалы ат йөргәнлектән борынгы язулы кабер ташлары ватылып, юкка чыгып бара. Безнең зиратта күп иде алар, инде чиреге дә калмагандыр. Кабер өстенә куйган чардуганнар җимерелә. Күбесенең авылда туган-тумачалары юк, таралышып беткәннәр, күп каберләрнең эзе дә калмады инде. Картлар җәй башында зиратны рәткә китереп куйганнар иде, эскерт кую башлангач, тәртипнең «т» хәрефе дә калмады. Вәдүтов алай-болай рәислектән китеп, аның урынына Гашимов калса, зират белән ни булачагын уйларга да куркыныч. Кыргыйлык бит инде бу. Вәдүтов – үзебезнең авыл кешесе, аның иманы бар. Иптәш Гашимов бу авылда туып-үсмәгән. Аның ата-бабасы, туган-тумачасы җирләнмәгән анда. Үткән атнада гражданнар

сугышы батыры, карт партизан Бәйрәмгали абзый белән кердек иптәш Гашимов янына. «Зират» дип авыз ачарга өлгермәдек, пыр туздырып куып чыгарды бүлмәсеннән. Правление яңа безнең, шәп бина төзеп куйдылар. Шунда кереп, гозерен сөйләп чыга алмасын инде карт партизан. Мин авыл халкы исеменнән Сезгә мөрәҗәгать итәм: иптәш Гашимовның бу башбаштаклыгына, ниһаять, чик куярга кирәктер. Бу хакта авыл советы рәисенә дә әйттем, якламады. Җитәкчеләргә зират печән эскерте кую өчен генә кирәк булып чыкты. Авыл советы рәисен дә гаепләп булмый: иптәш Гашимовка каршы сүз әйтергә курка. Бу эш тукталмаса, югары партия органнарына язарга кирәк булып чыга. Бу бик четерекле эш, партия колак салмыйча калмас дип уйлыйм.

Сездән эшлекле ярдәм көтеп, Шакирҗанов Әлфир. 1965 ел, 24 июнь».

Гашимов өчен яңалык түгел иде бу. Гасабиланып, прокурорга карап алды. Исе китмәгән кыяфәттә кулындагы кәгазьне өстәлгә куйды.

– Нәрсә диярсең? – диде прокурор ачуланган сымаграк.

–Урлыйлар бит... Җитмәсә алдашалар. Күзеңне ачып, колакны торгызып йөрмәсәң, беттең, минут эчендә дивана ясап куялар, – диде Гашимов, читкә карап. – Тәмам гарык булдым урлашу-алдашулардан. Дөресен әйтим, Вәдүтов күп нәрсәгә күз йома. Урлашуларга да...

Прокурорга Гашимовның сүзләре кызык тоелды.

– Алдашалар?... Мисал белән сөйләп-аңлатып кит әле. Ни дип алдыйлар алар синең кебек тәҗрибәле җитәкчене. Сине беләбез, иптәш Гашимов, теләсә кемне бармак тирәсендә бөтереп, әрекмән арасына чиртеп очырта алырлык кеше. Әле райкомда көлеп сөйләп торалар: «Гашимовны аны бернинди кислота да алмый», – диләр.

– Мисал дисең, иптәш прокурор, рәхим ит, көн саен бер хикмәткә тап булмыйча калмыйм. Кичә генә булган хәлне сөйлим алайса. Армиядән кайткан Мәкънүф дигән егет бар. Сөрхәнтәйрәк бер нәрсә шунда, ну таза, сәламәт үзе, таулар күчерерлек көче бар. Шуңа күрә тегермәнгә куйдырттым мин моны. Анда Шәйхи исемле карусыз, эштән башканы белмәгән кеше эшли. Шуңа ярдәмче булыр, авыр капчыкларны мөшкәгә салырга булышыр, дип уйладым үземчә. Шәйхи мин белә-белгәннән бирле тегермәндә, яше дә бара, олы арыш капчыгы күтәрү елдан-ел кыенлаша бара аңа. Ярый, Мәкънүфне эшкә куштык, карыйм, кайчан карама урамда очрый бу миңа. Тегермәнгә барып кына кайткалый сыман. Кичә тагын очраттым. Машинаны туктатып, каршысына сикереп төштем дә сорыйм:

– Нишләп эшләмичә, киләп-сарып йөрисең? Нигә тегермәндә түгел син? – дип табалыйм.

Егет бераз сакаурак, каршысында мин пәйда булгач, аптырап, бер мәлгә югалып торды да күзләрен челт-мелт итеп җавап кайтарды:

– Гашимов абый, без бит Ш-шәйхи белән алмашлап эшлибез, – ди. Тотлыгуын басар өчен кызу сөйләшергә тырыша ул.

– Ничек алмашлап эшлисез? – дим кызыксынып.

– М-м-менә, шулай эшлибез, Гашимов абый: Ш-шәйхи эшли – мин ял итәм, м-мин ял итәм – Ш-шәйхи эшли.

Күзен шар ачып, миңа карап тора бу.

Юкәдә икән чикләвек, минәйтәм, үзалдыма.

– Ярый алай булгач, дим. Килешкәнсез икән, сүзем юк. Түлке озак йөрмә, тизрәк тегермәнгә аттыр – дип китеп бардым.

Барам шулай, нигәдер күңел тынгысызлана. Тылсымлы сүзләргә тап булган шикелле Мәкънүф әйткән сүзләрне баштан әйләндерәм: «Шәйхи эшли – мин ял итәм, мин ял итәм – Шәйхи эшли...»

Прокурор баштарак бу сүзләргә игътибар итмәгән иде, аңлап алгач, шаркылдап көлеп җибәрде.

– Ну, егет, судан коры чыккан бит, ә? – дип, теге сүзләрне инде үзе кычкырып кабатлады. – Башыңны әйбәт әйләндергән бу, шәп, шәп, анекдот итеп сөйләрлек!

Гашимов прокурорга күз кырые белән карап алды.

– Үземне анекдотка әйләндереп баралар инде, җыен урам шпанасы өстеңнән көлеп китсен инде. Кәнишне ачу килә, бүген тегермәнгә кереп, пешереп чыктым әлеге саламторханны. Мыскыл иттем дип, авыз ерып йөрмәсен.

– Алдашу-хәйләкәрлек җитәрлек безнең халыкта. Монда инде партком секретарена эш буа буарлык. Колхоз членнарын тәрбияләү өчен бит инде партия комитеты. – Прокурор кабат кәгазьгә үрелде. – Шулай да, аңлатып кит әле, зиратның печән әзерләүгә ни катнашы бар? Кабер ташлары, каберлекләр турында ни әйтерсең? – Прокурор сорау алуга күчте, Гашимовның бу эшен өнәмәгәне сизелеп тора иде.

– Ат аунаган җирдә төк кала. Кемгә кирәк инде ул иске ташлар? Ул ташлар белән кызыксынган, андагы язуны укыган кеше дә юк бит инде. Бөтен тирә-якта гарәпчә укый белүче ике-өч кеше калгандыр калса...

Прокурор торып басты.

– Туктат бу эшне, иптәш Гашимов. Ярамый, үзең дә белеп торасың, килешмәгән эш икәнен. Син Аллага ышанасыңмы? – диде ул, Гашимовны аптырашта калдырып.

Гашимов ык-мык итеп торды.

– Шул-шул. Беркем дә кистереп әйтә алмый. Күкләр Җиргә тоташкан, ди иде миңа әбием. Җирдә ни кылынса, Күктә теркәлеп бара. Райкомда бу хакта сүз булды. Болай партия оешмасы секретаре гына булсаң, райком үзе чарасын күрер иде, монда син, вакытлыча гына булса да, вазифаи зат, хуҗалык җитәкчесе. Миңа сөйләшергә куштылар. Зират – изге урын, монда бәхәсләшер җир юк. Тимә син зиратка, кагылма! Вәдүтов та разый булмас, ишетелсә, хастаханәне ташлап чыгар да кайтып та җитәр.

Гашимовның башында прокурор әйткән сүзләр бөтерелә башлады: «Күкләр Җиргә тоташкан...» Кем күргән дә кем белгән. Әбисе әйткән, имеш...

Прокурор шелтәләвен дәвам итте.

– Югарыда ишетелсә, башыңнан сыйпамаслар. Югарыга язам дигән бит бу кеше дә... Язса язарлык. Киңәш итеп әйтәм әлегә, башка кабатлама моны. Зиратны җимерүгә партия дә кул куймый, халык үз җанына саксыз кагылуга бер дә битараф түгел ул, бу эш гореф-гадәткә хилафлык китерү санала. Турысын әйтим, утлар-сулар кичкән яугир бит син, иптәш Гашимов. Үлемнең күзенә туры караган солдат, болай кыланырсың дип, башыма да килмәгән иде. Зиратка үлгән кешеләр җирләнсә дә, исәннәрнең җаны сызлана, тавышы бер чыкмаса, бер чыгар. Бу Әлфир дигән кешегә рәхмәт

әйтергә кирәк, эшне зурга җибәрмәгәне өчен. Обкомга язса, хәл бөтенләй башка төс алыр иде.

Бәхеткә, Вәдүтов абый хастаханәдән шактый хәлләнеп чыкты. Авылның йөзе яктырып киткәндәй булды. Ул кайткач, Гашимов авылда озак тормады, аны башка районга күчерделәр. Зиратка яңадан печән эскерте өйдертмәделәр, әмма борынгы кабер ташларының күбесе ватылып, юкка чыгып беткәннәр иде шул инде. Бу авыл өчен әйтеп бетермәслек югалту булганын соңлап, бик соңлап кына аңладылар...

**8**

...Бер авылда шактый гомер кичерсәк тә, Әлфир абый белән әллә кайдан ук сәлам бирешеп, очрашкан саен хәл-әхвәлләр сорашып, гамьле әңгәмәләр корып яшәргә туры килмәде. Мин аңа караганда шактый яшь, ул исә, әйткәнемчә, бераз һавалырак кеше сыман күренде. Сөйләшер сүзләр дә булмагандыр. Аның әнкәй белән генә ачылып сөйләшкәнен ишеткәнем булды. Нигәдер әнкәйгә аерым бер хөрмәте бар иде аның. Калган кешеләргә бик егылып төшми, моңа әллә ни игътибар иткән кеше дә юк инде – Коры тек Коры инде. Бер генә мәртәбә миңа үзе башлап эндәште ул:

– Казанга барып укырга кергәнсең икән. Нинди һөнәр сайладың инде?

Чыннан да университетка укырга кереп кайткан идем. Авылда укырга керүем турында ишеткәннәрдер инде, әлбәттә, әмма болай кызыксынып, үземнән сораучы юк иде әле. Бары тик быел гына институт тәмамлап, агроном белгечлеге алып кайткан Фәнүс кенә, клубта очрашкач, гадәтенчә башын югары чөеп, миңа өстән карап, сорашып маташкан булган иде:

– Нәрсә, укырга кердеңмени? Университетка, диләр?

– Әйе шул, – дидем, сүзне озакка сузмаска тырышып. Нигәдер «җенем» сөйми иде бу егетне.

Фәнүс теш арасыннан берничә сүз ыргытты:

– Хәзер... барысы да укырга керәләр, – диде дә, тиз генә янымнан китеп барды. Үзеннән башка, авылда тагын кемдер югары белем алырга тиеш түгел, дип саный иде ул мәхлук. Укырга керүемне өнәмәве һәр хәрәкәтеннән, һәр сүзеннән сизелеп тора иде.

Инде Әлфир абзый сорау ала. Тавышына караганда, яман ният белән сорашмый. Гомумән, башкаларның уңышыннан көнләшә белде микән ул?

– Тарих-филология факультетына, – дидем, аның мине туктатып, хәлләрем белән кызыксынуыннан аптыравымны яшермичә. – Укырга уйладым шул.

Әлфир абый тамак кырып куйды.

– Һем... Тарих дисең инде... Сезнең нәселдән чыгарга тиеш... Укуга һәвәслек бар сездә. Тарих дигәч кенә күңелгә корт керде. Тарих бармы соң ул, гомумән әйткәндә?

– Бар инде, тарихсыз халык та, ил дә юк.

– Халык бармы? Ил бармы? Сөйләп күрсәт әле халык, ил тарихын.

Миңа бәйләнергә чамалый бу дип, тизрәк юлымны дәвам итәргә уйлап, алга атладым.

Коры Әлфир сөйләнеп, янәшәдән бара башлады.

– Сөйләп бир инде, тарих белгече, нигә качасың?

– Качмыйм, тарихны беләсем килгәнгә кердем бит инде укырга.

– Тарихны кем яза, шуныкы дөрес, – диде Әлфир абый, тавышын күтәреп. – Татарның тарихын укыганым юк. Әнә Әлфрид Халиков дигән бер галим «Казанга сигез йөз ел», – дип шаулап йөрде дә тынды. Тындырдылар чөнки. Бетте-китте, радио сүнде. Кем аңа тарих яздырып тора. Дөрес сукалыйсың, безнең ил дә юк, димәк ки, тарих та юк. Казанга сигез йөз ел, имеш. Нух пәйгамбәр чорыннан ук тора ул кала. Менә укы әле, тарихта актарын, нәкъ мин әйткәнчә булачак – Казан ул мең еллар элек тә Казан булган. Ә халык юк, юк ул халык! Тарихы булмаган халык юкка чут! Хәтта каршыда үсеп утырган тупылның да тарихы бар. Аны кемдер, ни өчендер шушы урынга китереп утыртып куйган. Шаулап үсә ул, чөнки аның үз тарихы бар. Ә безнең тарих юк...

– Булыр, булыр, Әлфир абый, тарихчылар күп бездә хәзер, язарлар...

– Син аларны тарихчылар дип уйлыйсыңмы? Ачтан үлмәс өчен казганучы бичаралар өере генә бар. Тарих укып, кеше алдап йөрерсең микән инде син дә? Йөрисең инде, кая барасың, синең дә ачка үләсең килми бит. Укыгач, файдасы булсын инде аның, әнә Фәнүс кайтты агроном булып. Җирне яратмый бит ул, нинди агроном булсын ул?! Син, энекәш, алай булма, тарихны ярат, татарны тарихлы ит. Ялган тарих сөйләп йөрмә, алдашма. Вәт булырсың белгеч!

Укуны тәмамлап, мәктәптә директор булып эшли башлагач, Әлфир абый белән тагын бер очрашырга туры килде.

... Март урталары иде. Кыш белән яз тарткалашкан чак. Бер карасаң, көннәр яктырып, карлар эри башлады, шул ук вакытта нәкъ март аендагы бураннардан да көчле буран булмый торгандыр безнең якларда. Язгы буран бер котырса, чыдап булырлык түгел, җепшек кар йөзгә сылана, керфекләргә боз ката, күз ачып булмый, җилнең ачы сызгыруыннан колак томалана, атларлык хәл юк, кисәк искән көчле җил зиһенне чуалта, юлны саташтыра. Менә шундый чакка туры килде ул елны сайлау көне. Сайлау комиссиясе рәисе итеп мине куйдылар, партком секретаре итеп – үзенә инде ныклап «Көрпә» кушаматы ябышып өлгергән Фәнүсне. Аның ныклы күзәтүе астында мәдәният йортында сайлау участогын җиһазладык, сайлау комиссиясе әгъзалары белән укулар үткәрелде, агитаторлар унйортлыкларга йөреп, авыл халкына быелгы сайлау тәртипләре хакында аңлатып чыктылар. Ягъни сайлау көнгә ныклы хәзерлек белән килдек, иртәнге сәгать алтыда, авылдагы иң өлкән коммунист, партизан Бәйрәмгали бабайны атка утыртып алып килдек.

Партизан Бәйрәмгали бабай күзләрен каядыр караңгы почмакка төбәп, нотыгын башлады.

– Әйе, иптәшләр, партизан булып, Шәмсетдин абзый малае Закирҗан белән Сөн буенда өч көн әрәмәдә качып яттык. Сенгерәнгә каршы инде ул. Кыш көне, карны чокып кердек тә ятабыз. Сенгерәндә түти яши иде, әйтәм Закирҗанга, түтигә генә кереп ятыйк, дим, риза түгел. Чөнки дә аның ипие бар, минеке юк. Алар хәлле кешеләр иде. Миндә бер кесә самосад бар, тәмәке... Ята торгач, тәмәке кабызасым килде. Закирҗан йоклап китте, авызга тәмәке кабуга, шалт! Безне эләктереп тә алдылар. Икебезне дә Сенгерәнгә китерделәр, сорау алдылар. Башта аерып булмый: кемнәр

болар, кызылармы? Аклармы, дигәндәй. Аклар булганнар. Партизаннар дип язып куйдылар. Атып үтермәкчеләр иде, өлгермәделәр, авылга кызыллар һөҗүм итте. Аклар безне келәткә ябып тоталар иде, кызыллар азат иттеләр. Шуннан бирле партизан Бәйрәмгали мин. Сугышлар бетте, инде яши башларга азапланганда, Сталин үлде... – Бәйрәмгали бабайның тавышы өзелеп торды. Бераз тын алгач, карашын каршысындагы комиссия членнарына төбәп, каты тавыш белән ярып салды: – Сталин үлде, әмма ләкин аның урынына кеше тиз табылды! Ну Хрущёв интектерде, өч ел кукуруз басуыннан карга куып йөрдем. Бусы Хрущёвның этлеге инде...

Партком секретаре Бәйрәмгали бабайның кирәкмәгән сүзгә күчүен өнәмичә, аны шып туктатты:

– Булды, иптәш Хасиятов, син беренче булып сайлыйсың. Илебез чәчәк атсын, сайла, Бәйрәмгали бабай! – дип, кулына бюллетень тоттырды.

Моның ишене беренче күрүем, һәммәсеннән кызык тапкан булып йөрим. Чыннан да эш гөрләп кенә барды инде. Иртәнге тугыз тулганда, сайлаучыларның барысы да диярлек «туган ил каршындагы изге бурычларын» үтәргә өлгерделәр. Бер кеше килми тора әлегә сайлауга – Коры Әлфир ашыкмый. Әлфир абыйның хатыны Фәрдия апа сайлау комиссиясе әгъзасы. Ул – алдынгы сыер савучы, сайлау участогына ямь биреп торучы чибәр апа, яшел йон кофтасының күкрәк турысында «Аеруча хезмәт күрсәткән өчен» медале ялтырап тора. Партком секретаре өтәләнә, күп сайлау участоклары инде райондагы сайлау комиссиясенә «исемлектәге сайлаучыларның йөз проценты сайлады» дип хисап биргәннәрдер, безнең «Солют» колхозына кергән авыллар гына сыната булып чыга. Әйткәнемчә, минем дә бу беренче сайлау комиссиясе рәисе булып торуым, бер дә ахырга каласым килми. Иң үрсәләнгәне, билгеле, Фәрдия апа, ул ишек ачылган саен зур матур күзләрен тутырып, кереп килүчегә төбәп ала. Тик Әлфир абый юк, керүчеләрнең күбесе районнан килгән буфетка ашыгалар. Анда исә башка вакытларда кибетләрдә сирәк күренгән дефицит товарлар – һинд чәе, «докторская» һәм «ливерная» колбаса, шоколадлы конфет. Ир-атларга сайлау көне чын бәйрәмгә әверелә, чөнки алдагы көндә колхоз акча бирде, буфетта йөз граммлап бүлеп, хәмер дә саталар. Ул чакта аракы сирәк кайта, кайтканы да Бәләбәйдә чыккан ниндидер сасы нәмәрсә. Монда исә «Столичная» бүлеп сатыла. Анысы кадалып китсен, менә Әлфир абый юк бит әле. Билгеле, участок комиссиясе төнге уникегә кадәр эшли эшләвен, вакыт бер карасаң муеннан. Канун шулай куша, әмма район бит хисап көтә. Фәрдия апа һаман өтәләнә. Яныма килеп, күзләрен мөлдерәтеп сөйләнә:

– Йоклап калган иде мин чыгып киткәндә. Иртәнге биштә торып нишләсен инде?.. Уянгач та килергә тиеш иде, алай озаклап йокы симертә торган гадәте юк аның. Нишләп килми торгандыр?

Аның бу соравына җавап бирүче юк. Бары партком секретаре, ни булса, шул дип, телефоннан «Солют» колхозы хезмәтчәннәре һәм авыл халкының йөз процент рәвештә тавыш бирүе турында хисап биреп ташлады.

Көндезге уникеләр җитте. Абыебыз һаман күренми. Фәрдия апа сабырсызлана. Миннән берничә мәртәбә өйгә кайтып килергә рөхсәт бирүемне сорап карады. Мин бик риза да, «Көрпә» рөхсәт бирми:

– Сайлау комиссиясе әгъзалары участоктан чыгарга тиеш түгел! – дип, җене белән карыша.

Матур башланган көннең рәте китте. Сайлау комиссиясендәгеләрнең кәефләре юк, беркемнең сөйләшәсе килми. Ара-тирә ишек ачыла, «ялт» итеп ишек ягына карап алабыз... Укытучы Мирсәй абый белән Хәеркәй абыйларның гына исләре китми. «Көрпә» күрмәгәндә, буфет тирәсеннән әйләнгәләп килгәннәр иде, йөзләре алсуланып, күзләре яна башлады тегеләрнең, читтәге өстәл янына утырып, шыпырт кына әңгәмә корып, шахмат уйныйлар. «Көрпә» тегеләргә кисәтү ясамакчы булып, бер-ике мәртәбә укталды да, кулын селтәп, бүлмә буйлап, әрле-бирле йөренүен дәвам итте.

Вакыт әкрен генә кыймылдаган була. Юк, Әлфир дигән гөнаһ шомлыгы күренми. Сәгать өч тулды, кичке алты... сигез... Әлфир абзый менә килер, менә килеп керер дигән өмет-уйдан башлар исәнгерәде, әмма абзый күренми. Инде партком секретаре Фәрдия апа ягына карап-карап ала. «Өенә кайтарып җибәреп, ирен өстерәп алып килсен», – диясе килә инде аның, тик сүзен сүз итәргә кирәк, «башкасын бирсә дә сүзен бирми» дигән кешеләр төркеменә керүче «Көрпә» бу «түбәнлеккә» бармаячак инде.

Сәгать кичке, төнге дисәң, авыл өчен дөрес тә булыр, унбер җитте. Инде вакытны минутлап саный башладык. Әлфир абзыйның озын гәүдәсе күз алдыннан китми. Кыяфәт авыру төсенә керде. Фәрдия апаның чибәр йөзенә сары йөгерде. Унике туларга егерме минут кала, кызарган күзләрен түбән төшереп, «Көрпә»гә дәште:

– Ни, Фәнүс энем, эчеп исереп ята torгандыр инде бу. Килмәс инде... Үзем генә салсам... аның өчен бюллетеньне дим....

Башка вакытта кырт-мырт сөйләшкән партком секретарена апаның йомшак сүзләре баткан кешенең саламга тотынуыдай тәэсир итеп куйды, ахры. Эченә җан кереп китте. Кырт килеп, ярып салды:

– Шулай итәргә кирәк! Бер алкаш аркасында бөтен колхозны буяр хәл юк! Сал бер бюллетеньне урнага! – Аннан сайлау комиссиясе әгъзаларын кисәтеп тә алырга онытмады. – Карагыз аны, күрмәдегез, белмәдегез! – Аннан төксе генә миңа эндәште. – Калган буш бюллетеньнәрне китер! Уничтожать итәбез.

Файдаланмаган бюллетеньнәрне алып, партком секретарена суздым. Ул чүкеч тотып, алдан әзерләнгән калын такта кисәгенә куеп, бюллетеньнәрнең уртасына ике йөзле кадак кагып, тишек ясады. Кадакны алып кесәсенә салды, чүкечне миңа тоттырды.

– Бюллетеньнәрне саный башлыйбыз. Бүгенге хәлләрне беркемгә дә сөйләнеп йөрмәгез! Ишетсен колагыгыз!

Бу кисәтүгә җавап булып, Мирсәй абый белән Хәеркәй абыйларның парлап гырлаулары ишетелде. Алар шахмат уйнаган өстәлгә башларын куеп, йокы бүсәләр иде.

Бәхетеңне үгез сөзсә... Фәрдия апа урнага бюллетень салып өлгермәде, алагаемга ишек ачылып китте. Ишектән керүче... Әлфир абый иде.

Абзыебыз бәйрәмчә киенгән. Өстендә – соргылт сукно тышлы, озын гәүдәсенә килешеп-ятып торган пальто, башында – сирәк кешеләрдә генә була торган кеш тиресеннән эшләнгән бүрек, аягында ялтырап торган

штиблет ботинка, муенында – ак шарф. Йөзләр балкып тора – абзый шома итеп кырынган. Сайлауга килергә иркенләп әзерләнгән бу. Керүгә, беркемгә сүз катып тормыйча, кызыл постау ябылган өстәл янына атлады. Тәкәллефсез генә:

– Бирегез минем бюллетеньне! – диде.

Әйтерсең, аның өчен аерым бюллетень саклап торганбыз.

Фәрдия апаның өстенә салкын су койдылармыни, Әлфир абыйның җиңенә ябышты.

– Әлфиркәем, сабыр гына тыңла әле, – диде ул, ирен читкәрәк өстерәп.

Әлфир абый нидер сизенеп, кулын тартып алды.

– Син нәрсә, сайлатмый калдырмаска уйлыйсыңмы мине? Кая өстерисең?

«Көрпә»нең йөзе агарып катты, минем дә хәлләр шәптән түгел. Ичмасам, исән бюллетень дә юк бит. Ашыкты «Көрпә» бюллетеньнарга кадак кагып. Аны берничек тә Әлфир абзыйга биреп булмый инде. Коткарса, Фәрдия апа гына коткара безне бу бәладән.

Бу безнең өчен ике аяклы афәт иде. Сүзсез торуыбызны дәвам итәбез.

Фәрдия апа үз өстенә төшкән бурычны бөтен катгыйлыгы белән аңлый иде.

– Тыңла әле, Әлфиркәем, холыксызланма, – дип, Фәрдия апа ирен бер кырыйга этәрә төште.

– Нигә холыксызланырга тиеш әле мин? Мин тыныч, холыксызланмыйм, – диде Әлфир абый, берни булмагандай. – Сайлауга килдем, тизрәк бирегез миңа бюллетень, унике туларга унбиш минут калып бара, – дип, стенадагы сәгатькә күз ташлап алды.

– Ни бит... Әлфир, ялгыштым мин, – диде Фәрдия апа еларга җитешеп. – Килүеңне көттем-көттем дә синең өчен үзем сайладым да куйдым. Килмәвеңдер дип уйладым. Ашыкканмын, гафу ит инде...

Әлфир абыйның күзләре түгәрәкләнде.

– Ничек минем өчен сайладың син? Мин, нәрсә, гарип-горабамы? Мине тавыш бирү хокукыннан мәхрүм итәргә ни хакыгыз бар? – Ул Фәрдия апаны читкә этәреп, партком секретаре янына килеп басты. – Ни хакыгыз бар? Мин сайлау участогына вакытында килдем, үз кулларым белән сайлыйсым килә, бирегез миңа бюллетень!

– Бюллетеньнәр юк! Без аларны гамәлдән чыгардык, – диде Фәнүс каушый төшеп. Закон шулай куша.

Тавышка Мирсәй абый белән Хәеркәй абый да уянды. Кемдер аларга тавышның нидән килеп чыкканын аңлатып өлгергән иде инде.

– Закон алай кушмый! – диде Әлфир абзый, өздереп. – Сайлау вакыты чыккач кына эшләнергә тиеш гамәлдән чыгару. Сез алдан эшләп куйгансыз, җитмәсә, мине тавыштан мәхрүм итеп маташасыз. Кая телефон, район комиссиясенә шалтыратам, туздырам мин сезне, – диде ул, бер партком секретарена, бер миңа батырып карап. – Сезнең белән сөйләшеп тә тормыйм, сез – закон бозган кешеләр, тормагыз юлга аркылы төшеп! Шалтыратам, кирәк икән, Мәскәүгә үк хәбәр салам. Аерым совет гражданинын гына түгел, совет властен мыскыл иттегез сез, демократияне аяк астына салып таптадыгыз! –Ул чынлап торып шалтыратырга уйлый иде булса кирәк, кесәсеннән кәгазь кисәге тартып чыгарды. Анда район сайлау

комиссиясенең телефон номеры язып куелган. Каһәрең, абзый алдан ук ни буласын чамалап, соңгы минутларга кадәр көтеп торган икән бит.

Нишләргә белмичә, Мирсәй абыйга карап алдым.

– Берәр ярты бармы? – диде Мирсәй абый, күзен кыса төшеп. – Сайлау комиссиясенә дигән? Элекке сайлауларда була торган иде бит...

– Бар ла ул, сабыр итегез инде. Менә бит ни килеп чыкты әле монда. Уйламаган җирдән ЧП, – дидем, аңлап җиткермичәрәк. Мирсәй абый, «борчылма» дигәндәй көлемсерәп куйды.

– Бар, алып кил артыңны. Әлфир белән үзем сөйләшәм.

Унике тулып килә. Урамда буран котыра, безнең авылдан район үзәгенә хәйран ерак кына. Мин, участок рәисе, бюллетеньнарны районга илтеп тапшырырга тиешмен, район комиссиясе рәисенә хисап тотып, барысын тапшыргач, кире кайтырга чыгасы. Инде кайбер участок рәисләре, алдан ук эшләрен тәмам кылып,  юлга чыгып маташа торганнардыр. Трактор белән барасы булыр, таң атканда барып керсәк, сөенерсең.

Тиз генә яшереп куйган җирдән бер шешә тартып чыгардым.

Мирсәй абый яртыны чалбар кесәсенә тыгып куйгач, һаман ярсып, үзен «тавыштан мәхрүм итүләре» өчен бервакытта да гафу итмәячәге турында ныклап аңлатуга күчкән Әлфир абый янына килде. Фәрдия апа урна янына басып елап тора.

Мирсәй абый ярсынган Әлфир абыйның иңсәсеннән кочып алгандай итте дә колагына нидер пышылдады. Мирсәй абый физика укыта, Әлфир абый укытучылардан аны гына чын күңеленнән ихтирам итә, үзенә тиң күреп сөйләшә иде. Мирсәй абый нindирәк серле сүзләр тапкандыр, Әлфир абый ул хикмәтле сүзләрне ишетте бит,  бераз сүрелә төште.

Әлфир абый, сайлау әгъзалары утырган якка мәзәгрәк караш ташлап, тавышын кыса төште.

– Мин нәмә, нәмә... Миндә бит дөреслек... Сайлау хокукыннан мәхрүм итеп маташкан булалар, ә?! Ник әйтмәскә, мин кемнән ким? Сайлау вакыты чыгарга әле биш минут бар, бирегез бюллетень!

Мирсәй абый аны эчке бүлмәгә алып кереп китте. Өч-дүрт минуттан Әлфир абый кабат күренде.

– Карагыз аны, соңгы мәртәбә! Тагын да шулай кылансагыз, белегез, болай гына калдырмаячакмын. Әйдә, миннән булсын яхшылык, тавышымны бирдем дип исәпләгез. Мирсәй абыегызга рәхмәт әйтегез, ул булмаса... – дип сөйләнә-сөйләнә, кесәсендәге шешәне кармалап алгач, Фәрдия апага эндәште. – Ә синең белән кайткач сөйләшермен, күрә торып тавыштан мәхрүм итсеннәр инде, җә! Шартлап үләрсең, – дип, башын артка чөеп, ашыкмый гына чыгып китте.

Трактор белән көрт арты көрт ярып бара торгач, район үзәгенә килеп кергәндә, таң атарга чамалый башлаган иде инде. Буран да басылды. Район сайлау комиссиясендә кеше юк диярлек. Комиссия каршында хисап тоткач, мине комиссия рәисе янына кертеп җибәрделәр.

Рәис райкомның идеология секретаре Дилшат Гомәрович иде.

Мине төксе каршы алды ул.

– Нәрсә, Сәяхов, юл тапмый йөрдегезме? – диде ул, күтәрелеп тә карамыйча.

– Буран шул... трактор белән килергә туры килде. Озаккарак китте... – дип акланып маташкан булдым.

– Маркс, Чапаев, Крупская, XXII партсъезд колхозлары сездән якынракмыни? Алар килеп, хисап биреп киткәнгә ике сәгать вакыт үтте. Аларның юлларыннан көртне көрәп, асфальт җәеп куйганнармы? Син, адәм тәганәсе, бөтен районны артка сөйрәдең. Телдән выговор. Йә, сөйлә, ничек үтте сайлау?

– Әйбәт үтте, Дилшат Шакирович, тәртиптә.

– Һе, тәртип, имеш... Ул Әлфир дигән адәмегез кайда эшли?

– Колхозда, техника паркында электрик.

– Кирәкме соң ул аның эше?

– Кирәк инде, хәзер техникалар бик катлаулы бит, аның белеме бар... – дигән булдым, Әлфир абыйны күз алдына китереп. Машина-трактор эчендә казына башласа, маңгаена тир бәреп чыга иде аның, хәзер үземнең маңгайдан бөрчек-бөрчек тир тәгәри.

– Белгеч... Син яшь кеше әле, әйбәт сабак биргән ул адәм сиңа. Йә, бусы шулай булсын. Ә бер бюллетеньда КПСС хакында начар сүзләр язылган, анысына нindирәк аңлатма бирәсең?

Башны түбән иеп торам. Чаршау артында кем ни язмас, каян беләсең инде аны. Димәк, «Көрпә» сайлау участогында булган бөтен хәлләрне районга җиткереп куйган.

Дилшат Гомәрович минем уйларны укып торган диярсең:

– Кем икәнен табачакбыз, непременно табачакбыз! – диде һәм, телефонга үрелеп, кемгәдер эндәште: – Прокурор, судья, милиция начальнигын чакырыгыз! – Кыбырсынганымны күреп, кулы белән «урыныңнан кузгалма» дигәнрәк ишарә ясады.

Баш миенә гөжләп кан йөгергәнен тойдым. Шулар алдында җавап тотарга тиеш микән инде мин? Тотарга туры килер шул, бер кешене «сайлау хокукыннан мәхрүм иттек», бер бюллетеньга олы хәрефләр белән берсе: «КПСС – гад!» дип язып куйган...

Райкомга керешли буфетның ачык ишегеннән күреп калган идем – прокурор, судья, милиция начальнигы, тагын райком тирәсендә йөрүче ике-өч кеше матур гына гәпләшеп, хәмер чөмереп утыралар иде. Болар монда ни өчен кирәк инде дип уйлап куйган идем. Димәк, кирәкләре чыга инде болай булгач.

Ишектән формадан киенгән прокурор, милиция начальнигы, алар артыннан гражданский киемдәге судья кереп, Дильшат Гомәрович каршысына тезелеп бастылар. Шактый кызарышканнар...

Дилшат Гомәрович минем якка карап алды. Инде тир маңгайдан гына түгел, аркадан ага иде.

– Хөрмәтле иптәшләр! — диде Дилшат Гомәрович ясалма тавыш беләнрәк. – Районда сайлау тыныч үтте, хокук бозулар булмады, сезгә рәхмәт белдерәм. Сайлау төгәлләнде, өегезгә кайта аласыз, – диде. Тегеләр шаулап тын алдылар, Дилшат Гомәровичның кулын кысып азапландылар, шул ук вакытта райком секретарена телләре көрмәкләнгәнен сиздермәскә дә тырышалар иде.

Алар чыгып киткәч, Дилшат Гомәрович елмая төшеп, миңа да кузгалырга вакыт җиткәнен белдерде:

– Шулай, Сәяхов, мондый җаваплы эштә беренче чыныгуың белән сине дә котлыйм. Күргәнеңчә, гади генә түгел безнең тормыш. Баштан ниләр генә кичми эш барышында. Шулай да сизгерлекне, уяулыкны югалтмаска тиешбез. Партия безне шуңа өйрәтә. Хәзер бар, кайт, монда ишеткәннәрне сөйләнеп йөрмә. Болтун – находка шпионов! Дошманнар җитәрлек безнең.

***

Әлфир абыйны соңгы мәртәбә кайчан күргәнемне дә онытканмын инде. Ничәнче ел булгандыр, истә калганы шул – язгы пычрак, карлар эреп беткән, әмма сукмак төшмәгән иде әле. Вакыт табылды, авылга кайтып, әткәй-әнкәйнең хәлен белеп килергә уйладым. Олы юлдан авыл ягына борылып, инеш аша салынган тар күперне чыгуга, юл бетте дисәм дә була. Машина тәгәрмәченә пычрак урала, һәр чокыр-чакырга кереп батармын сыман, шулай әкрен генә юлсыз юлдан барып маташам, каршыга Әлфир абый килеп чыкты. Техника паркыннан кайтып килеше. Аягында сүчинкә, өстендә шактый таушалган телогрейка, башында кара бәрән бүрек. Элекке Әлфир абый түгел инде, адымнары авыр, салмак, мине танымакчы булып, машина тәрәзәсенә төбәп караш ташлады, танымагандыр¸ әлбәттә, йөзенә битарафлык чыгарып, читкәрәк чыгып, юл бирде. Олыгайган, алҗыган, сүрелгән иде ул...

**9**

Быел җәй матавыклы булды. Республикада берсеннән-берсе зур чаралар үткәрелде. Инде бераз хәл алырга була дип тынычлана гына башлаган идем, Халыкара конференция үткәрү планы килеп төште. Оештыручылар арасында безнең уку йорты да бар, ректор күп уйлап тормады, мине җаваплы итеп беркетте. Мәшәкатькә кереп чумдым.

Фәннәр академиясенең аксыл мәрмәр таштан эшләнгән баскычыннан төшеп киләм. Кесә телефоны уйнап алды. Таныш номер түгел. Бер тынга туктап, телефонны колакка куйдым.

Кыбырсынган тавыш ишетелде. Тавышны да таныйм дип әйтә алмыйм. Карлыккан, юеш чүпрәк аша ишетелгән сыман.

– Алло, алло! – ди үтә дә ашыккан тавыш.

– Әйе, мин әйтәм, тыңлыйм сезне.

– Мин әле бу, Финсәт Шабырдин.

Куанычтан кычкырып җибәрдем:

– Финсәт! Дустым, синме бу? Әллә Казанга килеп чыктыңмы? Каян тавыш бирәсең?

Финсәт – яшьлек дустым, заманында агылый белән тагылый сыман йөри идек. Бер үк елны Казанга укырга кердек. Мин шәһәрдә урнашып, үз белгечлегем буенча эш-мәшәкатьләргә кереп чумдым. Ул институттан соң авылга кайтты. Аның яшь чакта ук кызыклы, мин бик үк аңлап җиткермәгән бер сыйфаты бар иде – һәрчак кеше күз уңында буласы, үзен күрсәтәсе килә иде. Шактый дәрәҗәле эшләргә куеп карадылар үзен, әмма берсендә дә артык «бүрттемәде» кебек.

Шөкер, миңа язмыш мәрхәмәтле булды диимме соң, гыйлем юлын сайладым, үземне иҗатта таптым, шушы юнәлештәге фәнни даирәләр белән

дә аралашып торам. Миңа ошый бу эш. Баштарак Финсәт белән очрашкан саен ачылып сөйләшә идек, тора-бара очрашу-аралашулар сирәкләнде, үзе дә миңа төксерәк караган шикелле тоела башлады. Анда миңа карата ниндидер көнчелек барлыкка килде. Хатыны да, чиләгенә күрә капкачы дигәндәй, шундыйрак булды бугай. Көнләшү борынгыдан килгән үз чиребез, аннан котыла торган дару юк. Ул яктан да уңдым – көнләшүчеләр дә, яла ягучы хөсетләр дә җитәрлек булды юлымда. Дошманнар да аз түгел, аларын да эзләп йөрисе юк. Яңгырдан соң баш төрткән гөмбә сыман уйламаган җирдән кинәт кенә пәйда булалар алар аяк астында. Ныклап уйласаң, дошманлыкның нигезендә дә шул көнчелек, мин-минлек ята инде.

– Нинди Казан булсын, авылдан шалтыратам, – диде Финсәт, канәгатьсезлеген белдертеп. – Әле мине ветераннар советы рәисе итеп сайладылар... Шул эш белән йөрү... – Финсәт кинәт кенә сүз сөрешен үзгәртеп, усал, җикеренгән тавыш белән өтек-төтек сөйләргә тотынды. – Син, парин, зиратка кайтып, нәсел-нәсәбең күмелгән урыннарны тәртипкә китер. Ярты зират сезнең нәсел, кем эш итәргә тиеш аларны?..

Дөрес сүзләр. Ел саен туганнар бергә җыелып кайтып, зиратны тәртипкә китерәбез. Әйтәм бит, зират зур безнең, биләгән мәйданы шактый. Элек картлар җәй буе шунда печән чабып зират-кабер тирәләрен рәткә китереп йөриләр иде. Печәне каерылып уңа, шуны чабып, бүлешәләр, тарала башлаган чардуганнарны төзәтәләр, буйыйлар, ауган агачлардан арындыралар иде. Зират чабарга тиешле исемлекне картлар алдан килештереп төзиләр. Арага теләсә кем болай гына керә дә алмый иде. Бер елны элегрәк партия оешма секретаре булып йөргән абзый шушы «командага» әләгергә омтылып, гауга чыгарып та йөргән иде. Картлар кертмәделәр. Зиратта печән өю вакыйгасын искә төшерделәр. Быел, әйткәнемчә мәшәкатьле ел булды, май аенда бер кайтып, туганнар белән өмә ясаган идек, инде июльнең егермеләре тирәсендә кайтырга уйлашып торабыз. Финсәткә шуны аңлатырга тырышам:

– Кайтам, дустым, кайтабыз. Һәр елны өч мәртәбә кайтып, зиратны җыештырып киләбез. Тагын ике атнадан кайтабыз, – дим тыныч кына.

– Нинди өч атна? Бүген үк кайтып җит! Кайт, синең ата-анаң каберен кем карарга тиеш! – дип, һаман үзенекен кабатлый бу. – Юк-бар эшләреңне ташла, бүген үк кайтырга кузгал!

– Бүген үк булмас. – Ачуым кузгалып куйды. – Болай да кайткан саен үзебезнекен генә түгел, якын-тирәдәге каберлекләрне чистартып, билгә җиткән үләнен чабып (хәзер зират печәнен түгел, болынлыктагы печәнгә төшкән кеше дә күренми) китәбез. Өч-дүрт машинага төялеп кайтабыз, ду китереп эшлибез, авылга кереп торырга да вакыт калмый, китеп тә барабыз. Кайбер чакта улым белән икәү генә кайтырга туры килә. Туганнар картаялар, балалары кайсы кая таралып беткән, бер сызгыруга җыелып бетешле түгел. Еллар буе шулай.

Финсәтнең ишетәсе килми.

– Кайт, ни эшең бар?

Нәрсә әйтим? Нәрсә әйтсәң дә, акланган сыманга әйләнә. Турысын әйттем инде.

– Халыкара конференция оештырып йөрибез. Шул кулны тота.

– Халыкара конференция, имеш. Тапкан берәү, эшем иясе! Ташла конференцияңне, кайт, зират сине көтә!

– Зират барыбызны да көтә инде ул, – дип, сүзне бераз шаяртуга борып алмакчы булдым.

Минем сүзләрне ишетмәде бугай, һаман үзенекен тукый, ачы тавышы колакны яра.

Артык сөйләшеп торуның файдасы юк иде, телефонны сүндереп куйдым.

Ике атнадан соң туганнар җыелышып кайттык, гадәттәгечә, зиратны тәртипкә китереп, эшне төгәлләп, чыгу юлына кузгалдык.

Нигәдер тоткарландым. Күңел сулкылдап алды. Көзгә кергәч кайтып булса ярый да инде. Шәһәргә китеп, авылда туган-тумачасы калмаган берәү әйткән: «Хәзер минем авыл – шушы зират инде, – дигән. – Елга бер тапкыр зираттагы әрвахларга дога кылып китәбез дә вәссәлам. Зират каршы ала, зират озатып кала...» Минем дә авыл шушы зират, дияргә була. Авылда туган-тумача юк дисәң дә була, әткәйнең якын ир туганнары сугышта башларын салганнар. Калган туган-тумача гел ятим-җилпе хатын-кызлар, әби-чәбиләр иде. Аларны сугыш ятим иткән... Дус-ишләр юк, мин белгән, аралашкан, бергә эшләгәннәрнең күбесе авылдан чыгып киткән, зиратка, мәңгелек йортка күчкәннәре дә байтак. Уйлый башласаң, күңел ташып түгелергә тотына. Килер бер көн, бакыйлыкка китеп барырмын. Минем дә үз авылымда җирләнәсе килә. «Шагыйрьләр авылда туалар, шәһәрдә үләләр; мәңгелек йокыга талгач, туган җир туфрагы баш астында мендәр булыр...» Шуңа өмет итәм. Әмма тагын бер ветераннар советы рәисе табылыр, минем каберем тирәсендә тузынып йөрер, рәшәткәгә, баш өстендәге ташка ачу белән карап үтәр. Улым, кайтып, кабер алларын тәртипкә китерер дә китеп барыр. Күргән кеше дә булмас. Ул китеп беркадәр вакыт үтүгә, тагын билдән үлән үсәр. Ветераннар рәисе тагын тузынып, сүгенеп үтәр бу тирәдән. Үлгәч тә, тынычлыкта калдырулары икеле.

Күңел ташып өлгергән чакта гына ягымлы тавыш ишетелде.

– Абый-й-й..

Сискәнеп, артка борылдым. Ике-өч адым ераклыкта бер яшь хатын белән таза ир басып тора.

Хатынның күзләреннән шаян чаткылар сирпелде.

– Абый, танымыйсыңмы безне? – Чибәр, ачык йөз, килешле гәүдә, иңнәренә таралып төшкән кап-кара чәчләр. Кемнедер хәтерләтә...

– Таныйм да кебек... – Кинәт исемә килеп төште. Фәрдия апаның чагылышы! – Әлфир абыйның кызы Иринә бит син!

Хатынның елмаюы бөтен йөзенә җәелде.

– Таныйсың икән бит әле! Иремне дә беләсең, абый.

– Күрше авыл егете Айнур. Минем укучым.

Икесе берьюлы мине кочаклап алдылар. Зиратта бу ярыймы, юкмы, анысын уйлап тормадык. Шау-гөр килеп хәл белешергә тотындык.

– Абый, син язган һәр әсәрне укып барам, – диде Иринә. – Шул кадәр тормышчан язасың. Әти дә син язганнарны яратып укый иде.

– Әлфир абый... Вафатына да байтак вакыт үткәндер инде...

– Быел ун ел тулды. Шуңа каберен күреп, чәчәкләргә су сибеп кайтыйк

дип кердек. – Кулындагы биш литрлы савытка ымлады. Атна саен кайтабыз, абый. Район үзәгендә генә без, ерак китмәдек.

– Фәрдия апа исәнме әле?

– Аллага шөкер, әнием исән-имин, – диде Сиринә, сөенечтән балкып. – Әни янына кайтып йөрибез. Әле кайтышлый Айнурның авылына кереп чыктык. Андагы әти-әнинең дә хәлләрен белеп кенә торабыз. Эше дә табылып тора инде. Авыл җире бит.

– Шулай инде, – дидем, килешкәнемне белдереп.

– Әти безне көтеп тора инде, – дип, минем әткәй кабереннән ерак түгел чардуганга ым какты.

Ул каберне күрми мөмкин түгел, гөлгә күмелеп, ерактан ук игътибарны җәлеп итеп тора.

– Базар урамына күмегез, Тавык урамыннан гарык булдым, – диде вафаты алдыннан. Хәзер безнең урамны матур итеп төзәттеләр, таш-ком җәйделәр. Әти генә күрә алмый калды. Шул чокырлы-чакырлы урамда яшәп китте.

– Истә Тавык урамы...

– Безнең зират бигрәк иркен инде, – диде Сиринә. – Агачлар гөрләп үсә, кошлар җырлап туймыйлар. Ул җиләкләр... Сизәсезме, җиләрдә җиләк исе... – дип елмайды ул.

***

Шуның белән шул... Әлфир абый хакында белгәннәремне бер кыйссага теркәдем мин. Рухына дога булып барсын, берни дә арттырмадым, киметтем дип тә әйтә алмыйм, мин бит аны бик аз белә идем. Аның рухы, бәлки, Күккә ашкандыр.

Күкләр Җиргә тоташкан, чөнки безнең гәүдәбез Җирдә, ә үзебез каядыр ашкынабыз, очынабыз, бар булабыз, югалабыз, табылабыз – чынлыкта Җирдә без кунак кына. Җир – вакытлыча тукталыш, җаныбыз исә безне асылыбызга – Күккә кайтарырга ашкына.

Һәр авылда, шәһәрдә дә танышлар арасында бер Әлфир абый табылмый калмыйдыр. Бер карасаң, ул минем өчен бөтенләй чит кеше, икенче яктан карасаң, безнең гаилә язмышында ниндидер эз калдырган икән бит ул. Кызык... «Ачык дәфтәр»гә юктан гына килеп кермәгәндер, шулай уйлыйм.

Өстәлдә яткан дәфтәремне ябып, китап киштәсенә алып куйдым. Моннан ары язу өстәле янына утырган саен җанны бораулап, «Коры Әлфир» дигән сүзләр чекерәеп бакмаслар инде дигән уйдан җаным тынычланып калды. Бәлки, Әлфир абыйның да рухы тынычлангандыр, кем белә бит...



Лилия
Сәгыйдуллина

# АЛСУЛАНЫП, ЯНӘ КОЯШ ЧЫГА...

## Томанлы иртә

Сөн буйлары – ап-ак томан... Бүген болыт – җәяүле.
Бәлки, таңда савымчының түгелгәндер чиләге?
Безне юксынудан үксеп, йолдызлар яшь койганмы?
Әллә кояш, йөз яшереп, аксыл пәрдә корганмы?
Төн – көн арасында томан сыгылмалы басмамы?
Киләсенең йөз-фигылен яшергән ак язмамы?
Йокымсырап, йортлар йөзә.. Ага агач, куак та...
Тау гына тау булып калган биектә һәм еракта.
... Әкияти сер-хикмәт бар гади генә томанда.
Ачылмаган серләр калды томан йоткан елларда.

## Кунакта

Кунакка дип кайттым әле каеннарым янына.
Алар кочагында гына сагышларым языла.
Хәер, нинди кунак инде?! Мин дә бу җир баласы:
Аклыгы да – үземнеке. Үземнеке – карасы.
Мин дә каендай саргаям. Гел сулкылдый яра да.
Әмма бернигә карамый, һәр яз өмет ярала...
Саубуллашам. Каеннарым моңсу гына озата.
Кайгырмагыз, туганнарым, китмимен бит озакка.
...Китәм дип тә киталмыйсың үз-үзеңнән еракка.
Мин генәме? Вакыт үзе мәңгелектә кунакта.

***

Тәрәзәмә бәреп, яңгыр ява.
Яуган. Ява. Һәм дә явачак.
Кем ул – Күктә үкси? Әллә – әйди?
Сорау – сорау булып калачак...

Лилия СӘГЫЙДУЛЛИНА (1956) – *шагыйрә, Башкорт дәүләт университеты доценты; «Абага чәчәге», «Мизгелләр йолдызлыгы» исемле китаплар авторы. Уфада яши.*

Тәрәзәмә бәреп яңгыр ява.
Күзәтәмен юл-юл эзләрен –
«Балам – багалмам!» дип, безне уйлап,
Юлга баккан әнкәй күзләрен...

Тәрәзәмә бәреп, яңгыр ява.
Әллә яшьлек, әллә балачак
Үрелепләр карый тәрәз аша:
Ни югалтып, ул ни табачак?..

Тәрәзәмә бәреп яңгыр ява.
Арыналмый Җир-Күк болыттан.
Яңгырларга түзеп булыр да ул –
Җан күшегә Кояш юклыктан...

Тәрәзәмә бәреп, яңгыр ява.
Каерып ача күңел ишеген...
Күр: Җир тырнап, Күк кадәр Күк елый,
Нишләвең, дип, кешем, бу синең?..

***

Мин Күкләргә бик күптәннән гашыйк.
Кайчан? Белмим. Бәлки, туганчы?..
Мәңгелектән вакыт бөреләнеп,
Мәңгелеккә орлык койганчы?..

Бала чакта, җиргә чалкан ятып,
Күксел болын иңләү дисеңме!
Йолдыз әлифбасын отып алып,
Күккә ую Синең ис(е)меңне...

Теләк теләү йолдыз яңгырында.
Кабул микән? Булса – ничәсе?..
Асманнарга ашу, белә торып,
Берчак кыелыплар төшәсен...

Гаҗизләнү болытларга карап:
Кайдан килә? Китә кайларга?..
Болыт белән тәңгәллекләр табу:
Кем әмере юлны сайлауга?

Мин Күкләргә бүген дә бит гашыйк.
(Тере микән Күкнең хисләре?..)
...Алсуланып, янә кояш чыга,
Баеса да һәрчак кичләрен.

## Матурлык

Һәрбер таңда, калып таңга,
Мин матурлык җыям җанга...
Бу матурлык: төстә, истә,
Өндә, ымда һәм тоемда...
Шигъриятнең им-томында.
Бу матурлык: чык, тамчыда,
Бәби нурда, һәр нотада –
Әсәрләгән сихри моңда.
Бу матурлык сыймый аңга.
Сүз-тәгъбир дә чит-ят аңа.
Башка аңлам кирәк монда.
Бу матурлык бик якында...
Бу матурлык бик еракта...
Җитеп була җан-канатта!
Ачар өчен яңа көнне,
Кичәр өчен яңа төнне
Чыныктырам йөрәгемне:

Һәрбер таңда, калып таңга,
Мин матурлык җыям җанга.

## Сагыш

Авылыңны сагынасыңдыр, диләр.
Юк, сагынмыйм. Сагыныр кешем юк.
Бу дөньяны куып җитәм диеп,
Йөгерә-йөгерә эшләр эшем юк.
Эзләр эзем дә юк. Аларны да
Күмеп киткән еллар бураны.
Тапканын да әнә язмыш-кайчы,
Һич аямый, кат-кат турады.

Мин бары тик хәтер яңартамын:
Мин киткәнче китеп бармасын!
Шуңа да мин авыл ягына борам
Бик еш кына гомер арбасын.

Һәр тукталыш – йөрәк ярасына
Учлап-учлап кабат тоз салу
Икәнлеген белгән килеш кайтам:
Көтә сыман монда яңару.

Чәчәктавым итәгендә – башым:
Моң нәкышли җанга кылганнар,
Тибрәләмен хәтер бәллүендә,
Җанда кайтавазлый тын ымнар...

Авылыңны сагынасыңдыр, диләр.
Юк, сагынмыйм, дим дә... Сагынам!
Үткәнемне киләчәккә үреп
Сүндем дигәндә дә кабынам.

## Хәят. Ияртемнәр.

Яфраклар шыбырдавы, энҗе кар шыгырдавы,
тамчылар тыпылдавы, таң җиле пышылдавы,
елганың елкылдавы, йолдызлар елтыравы,
чишмәләр челтерәве, кояш-нур җемелдәве...

Каргалар каркылдавы, чыпчыклар чыркылдавы,
бакалар бакылдавы, бытбылдык бытылдавы,
еланнар ысылдавы, сандугач чутылдавы,
бүреләр улашуы, күгәрчен гөрләшүе...

Бәбинең тәтелдәве, әбинең теркелдәве,
бабайның кеткелдәве, әнинең өлтерәве,
әти үчтекиләве, сәгатьнең текелдәве,
самавыр гөжелдәве, ояның чөкердәве...
.....................................
Хәятнең лепелдәве...

***

Татар булып туу гына җитми,
Татар булып яшим дигәнгә.
Алдаткычлар... Борылышлар... Түмгәк...
Абына бәндә тигез җирдә дә...

Татар булып туу гына җитми.
Һәркөн яңа дәлил сорала.
«Бабам – татар!» – дисең.
Фидакарьлек!..
Ә оныклар ни дип тын ала?..

Татар булып туу гына җитми,
«Илем!» – дигән җирең ят кылса.
«Уян, татар!..»
Шигарь кабатлана...
Уяныргa вакыт лабаса!

Татар булып туу гына җитми,
Кеше булу кытлык заманда.
Ике башлангычның бөтенлеге
Мөмкин бары тере җаннарда.

...Татар булып туу да бик җитә,
Исемеңә җисем салганда:
Чишмә башын гел кайгыртып торсаң,
Елга ага шул ук ярларда.

## Ватансызлык

Ватансызлык ни, дисезме? Илең өчен оялу.
Хакимлекнең нәҗесенә җаның-тәнең буялу.

Ватансызлык ни, дисезме? Туктаусыз ялган ашау.
Карачкыга ярамасны – уйнапмы? – Балбал ясау.

Ватансызлык ни, дисезме? Коллыгыңны аңламау.
Зур мәртәбә: җаен табып, үз илеңне алдалау.

Ватансызлык ни, дисезме? Гамьсезлеккә табыну.
Өметсез ил кочагында тәмуг булып кабыну.

Ватансызлык ни, дисезме? Гаделсезлеккә түзмәү.
Килмешәк булып, чарасыз чит җирдән Ватан эзләү.

Ватансызлык ни, дисезме? Үксезлегеңнән үксү.
Туган җиреңдә яшәп тә, үз Ватаныңны җирсү.

Ватансызлык ни, дисезме? Тарихларда югалу.
«Яңа чор!..» – дип өметләнсәк, дежа вю да дежа вю.

## Эзоп теле

Эзоп телен өйрәнергә вакыт җитте тагы да.
Хәер, аның булмады күк онытылган чагы да...

Эзоп нишләсен?.. Яшәгән бит ул коллык чорында!
Ә сүз иреге яулана иреклеләр корында[1]...

Кинаяне аңлыйсыздыр: уең йом тел төбенә!
Уең ирекә омтылса, тел тамырдан өзелә.

Тел генәме?.. Аһ, гомерләр!.. Чәрдәкләнә буыннар!
«Солых = сугыш!»[2] – дигәннәргә инанучы оланнар...

Яшерен тел кулланмаучы кан дошманга тиңләнә.
Бүген кытлык мондый йөкне күтәрердәй иңнәргә.

Эзоптан баш тартканнарга «яңател»[3] – төп кулланма.
Аны «5»кә белүчеләр ватанпәрвәр санала.
..................................................................................
Куласадагы тиен без – коллар – Эзоп хәлендә!..
Үз телеңдә Сүзең әйтү насыйп тик үз илеңдә.

***

*Моим стихам, как драгоценным винам,*
*Настанет свой черёд.*

М.Цветаева

«Минем шигырьләргә чират җитәр...» –
Дигән өмет миндә юк икән.
Бүген теллеләргә кирәкмимен –
Телсез иртәгәдән ни көтәм?..

Телсез иртәгәбез шыгыр-шыгыр
Шыгырдата төяк капкасын.
Йорт-дөньясын җайлап корган бабам
Көтмәгәндер ятлар таптасын.

Бабам төшенә дә кертмәгәндер
Оныкларның телен сатасын.
Сатуларга калкан булалмагач,
Ук булмагач – мин дә катнаштым...

[1] кор – монда: мохит, даирә мәгънәсендә.
[2] Дж. Оруэллның «1984» романына сылтама;
[3] Атамаларның мәгънәсен үзгәртеп куллану. Шул ук әсәргә сылтама.

Өметкә дә тамчы өметем юк:
Йөз чөергән дөнья шигырьдән.
Башка потлар... Башка табынулар...
Җан камаша яңа шигарьдән.

Шигыремә, беләм, чират җитмәс.
(Җитмәве дә әллә гаделме?..)

Тик Тукайсыз калсак, Туфаннарсыз,
Туфан йотар безнең кавемне...

«Оптимист?!» дип уйласыннар әле,
Тауда бер мәл кысла сызгырыр.
Сорап куйды бүген бер шәкертем:
«Гаделлек» һәм «гарьлек» – ни булыр?»

## Гомерне нәрсәгә сарыф итәбез?..

*На что мы тратим жизнь?..*
Б.Серкебаев[4]

Гомерне нәрсәгә сарыф итәбез?
Ыгы-зыгыга, ызгыш-гаугага...
Буп-буш сүзләргә, чүбек чәйнәүгә...
Үпкә, нәфрәткә һәм җаһиллеккә...
Ә кирәк иде бит – мәхәббәткә!

Гомерне нәрсәгә сарыф итәбез?
Йөгереш, көрәшкә, өлгерешкә...
Мал-мөлкәткә, «фирмовый» чүпрәккә...
Түрләр түренә һәм дан-шөһрәткә...
Ә кирәк иде бит – мәрхәмәткә!

Гомерне нәрсәгә сарыф итәбез?
Ошау – охшау өчен ят-читләргә,
Асылыбызны бикләп чикләргә,
Йөзебезне яшерәбез битлеккә...
Ә кирәк иде чыгу – иреккә!

Гомерне нәрсәгә сарыф итәбез?
Борчылу һәм зарлануга, елауга...
Мин-минлеккә, мактануга, ялганга...
Билгесезлеккә илткән юлларга...
Ә кирәк булган бит – дус-туганнарга!

Гомерне нәрсәгә сарыф итәбез?
Сайлый алмасак та – сайлауларга...
Ничек сайласак та – алдануга...
Вак мәшәкатьләргә һәм юк-барга...
Ә кирәк булган бит – хыялларга!

Гомерне нәрсәгә сарыф итәбез?
Нәтиҗәсез ният-гамәлләргә...
Соралмаган киңәш-ярдәмнәргә...
Үз дөньяңа үги адәмнәргә...
Кирәк – нур табу үз галәмеңдә!

Гомерне нәрсәгә сарыф итәбез?..
Кирәк, кирәк бит бары яшәргә:
Нәкъ шушы урында... һәм бүгендә...

---

[4] Б.Шукеновка багышланган хәтер кичәсендә Б.Серкебаев укыган шигырьгә парафраз.



Шәмсия
Җиһангирова

# МӘХӘББӘТ НИЧӘҮ БУЛА?

хикәя

Мәхәббәт турында күп языла, күп сөйләнә. Матбугат битләрендә, рәсми урыннарда да, сәясәткә, әдәбиятка бернинди катнашы булмаган төрле-төрле даирәләрдә дә куба андый бәхәсләр. Даирәләр дигәнем, мәсәлән, безнең кебек – кырык ел элек бер мәктәпне тәмамлаган, тормыш дулкыннарына ташланып, кайсыбыз ничек йөзеп, ярга чыккан, биш дистәне ваклап бетереп, алтынчысы белән теш кайрашучы, очрашырга-сөйләшергә ничек тә җай табалмыйча, бүгенге көнгә килеп терәлгән, ниһаять, бу дөньяның бик тә фанилыгын, күз ачып йомганчы үтүен тәмам төшенеп, сабакташыбыз Сөмбеләнең Казанга терәлеп үк торган «Патшалар» бистәсендәге затлы өендә җыелышкан җиде хатын-кыз даирәсе. Кайберләребез белән кырык ел дәвамында бер генә мәртәбә дә күрешкәнебез булмавын искә алсак, мәхәббәттән башка да сөйләшер сүзләр бихисап җыелган, бүген сүз аңа барып җитмәс кебек иде. Юк шул, алай булмады...

Һәрберебез сүз алып, кыскача гына үзенең хәл-әхвәлен, бүгенге очрашу көненә кадәр ни эш-гамәлләр кылганын, нинди юллардан йөргәнен сөйләп, танышып-таныштырып чыктык. Кайберәүләр иренең, балалары-оныкларының фото-сурәтләрен, хәтта гаилә альбомнарын ук күтәреп килгән, күмәкләшеп карадык, елаштык, көлештек... Аралашу дәвамында шул ачыкланды: барыбыз да ир тәмен татыган гына түгел, бер, ике, өч, Кәримәбезнең исә җиде (!) баласы бар икән. Ул безне: «Гаиләмдә бөтен һөнәр ияләре дә бар: юрист, хисапчы, төзүче, табиб, мөгаллим... читтән эзләп йөрисе юк», – дип көлдерде. Кайберләребезнең исерек булса да, урыс булса да, һаман ирләре бар, икебезнең (икенең берсе – мин), ирләре гүр иясе икән. Ирләр турында сүз чыккач, төрле кызык хәлләр, хәйләмәкерләр турында сөйләшә-көлешә торгач, Раиләбезнең йөзе кинәт кенә моңсуланып-боегып китте, күзләрендә яшь бөртекләре җемелдәп алды.

Шәмсия ЖИҺАНГИРОВА (1951) – *шагыйрә, прозаик; Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, «Төсле моң», «Якты сагыш», «Илаһият» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Әллә нинди эчке бер үкенеч-уфтану белән: «Иремне яратып яшәмәдем бит мин, кызлар, аерылмадым да... Их, бүгенге акылым булсамы?!.» – дип куйды. Аның бу сүзләреннән соң, әйтерсең, өермә кузгалды, берсен-берсе уздырып, һәркем үз фикерен әйтеп калырга ашыкты. Иң әүвәл Сәрия чәчрәп чыкты. Мәктәптә чакта ук «таш астыннан чыккан» иде, шул гадәте әлегәчә калган икән!

– Минем ничегрәк кияүле булганымны беләсез бит инде, кызлар, – диде ул, кет-кет көлеп. – Алдан ук «фигурамны бозган» идем, чыкмыйча чарам юк иде Рәшитемә... Ул чагында нәрсә белә идем соң мин гаилә, сөю-мәхәббәт турында... Тордык инде... Өч балабыз...

Аның сүзләрен Миңнеруй эләктереп алды:

– Мин дә чыккан идем бер татарга... Эчә дә кыйный, ашый да йоклый... Әти белән әни «кеше көлдермә, аерылма, тор», дисәләр дә, бер яше тулмаган кызымны алып, Ташкент якларына, апам янына чыгып качтым... Хәзер рус белән торам. Рус булса да, балама – ата, үземә – ир. Кул күтәрү түгел, авыр сүз әйткәне дә юк. Кая телим, шунда барам, кайчан телим, шунда кайтам... Торабыз... Яратмасам да... Ә тегесен ярата идем... Ни пычагыма соң ул мәхәббәт! Ир кеше аңлыймы аны?!

Аның сүзен эләктереп алып, кемдер тагын да куертып-күпертеп җибәрде, кемдер «мәхәббәтсез булмый ул», кемдер «ирең яраткач, җиткән!» дип сөрән салды. Кемдер «минем мәхәббәтләрем бишәү булды», диде...

Кызып-кызып сөйләшкән, бәхәсләшкән җирдән, кинәт бертавыштан дигәндәй, барыбыз да тынып калдык. Кадриябез ни актан, ни карадан безнең сүз-бәхәскә кушылмый утыра икән ләбаса!

Дөресен генә әйткәндә, мин аны башта Сөмбеләләргә җыелышканда, нишләптер танымадым. Җидебез арасыннан башкаларны кайда да булса, кайчан да булса очраткан-күргәнем бар, ә менә Кадрияне мәктәпне тәмамлаганнан бирле, ягъни кырык елга якын узган гомер эчендә беренче күрүем икәнен исәпкә алсак, танымавымны аңлап-аңлатып та буладыр. Алай гына да түгел, ул, гомумән, икенчеләнгән, сабыр-тыйнакланган, моңсуланган димме, кырык ел элек белгән Кадрия түгел иде. «Икебезнең ирләре гүр иясе икән» дигәннең берсе мин булсам, икенчесе – Кадрия. Шуңа моңсуланган, боеккандыр дияр идең, ире үлгәнгә егерме ел икән ләбаса. Кайгы ул, никадәр зур-авыр булса да, тора-бара, яши-яши тоныклана, җиңеләя төшә. Үземнән беләм. Кадриябез икенчеләнүенең сәбәбе ул булмаска тиеш...

Безгә кушылмау-кысылмавын сизеп-күреп алуыбыз булды, төрлебез төрле яктан аңа ябырылдык. «Нигә бер сүз дә дәшмисең?» «Ирең белән ничек яшәдең?» «Берәүне дә яратмадыңмы әллә?» «Икенчегә бардыңмы яңадан?» «Мәхәббәт юкмыни, синеңчә?!»...

Безнең шаулашканны-даулашканны итагатьле генә тыңлап торды да Кадрия, «башка сүзегез юкмы инде?» дигәндәй, сабыр-моңсу карашын безгә төбәп, «алайса башлыйм» дигән сыман тирән тын алды һәм әкрен генә сөйләп китте...

– «Ирем белән пар сандугачлар кебек, авызга-авыз, иңгә-иң, чөкердәшеп кенә яшәдек» дигәнгә ышанмагыз, кызлар! Ирләр белән бөтен хатын-кыз да бертөрлерәк яши. Дөрес, хатын-кызның хәйләкәре, үз-үзен сөйгәне,

үз мәнфәгатен, үз җаен гына кайгыртканы, алдаштырып-йолдаштырып дигәндәй, артыграк рәхәт күрергә мөмкин. Ә болай... барысы да бер чама. Безнең әни-мәрхүмә әйтмешли, ирләрнең өч йөз алтмыш дүрт көне – кан да яшь, бер генә көне бал да май инде аларның... Төптәнрәк уйлап карасаң, барысы да шул мәхәббәткә барып тоташа. Бүген дә, әнә, кайсыгыздыр биш мәхәббәтем булды, дип ычкындырды...

– Мин әйттем аны, – диде Мөнирә. – Чыннан да шулай булды. Бишенче класста ук, хәтерлисездер әле, мин Раилгә гашыйк булган идем. Тугыз тиенлек туңдырма белән сыйлый бу мине, боз инде гел. Шуны ашагач, тамак шешеп чыга чыгуын, ләкин аның кулыннан тәмле иде ул. Хатлар да языша идек. Шыбыр хата булыр иде, кызыл каләм белән төзәтә-төзәтә, көлә-көлә укыйм тегеләрне. Ялкау иде бик... Үтте тагын үзе ул беренче мәхәббәт...

Тугызда укыганда, сигезенче класс малаена үлеп гашыйк булдым. Институтта – бер удмурт егетенә... Мин дип, татарча сөйләшергә өйрәнде, бахыр... Оз-а-ак йөрде арттан. Аннары үзебезне укыткан бер доцентка мәхәббәт тоттым... Анысы артыннан үзем оз-а-а-ак йөрдем. Гаиләсе бозылды хәтта. Ну... барып чыкмады, барыбер өйләнмәде миңа, каһәр!.. Аннары ирем инде. Бишенчесе... Ләкин... соңгысы булмаска тиеш әле, тагын берәү булмагае дип торам... мәхәббәт! – дип, самими дә, үкенеч төсмерлерәк тә итеп көлеп куйды.

– Син шуны мәхәббәт дип уйлыйсыңмы?!

– Ничек инде мәхәббәт булмасын! Яраттым бит мин аларның һәрберсен дә! – диде дә Мөнирә бераз уйланып торгач өстәп куясы итте: – Яратам дип уйладым...

– Соңгы сүзеңне дөрес әйттең, – диде Кадрия, элеккечә тыныч-сабыр кала биреп. – Уйлагансың гына, ә алар берсе дә ярату, чын мәхәббәт булмаган.

Нидер әйтмәкче булып омтылган җиреннән Мөнирә дәшмәскә, бәхәсләшеп, вакыт үткәрмәскә ниятләптер, ахрысы, авызын йомды.

– Сез минем белән килешерсезме-юкмы, белмим, тик... ни генә булса да, минем фикерем бер һәм ул үзгәрмәячәк! Мәхәббәтнең беренче, икенче, өченчесе булмый. Мәхәббәт, чын мәхәббәт, бер һәм бердәнбер генә була ала!

– Менә сиңа, мә! Торып-торып бер амин! – дип, тел шартлатты кемдер.

– Һәм син андый мәхәббәт барын беләсеңме? Татып та карадыңмы? – Бу сорауны Раилә бирде.

Кадриянең җавабы кыска һәм катгый иде:

– Беләм! Татып карадым! «Карадым» дип дөрес әйтмәдем... Хәзер дә татыйм! Чөнки беркайчан да үтми, онытылмый, ул – мәңгелек...

Шул сүз җитә калды. Кызлар төрле яклап, сөйлә дә сөйлә дип, Кадриягәябырылдылар. Нидән тотынсам, дөресрәк булыр икән, дигәндәй, мизгел генә уйланып дәшми торды да Кадрия сүзен шулайрак башлады:

– Мәрхүм ирем белән танышып, дүрт елга якын дуслашып йөреп, яратам дип уйлап чыктым мин кияүгә. Яшем дә чирек гасыр сызыгына җитеп килә, авылга кайткан саен әти, әтидән бигрәк әни «картаясың, кеше кулы тигәнче тизрәк кияүгә чык...» дип, колак итен гел ашап тора. Чиста, намуслы килеш, кыз килеш дию. Егет тә начар кебек күренми, дүрт елга якын очрашып йөрү

дәвамында үпкәләшү-талашу да, елашу-көлешү дә булмады. Кияүгә чыгып, зөфаф кичендә ул миңа кулын салып, хатын булгач, тәнемнең моңарчы беркем дә күрмәгән җирләрен аңа күрсәтеп, мунчалар кергәч кенә, иремне яратмавымны аңладым. Аңлаганымны беркемгә сиздермәскә, яшәргә ният кылдым. Минем аны яратмавымда иремнең бер бөртек тә гаебе юк лабаса! Хаклыкны әйтеп, аның миңа булган ышанычын челпәрәмә китерергә ни хакым бар?! Тәмле итеп, телләрне йотарлык итеп (монысын ирем әйтә иде), аш-суын да пешерәм, көн аралаш диярлек килеп торучы туганнарын, төрле йомыш белән ни өчендер гел безгә килеп керүче кардәш-ыру, дус-ишләр, авылдашлар-торгашларын да каршы алам. Тәмле ризыкларымны ашарга дип, шулай еш, гел бездә җыелышуларын үзләре дә яшереп тормый иде туганнары. Җан җылымны кушып пешергән һәр ризыгымны мактый-мактый, «минем хатынның кулы никтер болай тәмле түгел шул», ди-ди ашарлар иде.

Суыткыч тулы азык-төлектән тәмсез аш пешергән хатын-кызны аңламыйм мин. Акчага тиенеп, иркенлектә-барлыкта яшәдек, димәс идем, бер-ике кило итне атна буена җиткергән вакытлар еш була иде.

Сыерчык оясы кадәр генә бүлмәбезне дә чиста-пөхтә тоттым. Иртән бер юган идәнне кич ирем эштән кайтыр вакыт җиткәндә кабат юып алам. Ике бала арасында улыбыз аеруча тынгысыз-елак булды, көне-төне кулда күтәреп, аягүрә йоклап йөргән көннәрем бихисапка җыела иде. Бала елый дип, кайбер хатыннар кебек иремнең төн йокысын бүлдереп, кулына бала тоттырганым, эштән кайтканда, кайнар ризыксыз каршылаганым булмады. Үзен яратмыйча яшәвемне сизми-тоймый бу якты дөньядан китте дип ышанам.

...Ә мәхәббәт, бердәнбер чын мәхәббәт, көтмәгәндә-уйламаганда килде миңа.

Иремнең вафатын бик авыр кичердем. «Нигә алай әле, яратмыйча яшәгәнсең бит», диярсез. Моның сәбәбе, мөгаен, минем күңелемдәдер. Башкача була алмавымдадыр. Мәчең чыгып югалса да, елыйсың, эзлисең, сагынасың... Ә монда бит, ни генә булса да, унбиш ел гомер иткән ир! Иремнең вафатына елдан артык вакыт үтеп китсә дә, һаман шулай җир белән күк арасында йөргән көннәрнең берендә, аерылгысыз дус ук булмасак та, шактый аралашып-сөйләшеп, хәтта бераз серләшкәләп тә йөри торган, миннән шактый өлкән яшьтәге авылдашым туган көненә чакырды. Бармаска дип, озак тарткалаша торгач, җиңелеп, ризалаштым. Табын янында барысы да миңа таныш түгел кешеләр, соңгарак та калган идем, башымны иеп кенә, өстәл читендәге буш урынга кереп утырдым. Табын гөр килә. Андый мәҗлесләрдә гел шулай бит: көләселәре килмәсә дә көләләр, җырлыйсы-бииселәре килмәсә дә, осталыклары булмаса да, бии-җырлыйлар. Ә минем, тиктомалдан урынсыз кычкырып көлә, юк сүз белән кеше гәпләшкәнгә кысыла торган гадәтем юк, кайгы сөреме дә әлегәчә үзенекен итә иде әле. «Табынның ямен җибәреп, бүселеп утыра» димәсеннәр өчен генә мин дә җырларына кушылгалыйм. Баян уйнаучы егетнең оста әйттерүенә түзалмыйчамы, түгәрәктән мәҗбүриләп сөйрәп үк чыгаргангамы, биеп тә алдым әле. Оста уйный гына түгел, бик моңлы җырлый да икән, күмәкләшеп җырлый башлауга, җаныннан ярылып чыккан моңлы тавышы башка тавышлардан аерылып, күңелнең әллә нинди почмакларына үтеп керә, күздән яшь чыгара, уйландыра, моңландыра

башлый... Моң хөкеменә бирелеп, ирексездән күтәрелеп карадым үзенә: искитәрлек берние дә юк икән лә, яше бик өлкән күренмәсә дә, чәче коелып бетә язган, ни сәбәпледер, чәче кебек тешләре дә иртә коелган, җырлаганда киереп ачылган авызыннан исән калган өч теше генә (аның да берсе саргайтылган тимер) тырпаеп тора. Өс-башы да шактый йончу, беркайчан да үтүк күрмәгәнгә охшап тора. Әллә буйдак, әллә ялгыз... Хәер, үз хәлем – хәл, миңа моның сукыр бер тиенгә дә кирәге юк иде...

Тәнәфескә туктап, өстәл яныннан кем кая таралышкач, яныма килеп, сүз катмакчы булып та азапланды теге баянчы, тавышыгыз матур, имеш, сез нигә алай боек, теге дә бу... Әрсезләнеп, сагыз кебек ябышып түгел үзе, ничектер базмыйча, оялып, уңайсызланып кына... Хәер, инде әйткәнемчә, миңа моның сукыр бер тиенгә дә кирәге юк иде. Дөньясы шыксыз, яшәү мәгънәсез, бәндәләр синең күңел халәтеңә битараф, бихәбәр...

Тордым, җыендым да, инглизләрчә, беркемгә сиздермичә генә кайттым да киттем. Бераздан булмаган да кебек әлеге туган көн турында бөтенләй онытттым. Авылдаш апа гына, шалтыратып, әйтми китүемә үпкәләп, шелтәләп алды. «Теге баянчы сине сорап аптыратты, танышырга исәбе булган, ахрысы, – диде. – Үлгән артыннан үлеп булмый, син яшь бит әле, болай булса, ялгыз калмагаең, күзеңне ачып йөр...», – дип тә өстәде.

Ә минем, чыннан да, күзләрем генә түгел, җаным-тәнем, вөҗүдем, күңелем ябык иде дөньясына, бәндәсенә... Әле яшәргә дә өлгермәгән, кырык яшең дә тулмаган килеш, ике бала белән утырып кал әле! Бу бит коточкыч гаделсезлек! Башка бөтен кеше дә парлы-парлы, бу гаделсез, кырыс фани дөньяда мин генә моңлы-зарлы, ялгыздыр кебек тоела иде миңа ул чакларда. Йөрим шулай шәүлә кебек иртән эшкә барып, кич кайтып...

Беркөнне кич, бергә эшли торган дус хатын, эш сәгатебез беткәч, ай-вайлатып, үзләренә алып китте. Кичә авылдан килдем, каймак-катыклар алып килдем, чәй эчәрбез, ди. Киттем теләр-теләмәс кенә. Сөйләшә-серләшә чәй эчә-эчә кич утыра торгач, бөтенләй сизелмәгән дә, сәгать төнге ун җиткән. Дустым кунарга кыстый. Ә минем кешедә кунып кала торган гадәт юк, кайтам булгач, кайтам, дим. Чыгып утырдым троллейбуска. Кеше күп. Энә төшәр урын да юк. Кич булса да, җәй челләсе сүрелмәгән, бөркү, тынчу. Җитмәсә, тукталыш саен чыгучыга караганда керүче күп, кеше һаман өстәлә генә бара. Керүчеләргә ачу килә башлады. Шулай кысылып, этелеп-төртелеп кайта-кайта «Комсомолец» тукталышына җиттек. Тагын кешеләр керә. Тукта! Чү! Иң арттан керүчесенең йөзе таныш лабаса. Бу бит теге – туган көндәге баянчы. Бер секунд-мизгелгә генә күз карашларыбыз очрашып алды. Мин, шуны сизеп, тиз генә керфекләремне түбән төшердем. Тик... шул күз ачып йомган мизгелдә бу кеше баш кагып кына булса да, минем белән исәнләшергә тиеш иде кебек. Ни дисәң дә, бер табында җырлашып утырган идек ләбаса. Юк! Исәнләшмәде. Ә кирәк идеме икән соң миңа аның исәнләшүе? Юктыр... Юк икән, юк! Димәк, кайчандыр, кайдадыр күргәнен оныткан. Һәм бу табигый дә. Без бит яхшылап танышмадык, аралашмадык. Исемнәрне дә сорашмадык хәтта. Мин, ярар, күрмәсә-күрмәсен дип, аркам белән борылып бастым да кайта бирәм. Халык бераз сыекланды, этеш-төртешләр кимеде. Иркенләбрәк бастым. Һәм, үзем дә сизмәстән борылып, ни сәбәпледер, ишек буендагы

бая теге баянчы егет кереп баскан урынга күз салдым. Урыны буш иде. «Ярар, хуш! Буш икән – буш. Үз тукталышына җиткәч, төшеп калган, димәк...» дигән җиңелчә уй йөгереп үтте...

Ул да булмады... кинәт! Баш түбәмнән башланып, аяк табаннарыма кадәр бөтен тәнем буйлап ниндидер дулкын-калтырану йөгерә башлады. Тагын, тагын... Гадәттә, кемдер сиңа якын килеп, терәлеп үк басып, муен турыңа йә аркаңа сулап барса, шулайрак була. Юк, алдыйм, андый чакта бөтен тәнең буйлап мондый дулкынлану, калтырану узмый лабаса! Ниндидер ачу китергеч болганчык һава дулкыны гына үтеп китә. Бу бит бөтенләй башкача! Минем мондый тойгыны беркайчан да кичергәнем юк иде! Үз халәтемә үзем ышанмыйча, сул як җилкәм аша башымны борып карадым. Миңа терәлеп беркем дә басып тормый иде. Ирексездән, аптырап, уң як җилкәм аша борылдым һәм... көтелмәгән хәлдән сискәнеп киттем, миңа терәлеп түгел, шактый ара калдырып, теге... баянчы басып тора. Ул чакта да, хәзер дә шул халәтемне аңлата алмыйм. Ул бит миңа терәлеп басмаган, терәлеп баскан очракта да, әйткәнемчә, җаның аша үтеп, баш түбәсеннән аяк табанына кадәр йөгерми сихри дулкын. Йөгергән хәлдә дә, андый түгел, ул төндәге кебеге түгел!

Минем борылганны күреп, ул: «Исәнмесез...» диде дә, җавабымны көтмәстән, «Каян кайтып киләсез болай соңлатып?»ны өстәде. «Сезгә дә шул ук сорау...» дидем мин кыюсыз гына. «Әәәә... минме? Мин... Әниләр килгән иде энекәшләргә... Шуннан кайтып киләм...» Без, озак күрешми торып сагынышкан күптәнге танышлар кебек җиңел генә сөйләшеп киттек. Ул арада булмады – минем тукталыш. Ул чакта, төшмичә, үз тукталышымны узып китәргә дә риза идем бугай. Тик... минем баскан урынымнан кымшанып, ишек ягына укталып куйганымны сизенеп, ул да кузгалды. «Аның яшәгән җиренә дә шушы тукталышта төшәргә кирәктер...» дип уйлап алдым. Без троллейбустан да сөйләшә-сөйләшә төштек. Әйтерсең лә, ниндидер сәбәп белән безне бүләргә мөмкиннәр дә, иң кирәк, иң кадерле сүзләр әйтелми калыр сыман. Сөйләшкән саен сөйләшәсе килә. Теләп, ихластан сөйләшүнең никадәр ләззәтле була алуын мин шул төнне үз гомеремдә беренче мәртәбә татыдым.

...Инде таң атып килә. Без һаман урам буйлап атлыйбыз. Шәһәр төненең дә кешесез чагы була икән. Урамда бездән башка беркем дә юк. Хәтта машиналар да. Булсалар да, бәлкем, маңгай күзләребезгә күренмәгәндер. Тулып-пешкән ай гына безгә күктән мөлдерәп карап тора. Әйтерсең лә, иксез-чиксез җиһан үзе шулай сискәнеп, әсәрләнеп, «ни булган боларга?!» дип, безне читтән сак кына күзли. Шул төннән соң андый гаҗәеп айны кабат күргәнем булмады да бугай. Ае булгандыр аның, тик шул төндәгесе җаныма уелып калды. Чын мәгънәсендә бәхет төне булып тоелды ул төн миңа! Биек үкчәле түфлиләремнең аякка җайсыз булуын да бөтенләй онытканмын. Юкса көндез эштә «ник кидем икән» дип салып, аякларымны ничә мәртәбә ял иттергән идем...

Кадрия бер генә мизгелгә тукталып калды. Күзләреннән баядан бирле менә тамам, әнә тамам дип торган яшь бөртекләре бит очлары буйлап тәгәрәде. Без аны уңайсыз хәлдә калдырудан, сүзе бүленүдән куркып, тын да алмый утырабыз. Кинәт әлеге тынлыкны Мөнирә бүлде:

– Үбештегезме соң? Тагын нәрсәләр булды? Сөйлә инде тизрәк...

Усал күз карашларыбыз белән сабырсыз Мөнирәбезнең теленә дәррәү «йозак элдек».

– Нинди үбешү, ди... Андый уй икебезнең дә башына килмәгәндер, мөгаен. Безгә җитәкләшеп йөрү дә әйтеп бетергесез ләззәтле иде.

– Иии, син бигрәк инде! Китап сүзе белән сөйлисең. Бала-чага кебек диимме, яшь җилкенчәк чагың булса – бер хәер! – Бу юлы мавыгып, ләззәтләнеп сөйләгән җиреннән Кадриябезне Сәрия бүлдерде. – Безнең яшьтә кем шулай кылансын?! Кайчакта юньләп танышып, исем-мазарын да сорашып тормыйсың ла ир-атның! Туп-турыга – туп пошёл...

– Баштан ук әйттем бит, – диде Кадрия, – минем ул чактагы халәтемне аңлар өчен чын мәхәббәтнең ни-нәрсә икәнен татып карарга кирәк. Әгәр гомер юлымда ул очрамаган булса, бәлкем мин дә менә хәзер синең кебек ышанмыйча утырыр идем...

Бу юлы күз карашларыбыз белән Сәриянең авызына «йозак элдек». Сабырсызланып, барыбыз да беравыздан диярлек, «шуннан... шуннан...», диештек.

– Шуннан... Бер сәгать тә черем итеп алмаган килеш эшкә киттем. Эштә атлап түгел, очып йөрим. Һәрнәрсә җиңел, эшләве рәхәт. Эшемне бик яратам икән бит мин! Ә кешеләр? Бөтен кеше әйбәт. Ә дөнья? Кара инде син аны?! Дөнья шулкадәр гүзәл, гаҗәеп матур икән ләбаса! Ничек мин моны элек күрмәгән, тоймаганмын икән! Минем бит өйгә кайтсам, эшкә барасым, эшкә барсам, өйгә кайтасым килми иде. Миндәге сәер үзгәрешне хезмәттәшләрем дә сизенде. «Ни булды сиңа? Күзләрең ут чәчеп тора, йөзеңнән нур бөркелә» дип, сәбәбен ачыкламакчы булып аптыраттылар. Ә сәбәбен... Ул чакта мин үзем дә белми идем. Миндәге сәер хәлләрнең башы гына иде әле бу.

Өлкәннәр әйтмешли, һәр нәрсәнең – үз вакыты. Кемгәдер күз төшүләр, свидание, дискотекага йөрүләр, кочаклашу-үбешүләр... Яшең кырыктан узып киткәч, бу хәлләр үзеңә дә, чит кешеләргә дә сәер тоела. Автобус, трамвай, троллейбусларда яшь җилкенчәкнең бер-беренә сагыз кебек сыланып, юл буе үбешеп, кочаклашып барганнарын барыбызның да күргәне бар. Бу хәлгә беребезнең дә артык исе китми. «Яшьләр бит! Яшь чакта кем ни кыланмас...» дип кенә карыйбыз. Алар урынында кырыкилле яшьтәгеләр булса, шау-шу кубар, кем генә авызын ачмый, гаепләп сүз әйтми калыр иде икән! Ирем үлгәч, миңа да яучылар килгәләде. Һәрберсе дә диярлек сүзне бертөрлерәк башлый: «...Чәчәк-букетлар бүләк итешеп, үбешеп, капка төбендә таң аттырыр унҗиде-унсигез яшьлек чагыгыз үткән, күрешеп-сөйләшегез дә иртәгәдән бергә яши дә башлагыз...»

Юк! Юк! Болар берсе дә дөрес түгел! Яшең кырыкка җиткәндә дә бар һәм бик кызык икән ул очрашу-свиданиегә йөрүләр. Үзем шул рәхәтлекләззәтне татыган кеше буларак әйтәм! Чөнки без оялчан яшүсмер егет белән кыз шикелле шактый урам таптадык Нурлан белән беренче кочаклашу, үбешүгә кадәр. Мин аның исемен дә өченче очрашуыбызда гына белдем әле. Әнисе – укытучы. Ул куйдырткан икән аңа шундый – татарларда сирәк очрый торган исемне. Нурлан һәр көнне диярлек эш сәгатем беткән вакытка минем янга килә. Ул килә алмаганда, мин аның эшли торган бинасы янына

килеп басам да, китәбез җәяүләтеп урам таптарга. Шунысы гаҗәп, без бер үк урамда яшибез булып чыкты. Яшәгән йортларыбыз да бер-берсеннән ерак түгел – бер тукталыш кына ара икән. Ял көннәрендә без үзебез яши торган урамда очраша идек. Ниндидер билгесез нәсел-нәсәпләр катнашудан дөньяга яралган җан иябез – этебез бар иде. Мин кичләрен урамга шуны ияртеп чыгам. Ул шул вакытка чамалап, минем янга килә. Кулларны кулдан, җаныбызны җаннан аера алмыйча, кичләр буе йөрибез шулай. Саубуллашып, хәерле төннәр теләшеп, икебез ике якка китеп барабыз. Һәм... мин борылып карыйм. Ни гаҗәп, нәкъ шул вакытта ул да борыла. Без йөгерешеп киләбез дә янә бер-беребезгә сыенабыз. Теге җан иясе, бичаракаем, икебезнең арабызга кереп баса да, без үбешкән, кочаклашкан саен башын әле бер, әле икенче якка борып карый-карый, безне кötә-кötә аптырап, туңып бетә, кайчакларда шыңшый, елый ук башлый... Ул гынамы?! Ял көннәрендә безнең урамнан ерак булмаган урманга чаңгы шуарга чыгабыз. Артыбыздан көртләргә батачума этебез чаба. Битләребез әллә салкыннан, әллә эчтәге сөю ялкыныннан уттай яна. Шундый көннәрнең берсендә Нурлан бер юкә агачына пәке белән уеп, «Н» плюс «К» дип язып та куйган иде әле...

Бер көнне мәрхүм иремнең каберен зиярәт кылмакчы булып, аның туганякларына кайтырга ниятләгәнебезне әйткәч, Нурлан да безнең белән юлга чыгарга булды. Ни өчен дисәң, ул да тумышы белән шул районнан икән, җитмәсә, авылларының арасы да кырык чакрым чамасы гына. Балаларым кем беләндер очрашып йөрүемне сизенсәләр дә, аны күреп белмиләр иде әле. Шикләнү, борчылуларыбыз юкка гына булды, алар бер-берсен күптәннән белгән танышлар кебек җиңел генә аралашып, сөйләшеп киттеләр.

...Сөйләшү, көлешүләр белән юлның озынлыгы да сизелмәгән, Нурланның туган авылына килеп тә җиткәнбез икән. «Чәй генә эчеп чыгарсыз...» дип, никадәр кыстаса да, ризалашмадык, әле тагын кырык чакрым юл үтәсебез, җитмәсә, теге «нәсел-нәсәбе билгесез» этебез дә бар, безне бөтенләй белмәгән чит-ят кешеләр янына килеп керергә кыюлыгыбыз җитмәс иде... Казанга кире кайтышлый аны кереп алырга килешенеп, өеннән ерак түгел генә төшереп калдырдык та юлыбызны дәвам иттек.

Кире кайтышлый, өйләре янына килеп туктагач, ирексездән урам якка караган бер тәрәзәгә күзем төште, ни өчен дисәң, бөтен буе белән тәрәзәне каплап, Нурлан басып тора иде. Ул да булмады, атылып диярлек урам капкадан килеп тә чыкты. Аңа ияргән әнисе, бераз арткарак калып, ике култык таягына таянган әтисе күренде. «Сезне көне буе тәрәзәгә ябышып көтте инде Нурлан...» дип өстәп куйды әнисе «Әйдәгез, рәхим итегез!» дигән сүзләре арасына. Ояла-ояла гына килеп керсәк, безне якты, чистапөхтә өйдә мул сыйлы табын көтеп тора иде...

Ашап-эчкәч, сөйләшеп, шактый гына танышкач, рәхмәтләребезне әйтеп, кайтыр юлга кузгалдык. Безнең ничегрәк таныш булуыбыз, үзара мөнәсәбәтебез турында ләм-мим бер сүз дә кузгатылмады. Шуннан соң берәр ай үткәндерме-юкмы, «Әти-әни синең белән бергә кайтырга кушты...» дигәч, ризалашып, юлга җыендым...

«Әти-әни» дигәннән, әти-әнисе, бигрәк тә әтисе, бик яратты үземне. Әнисе – укытучы, дидем бит. Укытучының да нинди генә әле – математика укытучысы, тәрбия эшләре буенча директор урынбасары, каш астыннан

сынаулы карап, бик ныклап «өйрәнде» мине. Күрәсең, күңеленә хуш килгәнмендер, кич җиткәч: «Урынны икегезгә бергә җәям...» – дип кырт кисте. Әтисе исә киткәндә: «Кадрия балам, кадерлем, әйтүем шушы – минем улымны ташлама!» – дип озатып калды. Соңгы курешүебез булган икән... Сугышта алган яраларыннан сихәтләнә алмыйча, ничә еллар җәфаланган-сызланган әтисе үләр алдыннан: «Балаларга каршы килмәгез, никахлашып, бергә торсыннар», – дигән.

Менә шулай көннәрдән бер көнне никах укыттык та бергә яшәп киттек. Минем биләмәм дә. Шунысы гаҗәп: безнең бергә яши башлавыбызга балаларым да каршы килмәде, туганнар, таныш-белеш, дус-ишләр дә гаҗәпләнмәде. Балаларым, каршы килмәү генә түгел, нык шатландылар, сөенделәр хәтта. Чөнки бернигә дә исем китмичә, тере мәет кебек эшкә барып, эштән кайтып йөрүемнән шикләнә башлап, үзләре үк: «Әнием, йөрмә болай, зинһар, берәр кешене тап, без каршы килмәячәкбез...» – дип, күптәннән үгетлиләр иде инде...

Һәр эшне җиренә җиткереп, кешенең күңеле булырлык итеп эшли торган гадәтем бар. «Гадәтем» дип ялгышамдыр, бәлкем, нәселдән килә торган сыйфаттыр ул җиренә җиткерү, иренмәү, җитезлек. Аның белән яши башлагач бигрәк тә, мин бөтенләй җиде күкләрдә – очып кына йөрим. Сәгать түгел, көннәр, айларның үткәнен тоймыйм. Ул, югары уку йортында хор-дирижёрлык белгечлеге буенча белем алган булса да, ни сәбәпледер, милициядә эшли иде. Кайчакларда, бигрәк тә ай саен әзерләп тапшырасы отчётлар вакытында, ул төнге бер-икеләрдә генә эштән кайта, иртәнге бишләрдә кабат эшкә китә. Кайчан гына кайтса-китсә дә, өстәлемдә кайнар ашым әзер, һәрчак аягүрә, кайнар аш белән каршы алам, кайнар аш белән озатам, киемнәре юып-үтүкләнгән. Авырыксынмыйм да, арымыйм да, «йокы әләкми» дип үпкәләмим дә.

...Бала чагыннан башланган фото-альбом, эшеннән бирелгән форма-шинель, ботинкалар, бер-ике күлмәк, аягындагы тишек носкилардан башка «байлыгы» юк иде. Һәм миңа болар берсе генә дә мөһим түгел, ул бар – бетте-китте! Юк! Алдыйм! Минем өчен бик тә мөһим тагын бер нәрсәсе – иске баяны бар иде бит әле. Әз генә буш вакыты булуга, кулына баян алып, сыздырып уйный башласа, мин, күңелем дулкынлануга чыдый алмыйча, үзем дә сизмәстән кушылып җырлап җибәрәм:

Утырдым да күлнең, әй, читенә,
Карадым ла суның төбенә.
Су төпләрендә, әй, кара юк,
Язмышларны күрми чара юк...

Ул, тавышың моңлы дип, гел мактап торгач, мин отыры кыюланам. Аның тавышы янында минеке чүпкә үлчим генә иде югыйсә! Җырлаганын бер генә мәртәбә ишетсәгез дә, иманым камил, үлеп гашыйк булыр идегез! Нинди генә җырлар җырламадык та ниндиләрен генә өйрәнми калдык икән?!

Мин аның эчке дөньясы белән яшим. Ул дөнья миңа гаҗәеп якын һәм үз, иң мөһиме, анда теләсә кем керә дә, ул дөньяның серләрен белә дә алмый. Бу – фәкать аның вә минем генә дөньябыз иде! Анысы шулай. Тик безне

әйләндереп алган кешеләр, фани дөньяның үз кануннары, үз фикере бар бит әле. «Киеменә карап каршы алалар, күңеленә карап озатып калалар» дигән халык мәкале искергән заманда яшибез шул, кызлар. Чит-ят кешенең синең күңелеңдә бер тиенлек тә эше юк, килгәндә дә, киткәндә дә ул синең киемеңә карап озата, каршы ала. Шул кануннарга ярашырга теләптер, юк, аның өчен генә түгелдер, яңәшәмдәге кешенең, эчке дөньясы гаҗәеп бай кешенең, башкалар күзлегеннән мескен кыяфәттә күренмәвен теләгәнгәдер, милиция шинеленең өзелеп төшмәсенгә сары тимерчыбык белән борып куелган сәдәпләрен сүтеп алып, матурлап кире тагып чыгам. Үзе әйтмешли, тугызынчы сыйныфтан ук калган күлмәкләрен, җепләре сүтелә башлаган чалбарларын салдырып ташлап, әнәсеннән җебенә дигәндәй, матур итеп киендерәм. Затлы бүрек, түфлиләр... Кием килешә иде аның гәүдәсенә! Карап сокланып туймый идем. Әйттем инде, чәче дә, тешләре дә коелып бетә язган, эшеннән бирелгән йончып беткән «казённый» киемнәрдән йөрүенә оялыптыр, күрәмсең, вакытыннан алда олыгаеп киткән, гәүдәсен бөкрәйтебрәк йөргән кешем кинәт тураеп басты, яшәреп, буе озынаеп, йөзе нурланып китте. Мин аңа карап сокланып, сөенеп туялмыйм. Яшәр өчен көч-егәр бирә алдым дип, эчтән генә горурланам...

Ирем, мәрхүм, мине «салкын кеше син», ди, һәм ул бу сүзләрне һич тә мине гаепләп әйтми иде кебек. Аның бу бәяләмәсе белән үзем дә килешәм, табигатем шундыйдыр дип уйлыйм һәм моңа артык кайгырмыйм да, сәбәпләрен дә эзләми идем. Хәер, сәбәбенә керешеп торырга вакыт та юк: ике бала үстерәсе, көне-төне ашарга пешерәсе, җыясы-юасы, бәйлисе-тегәсе, иртәнге сигезгә эшкә йөгерәсе, тагын әлләниләр эшлисе бар. Аллаһы Тәгалә шулай яраткан – бетте китте! Гөнаһсына керәсем килми, бәлкем читтә наз тапкандыр, иремнең үзе әйтмешли «салкын»лыгыма артык исе китми дә иде кебек.

– Ә моның белән... Нурланың белән... ничегрәк булды соң?!

Сабырсыз Мөнирәбезнең тавышы иде бу. Без, барыбыз да беравыздан диярлек, «Бүлдермә!» – дип кисәттек. Кадрия үзен бүлдергәнгә үпкәләп, «Әй, алайса сөйләмим...» димәгәе дип, куркып, тын да алмый утырабыз.

– Ә монда! Җанкисәккәйләрем! Оят булса да әйтим инде, гел сыенып, назлап-назланып, яратышып кына торасым килә... Күз сирпеп бер каравы, гәүдәсе күренү генә түгел, аның хакында уйлавым гына була... Үземдәге бу аңлаешсыз, гаҗәеби-алиһаи сәер халәтемне аңларга теләгем дә юк. «Минме соң бу?!» дип, гаҗәпләнеп кенә куям...

– Җир кешесе идеме соң ул? Бар идеме? Әллә уйлап кына чыгардыңмы, хыялыңда гына тудырдыңмы? Кайда яткан соң ул? Гаиләсе? Баласы?

Кадриянең мавыгып сөйләгәнен, безнең тын да алмыйча йотлыгып тыңлаганны бүлдереп бирелгән, барыбыз да җавабын ишетергә теләгән сораулар иде бу.

– Бар иде. Булган ул. Әйттем бит инде, мин яшәгән йорттан бер генә тукталыш арасында яшәп яткан гаиләсе белән... Гаиләсе белән дип әйтү дөрес микән бу очракта?! Белмим. Үзем барып күрмәдем. Аның сөйләве буенча гына фикер йөртә алам. Миңа, мәсәлән, андый гаиләнең булганыннан булмавы хәерлерәк. Егерме сигез яшендә, институтның соңгы курсында өйләнә ул. Яратмыйча. Гаилә кормый, бала бәхетен татымый калмас өчен. Дустына ияреп.

Апалы-сеңелле кызларга өйләнәләр. Шәһәр кызларына. Җитмәсә, үзеннән ун яшькә яшьрәк тә бит әле! Авыл егете өчен шәһәр кызы булуы гына да ни тора, читтән караганда! Читтән караганда гына шул! Өйләнешеп яши башлагач килер әле, бала булгач килер дип өметләнгән ярату хисе, мәхәббәт һаман килми көттерә. Ул гына да түгел, дүрт ел бер фатирда торсалар да, балалары булмый. Бирми Аллаһы Тәгалә! «Бер мендәр белән юрган. Йоклар урыным диван ...» Шул рәвешле шаярта идеме, үкенә идеме икән ул...

Дәвалануны сылтау итеп курорт, санаторийлардан кайтып керми йөри торгач, ниһаять, ир бала «бүләк итә» аңа хатыны. Көлмәгез, чыннан да шулай. Табуга, кулына тоттыра. «Теләдеңме, сорадыңмы? Рәхим ит, үстер!» Шулай була да. Хатыны баланы имезми генә түгел, төннәрен елап уянганда торып, янына килеп тә карамый, чүпрәк-күлмәкләрен дә юмый. «Әти-әни, туганнар: «Чит кеше баласын үстергәнеңне беләсеңме...» дип, гел әйтеп тордылар торуын. Тик, нишләмәк кирәк, бала булуын мин теләдем бит. Шулай булгач, хатының күршеңнән бала табып бирсә дә, карыйсың инде, кая барасың...» – ди иде Нурлан һәрчак шул хакта сүз кузгалганда. «Кеше ышанмаслык сүзне хак булса да сөйләмә», ди халык. Кеше ышанмаслык булса да, ялган булмагандыр бу хәлләр. Әнисе дә сүз арасында: «Теге хатынның безгә кайтып күренгәне булмады, баласын да алып кайтып күрсәтмәде...» – дигән иде ләбаса...

Бергә яши башлап, ярты ел чамасы вакыт үткәч, аерылышты ул. «Аерылышты» дип әйтергә генә ансат. Хатыны бик озак ризалык бирмәде. Судта: «Аның әле баласын үстереп бетерәсе бар!» – дигән. «Бала сезнеке дә түгелмени?» дип сораганга: «Юк!» дигән җавабыннан судья туктый алмыйча озак көлгән, имеш.

...Шушы күңелсез, аның өчен авыр вакыйгаларның ирексездән шаһите булганга, аның хәлен җиңеләйтим, кәефен күтәрим, күңелсез уйларга бирелдермим дип, көне-төне тырыштым. Дус-туганнарга кунакка, концерт-театрларга йөрү, тәмле ризык, затлы кием-салым белән сөендерергә тырышу дисеңме, берсе дә калмады. Көндезе, киче ярый әле, төннәрен, йоклап китәргә дә өлгермим, аның җанын ярып, әллә кайдан йөрәк түреннән яңгырап чыккан «у-уу-фф-ф»ыннан сискәнеп уянып китәм. Өнме, төшме икәнлеген абайлый алмыйча: «Нәрсә, ни булды?» дип соравыма һәрчак җавабы бер: «Малайны сагынам, аннан башка яши алмыйм...» Нинди сүзләр белән тынычландырырга кирәктер мондый очракларда кешене, кем белсен?! Аптырагач: «Әйдә, улыңны үзебезгә алыйк, монда яшәсен...» дип карыйм. «Ничек инде монда?! Сиңа үги булачак бит ул. Мин улымны үги әнидән каратыйммы?!» Егыл да үл шуннан соң! Юкса, ул бала миңа бер дә үги булыр төсле түгел. Үз балаларым белән тигез яратыр идем кебек. Шулай булмый ни?! Ул бит минем яратканымның баласы! Аның шундый сүзләре мине рәнҗетә дип үк әйтмим, бераз кимсетә дә иде. Шулай булмый ни?! Җаныңны бирергә әзер була торып та, шундый бәя ал әле син?!

Ә аның уфтануларын кая куясың? Һай, ул күкрәк ярып чыккан төнге «уф-ф»лар! Минем хәлемне аңлар өчен, сезгә бер генә мәртәбә булса да ишетеп карарга кирәктер аны, дускайларым.

Ялгыш кына «уф» дип куйсаң, әнием мәрхүмә сискәнеп китәр, шып туктатыр иде. «Кызым! Зинһар уфтана күрмә, Аллаһы Тәгалә тагын да

авыррагын бирермен дигән уфтанган кешегә...» – дияр иде. Менә ни өчен дә аеруча курка идем мин ул «уф-уф»лардан. Бер генә түгел, көн саен бит ул! Төнгә кердекме, ирексездән, кайчанрак «ууфф»лый башлар икән дип, йоклап китә алмыйча, тыңлап ята торганга әйләндем. Бара-бара шулкадәргә барып җиттем ки, көннәрдән бер көнне төнлә, чираттагы «уу-фф-ф»ка сискәнеп-куркынып уянып китеп, торып утырдым да: «Син болай интекмә, бар, улың янына кайт...» – дидем. Мин бу сүзләрне үземне көчләп, үз-үземә каршы килеп, мәҗбүри әйттердем. Башка чарам булмаганга. «Иртәнгә кадәр калырга мөмкинме?» – дигәненә, бер дә исем китмәгәндәй күренергә тырышып: «Юк, хәзер кит, иртәнгә кадәр йә үлеп китәрсең...» – дидем.

– Беләм, сез хәзер мине дәррәү орыша башлаячаксыз, кызлар. Янәсе, кем инде үлеп яраткан кешесенә шундый сүз әйтә! Нәкъ үлеп яраткан өчен әйттем дә инде! Уйлап кына карагыз әле, мин аның өчен барысын да эшләргә, бар нәрсәдән баш тартырга әзер булып торам. Ә ул?! Улымнан башка яши алмыйм дип, барысыннан да ваз кичәргә әзер. Гаделлекме бу? Улы бит әнисе янында. Гадәттәгечә. Гаилә таркалганда була торганча. «Ир кешенең баласы юк. Алар кем белән яши, шуның балаларын ярата», – ди иде каенанам. Мондый сүз белән килешеп булмый да кебек. Ә төптәнрәк уйлап карасаң, тормыштагы хәлләрне исеңә төшерсәң, шулайрак килеп чыга. Хатыныннан аерылгач, ир-атлар бик сирәк очракта гына баласын үзендә калдыра, бик азлары гына балаларын кайгырта. Бу, мөгаен, шул сирәк очрак булгандыр...

Аннары... Сезнең дә ишеткәнегез бардыр халыкта элек-электән яшәп килгән шундый ырым-ышануны: яңа туган баланы иң әүвәл этисенең күлмәгенә төрергә кушалар. Әтисенең балага мәхәббәте булсын өчен. Элегрәк шулай эшләгәннәр дә. Әнкәем дә гел сөйли иде. Әле хәзер дә хатын-кызның акыллыраклары «иртән эшкә барасы бар» дип кызганып тормыйча, татлы йокысыннан уятып, төнлә елап интектергән баланы иренең кулына тоттыра. Шул ук – мәхәббәте артсын өчен!

Баласына мәхәббәте башка бөтен нәрсәдән дә кадерлерәк булган, күрәмсең, шул төнне, торып киенде дә бер сүз әйтми-нитми генә чыгып китте Нурланым. «Мәхәббәттән нәфрәткә – бер адым», диләр. Мин еламадым да, берни уйламадым да. Әйтерсең лә күкрәк читлегемне каерып, җаныма саксыз кагылып, имгәтеп ташлаганнар иде... Җир белән күк арасында очып йөргән халәтемнән мин элеккеге бөтен нәрсәгә битараф хәлемә төштем: шатланмыйм да, көенмим дә, җырламыйм да, еламыйм да...

Ун-унбиш көннәр үткәндер, бер кичне телефон шалтырады. Алсам, Нурлан: «Өйдә буласыңмы, әйберләремне алып китәр идем...» – ди. Килде. Ул зал ягында әйберләрен җыя. Мин кухняда. Элеккегечә халәтемдә. Уйсыз... гамьсез... битараф... Күпме вакыт үткәндер, ниһаять: «Сау бул, мин китәм...» – диде. Аһ! Шул чак... Әйтерсең лә, мәрткә киткән җиремнән кинәт айнып, сискәнеп киттем. Үземне үзем белештерми, тыя алмыйча: «Китмә!» дип кычкырып җибәрдем. Муенына килеп сарылдым. Ул: «Юк... китәм...» – диде.

...Шул көннән соң, әйтерсең лә, мине алмаштырып куйдылар. Өйдә кияргә дип алган фирүзә төсендәге спорт костюмы юыну бүлмәсендә эленеп калган булып чыкты. Мин шул киемне исни-исни, сабый баланы

күтәргән кебек, көннәр буе күтәреп йөртәм, төннәрен янәшәмә куеп ятам, иртән күземне ачуга, бисмилламны әйтергә өлгергәнче, «Нурланым...» дип елый-елый, күкрәгемә кысам... Аллаһы Тәгалә һәр бәндәгә шатлыкны да, борчу-кайгылырны да үзе күтәрә алган кадәр бирә, диләр. Хактыр. Миңа да баштарак бу хәлләргә түзә алмам, янып-көеп бетәрмен, йә акылдан шашармын кебек тоела иде. Дөрес, йокысыз елак төннәр, баштан бер генә мизгелгә булса да чыгып тормыйча тилмерткән көйсез-мәгънәсез уйлар йөземә сары булып ятты, күзләремнең янып торган очкыннарын төссезләндерде, сүндерде... Ләкин яшәргә, алга барырга кирәк иде. «Чи иткә ут капмый...» ди халык. Чыннан да, әгәр чи иткә ут каба торган булса, мин дөрләп янып беткән булыр идем, мөгаен.

Шулай яши-яши, көннәр, айлар үтә торды. Ел да үтеп бара... Көннәрдән бер көнне телефон шалтырады. Ял көн. Өйдә идем. Алсам – Нурлан! Бер мизгелгә телсез калдым хәтта...

– Мөмкинме, мин яныңа киләм, әйдә, барысын да уртага салып сөйләшик. Мин мәңгегә синең белән яшәргә телим, гомер ахырынача... Син ничек әйтсәң, шулай булачак!

– Ничек инде?! Ә улың? Син бит аннан башка яши алмыйсың...

– Мин бәлкем яши дә алмас идем... Ә ул миннән башка яши ала булып чыкты. Ул бит миңа сугарга кизәнде... Уйлап кына кара әле?! Мин бит аны шешәдән сөт имезеп, елавыннан туктатам дип, төн йокысыз күтәреп йөреп үстергән кеше... Әтисе! Өйдән чыгып киткәнемә ярты еллап инде. Энекәшемдә яшәдем...

Кадрия туктап, тынып калды. Без барыбыз бертавыштан диярлек:

– Урр-ра-а! – дип кычкырып җибәрдек. – Димәк... кире кайтты Нурланың?!

– Юк шул! Ялгышасыз, кызлар. Кайтмады...

– Ничек инде... кайтмады?!

– Әйе, кайтмады. Мин ризалашмадым...

– Ә мәхәббәт?! Өзелеп ярату?!

– Нәкъ менә шул өзелеп яраткан өчен кире кайтармадым да инде мин аны. Әйтәләр бит, дөресрәге, кайсыдыр бер бөек әйткән: «Хатын-кыз янына кире кайтырга ниятегез булса, бу эшне, ул сездән башка яшәү күпкә җиңелрәк икәненә төшенгәнче, мөмкин кадәр тизрәк эшләгез!» Хак сүзләр икән. Теге – мин: «Китмә!» дип, муенына сарылган чакта калган булса иде ул! Ә беләсезме, ул чакта, әйберләрен алып китәргә дип килгән чакта аңа Аллаһы Тәгаләдән ишарә булган бит, кызлар!

Бу гайре сәер сүзләренең ахырын тыңлап бетергәнче, без, ирексездән бер-беребезгә карашып, көлемсерәп алдык. Моны Кадрия дә сизми калмады, әлбәттә.

– Бик тә аңлыйм, сез мине бераз юләргә саныйсыз... Мин «Китмә!» дип, муенына сарылганнан соң, чыгып киткәч ул лифтка керә, кнопкага баса. Лифт исә, урыныннан кузгалып, бераз гына аска таба төшә дә, шып туктап кала. Дүртенче белән өченче кат арасында. Бер сәгатькә якын утыра ул лифтта, үзе әйтүе буенча, «коллыктан» котылгач та, коридорда шактый өнсез булып басып тора әле. «Денсезлегем һәм кирелегем комачаулады синең яныңа кире керергә шул чагында...» – диде. Бу хәлне белгән булсам,

мин дә бит түзеп торалмас, атылып чыгып, кочагына ташланган булыр идем. Белмәдем...Тикмәгә генә: «Алдырмак көн – яздырмак көн», димәгән халык...

Сәер хәлләр аның белән генә бетмәде әле. Яшәп ятам шулай ут белән су арасында. Шундый көннәрнең берсендә Чаллыда яшәүче якын танышым, дөресрәге – Нурланның армиядә бергә хезмәт иткән дусты, хәтта гаилә дустыбыз дияргә дә ярыйдыр, шалтырата. Юбилеен зурлап, Мәдәният сараенда уздырырга җыена икән. Ул, артык зур талант иясе булмаса да, көйләр, үз көйләренә сүзләр дә яза, ярыйсы гына җырлый, озын сүзнең кыскасы, үз шәһәрендә шактый гына танылган кеше. Нурлан белән без – аларда, алар бездә кунакта булганыбыз, озын кичләр буе җырлашып утырганыбыз да бар, бергә яшәмәвебез дә аңа әллә кайчан мәгълүм иде. Мине зурлап чакыруы да залда тамашачы булыр өчен түгел, үзе язган бер җырын сәхнәдән җырлавымны үтенә. «Мин җырчы түгел бит», дип, аяк терәп каршы торсам да, «Синнән башка беркем дә ул җырны шулай җиренә җиткереп башкара алмый...» дигәч, ризалашмый чарам калмады. Киттем чакырылган көнендә җыенып. Юкка гына борчылганмын, репетиция вакытында берничә мәртәбә җырлап карагач, башкалардан бер дә ким түгеллеген белгәч тынычландым.

...Менә минем чират. «Казаннан килгән кунагыбыз, гаилә дусты...» – дип, матур гына игълан итүгә, сәхнәгә чыгып бастым. Халык белән шыгрым тулы залны йөгерек күз карашым белән «сөреп» чыктым да тәвәккәлләп, җырымны башлап җибәрдем. Ул ба булмады, күз карашым алтынчы-җиденче рәтләр тирәсендә, уң яктан рәт уртасындарак утыручы бер ир-атка барып төртелде. Затлы итеп киенгән, кара костюм-чалбар, ак күлмәк... Нурлан бит бу! Башка беркемне дә күрмим! Көтелмәгән хәлдән бер мизгелгә генә башым әйләнеп китте хәтта. Тик... Сер бирергә ярамый иде. Үземне кулга алып, җырымны ахырынача җырлап бетердем. Сәхнә артына чыккач кына, аякларымның камырга әйләнгәнен тоеп, янәшәдәге урындыкка сыгылып төштем. «Нәрсә булды?!» дип, юбилярым килеп басты. «Анда... Нурлан... җиденче рәттә... Ник син миңа аның концертка киләсен әйтмәдең?!» «Юк, ни сөйлисең син?! Мин аны алдан да чакырып караган идем, бүген дә сөйләштем. Килмим, диде. Хатыны килми дә килми инде аның. Нурлан да элеккеге – син белгән Нурлан түгел хәзер... Ышанмасаң, аңа дигән чакыру кәгазе минем кесәмдә...» Ул чакта мин, чыннан да, аның сүзләренә ышанып җитмәдем. Алдаша дип уйладым. Бераз соңрак, аек акылым белән уйлап карагач, чынлыкта алай була алмаганына, Аллаһы Тәгаләнең хикмәте белән күземә генә күренгәненә инандым. Өстендәге яңа гына энәдән төшкәнгә охшаш гаҗәеп нәфис киеме, уйсыз-гамьсез, әкияттәге (бәлкем оҗмахтагы!) хур егетләренекен хәтерләткән ачык-ак йөзе, томан эчендәге өрфиядәй беленер-беленмәс тоныкгәүдә чалымнары... Ышанасызмы-юкмы, менә шулай! Белмим, ул чакта да аңламадым, хәзер дә аңыма барып җитми... Залдагы ул урын буш булгандыр бәлкем...

Хәтерегездәдер, бар иде бит шундый заманнар, эш урыныннан санаторий, ял йортларына юллама бирәләр иде. Көннәрдән бер көнне, җәй уртасында, безгә дә – коллективтан берьюлы дүрт кешегә – санаторийга юллама бирделәр. Җыенып киттек. Кайсыбыз кая урнаштык. Көн кичкә авышып килә иде. Тиешле язу-сызуларны тәмамлап, бүлмә ачкычы, ашау талоннары

алганчы, кичке аш вакыты җитте. Ашханәгә кереп, кулыма поднос алдым да ризык бирә торган урынга килеп бастым. Тәлинкәгә үрелдем. Үрелүем генә булды... Кинәт! Баш түбәмнән башланып, аяк табаннарыма кадәр бөтен тәнем буйлап ниндидер серле дулкын-калтырану йөгерә башлады. Тагын, тагын... Нәкъ теге чакта – Нурланны төнге троллейбуста очраткандагы кебек! Әлеге сихри дулкын җаным аша үтеп, баш түбәсеннән аяк табаныма кадәр йөгерә дә йөгерә... Үз халәтемә үзем ышана алмыйча, ирексездән сискәнеп, әсәрләнеп борылып карасам – Нурлан! «Исәнмесез, Кадрия Лотфулловна! Хәлләрегез ничек?» – ди. Аның кебек үк тыныч, ваемсыз булырга тырышып: «Исәнмесез, Нурлан Әхмәтович! Сезнең хәлләр ничек?» – дия алдым. «Менә... ялга килдек әле. Бер атна булды инде...». Шунда гына игътибар иттем, Нурланым өч подноска ризык җыйган иде. Менә ул беренче подносын күтәреп, ике хатын-кыз утырган өстәл янына китте. Подносын өстәлгә куйды да килеп, икенчесен, өченчесен алып китте. Мин дә үземә билгеләнгән өстәл номерын табып килеп утырдым. Йа Аллам! Шулай туры килергә кирәк бит, мин утырып ашарга тиешле өстәл тегеләрнеке белән бер рәттә! Әле дә ярый янәшә түгел! Ике арада бер өстәл бар иде. Үзем ашыйм, имеш, үзем башымны игән килеш сиздерми генә, астан гына Нурланнар өстәлен күзләп алам. Баксаң, теге ике хатын-кыз бер-берсенә шактый охшашлар икән. Аерма шунда гына: берсе – яшьрәк, берсе – өлкән. Өлкәнрәге әнисе яисә апасыдыр дип уйлап алдым да яшьрәк дигәнен җентекләбрәк күзәтә башладым. Ничегрәк икән: миннән яшьрәкме, чибәррәкме? Гаҗәп хәл! Моңа кадәр мин үземне көнче, кызыгучан-кызыксынучан дип белми идем. Бу, чыннан да, шулай иде! Беркемнең, бигрәк тә хатын-кызның килеш-килбәте, төс-бите, кием-салымы миңа сукыр бер тиенгә дә кирәк түгел! Кызыкмыйм, чагыштырмыйм, көнләшмим... Киресенчә, һәрдаим диярлек үземнән көнләшкәннәрен, хөсет-үчлекле карашларны тоя идем. Һәм миндә андый тискәре хисләрнең булмавына ихластан шатлана идем. Шулай булмыйни?! Көнченең үзенә генә начар бит ул күңел тарлыгы, каралыгы, хөсетлек, көнчелек. Тора-бара андый кеше чиргә, хастага сабышырга мөмкин. Ә ул көнне... шул астан гына күзәтә башлаган мизгелдә, мин үземдә көнчелек хисен тойдым. Тойдым гына да түгел, әлеге хис бар җанымны, вөҗүдемне биләп алды хәтта. Шул вакытта көзгедән карау мөмкинлеге булса, иманым камил, йөземә каралык сөреме дә өретелгән булгандыр. Юк! Юк! Көлмәгез, кызлар! Сүзләрем хак! Кешенең эчендәге кара уйлары, көнчелек, хөсетлеге һичшиксез йөзендә чагыла. Йөзендә генә дә түгел, аяк атлап йөрешендә! Игътибар итеп карарга гына кирәк, азмы безнең арада йөзе мәңге ачылмас, яктырмас һәм, киресенчә, йөзеннән яктылык, җылылык, нур бөркелеп торганнар!

Шөкер, минем өчен бөтенләй ят бу хис икенче мизгелдә үк диярлек эреп юкка да чыкты. Ни өченме? Чөнки Нурланым белән бер өстәл артында утыручы, ул гына да түгел бит әле – бер ятакта йоклаучы ул ханым миннән артык түгел иде! Ни гаҗәп, өчесенең дә йөзләрендә ни елмаю, ни күңел халәтеннән йөздә чагыла торган яктылык юк иде. Нурланым берничә мәртәбә өстәл яныннан кузгалып, ханымнарга нәрсәләрдер алып килә, ташый торды. Ул гына җитмәде, ахрысы, ниһаять, яшьрәге (минем көндәшем була бит инде!) үзе кузгалып, нидер алырга китте. Аягындагы туфлиләре, дөрес

басып йөрмәүдән, әлбәттә, ян-якка кыйшайган, шуңадырмы, гафу итегез, атлап йөреше яңа дөньяга килеп, аяклана алмыйча азапланган бозауныкы кебегрәк иде. Бу манзара мине бөтенләй тынычландырып җибәрде. Күңелем мәтәлчек ата иде хәтта. Ул миннән артык түгел! Төс-бите, уңганлык, пөхтәлек, җитезлек, эчкерсезлек белән дә миннән артык түгел! Син аны бөтенләй белмисең бит, бәлкем ул Нурлан өчен җан атып торадыр, дисезме?! Юк, бәгырькәйләрем! Ялгышмыйм, дип уйлыйм. Шушы бер күзәтү җитте. Җан атмый, яратмый ул Нурланны. Яратсамы, чын яратсамы?! Аның күзләре очкынланып янар, йөзе нур чәчеп торыр, атлап йөрешләре башкача булыр иде! Нурланнан өч поднос ташытмас, үзе йөгереп йөрер иде.

– Мин синең белән килешмим, – диде Миңнеруй. – Каян беләсең син аларның тормышын? Бөтен нәрсәне яратуга гына кайтарып калдырырга ярамый. Нурланга рәхәттер бәлки шулай яшәү, хезмәт итү. Ә ярату... Нәрсәгә кирәге бар соң аның?! Булса да, тора-тора бетә инде ул, юкка чыга. Бер-береңә күнегү генә кала.

– Туктале, Кадрия, тыңлап торсаң, синең фәлсәфәң бик сәер килеп чыга, – дип, Миңнеруйның сүзен дәвам итте Кәримә. – Менә син, «яратмый ул Нурланны, аның өчен җан атмый», дисең. Ә бәлки Нурланың яратадыр аны, рәхәттер аңа шулай яшәү, хезмәт итү. Без унҗиде-унсигездәге башында җиләс җил уйнаучы җилбәзәк кыз-кыркыннар түгел ләбаса, бу фанинең гыйбрәтләрен күрә-күрә шактый акыллыландык, миңа калса, сукыр бер тиенгә дә кирәк түгел хатын-кызның яратуы! Ирең яратсын сине! Андый ирләрне үзең теләгән якка борырга, бау итеп ишәргә була...

– Теләсә нәрсә әйтегез, теләсә ни уйлагыз минем турыда, тик... мин сезнең сүзләр белән килешмим, – диде Кадрия. – Ләкин бәхәсләшмим, үз фикеремне көчләп такмыйм, ышандырырга да тырышмыйм. Ярату мәсьәләсендә генә түгел, гомумән, һәр нәрсәгә, кемнеңдер эш-гамәлләренә һәркемнең үз карашы, мөнәсәбәте, үз бәясе, үз фикере. Мин менә шулай уйлыйм, шулай яшим, шулай яратам... Яратканыма җигелеп хезмәт итәргә, һәрдаим күңелен күререгә, аны рәхәт яшәтергә телим, шуннан тәм, яшәвемә ямь табам...

– Иии кызлар, нишләтергә инде сезне, тәмләп, ләззәтләнеп кенә тыңлый башлыйм, тотасыз да бүлдерәсез Кадрияне, – дип, ризасызлыгын сиздерде Сөмбелә. Бераз гына уйланып-моңаеп торганнан соң, Кадрия сүзен дәвам итте:

– Ял итәбез шулай, минем белән бергә килгән хезмәттәшләрем көн саен санаторий клубында оештырылган кичәләргә, танцыга йөриләр, аш өстәле янында шунда күргәннәрен, кемнәр белән танышканнарын кызык итеп сөйлиләр, беркая да чыкмаган өчен мине шелтәләп алырга да онытмыйлар. Ә минем үз хәлем хәл. Нурлан һәм аның «командасы» күземә күренүдән шүрлим. Ашарга да алар ашап киткәч кенә йөрим.

Ә беркөнне ялдашларым мине концертта катнашырга үгетли башладылар.

– Монда шундый гадәт бар икән, кем нәрсә булдыра, бии ме, җырлыймы, мәзәк сүз сөйлиме – халык алдында үз һөнәрен күрсәтә. Мин биемәкче булдым, мәктәптә укыганда аяк тыпырдатканым бар иде. Шамил «Мокамай»ны сөйли. Рәфыйк безгә сөйли торган мәзәкләренең «колакны ярмый», йөзне кызартмый торганнарын сайлаштырып сөйләмәкче булды. Син җырларсың. Анда тагын кемнәрдер катнаша бугай.

– Юууук, сез нәрсә?! Җырламыйм! Тавышым да, теләгем дә юк.

– Синең матур җырлаганыңны әйттек инде без оештыручыларга. Хәзер без генә түгел, алар да белә. Җырлыйсың булгач, җырлыйсың.

– Эш урынында, табында җырлау – бер хәер, ә монда йөзләгән халык алдында... Фонограмма, һич югы баянчы кирәк.

– Баянчы табабыз, – диде концерт турында сүз башлаган Рәлиф. – Монда минем белән институтта бергә укыган егет ял итә. Ул уйнар сиңа баянда. Мин сөйләшермен Нурлан белән.

«Нурлан» дигәнне ишетүгә, ток тоткандай сискәнеп, баскан урынымда тыпырдап куйдым хәтта.

– Юк! Мин ул уйнаганга җырламыйм!

– Алай «юк» дип кырт кисмә әле син, белмәгән килеш. Башта уйнап-җырлап карагыз. Матур гына уйный иде ул заманында.

Минем нәрсәдән курыкканымны, корт чаккандай «юк» дип кычкырып җибәрүемнең сәбәбен сизенмәүләренә сөенеп тә куйдым.

Икенче көнне Рәлиф сәгать кичке дүрттә клубка репетициягә барырга кирәклеген, Нурлан белән сөйләшкәнен, ул да шул вакытка киләчәген әйткәч, минем тынычлыгым качты. Алып килгән өч-дүрт күлмәгемнең әле берсен, әле икенчесен киеп карыйм, берсе дә гәүдәмә килешми кебек, чәчем дә дөрес ятмый, күз карашым да дөрес түгел...

Вакытына туры китереп, тәвәккәлләп, киттем репетициягә. Килеп җитәрәк башымны күтәреп карасам, клуб каршындагы утыргычта минем кебек үк башын түбән иеп, Нурлан утыра. Мине күреп алуга, ялт итеп урыныннан торды. Ни әйтергә, ни кылырга белмичә югалып калды. Бер мизгелдән үзен кулга алып: «Мин кереп чыктым, анда синең белән миннән башка репетиция дип килгән кеше юк бугай...» – диде.

Без клубка килеп керүгә, Нурланның каршысына өч баян китереп куйдылар. Ул әле бер, әле икенче баянны кулына алып, телләрен баскалап карады да, ниһаять, үзенә яраклысын табыптыр, сыздырып уйнап җибәрде...

Бераз уйнагач, миңа күтәрелеп карап, «Нинди җыр җырларсың икән?» – дип сорады. Мин иңемне сикертеп куйдым. «Нинди җырлар җырлый идек әле без синең белән... «Уел»ны җырлый алыр идеңме, ...бик матур җырлый идең син аны. «Сибелә чәчем», «Үзең бүләк»... Хәтерлисеңме, икәүләп җырлый идек «Үзең бүләк»не», – диде дә, сыздырып уйнап та җибәрде. Аңа кушылып:

> Нигә икән синең исемеңне
> Кушам һаман моңлы җырларга?
> Мәхәббәтем, бәхеткәем минем... –

дип җырлый башлавым гына булды, гүя кинәт җанымның бер кылы өзелеп китте... җырым бүленде... Ниндидер ят тавыш белән ачыргаланып, кычкырып елап җибәрдем. Үземне белештермичә, ишеккә ташландым. Коридорга атылып чыктым. Әле бер, әле икенче бүлмәнең ябык ишекләренә төртелдем. Миңа каядыр кереп югалырга, кешеләрдән түгел, үземнән качарга кирәк иде. Шулай сугыла-бәргәләнә торгач, кинәт бер бүлмәнең ишеге ачылып китте. Атылып кердем дә почмакка согындым...

Күпме утырганмындыр, күпме елаганмындыр, хәтерләмим. Хәер, елау да түгел иде бугай бу, Нурланымны өзелеп яратып та муенына сарыла, кочагына сыена, моңлы күзләреннән үбә алмавымның җан газабы, ыңгырашу, әрнү булгандыр...


Ниһаять, тынычланып, башта коридорга, аннары урамга чыксам, башын түбән иеп, Нурлан китеп бара иде. Ни гаҗәп, ни клубта, ни урамда аннан башка беркемне дә күрмәдем. Кем белсен, бәлкем Нурланым да күземә генә күренгәндер...

...Намазлар укып, көне-төне башымны бәреп, Бөек Кодрәт Иясенә табынып-ялварып утырмасам да, үземне денсез кеше, димәс идем. Бүлмәмә килеп керүгә, кыйблага карап, Аллаһы Тәгалә каршысына тезләндем. Илереп елый-елый, үземне сөю газабыннан коткаруын, Нурланны онытырга, күңелемнән сызып атарга булышуын үтендем. «Йа, Раббым, үзең бирдең, үзең ал...» – дип тәкрарладым. Шулай ялвара торгач, кинәт аңым ачылып киткәндәй булып, вөҗүдемне моңарчы тоемланмаган тынычлык, хәтта битарафлык биләп алды. Торып бастым. Көзгегә күзем төште. Анда хасил булган сурәтемә сәерсенеп-әсәрләнеп карап тордым. Мин дә, түгел дә иде ул...

Шул рәвешем, шул халәтемдә күпме булганмындыр, кемнәрдер дөп-дөп коридордан үтте, кемдер ишек шакыды, мин боларны ишеттем дә, ишетмәдем дә. Шул – үзем өчен моңарчы таныш булмаган сәер халәтемнән айнып, бу дөньяга кайтып төшеп, бүлмә ишегемне ачып чыкканда, инде төн әллә кайчан үткән, көн уртасы җиткән иде. Ишекне ачуга, идәнгә бөтәрләнгән кәгазь кисәге килеп төште. Анда бер генә җөмлә язылган иде: «Мин сине үлеп яратам». Үземне үзем белештермичә, кая барырга теләгәнемне күңелемнән тәгаенләмичә генә, урамга томырылдым. Санаторийга килгән-киткәннәрне теркәү бүлмәсенә барып кергәнмен. Керә-керешкә, ярымпышылдап: «Галиев Нурлан Әхмәт улы» дип әйтә алдым. Кычкырып әйтергә тавышым чыкмады. «Әәәә... әйе... аны иртән ашыгыч ярдәм машинасы белән алып киттеләр... йөрәк... хастаханәгә барып җитә алмаганнар... юлда...». Кинәт үзем тирәли диван, урындыклар, килгән-киткәннәрне теркәп утыручы кыз,тагын кемнәрдер әйләнә башлаганын хәтерлим... Аңыма килеп, күземне ачканда, янәшәмдә ай-вай килеп, ак халатлы ир-ат, хатын-кызлар басып тора иде. «Куркыттыгыз, – диде ак халатлы ир кеше. – Берсенең үлүе җитмәгән... Анысы ярый әле юлда... сәламәтлегегезне кайгыртырга кирәк, ханым... санаторий белән генә булмый... »

...Җае чыккан саен мин Нурланым янында. Елыйсым килсә – елыйм, сөйләшәсем килсә – сөйләшәм, җырлыйсым килсә – җырлыйм. Миңа аны яратырга, аныңча әйтсәк, үлеп яратырга, беркем комачауламый... Ул – минеке генә! Кабере өстенә йөземне куюым гына була... Кинәт! Ниндидер серле рәхәт, назлы дулкын-калтырану җаным аша үтеп, баш түбәмнән аяк табаннарыма кадәр бөтен тәнем буйлап йөгерә башлый... Мәхәббәт назы, сөю дулкыны...

Фәрит
Габдерәхим



# КАБАТЛЫЙСЫҢ БАБАҢ ХАТАСЫН...

## Сине яратам

Җүләр сыман һаман мактанабыз,
Хакыйкатьнең карыйк күзенә.
И татарым! Ераккарак китеп,
Ник бакмыйсың икән үзеңә?!

Ташланасың утка. Ләкин син бит
Гаярь генә түгел, куркак та.
Бер сызгырса хуҗаң, «баш өсте!» дип
Юргалыйсың күндәм юргактай.

«Халкым таркау!» – дисең, ә бит үзең
Кабатлыйсың бабаң хатасын.
Саесканың шыкырдасын өчен,
Милләт сандугачын сатасың.

Тун ягасың беткә үч итеп син...
Яратырга сине хакым юк.
Яратмыйча ләкин мөмкин түгел,
Синнән гайре газиз халкым юк.

## Аз язам...

– Әллә соң син гөнаһларың өчен
Юлыктыңмы каһәр-җәзага?
«Халкым!» – дисең гелән – аңа атап
Күпме мөмкин шигырь язарга?!

– Татар кебек тоташ җәберләнгән
Халыкларның, әйтче, кайсысы?!
Юк, аз язам: мең шигырьгә сыймас
Фаҗигасе аның, кайгысы...

---

Фәрит ГАБДЕРӘХИМ (1933) – *Башкортстанда (Уфа) яшәүче татар шагыйре; татар һәм башкорт телләрендә чыккан дистәдән артык китап авторы.*

## Син дә татар ласа

*«Һәркем үз милләте белән*
*горурланып яшәргә тиеш!»*
Милләтпәрвәрләр афоризмы.

Кайгы-хәсрәтләрне җиңәр көчне
Бирә аламыни ялгызлык?
Милләттәшем, киттек! Урман көтә.
Тын акланда учак кабызыйк.

Ерак бабайлардан килгән гадәт:
Учак ялкынына багарбыз.
Көтмәгәндә өстебезгә ауган
Бәла-казаларны ягарбыз.

Калмаганмы татар мондый гына
Җәбер-золымнардан котылып?!
Кайгыдашым, син дә татар ласа,
Үз-үзеңне сакла, ки толып!

## Таллар исән!

Каеннарны, имәннәрне давыл төбе-тамыры белән актарган.
Ай, афәрин! Таллар исән! Таллар охшаганнар икән татарга!

## Чабак, Табан, Чуртан

*(Мәсәл)*

Елганың бер тыныч култыгында
Чабак белән Табан балыгы
Көн итәләр. Табан: «Минем култык!»
Чабак әйтә: «Ходай байлыгы!»

Күкрәк кага Табан: «Ләм минеке.
Камышлык та. Яшә бер читтә!»
Чабак: «Минсез кыен булыр сиңа:
Мин бит суалчаннар үрчетәм».

Көтмәгәндә бөек фикер туды,
Бар дөньяга Табан чаң какты:
«Тәңкә-йөзгечләре тач минеке,
Табан булсын аты Чабакның!»

Чабак хәтта судан сикереп чыкты:
«Сүзеңне син сөйлә чамалап!»
...Зур авызлы Чуртан икесен дә
Су төбендә ята сагалап.

## Шагыйрьнеке иде

*Бөек испан шагыйре Федерико Гарсиа Лорканың*
*җәсәденә бер чеметем туфрак.*

Аклан уртасында яшь шагыйрьнең
Йөрәгенә төзәп аттылар.
Күмеп тормадылар. Погонлылар
Дәртле бер җыр җырлап кайттылар.
Ул дәртле җыр... Лорканыкы иде...

## Төнге кунак

*Риваятьтән өзек*

Төн уртасы. Инде ничә сәгать
Буран улый бүре шикелле.
Килеп керде ят ир – бер мосафир,
Шакып тормый биксез ишекне.
Хуҗа хатын сәерсенеп карый.
Сүзе сүзгә ирнең ялганмый.
Төнге кунак телгә килде шулай.

Ул сөйләмәс һич тә ялганны:
«Бүгенгедәй буран. Атлы чана.
Ир вә хатын. Ими баласы.
Бүре өере арттан куып килә.
Ничек кенә исән каласы...
Куып җитте өер, куып җитте,
Котылырга бармы бер чара?!

Яшендәй уй узды – үзе, ире
Исән торып калыр, ничава...
Үзен-үзе белештерми, ана
Нарасыен атты өергә...»
Тынлык чыңлый өйдә. Хәтта тышта
Тынып калды буран-өермә.

Хуҗа хатын тораташтай катты.
Чәчләренә кинәт кар ятты.
«Саумы, әнкәй!
Менә мин кайттым! – дип,
Төнге кунак сәер ым какты, –
У-ууу! У-ууу! У-ууу!»

## Әллә...

Дөм караңгы. Җир-күк балкып алды,
Ымсындырып, алгысытып җанны.
Ачылдымы әллә күк капусы,
Әллә берәр шагыйрь дөрләп янды...

## Гаҗәп һәйкәл

Үз гомеремдә гаҗәп һәйкәл койдым,
Булмасам да гәрчә мин сынчы.
Шигъриятне, олуг мәхәббәтне,
Батырлыкны данлап торсынчы.

Бронзадан да түгел, мәрмәрдән дә,
Койдым аны шигъри сүзләрдән.
Гарасатка, хәтта ут-ялкынга
Шигъри сүзләр генә түзәрләр.

Гаҗәп һәйкәл: гүзәл ханым килә,
Бөтен дөнья аңа нур сибә.
Үтеп чыккан сират күпереннән
Фәнискәен[1] кочып Нурсөя[2].

## Биана туфрагыннан

*Күренекле әдип Айдар Хәлимнең*
*хәләл җефете Венера ханымга.*

Миңлесорур ханымныкы кебек изге күңелең.
Исән булса, әйтер иде: «Иң яраткан киленем!»
Рәнҗетсәләр дә үзеңне, рәнҗетмисең беркемне.
Гел саваплы эшләр кылып үткәрәсең һәр көнне.
Сынаулардан булмый качып, язмыш, әйдә, сынасын.
Миңлесорур килене син! Инша Аллаһ, сынмассың.
Син бит, сеңлем, сабырлыкның коеп куйган һәйкәле.
Бу кадәрле җан җылысын каян алдың, әйт әле!
Яшеннәрдән, күкрәүләрдән, давыллардан качмадың.
Син бит Борис Хәлимовтан Айдар Хәлим ясадың.
Һәркемне якын итәсең, тиң күреп туганыңа.
Ифрат хак сүзләр: «Киленнәр биана туфрагыннан...»

## Биш хатынлы

Сезгә генә ачам серем, йөрмәгез лә сөйләнеп.
Биш хатынлы булып куйдым, тик бер генә өйләнеп.
Беренчесе бага миңа гашыйк күзләре белән.
Җаннарымны эретәдер назлы сүзләре белән.
Икенчесе сөйләшмичә йөри көннәр буена.
Йөзе сытык. Өмет итмим инде җылы куенына.

[1] Фәнис – олугъ татар шагыйре Ф Яруллин.
[2] Нурсөя – шагыйрьнең хәләл җефете.

Өченчесе өтәләнеп йөри янымда биеп.
Туганнарны кочып ала: «Сагындырдыгыз!» – диеп.
Дүртенчесе җыймый байлык: «Син үзең, – ди, – алтыным!»
Белә бәхетле икәнен. Шушысы – иң якыны!
Бишенчесе үтә көнчел: «Әйе, – ди, – ул бит чибәр!»
Җанны кыя... Сезгә җиңел: имеш, аер да җибәр.
Мөмкин түгел. Үз-үземә әмер бирәм: «Бул түзем!»
Хатын... бирәү. Әмма ләкин бишкә тора берүзе.

## Бурычлымын

*И аракым, җаным, синнән башка*
*Көнем кара, төнем күңелсез.*
Ә.Атнабаев

Янма, йөрәк, ян тәмәке, имеш!
Малай чактан тарта башладым.
Бүтән бер дә тартмаячакмын дип,
Ничә тапкыр сине ташладым.

Тик син генә ташламадың мине:
Калдырганда дуслар ялгызым,
Нахак сүзләр талаганда җанны,
Папиросым, сине кабыздым.

Гаиләм имин. Шуның өчен дә мин
Синең алда ифрат бурычлы.
Савыт-саба шалтыраган чакта,
Сүзләр яуса тозлы-борычлы,

Мин тиз генә чыгып китеп тышка,
Папиросым, сине көйрәттем.
Гаиләбезне сугар яшеннәрне
Яшерергә син бит өйрәттең.

Папиросым мактар идем сине,
Тәмәкене мактау килешми.
Тышта үтте, синең белән үтте
Гомеремнең байтак өлеше.

Бичә белән тату яшәдек.
Ә яшеннәр... җанда яшьнәде...

## Төннәр

Яшь чагында төннәр кыска, гел ашыгып таң ата.
Ә картайгач, ифрат озын җәйге төннәр дә хәтта.

***

Гасырга якын яшәлде, ямансу көннәр җитте.
Сокланып туя алмадым: гомер үтте дә китте...

## Соңгы тапкыр

Кичерегез! Соңгы тапкыр мәшәкатьләрмен сезне.
Мәшәкатьләмәс идем дә, күмәлмәм үз-үземне.

**Редакциядән:**

*Бу айда каләмдәшебез үзенең 90 яшьлек юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*



*Диана – Әлмәт кызы. Бүгенге көндә ул Риза Фәхреддин исемендәге 1 нче гимназиянең 10 нчы сыйныфында белем ала. Хикәяләр, мәкаләләр яза, китаплар укырга ярата, кыска метражлы фильмнар төшерә. Дианага телләр өйрәнү бик ошый, шуңа күрә киләчәк тормышын әдәбият һәм телләр дөньясы белән бәйләргә уйлый.*

*Бишенче сыйныфта укыганда, беренче шигырьләрен язып карый, алга таба хикәяләр иҗат итә. «Көмеш кыңгырау» газетасы белән даими элемтәдә тора, анда мәкаләләре еш дөнья күрә. Узган ел исә Диананың хикәясе «Глаголица» халыкара әдәби конкурсында «Проза» номинациясендә Гран-прига лаек дип табылды.*

Диана
Фәрхетдинова

# ЯЗМЫШНЫҢ СОҢГЫ БҮЛӘГЕ

хикәя

Яңгыр. Суык. Сөякләрне авырттыра торган салкын яңгыр. Тәнне дә, җанны да өшетә торган салкын. Кайвакыт җил яңгыр белән уйнаклый, ләкин аңа гына күңелле. Җил юка тәрәзәләрне дерелдәтеп куя, яңгыр тагын да ныграк яварга тотына. Кызык аларга, Сәлимә генә «шатлык» сүзенең мәгънәсен күптән оныткан. Күзләрен ачкан саен – яңгыр. Йокы гына аның бердәнбер тынычлыгы. Күзен йомган саен: «Менә ул үлем, килеп җитте…» – дип уйласа да, яңа көн туа. Аның алдында шул ук буш өстәл, шул ук соры нәзек тәрәзә, шул ук ватык сәгать, шул ук ялгызлык.

Яшәүнең мәгънәсе күптән җуелган инде, ләкин үлеп кенә булмый, Газраил нәрсәнедер көтә, күрәсең. Моны Сәлимә карчык аңларга тырыша иде. «Юкка гына бу көннәр бирелмәгәндер инде», – дип уйлап куя ул. «Ләкин нәрсә тотып тора икән, ни өчен мин һаман монда», – дигән уйлар аңа тынычлык бирми. Бердәнбер белгән догасы – «Әл-Ихлас» сүрәсе иң авыр көннәрен әз генә җиңеләйтә.

Сәлиманең яшәгән җире – бер бүлмәле фатир. Уты күптән юк инде. Сибгать бу фанилыктан мәңгелеккә күчте: бу ачы, караңгы һәм салкын дөньяда Сәлиманең берүзен калдырып китте. Бөтен нәрсә шул килеш калды, инде алары да ватылып кына бара. Агач өстәл, кыегаеп киткән аяклары белән ике урындык, газ плитәсе (аңа Сәлиманең шулай ук тотынганы юк, бары тик су гына кайната иде) – болар кухняда. Ә бердәнбер бүлмәсендә – Сибгать белән бергә берничә ел элек, әле дөнья кояшлы булган көннәрендә алынган диван тора, аның алдында китаплар белән тулган агач стеллаж… Ул китапларны алар бергә рәхәтләнеп укыйлар иде… Әйе, барысы да Сибгать

белән бәйләнгән, башкача була да алмый: алар бит студент чакларыннан ук бергә, бернигә карамыйча, алар гел бергә иде. Хәтта балалары булмау хәсрәте дә аларны аера алмады. Хәзер дә бергә, моны Сәлимә күңелендә калган җанга якын җылылыгы белән сизә иде, бу җылыны да ул бирә сыман. Ул монда, якында, кулны сузсаң, алып китәр сыман, әмма нидер тота, җибәрми әле.

Акчасы да юк диярлек. Яртысы бу буш фатир өчен китә, ә калганы ашау мәсьәләсенә. Үзе пешеренә алмый инде Сәлимә. Якындагы пекарнядан 15 тиенгә ипи, 45 тиенгә сөт ала. Әз генә дә булса рәхәт вакытларын искә төшерер өчен, сырганаклы чәй ясап куйгалый иде, ләкин аның өчен ераграк барырга туры килә шул. Аякларының егәре көннән-көн бетеп бара, кулларының да җылысы күптән юк инде.

Яз! Елның бу чоры – Сәлимә карчыкка иң кадерле, истәлекле вакыт. Алар Сибгать белән яз көне өйләнештеләр, кайчандыр нәкъ яз көне бу фатирга күченделәр, кайчандыр Умырзая исемле песиләре дә бар иде бит, ул да яз көне алар белән яши башлады. Яз гына һәр ел Сәлимәгә өмет бирә. Бу язда да аның күңеле нәрсәгәдер өмет итә иде. Үзе дә белми, ләкин ниндидер ялкын кабынып китте бу язда.

…Бүген яңгыр кабат коеп яуды. Бөтен дөньяны юды. «Менә кем көчле!» – дип әйтә сыман. Фатир тәрәзәләре шыбырдап яуган яңгырдан зеңгелдәп торды, Сәлимә моңа игътибар итмәде. «Үлем шулай киләдер», – дип кенә уйлады. Хәле дә начараеп китте: ул берничә көн ашамады, ашказаны ризык сорамый иде.

Кичкә таба яңгыр тынычланды. Карчык күзләрен ачкач, башка беренче килгән уй – җылы ипи ашау. Пекарня инде ябык, иртәне көтәргә кирәк. Яңа көн тууын көчкә көтеп җиткергән Сәлимә, авыр аякларын өстерәп, кибеткә ашыкты. Ул кергәндә, кырыйдагы өстәл янында чибәр генә хатын-кыз китап укып утыра иде. Витринада үзе ала торган ипине тапмады карчык.

– Унбиш тиенлек ипи әллә юкмы бүген? – дип сорады сатучыдан.

– Бу атнада андыйны пешермиләр, апа. Башкаларын карагыз, кырыкка булганы тагын да тәмлерәк, – дип җавап бирде сатучы.

– Анысына акчам җитмәс шул, матурым, ярый, соңрак керермен әле тагын…

Китап укып утырган ханым барысын да ишетеп торган иде, аның күңелендә әбигә карата кызгану, шушы бөрешеп беткән карчыкка ярдәм итәсе килү хисләре уянды. Аның калтыранган тавышын ишетү бик авыр иде. «Хәзерге заманда болай да була икән. Юк, әбине буш кул белән чыгарып җибәрү ярамас», – дип уйлап куйды да урыныннан торып, карчык янына килде.

– Апа, ни телисез, шуны алыгыз, мин түләрмен, – диде хатын.

– И, юк, рәхмәт, кызым. Мин үзем соңрак килермен әле, – дип баш тартты Сәлимә.

– Мин чынлап, апа. Сезгә бүләк итеп алам, – дип дәвам итте хатын.

– Ярый, ләкин үзеңә ошаганнарын ал, минем күптән ипидән башка әйбер алганым юк, кызым, – диде карчык.

Хатын-кыз бу сүзләргә шаккатуын күрсәтмәде, ләкин аның күңеленә тагын да авыррак булып китте. Ул пакет тутырып, төрле тәм-томнар алды, карчык утырып торды.

– Барысы да сезгә, апа. Туйганчы ашагыз! – дип, карчык янына килде.

– Ничек инде барысы да?.. Син нәрсә, кызым, бер кисәк ипи – миңа зур туклык!

– Баш тартмагыз, апа, – дип елмайды ханым, – алыгыз, миннән сезгә хәер булсын!

Сәлимәгә бик уңайсыз иде, ләкин бүтән каршы килмәде, алды. Рәхмәт хисләре белән бар күңеле тулды: күпме генә кабатласа да, һаман җитми сыман.

Икенче көнне кинәт кемдер ишеккә шакыды. Кем булыр бу? Сәлимә аптырап, ишекне ачса, кичәге ханым басып тора. «Хәерле көн! Кичә сезнең хәлегезне күргәч, кабат ярдәм итәсем килде. Каршы булмасагыз, өегезне җыештырып, ашарга пешереп китәрмен», – диде ул. Сәлимә карчык ни әйтергә дә белмәде. Ул гаҗәпләнүдән сүзсез калган иде. Зөлфия (ханым үзе белән шулай дип таныштырды) бер сәгать эчендә бөтен җирне юып чыкты, хуш ис бөркеп торган токмачлы аш та пешереп куйды. Бу көтелмәгән яхшылыклар өчен карчык чиксез рәхмәтле иде, ләкин Зөлфияне нәрсә белән бәхилләтергә дә белмәде. Бернәсәсе дә юк иде дә.

– Гафу ит, кызым, бирер акчам да, әйберем дә юк, – дип кенә әйтә алды.

– Юк, сез нәрсә! Миңа берни дә кирәкми, сезнең елмайган бәхетле йөзегез, укыган догаларыгыз – миңа бүләк, – дип хушлашты ханым.

Шулай итеп Зөлфия Сәлимә карчык янына бик еш килә башлады. Яңгырлы көннәр күптән онытылды. Күзләрдә күптән сүнгән шатлык очкыннары күренде, кулларга да җылылык керде…

Әмма кайберәүләр үз баласыннан күрмәгән тәрбияне Зөлфиядән тапкан карчыкның хәле бик үк яхшы түгел иде. Акрын гына ишегалдына чыга алса да, Сәлимәгә һавалар да үзгәргән, элеккеге җәйге хуш исләр дә юк кебек. Яңгырлар юып бетергәнме?.. Аңа инде берни дә кирәкми, ул ялгыз булуына карамастан шат иде. Бик тыныч һәм шат иде.


Кечкенә адымнар белән көз килә башлады. Көзне Сәлимә карчыкның бүтән күрәсе килми иде. Көз аның сөйгән ярын алып китте, Умырзая да көз көне өйдән чыгып китеп югалды. Көз аны ялгыз итте. Күңелгә суык тудырды. Язгы җылылыктан соң ул көзне күрергә бүтән теләми иде. Җиткән.

Шулай беркөнне тыныч кына җылы яңгыр яуды. Яңгыр булса да, Сәлимә әбинең соңгы көннәрдәге даими һәм бердәнбер кунагы килде. Карчык ятып тора иде. Ул бүген элеккегә караганда тынычрак иде. Ашарга да теләмәде. Күзен авырлык белән генә ачты.

– Бар күңелемнән мин рәхмәтле сиңа, кызым. Син миңа зур шатлык китердең, кояшлы көннәремне кайтардың. Бәхетле бул, балам, бар гомереңне шатлыкта үткәр. Бу минем соңгы теләгем булыр, – дип тәмамлады сүзләрен Сәлимә.

– Миңа сезнең янда рәхәт кенә. Әбиләремне искә алдым. Сезнең аша аларның җылылыгын кабат сиздем, – дип дәште ханым.

Сәлимә карчык бу сүзләрне ишеткәч, күңеле әйтеп бетермәслек рәхәтлек тойды. Аның күңелен ниндидер йомшак, назлы җиргә алып киттеләр сыман. Йөрәге тынычланып калды, сулышы да әкренәя башлады. Менә аның алдында кунагы түгел, газиз ире Сибгать басып тора. Ул аңа кулын суза. Хәзер инде Сәлимә аның кулын сизде, аңа тартыла алды. Шатлыгы чиксез. Күңеле дә тыныч. Алар, ниһаять, кабат бергә. Хәзер берни дә аларны аермас. Беркайчан да.



*Алексей Сагатаев – хакас шагыйре, драматург, театр артисты, КВНчы, агач сувенир эшләнмәләре остасы. Ул 1983 елның 6 июлендә Хакасия Республикасының Бейск районы, Кече Монок авылында дөньяга килә. Шунда Аскиз урта мәктәбен тәмамлагач, Н.Ф.Катанов исемендәге Хакас дәүләт университетына укырга керә һәм этник сувенирлар ясарга өйрәнү белән беррәттән туган телендә шигырьләр дә яза башлый. Беренче шигырьләре 2004 елны «Хакас җире» газетасында басыла. 2010 елда «Пилтiр оолнын, чоогы» («Яшь тайгачы җырлары») исемле шигырь җыентыгы дөнья күрә.*

*Алексей 2014 елдан Абаканның «Читиген» («Җидегән») драма һәм этник музыка театры артисты. Шигырьләренә килгәндә, аларда тайга һәм табигать стихияләренең рухы аеруча калку чагыла.*

## Алексей Сагатаев

# МИНЕМ ХАЛКЫМ – КАЛЫН ТАЙГА...

### Шагыйрь

Шагыйрь туса – урман калкыр, җимеше-гөмбәләре – сүзләр.
Шагыйрь үлсә – корыр урман, муллык булып килмәс көзләр...

### Ел башы

Кайныйдыр ут өстендә өйрәле ит шулпасы.
Җыя якын дусларны бу олуг көн – ел башы.
Авыз итә шулпадан кызлар, казан тирәли.
Киң даланы күмеп җыр, колакларны иркәли.
Егетләр дә биредә елгыр атлар өйрәтеп
Әзерләнә ярышка, кызлардан җыр көйләтеп.
Чаламага-тасмага бай кызы каенбикә
Байый төшә тагын да – тадарлар[1] бәйрәм итә.

### Кыз урлау

Иске йола – яңа тормыш башы. Акбүз атның тояк чыңында
Туган йортка урлап кайтып киләм – килен елый бәхет юлында.
Күз яшьләре ага акрын гына, һәр тамчысы өтә бәгырьне.
Атым ярсып чаба...
– Күңелем гөле! Бар да яхшы булыр, кадерлем!

[1] Тадар – хакасларның борынгы атамасы.

## Ярлы хәсрәте

«Кырдагы чәчәкләр сатылмый!» диеп мин самими уйладым.
Тик байлар бүлделәр уемнан: «Синеке түгел, – дип, – ул байлык».
Җир-ана куенын илиләр, казыйлар, диварлар торгызып.
Һәм аннан табылган байлыкны каядыр ташыйлар көнозын.
Ә халык битараф, канәгать – булдыклы байгура эшеннән.
Кырдагы чәчәк тә аныкы икән бит, мин – яңа төшенәм...

## Калын тайга

Минем халкым – калын тайга, ул – тайга сыман чуар.
Таный алмый гизәм аны узгачтын байтак еллар.
Җанда хатирә яңартам: эрбет агачы белән
Очраштык. Ул үткәннәрне сөйләде берәм-берәм.
– Сәлам, әй, Эрбет агачы! Ник болай ялгыз калдың?
Әйләнә-тирәң шыр төпчек, кизләвең кипкән тагын...
Кайчандыр монда карурман иде үтеп кергесез,
Кизләү шаулап агып торды, кош сайрады өзлексез.
Искә төшә карт эрбеттән чикләвек җыйганнарым,
Җиләкләр белән сыйланып, аланда уйнаганым.
Ишетәсеңме, әй, карт Эрбет! Ант эчәм! Сезнең сакка
Багышлыйм бар булмышымны! …Күзләрдән кизләү калка.

## Ярымходай

Ялгышмамдыр төсле, әнкәм, ярымходай дисәм, сине.
Карыныңда сулыш өреп, кешелеккә бирдең мине.
Һәм үстердең әзер булып тормышның һәр михнәтенә.
Үзем әти булгач, хәзер сине ныграк аңлыйм менә.
Хәтеремдә – балачакта елап, сиңа йөгерә идем...
Башымнан бер сыйпау белән оныттыра идең чирем,
Борчу, курку – һәммәсе дә шул мәл онытыла иде...
Бүген төнлә яман төштән куркып улым: «Әни!» – диде.
Авыр чакта үз баласын әнкәй генә юатала –
Бишек җырын көйләп назлый әнкәй, гүя ярымалла!
Һәм уртак тел табала ул Ут алласы белән хәтта,
Һәм Умайдан бәхет сорап, дога кыла безнең хакка!
Ярымходай дими, әнкәм, тагын сине кем диим соң?!
Чал чәчләрең буйыйсың һәм яшьле күзең яшерәсең...
И әнкәем, чал чәчләрең, күз яшьләрең яшермә син!
Ярымходай күңелкәе юк-бар уйдан борчылмасын...

## Шомыртлар

Әтиләр-әниләр моңая, очты дип балалар оядан.
Кайгыра ничек дип хәлләре, кайтырлар микән дип яңадан.
Авылым артында шомыртлар... Аларда балалар гөр килә.
Сабыйлар иңенә кошлар күк очардай канатлар бирелә.
Ә әти-әниләр шомырттай – җимешләр гел әзер балага.
Тик вакыт-суалчан шомыртның кәүсәсен кимерә һаман да.

## Моңлы җыр

Җан белән ишетәм борынгы җырларны,
Аналар йөрәген төрүче сагышка.
Мәһабәт таулардан агыла ул көйләр,
Ул таулар астында җирләнгән Алыплар.

Авылда балалар хәзер дә туадыр –
Җир-ана куенының уллары-кызлары.
Хөр сулап яшәргә сәләтле йөрәкләр
Алыптай булырга лаеклы нибары.

Корычтан эшләнгән хәнҗәрләр күгәргән –
Батканнар кызыл кан урынына тутыкка,
Һәм агач сөңгеләр буш ятып черегән,
Җир-ана өндәми яуга вә сугышка.

Атасы нигезендә улына ни шөгыль?
Тын аккан гомерне шәрабкә салумы?
Әллә соң ныгумы иң каты токымдай –
Олылар үгетен күңеленә ягумы?

Тауларның моң тулы авазы бүген дә
Ап-ачык кайтаваз халкымның күңелендә.
Бу таныш аһәңнәр Алыплар үстереп,
Кайныйдыр яшь буын йөрәге түрендә.

## Дуска

Алып җәнлекләр яши тайгада. Соклануыңны, дустым, бер күрим!
Халкым аюны туганы саный – аю йөрәкле булуың телим!
Сынаулар хәтсез яшәү дәверендә, шактый кирәктер сәламәтлек тә.
Яман гадәтләр ташлансын, дустым, үссен сабыйлар күмелеп бәхеткә.
Баксаң, без дә бит киек-җәнлектәй – үз урының табу мөһим тормышта.
Халкыма аю гайрәте тансык ирешү өчен бөек уңышка!

## Шәһәр

Таш йортлар, таш юллар... Күңелдә таш төер...
Өемне сагындым, сагындым тау җилен...
Җирсүем җан телә – тоташ таш сукмагым...
Сусатты зәңгәр күк һәм кара туфрагым.
Уртаклык бер генә – «ерткычлар» күп монда.
Шулай да юашрак алар да тайгада.
Йолдызсыз, томанлы монда күк йөзе дә...
Кошлар да сайрашмый таш тайга түрендә.

## Кырыс кыш

Кыш кырыс дип, әйтмәгез, зинһар.
Ул безгә һәрчак булды сөйкемле.
Көмеш юрганнан каплап җир өстен
Йоклатты аны, әнкәй шикелле.

Зарланмагызчы суык дип кышын.
Кышын зарлана бары хөрәсән.
Тояр идекме йөрәк җылысын
Зәмһәрир суык кышны белмәсәк?!

## Кубызчы кыз

Эрбетнең ботагы буенча сикереп йөрүче тиендәй
Кыз кулы тибрәтә кубызны, биетә үзенең көенә.

Артыннан күзләрең иярмәс чабышкы ат сыман ул кулның.
Уйнаклый, ял сыман елкылдап, яңгыратып тояклар хөр хорын
Сылуның кубызы – кулында; күзендә – киң дала балкышы,
Далада – ефәккә төренгән мең кызның хөр бию тавышы.

## Усалланма, җил!

Көчле җил, нигә син дулыйсың, юлыңнан себереп барчасын!?
Бер чибәр сүзендә тормыйча ачуың чыгарды мәллә соң?
Мин күрдем ничек син кыр буйлап бураннар бөтереп биисең.
Син гашыйк булган шул соң көздә... Хәзер яз! Әллә соң белмисең!?
Карсылу юк инде, ул эри! Дулама, файда юк бу эштән!
Сөеклең яңгырга әйләнеп кабаттан кайтачак бер кичтә!

## Яз җиле

Ягымлы аһәңең яңгырый, моңланып җан җырын көйлисең.
Сүзләрең кайтара язларны, күңелне язларга өндисең!
Син умырзаядай, язгы җил иркендә биисең, тибрәлеп.
Күлмәгең кояшта алланып бөтерелә, елкылдый җилләнеп.
Күңелне сөюгә төргән җил, язгы җил, назлы җил, көткән җил,
Мәхәббәт сүзләрен көй итеп, җыр итеп йөземнән үпкән җил.

## Моңсуланма җәйдә

Моңайма чыланган агачтай яңгырлы, караңгы бу көндә.
Искә ал сап-сары гөлләрне учактай балкучы ирнеңдә.
Мин сиңа әйтермен, дускаем, җәйләрдә начар көн булалмый,
Күңелең яктырыр кабаттан, чәчәкләр яңгырдан сулалмый.
Чык та бак яңгырлы күккә син, күз яшең юылыр яңгырда.
Күрерсең күз кыскан кояшны еракта, болытлар артында.

## Икәү бергә

Син якты ай булып балкырсың, мин – йолдыз булырмын күк тулы.
Төннәрен без җирне яктыртып торырбыз икәүләп, берьюлы.
Күгеңне болытлар капласа – миңа да шәүләсе эләгер.
Син матур гөл булсаң, янында минем җан чирәмгә әйләнер!
Кояшка сөенсәң – шатлыгың әзер мин урталай бүләргә.
Һәм күгең булырга әзермен – кош булып җилпенсәң күкләрдә.
Һәрвакыт янында булалсам – мин әзер барсына түзәргә...

## Кызларга

Толымга үрелгән чәчләрне кыскартып кисмә син, кыз бала
Яшермә егетләр күзеннән – чәчеңнән илаһи нур тама!
Чәчегез тузгытып туй итәр көн житәр, табылыр үз тиңең.
Шул чакны чәчеңә кушылып, толымга үрелер тәкъдирең.
Чәчләрнең тылсымлы тәэсирен беләмен, тоямын үзем дә.
Мин дә бит адаштым бер гүзәл сылуның толымы эчендә.
Сылулар, шул сезгә киңәшем! Кыска чәч – ул ирләр өлеше.
Егетләр сөйгәне хакында, яратып, «чәчбикәм» диешер.

*Хакас теленнән* **Фәнил ГЫЙЛӘҖЕВ** *тәрҗемәләре*

# ШИГЪРИ СҮЗ КОДРӘТЕ

## (МӨХӘММӘТ МИРЗА ИҖАТЫНА БЕР КАРАШ)

*Сүз кодрәте – үзәгенә*
*Янып керә алуында.*
*Буыннардан-буыннарга*
*Күчеп, тере калуында.*

М.Мирза

Мөхәммәт Мирза – XX-XXI гасыр чиге татар поэзиясе үсешенә, аның яңарышына зур өлеш керткән шагыйрь. Аның шигырь-поэмалары кешене олы кыйммәт итеп күтәрә, кешелекнең яшәеш кануннарын аерып чыгара яисә тормыш закончалыкларын тәнкыйть утына алган үзгә бер әдәби дөньяны укучы хөкеменә тәкъдим итә.

1980 елларның икенче яртысында лирик шигырьләре, җырлары, поэмалары, хикәяләре, әдәби тәнкыйть һәм публицистик мәкаләләре белән әдәбият мәйданына килеп керсә дә, М.Мирзаның таланты шигърият төрендә ачыла. «Кәккүк тавышын санадым» (1994), «Турайгыр» (1998), «Киек каз юлында» (2003), «Тере су» (2007) кебек җыентыклары басылып, әдәби җәмәгатьчелек һәм тәнкыйтьчеләр тарафыннан хуплап каршы алына. Бер-бер артлы дөнья күргән тәнкыйть мәкаләләрендә, фәнни язмаларда Р.Ганиева, Д.Заһидуллина, Ф.Хәсәнова кебек галимнәр, М.Әгъләмов, Г.Гыйльманов, Н.Акмал, Р.Мингалим кебек шагыйрьләр тарафыннан М.Мирза сагышлы, өзлексез эзләнүләр алып баручы, философ, үз фикерләрен укучыга тулы һәм чиктән тыш ачык җиткерә алучы, өлгергән шагыйрь буларак бәясен ала.

Әдәбият мәйданына килеп кергән һәр әдип үз сукмагын, үз йөзен булдырырга омтыла. Ә бу шәхси стиль әдипнең үзенә хас булган язу чалымнарыннан, ул яратып кулланган алымнардан, еш мөрәҗәгать иткән образлардан, формалардан, лирик героеның хасиятләреннән оеша. Мондый «индивидуальлек» М.Мирзага да хас. Билгеле булганча, XX гасыр ахырында иҗтимагый-сәяси вазгыятьнең алышынуы үзенчәлекле идеологик мәйданга әверелгән татар шигъриятенә дә көчле тәэсир ясый, поэзия үзгә фәлсәфи-әхлакый, эстетик, сәяси кыйммәтләр һәм аларны җиткерүнең яңа алымнарын, калыбын эзли башлый. Аерым сүз осталары татар шигъриятенең үсешен рус яки көнбатыш эстетик һәм сәнгати кануннарына юнәлтеп үстерүдә, аерым шагыйрьләр исә нигезне, традицияләрне яңартуда, шәрык әдәби үзенчәлекләрен заманга яраклы дәвам итүдә күрә. М.Мирза иҗатында соңгысы алга куела, шагыйрь шигърияtнең үсешен асыл кыйммәтләрне милләт хәтерендә яңартуга бәйли, шәркый сәнгати алымнарның актуальлеген югалтмавын дәлилли. Бу сыйфат аның шигырьләрендә чагылыш тапкан дөнья сурәтендә, лирик геройның дөньяга карашында гына күзәтелеп калмый, образлылыкта, жанрлар төрлелегендә яисә шигырь калыбын, хәтта үлчәмен сайлауда да ачык күренеп тора.

М.Мирзаның лирик герое төрле. Бер яктан, ул – дөньяны фәлсәфи аңларга-бәяләргә омтылучы, кичерешләре катлаулы образлар ярдәмендә чагылган уйчан шәхес; икенче яктан, хөр фикерле, тормыш-яшәешкә, үзе яшәгән җәмгыятькә һәм анда барган үзгәрешләргә ирония, сарказм белән сугарылган тәнкыйди бәясен, фикерен ишеттерергә омтылган актив гражданин шәхес; өченче яктан, авыр кичерешләрдән юануны балачактан, авылда үткән яшьлек сукмакларыннан, мәхәббәттән, Ана җылысыннан эзләгән хисчән кеше булып, ул шагыйрь иҗатын лирик-эмоциональ дулкынга көйли.

М.Мирза иҗатын үзенчәлекле иткән икенче хасият аның шигъриятендәге жанрлар төрлелегендә, шушы юлдагы форма эзләнүләрендә күренә. Форма ягыннан Көнчыгыш әдәби традицияләренең үстерелүе дә шагыйрь иҗатындагы жанрлар төрлелегендә ачык чагыла. М.Мирза классик Көнчыгыш жанрларын заман укучысына фикер әйтүдә файдалана. Аларны «уйнатып», тәҗрибәләр ясый.

Мәсәлән, шагыйрь газәл, робагый, касыйдә, нәсыйхәт жанрларын яңартып җибәрә. Шагыйрьнең нәсыйхәт тибындагы шигырьләре Көнчыгыш әдәбиятындагы әхлакый кыйммәтләрне киләчәк буыннарга тапшыру идеясе белән сугарыла. «Әйтче, кардәш, һаман түзеп торыйкмы...», «Бәләкәй булсаң бул, тик син вак булма...», «Күзгә-күз кагып бирәмсең сәламең...», «Холыксызлар кемнедер гел битәрләр...» һ.б. шигырьләр шундыйлардан. «...Карыйм да бу дөньяның дүрт ягына..» шигырендә былбыл, гөл кебек суфичылык поэзиясе аша мәгълүм образлар, бер яктан, лирик геройның үзен әйләндереп алган тормышка, яшәешкә мәхәббәте булып укыла. Икенче яктан, шушы тормышны бүләк иткән Аллаһка мөнәсәбәтне тасвирлауга юнәлтелә, лирик герой үз тормыш тәҗрибәсеннән туган караш-фикерләре белән уртаклаша:

*Хөрлегемә, саулыгыма мең разый,*
*Тулып агам гомер-дәрьям ярына.*
*Ил-йортым киң, ризыгым мул, рухым шат,*
*Юлым ачык – хилафсыз иманыма.*
*Ким итмәгән – ургып тора хисләрем,*
*Былбыл оя кора күңлем талына.*
*Күгем зәңгәр, таңым алсу, гөлләрем*
*Һәрчак шифа, илһам коя җаныма...*
*Җиде бабам көтеп алган бәхет бу:*
*Насыйп әйлә, Раббым, оныкларыма.*

Тормыш кичкән лирик герой кеше өчен саулыкның, тынычлыкның, ризыкның мөһимлеге хакында сөйли.

Дини эчтәлек, тәрбияви башлангыч М.Мирзаның газәлләрендә дә актуальлеген югалтмый. Аларда көнчыгыш классик газәлләренә хас мәҗнүнлек, мәхәббәттән шашыну мотивлары, гомумән, күзәтелми. Хәтта дөньяви мәхәббәт темасына язылганнарында да бу шулай: *«Әгәр сине сагынмасам, / Хатлар да язмас идем, / Җырларымнан баскыч тезеп, / Син балкыган биеклеккә / Менәргә базмас идем».* Мондый әсәрләрдә шагыйрь кеше гомерен Аллаһ тарафыннан бирелгән бүләк итеп таный, язмышның алдан язылуы хакында сөйли, ислам кануннарындагыча, язмышның Аллаһтан булуы турында сөйли. Мәсәлән, «Бер күк астында яшәп тә...» шигырендә кеше тормышы Аллаһ биргән язмыш белән тыгыз бәйләнештә карала. Лирик герой ислам фәлсәфәсен яхшы белүче, тормыш авырлыгыннан Аллага сыенучы, аңардан ярдәм көтүче, аңа рәхмәт укучы диндар кеше булып күренә, шушы юлны бердәнбер хакыйкать итеп таный. «...Фатихасыз бер көнем дә торалмам...» шигырендә ул, ислам кануннарында язылганча, Аллаһтан ярдәмне үзе өчен генә түгел, бөтен милләт, кавем өчен сорый:

*Фатихасыз бер көнем дә торалмам,*
*Ил-көнемә иминлек бир, бер Аллам.*
*Уң кыл юлын бөтен нәсел-ыруның,*
*Кодрәтең киң, рәхмәтең зур, бер Аллам!*

Дога рәвешендәге шигырьдә «Бер Аллам» рәдифен кабатлау аша кешегә Аллаһ ярдәменең иң мөһим шарт икәнлеге ассызыклана. Гомумән, М.Мирза газәлләре, төрки-татар әдәби традицияләрен үстерә: иҗтимагый-социаль эчтәлек, дини хис-кичерешләр белән сугарыла.

Шагыйрьнең дүртьюллык – робагыйларында да фәлсәфи, әхлакый, гыйшкый (интим), иҗтимагый мәсьәләләр күтәрелә: «Рас килде – фаразлар хаклыгын кара син…», «Туган җирең – кендегең төйнәлгән төш…», «Белмәс иде һичкем дә юкбарыңны» һ.б.

*Кемдә кемнең хакы йөри түләнәсе,*
*Кемне каплый кемнең кара күләгәсе.*
*Дөнья матур, дөнья киң, дип акыл сата*
*Денен, телен җуйган илнең кем-кемсәсе?,*

– дип яза ул.

Биредә әхлакый мәсьәләләр үзәккә куела; иҗтимагый-социаль кануннар да фәлсәфи-этик яссылыкта кире кагыла, рухи яңарышка өндәү мотивы яңгыраш ала.

1990 елларның ахырыннан М.Мирза иҗатында форма эзләнүләре көчәя, классик шигырь калыбыннан китеп, ул үз фикерен укучыга җиткерү юлында яңа формалар эзли, берьюллык, икеюллык, өч һәм дүрт, биш, алты, җиде һәм сигезьюллыклар иҗат итә башлый. Аның кыска шигырьләре Көнчыгыш әдәбиятындагы афористик гыйбарәләргә охшатып языла. Юкка гына ул аларны гыйбарә, күзәтүләр дип атамый. Мисал өчен: «Астыртынның сурәте – айсберг». Зур өлеше су астында билгесезлектә калган табигать стихиясе образы шагыйрьгә эчке дөньясы белән биктә калган, эчкерле кешене ачарга мөмкинлек бирә.

Шагыйрь иҗатында бишьюллыклар, аеруча «Адәм баласы» шигырьләр циклы үзенчәлекле. Милли шигърияттә «Туфан строфасы» буларак калыплашкан һәм лирик герой кичерешен, автор фикерен яңгыраш-тәэсир бөтенлегендә җиткерүгә йөз тоткан бишьюллыкны М.Мирза яңача, чичән шагыйрьләр стилендә, табышмак формасында коруга ирешә. Мәкаль-әйтемнәр куллану, шигырь юлларын хикмәтле сүз кебек төзергә омтылу, «шәркый» характерлы, бик нечкә ирониягә, төртмәле кинаягә мөрәҗәгать итү – барысы да аларның үзенчәлеген тәэмин итә. Шагыйрьнең осталыгы образларны көтелмәгән мәгънә борылышлары белән баетып, ассоциацияләр тудыра алуда да күренә.

Әлеге циклда урын алган бишьюллыкларны символик эчтәлекле җыелма Адәм баласы образы, философ статусындагы лирик герой һәм фәлсәфи башлангыч бербөтенгә туплый. Лирик герой укучыны кешелек өчен беренчел кыйммәтләр, яшәү мәгънәсе, шәхеснең тормыш-яшәештәге урыны, вазифасы хакында сөйләшүгә алып керә, кешелек һәм кеше турында уй-тойгылары белән уртаклаша. Шагыйрь үзе аларны «уйлы шигырьләр» дип атый: «Уйлы шигырьдә, мөнәсәбәт белдерү, тойгы уяту белән бергә, мәгърифәткә өндәү, әдәп-әхлакка чакыру, әхлак кануннарын җиткерү дә бар. Бу инде – Шәрык әдәбиятының гасырлардан-гасырларга күчеп килгән традициясе. Һәм, әйтергә кирәк, күркәм традиция». Шушы контекстта Адәм баласы кешелекнең үзе булып кабул ителә башлый.

Мәсәлән: *«Чәчәге – чәнечке… / Яфрагы – ут әнә… / Адәм баласының / Теленәсе күңле / Шул гөлгә үрелә...»*. Чәчәге чәнечке, яфрагы ут булган гөл образы эчтәлекне төрлечә аңларга юл күрсәтә. Шигырь контекстында ул чынга ашмаган хыяллар, иллюзия булган әхлакый, иҗтимагый, сәяси идеаллар, тигезсез мәхәббәт һ.б. мәгънә калыпларында уйнатыла. Лирик герой шушы халәтләрнең кеше күңелен имгәтүе хакында сөйли. Әмма текстта күпнокталар куелу, әйтеп бетерелмәгәнлек һәр кешегә үз тормыш тәҗрибәсенә бәйле нәтиҗә ясау мөмкинлеген бирә.

Шул ук үзенчәлек башка бишъюллыкларда да дәвам итә. Мәсәлән: *«Үзе таңнан эштә, / Акылы – төштән соң... / Адәм баласының / Кайчан, кайда, ничек / Авызы пешкән соң?»*. Ике татар халык мәкаленең аерым компонентларын файдаланып, шагыйрь яңа эчтәлеккә алып чыга: мәкальләргә хас «чеметеп», чит кыйммәтләрне алга куйган кешелекнең үткән буыннардан гыйбрәт алмавы турында сөйли.

М.Мирза иҗатында фәлсәфи шигырьләр күп. Алар кеше кыйммәте, кеше гомеренең бәһасе, яшәеш кануннары, кешелекнең Җир-галәмдәге миссиясе турында уйлана, яшәү һәм үлем бөтенлеген ислам кануннары яктылыгында бәяләп языла. Мисал өчен, «Кара каен» шигырендә үзәк образ ак каеннар турында шигырь укып күнеккән укучыны сискәндерә, строфадан-строфага ул берничә мәгънәне үзенә сыйдырган символга әйләнә. Мәңге табылмаслык бәхетне эзләп, авыллардан, әнкәләре янынннан киткәннәрне хәтерләткән кылганнар һәм карга оялары образлары белән янәшәлектә ташландык нигез кебек укыла; юкка чыккан авыллар белән ассоциация тудыра; лирик геройга гомеренең үтүенә бәйле туган сызлануны җиткерергә ярдәм итә: *«Япа-ялан кырда / Шадра кара каен... / Охшап барам аңар, / Гомер үткән саен. / Буразнасын ярып, / Кара ятты йөзгә... / Янып бетеп гомер, / Кереп барам көзгә»*. Шуның аша М.Мирза табигатьтә генә түгел, яшәештә дә һәр кеше ялгыз, яшәү вакытлы, үтә-югала дип кабатлый. Шушы ук фикерне «Киек каз юлында» шигырендә киек каз образы аша җиткерә *(«Калулар юк, калулар юк / Дөньяда – кыйгак, кыйгак... кыйгак»)*.

Мондый шигырьләрдә иман ныклыгы, сафлыгы иң төп мәсьәләләрнең берсе итеп күтәрелә. *«Бетмәс байлык – иман / Оҗмахка керерлек»* дип санаган шагыйрь өчен иман дини-әхлакый, милли һәм мәдәни таяныч, рухи кыйммәт дәрәҗәсендә кабул ителә. Мәсәлән, «Иң тынгысыз матдә – кеше» шигырендә иман ныклыгы аерым кешенең генә түгел, милләтнең дә әхлакый нигезе кебек аңлатыла. «Бүленгәнне бүре ашар» эпиграфы ачкыч ролендә укыла һәм интертекстуаль вазифа үти. Мәкальнең үзендә бүленүнең аяныч нәтиҗәләргә китерүе хакында әйтелә һәм бердәм булу кешелек җәмгыятендә яшәүнең нигезе дип тәкъдим ителә. Әмма шигырь кысаларында шагыйрь бүленү сүзе белән «уен» башлый. Бер яктан, бүленү арту, күбәю кебек шәрехләнә: *«Бүленешү – чиккән челтәр кебек, / Чылбырланып кабат берләшү. / Җирдә иң тынгысыз матдә – Кеше, / Яшәр өчен мәңге көрәшү»*. Шул ук вакытта бүленү соңгы строфада һәр кешенең эчке халәтенә бәйләп куела, эчке рух, иманның бүлгәләнүенә кагыла. Кавем, милләтләрнең, гомумән, кешелекнең бердәмлеге, алга таба яшәеше өчен һәр кешенең күңел ныклыгы, иманының бүленмәслеге кирәк, дигән фикер укыла башлый.

М.Мирзаның фәлсәфи эчтәлекле шигырьләрендә Көнчыгыш әдәбиятына хас изгеләштерү күренеше дә күзәтелә, шушы фонда шигърият, шигъри сүз еш кына Иләһи нур чагылышы кебек шәрехләнә, шагыйрь образының вазифасы да шуңа бәйле билгеләнә: *«Мин барлык кыйммәтләрне / Шигырь бизмәненә / Салып үлчим хәзер»*. Шигъри сүз, шәркый традицияләрдә, иләһи сүз югарылыгына күтәрелә, шушы яссылыкта *«Сүз – галәм илчесе, Адәм баласын ул мәңгелеккә илтер»* дип кабатлана. Шагыйрь – шигырь язучы чикләрендә генә калмыйча, яшәешнең пульсын алдан сизүче, җәмгыятьне рухи яктан төзек, сәламәт тотучы пәйгамбәр, милли юлбашчы кебек күзаллана. Мәсәлән, «Тукайлы башкала», «Мәңгелекне хаклап» шигырьләрендә Тукай, Такташ, Туфан, Җәлилләрне татар халкының әйдаманы, остазы, халык тормышына юл ярып баручы итеп сурәтләү калкулана, милли үсешкә, якты киләчәккә югары мәдәният, әдәби сүз, шагыйрьләрнең рухи батырлыгы аша гына ирешеп булуы турында фикер үткәрелә.

Гомумән, шагыйрь мәңгелек рухи кыйммәтләрне җиткерүгә хезмәт итәргә тиеш дигән фикер М.Мирза иҗатын иңләп бара. Автор фикеренчә, теге яки бу чорга дан җырлаган әдипләрнең иҗат гомере кыска: *«Кызыл шигырь язып / Дан-шөһрәт казанган / Адәм баласының / Иҗатын җирлиләр / Үзеннән алдарак...»*. «Шагыйрь дәште...» шигырендә шагыйрьләрнең гражданлык бурычы милләткә китергән файдасы, аның тормышында тоткан урыны белән бәйләп куела. Янәшәдә М.Мирзаның үз шәхси бәясе, билгеле фикерләргә үзенчәлекле ироник мөнәсәбәте калкулана: *«Шагыйрь дәште: – Көрәшчеләр кирәк!, – дип, – / Беләкле күп, йөрәклеләр кирәк, дип, / Көрәшләрдә җиңелмәдек, җиңмәдек, – / Һәрчак җитмәде безләргә бердәмлек»*.

М.Мирзаның гражданлык лирикасында 1990 елларда татар шигъриятенең үзәгенә күтәрелеп, үз милләте өчен көрәшергә әзер булган актив, хөр фикерле гражданин лирик герой алга чыга, тормыш-яшәешкә, үзе яшәгән җәмгыятькә һәм анда барган үзгәрешләргә бәясен, фикерен ишеттерергә омтыла. Лирик герой сәяси торгынлыкның нигезләрен үткән тарихтан эзли; өзлексез сугышлардан гыйбарәт тарих аерым кешене дә, милләтне дә, халыкны да бәхетле итә алмый дип раслый: «Сорау арты сорау туып торыр...», «Сугыш уеннарын күп уйнадык», «Ил-йортына яу килгәндә...», «Әйләнде дә басты куласа» һ.б. «Ил нидән башлана: / кавем, ыруданмы? / ... гаилә коруданмы» кебек сорауларга җавап эзләгәндә, ил, халык язмышы турында уйлану – милләт киләчәге, тел язмышы, гореф-гадәтләр, йолалар сакланышы, яшь буынның мәдәни кыйммәтләргә мөнәсәбәте мәсьәләләренә ялганып китә, «Ил-мәйданда төш түгел», «Сабантуй», «Агыйделдә ак пароход», «Нишләр идем» кебек шигырь-поэмалар шул хакта сөйләп, мәйданга чыга.

Мәхәббәт шигырьләре М.Мирза иҗатында күпчелекне тәшкил итми, аларның фәлсәфи мотивлар белән баюы күзәтелә. Шагыйрь мәхәббәтне ике кеше арасындагы хис-халәт, мөнәсәбәтләр баскычыннан яшәеш гармониясенең чыганагы югарылыгына күтәрә. Мисал өчен, «Сиңа кайтыр юлым» шигырендә традицион «юл / тау», «юл / карурман», «юл / диңгез» янәшәлеге, фольклор традицияләрендәгечә урау юллар, үтеп булмаслык таулар, карурман, диңгез кебек образ-сурәтләр шул хакта сөйли. Сөйгән ярдан аерылу лирик герой күңелендә сагыш хисен уята; шагыйрь, үтеп чыгып булмаслык каршылыкларны строфадан-строфага үстерә барып, бер-берсен баетып килгән образ-детальләр аша шушы хисне әрнүгә җиткерә. Алар аша үз фикерен шәрехли: беренче мәхәббәттән аерылу кешене мәңгелек сагышка сала һәм бу халәт кеше җанында даими хискә әверелә. «Хыянәтне кичермимен, дидең», «Көттем, дисең», «Хисләр чакырып алыр кунак түгел...», «Әле еллар ераклыгы...» һ.б. шигырьләрдә дә шушы фикер яңгырый.

Мондый эзләнүләр М.Мирзаның поэмаларында да дәвам итә. Мәсәлән, репрессия корбаны булган бабасы Нурлыгаянга багышлап язылган «Турайгыр» поэмасы милли сыйфатларның тарихи вакыйгаларда сыналуын күзәтә. 1930 елларда динле, иманлы буынның авылдан куылуы нәтиҗәсендә традицион рухи кыйммәтләрнең юкка чыгуы хакында сүз алып барыла, аның өчен шагыйрь нигезгә эленгән ал әләм, кызыл кәфенлек кебек үзенчәлекле образларга мөрәҗәгать итә һәм аларның мәгънәләрен үзгәртә. Үз хуҗасыннан тартып алынган ат – Турайгыр образы гаилә, кавем, халык, илнең терәге булган ир кешене бәяләүче кебек уйланылган. Әсәр тукымасында ул нигез, нәсел, авыл сакчысы гына түгел, милли ныклык, иман төзеклеге, системадан ризасызлык чикләрендә укыла алган күпмәгънәле символга әверелә.

Әсәр поэтик яктан да үзенчәлекле. Поэманың башында билгесезлек халәтен җиткерү өчен риторик сораулар кабатлана. Әрнү тойгысын эпитет, метафора һәм сынландыру алымнары хасил итә: Турайгырның кешнәвеннән, мылтык тавышыннан болытлар калтырый, йөрәкләр кага, җир шары сискәнә һ.б. Әлеге сурәтләү алымнары М.Җәлилнең «Вәхшәт» шигыренә дә ишарә ясый, әнә шулай шагыйрь сыйнфый көрәш нәтиҗәсендә авыл кичергәнне миллионнарча кеше язмышын җимергән сугыш фаҗигаләре белән янәшә куя. Ил күләмендә барган хәлләр символик образ-детальләр аша да тирәнәйтә: *«Турайгырның күзен чокыган / каракошлар бигрәк ач иде...»*. Гаепсез кешеләрне фаҗигагә этәрүчеләрнең символы булган каракош образы шушы максатка юнәлтелгән күренешләргә бәя бирә торган икенче эчтәлеккә юл ача.

Әлеге образ шушы ук мәгънәдә «Кабатланмас мәңге дигәннәре» поэмасында да очрый. Шагыйрь сугыш вакыйгаларын җентекләп сурәтләүне максат итмичә, алар тәэсирендә туган кичерешләр сызыгын алгы планга чыгара. Һәр сугышның мәңге кабатланмас дип тәмамланып та, даими яңарып торуы әрнү тойгысын иң соңгы чиккәчә үстерә. Г.Тукайдагы «кисмәк өстендә иттифакый кунган каракош» образына

ишарәләгән Каракош-козгын образы меңләгән кешеләрне үлемгә этәргән сугыш фаҗигасен хасил итә. Ил азатлыгы хакына гомерләрен биргән егетләрнең җаны, аларның тиңсез хәсрәт кичергән аналары каршында Ватан җаваплы дигән фикер әсәрдә төп идея булып яңгырый.

Совет системасына тәнкыйди караш, тормыш-яшәешнең көнүзәк проблемаларын яшәеш, милләт язмышы, халык әхлагы һәм традицияләре нокталарыннан күздән кичерү шигырь-поэмаларның гражданлык эчтәлеген тирәнәйтә. Бер гасырлык тарихны үз эченә алган «Кысыр Гариф» поэма-кыйссасы бу яктан аеруча көчле яңгырый. Асылда ул тормыш-яшәешнең үзәге, таҗы булган кешенең сугыш газаплары, рухи фаҗигаләр аша кичеп тә, кешелекле булып калырга омтылуы хакында сөйли. Әсәрнең башында ук «Сугышларны дөнья байлыкларын кабат бүлешү, таланган-яуланган байлыкның хуҗаларын аклау-саклау өчен махсус китереп чыгаралар дип бәяләүчеләр хаклымы әллә» соравы куела. Гариф образы аша М.Мирза шул чорның күп язмышларын бер ноктага туплый.

Әсәр татар шигъриятенә сугыш фаҗигасен буыннар фаҗигасе итеп таныган, аны фаҗигале үткән итеп бәяләүче, җимерелгән язмышлар өчен әрнүче лирик геройны «кайтара». Шул елларда җимерелгән язмышлар ил киләчәгенә бәйле күзаллана: илнең бәхете дә, хәсрәте дә аерым кешеләр бәхетенә яки кайгысына бәйле дигән фикер ассызыклана. Охшаш мотивлар алга таба шагыйрьнең әтисе фаҗигасен, әнисе язмышын сурәтләгән «Бакы – кубарык җил», әбисенең фаҗигале язмышын тасвирлаган «Хәбибҗамал» поэмаларында дәвам итә, үстерелә.

М.Мирзаның «Мохтар» әсәре хәзерге татар поэзиясенә яңа сүз булып килеп керде. Татар халкының танылган шәхесе, актёры, режиссёры Мохтар Мутинга багышланган бу драматик поэмада биографик мәгълүматлардан бигрәк, Мохтар Мутинның эчке халәтен, омтылышларын, фаҗигасен тарихи хакыйкать аспектында сурәтләүгә зур урын бирелә. Шагыйрь әлеге шәхесне күтәреп кенә калмый, аны яңа яктан ача. Татар укучысы өчен М.Мутин идеаллаштырылган образ булып түгел, тормыштагы тәртипләр белән каршылыкта торучы шәхес, үз-үзе белән, үзенең дөньяга карашлары белән көрәшүче трагик язмышлы кеше буларак ачыла. М.Мутинның ачы язмышын сурәтләү барышында шагыйрь халык кичергән фаҗигале вакыйгаларга да туктала, аның тарихындагы хәлиткеч чорларга басым ясый, шушы вакыйгаларда татарларның үзләренең роле турында уйлана. Әсәрнең кыйммәте дә шунда.

Шагыйрьнең мәхәббәт лирикасында сафлык, матурлык, мәхәббәт, югарыга-биеккә омтылыш, кадерле кешеләр сурәте калка. Мондый шигырь-поэмаларда авыр кичерешләрдән юануны, рухи камиллекне, матурлыкны, гармонияне балачак хатирәләреннән, авылда үткән яшьлек сукмакларыннан, Әнкәсе катыннан эзләгән эмоциональ лирик герой алга чыга. «Кош теле», «Йолдызлы басу», «Әнкәй», «Авылым чишмәсе» һ.б. шигырь-поэмаларында М.Мирза рухи кыйбланы үткәннәрдә, өлкән буынның яшәү рәвешендә таба, авыл мохитен, яшәешен югары күтәрә, туган туфракны ярату, җирсү хисен үзәккә ала.

Әнә шулай «берүзенә бер диңгез» тапкан М.Мирза иҗаты заманның актуаль мәсьәләләрен чарлый, күпсанлы шигырь-поэмалары бүгенге әдәби барышта шәркый традицияләрнең дәвам ителешен, үстерелешен, мәгънәви баетылышын дәлилли һәм шигъриятнең милли нигезләрне, кыйммәтләрне югалтмавы хакында сөйли.

**Нурфия ЙОСЫПОВА,**
*филология фәннәре докторы,*
*Казан федераль университеты профессоры*

# ҖЫР ШИГЪРИЯТЕ АЛИҺӘСЕ



*«Ходай аны бу дөньяга җыр чишмәсе итеп яраткан бит! Кайсы гына җыр текстын укып чыкма, күңелдә яңа көй уяна башлый. Шуңа күрә композиторлар аның тирәсенә елыша».*
*«... Аның матур гына җырлары музыкасы белән отышлы».*

Сибгат Хәким

*«Гөлшат Зәйнашева татар җыр поэзиясенә үзеннән лаеклы өлеш кертте. Аның җырларын халык үз җыры итеп кабул итте, яратты».*

Гариф Ахунов

Шагыйрә, драматург, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе Гөлшат Зәйнашеваның тууына – 95 ел. Аның ярты гасыр дәвам иткән күркәм иҗатын татар халкы, әдәбият, сәнгать, бигрәк тә җыр яратучылар яхшы белә. Халыкчан, күпкырлы оптимистик, популяр әсәрләре белән халкыбыз күңелендә әле дә яши.

Бу язмамда мин күренекле шагыйрәнең туганы буларак, кайбер хатирәләр белән генә уртаклашам. Ә иҗаты белән тирәнрәк танышырга теләгән укучыларга киңәшем шул: Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, доцент Дания Хан кызы Сибгатуллина-Нигъмәтҗанова 2006 елда «Гөлшат Зәйнашеваның җыр шигърияте» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклады. Шул исемдәге монографиясен 2009 елда бастырып чыгарды. Без, шагыйрәнең туганнары, сезнең сәнгатебез өчен бик мөһим хезмәтегезгә ихлас рәхмәтлебез, изге теләкләребезне юллыйбыз.

Гөлшат апа белән безнең туганлык болай. Аның әтисе Хисам (Хисаметдин) абый белән минем әнием Маһруйның (1910–1979) әнисе Фәрхисрур (1884–1971) – бертуганнар. Беренче карашка без ерак кардәшләр кебек күренсәк тә, чынбарлыкта якын туганнар булып, 1953 елдан алып, даими аралашып яшәдек. Чөнки Гөлшат апабыз туган җанлы, киң күңелле, мәрхәмәтле зат иде. Ә шәхсән мин үзем татар әдәбиятын, сәнгатен, җырларын ихлас яратучы, хатыным Венера да шундый калыптан. Шушы уртаклык, какшамас фикердәшлек безне нәселебезнең йөзек кашы, мәшһүр шагыйрә, мөхтәрәм Гөлшат апабыз белән нык якынайтты.

Нәшриятта басылып чыккан һәр китабын (алар 23 булды) Гөлшат апа җылы автограф язып, безгә бүләк итте, ә без ихлас куанып, аны һәрчак кайнар тәбрикләдек. Вафатыннан соң тагын өч калын китап дөнья күрде: «Сайланма әсәрләр» (2006 ел), «Шигырьләр, пьесалар, хатирә» – ике китап 2018 елда, шагыйрәнең тууына 90 ел тулуга мөхтәрәм Президентыбыз Р.Н.Миңнехановның финанс ярдәме белән нәшер ителде.

Минзәлә районында яшәгәндә, 1963 елда безне – Марс һәм Венераны шатландырып, кызыбыз туды. Гөлшат апа киңәше белән аңа Алсу исеме куштык. Шул чакта Гөлшат апа бер генә кичкә безгә килде, без бик шатландык, озак гәпләштек. Ул Минзәлә драма театрына чираттагы яңа пьесасын алып килгән. Дүрт чакрым араны ул кичен, кояш баеганда, юлы-ние белән яңа гына сөрелгән басу аша буразналар таптап, җәяү үткән. Соңыннан сөйләде: «Буразналар» җырының сүзләре күңелендә шул чакта, басуда туган икән. Күренекле композитор Җәүдәт Фәйзи аңа дәртле, моңлы көй язды, оста җырчылар башкаргач, ул популяр җыр булып китте.

Гөлшат Хисам кызы Зәйнашева 1928 елның 13 гыйнварында ТАССР Чаллы кантоны (хәзер Тукай районы) Иске Теләнче авылында биш балалы игенчеләр Хисам һәм Әнвәр Зәйнашевлар гаиләсендә өченче бала булып дөньяга килә. Теләнче елгасы буендагы Чаллы – Сарман юлының 39 нчы чакрымында урнашкан бу кечкенә матур татар авылында 1926 елда 366 кеше яшәгән.

Зәйнашев Хисамның (Хисаметдин 1896–1936) әтисе Хөснетдин (1848 елгы) Россия армиясендә озак еллар солдат хезмәтендә була, 29 яшендә рус-төрек сугышында (1877-1878) катнаша, батырлыгы өчен алтын медаль белән бүләкләнә һәм авылына кайта. Бай Хәлфин Йосыф кызы Хәлимәгә өйләнә, ә кәләш тузган, ямьсез өйгә мул бирнә белән килә. Хөснетдин – елгыр, булдыклы кеше була, игенче, мал-туар асрый. Тиз арада бирнә акчасына ике катлы мәһабәт йорт җиткерә. Беренче кат кызыл кирпечтән салына, анда кибет һәм шуңа тоташ склад урнаштырыла. Икенче катта нарат бүрәнәдән киң, күп тәрәзәле, якты торак йорт төзелә. Булачак шагыйрә Гөлшатка бабасы салган шушы кояшлы өйдә туарга насыйп була. 1940 нчы елларда ул йортта мин дә берничә мәртәбә кунак булдым. Фәрхисрур әби (Хөснетдин хаҗи кызы) безнең 3 чакрым ераклыктагы Иске Дөреш авылыннан мине (6 яшьтә) ияртеп, өч баласы белән тол калган Гыйная апа янына бара идек. Аның ире – Хисамның бертуган абыйсы Әгъләметдин Ватандашлар сугышында Кызыл Армия сафларында катнаша һәм һәлак була. 2022 елның сентябрендә кызым Алсу белән без Гөлшат апа туган авылда булдык, йорт нигезен фотога төшердек. Беренче каттагы кирпеч кибет һәм корылма әле исән, ә икенче каты инде сүтелгән.

Хөснетдин хаҗи гаиләсендә 7 кыз, 2 малай туган. Чибәр кызлар төбәкнең төрле авыл егетләренә кияүгә чыгып таралыша, ә төп йортта, әтисе янында төпчек улы Хисам Зәйнашев кала. Ул Зәй төбәге, Биш Субаш авылы инсаны Хәмәтҗан кызы Әнвәргә өйләнә, гаиләдә 4 кыз (өченчесе Гөлшат), бер малай дөньяга килә. Хисам абый оста гармунчы, шигырь ярата, әңгәмәдәше белән сөйләшкәндә, шигъри җөмләләр әйтә. Үзе бик булдыклы, хезмәт сөючән крестьян, кулыннан бөтен эш килә. Кардәше Нәҗип абый Гөлшат апага берчак әйтә: «Гөлшат, син әтиеңә охшаган, ул да шигырь белән сөйләшә иде», – ди. Хуҗабикә Әнвәр апа (әнисе) һәрчак моңланып, җырлап эшләргә ярата. Әти-әнисенең шундый күркәм гадәтләре кечкенә Гөлшатка да күчкән, күрәмсең.

1917 елгы Октябрь түнтәрелешеннән соң совет хакимияте хосусый сәүдәне катгый тыя, Хөснетдин Зәйнашевның кибетен тартып алып, сельпо дигән оешмага тапшыра. Барлык кирәк-яракны Хөснетдиннең универсаль, бай кибетеннән сатып алып көн күргән авыл халкы кыен хәлдә кала, чөнки күп тауарлар дефициткә әйләнә. Сәүдәне тыйса да, Зәйнашевлар совет хакимиятенә каршы булмый, ул вәгъдә иткән якты киләчәккә ышанып, зур өметләр баглап, тырышып эшлиләр. 1929 елда колхоз оештыралар, гаилә аңа кушыла, атсыз, мал-туарсыз, авыл хуҗалыгында кирәкле эш коралларсыз кала, аларны колхозга тапшыра. 1930 елдан хәлле крестьяннарга «кулак» дигән ярлык тагып, аларны аяусыз репрессияләү киң колач ала. Бу кара исемлеккә 82 яшьлек Хөснетдин хаҗи да эләгә. НКВДның ике башкисәре килеп, аны Соловкига сөргенгә озатмакчы булалар. Хисам абый, әтисен кызганып, юлда ук үләчәк дип, аны өендә калдыруны сорый. Аның урынына үзем китәм, ди. Ягъни үзе теләп, Соловкига китә. Бу турыда сөйләгәч, күпләр ышанмый, ничек инде бер гаепсез кеше үзе теләп сөргенгә китә, диләр. Хисам абыйны 1930 елның 6 мартында кулга алып, канунсыз, мәрхәмәтсез «өчлек» 27 майда РСФСР Җинаятьләр кодексының 58-10 маддәсе нигезендә нахак гаепли. Совет хакимиятенә каршы пропаганда алып барган, имеш. Бер гаепсез колхозчыны 5 елга хөкем итеп, лагерьга озаталар, Ак диңгез каналын кул белән төзүдә, авыр хезмәттә, ярым ач хәлдә 12 шәр сәгать эшләтәләр. Күренекле язучы Александр Солженицын «Архипелаг ГУЛАГ» әсәрендә «1930 елда Соловкида 50 мең тоткын булган», дип язды. Еллар үткәч, ул канал саега, аңа суднолар керә алмый, файдасызга әйләнә. Меңнәрчә, ун меңнәрчә халык шул утрауда һәлак була, каберләре дә билгесез кала. Бу җанкыйгыч лагерьда татар халкының мәшһүр уллары михнәт

чигә: Мирсәет Солтангалиев, Һади Атласи, Бакый Урманче, аның бертуган энесе Һади Урманче (һәлак була). Сәгыйть Сүнчәләй – шагыйрь, большевик, Ватандашлар сугышы вакытында лагерьда атып үтерелә.

Хисам абый күп җәфалар чигеп, хөкем срогын тутырып, капчыгына Сталин рәсемле Мактаулы кызыл кәгазьләр салып, 1935 елда авылына кайта, әмма үз йортына керә алмый. Чөнки әтисен, 4 баласын, хатынын ул өйдән куып чыгарганнар («халык дошманы» гаиләсе бит), сугышта һәлак булган бертуган абыйсы Әгъләметдин гаиләсенә биргәннәр. Авылында, гаиләсе янында хәл җыярга да өлгерми, Хисам абыйны тагын кулга алып, икенче мәртәбә шул ук сөргенгә озаталар. Бу юлы инде әйләнеп кайтмый, һәлак була. Ул киткәч, 1935 елда бишенче бала – Фатыйма туа. 40 яшьлек акыл иясе, эшчән, булдыклы Хисам абыйның кайчан, ничек һәлак булуы, кайда җирләнүе турында мәгълүмат юк, НКВД аны яшерде. Хәтта мәетләрне дә ГУЛАГ үзенеке санаган, гаиләсенә, туганнарына белдермәгән, тиешенчә җирләргә рөхсәт итмәгән.

1989 елда кызы Гөлшат мөрәҗәгатенә әтисенең репрессия корбаны буларак аклануы, реабилитация турында Татарстан прокуроры К.Ф.Әмиров имзасы белән белешмә алды. Дәүләт биш бала атасын үтергән өчен 8 мең сум (!) акча түләде, Гөлшат апа аны бертуганнарына өләште, үзенә бер тәңкәсен дә алмады.

Берсеннән-берсе кечкенә дүрт бала белән йорт-җирсез, ач-ялангач, хәерче хәлендә тол калган әнисе ике яшьлек Гөлшатны Хисам абыйның бертуганы, Минзәлә районы Югары Тәкермән авылында яшәүче баласыз Маһнуй (тулы исеме Өммеһани) апага асрамага бирергә мәҗбүр була. Гөлшат бу гаиләдә ачлы-туклы үсә, апасының ире, эш сөймәүче Хөрмәкәй эчүгә сабыша, еш тавыш чыгара, мәктәптә бик яхшы укучы балага дәрес хәзерләргә комачаулый.

Башлангыч мәктәптән соң, Гөлшат күрше Хуҗәмәт авылына 5 чакрым җәяү йөреп белем ала. Аннан соң 1942–1945 елларда Минзәлә педагогика училищесында 14 яшеннән үз көнен үзе күреп, бик яхшы укый. Кешеләргә идән юып, бәрәңге бакчаларын казып җан асрый. Берничә кыз янгын сүндерүчеләр каланчасы астындагы җылытылмый торган бүлмәдә яшиләр. Кышкы салкыннарга түзәр чама калмагач, Гөлшат кирпеч ватыклары җыеп, кечкенә генә «голландка» (буржуйка) миче чыгарып куя. Моңа янгын сүндерүче абыйлар шакката, ә иптәш кызлары чиксез шатлана. Гөлшат бик елгыр, җитез кыз була, гел «бишле»гә укый, үзешчән сәнгатьтә актив катнаша, сәхнәдә җырлый, шигырьләр сөйли; үзе дә шигырьләр яза башлый, алар дивар газетасында урын ала һәм район матбугатында басылып чыга. Ә НКВД Гөлшатны даими күзәтеп тора. Педучилищедагы аңа кагылышлы барлык документларны җыеп ала. 2011 елда көллият музеенда шагыйрәгә багышланган экспозиция булдырырга ниятләгән директор аларның берсен дә тапмады.

1945 елда Гөлшат, кабул итү имтиханнарын уңышлы тапшырып, Казан дәүләт педагогика институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. Бик тырыш, пөхтә студентка була, бик яхшы укый, үзешчән сәнгатьтә актив катнаша, сәхнәдә моңлы итеп җырлый, шигырьләр сөйли. Аны шагыйрә, җырчы дип йөртәләр. Курста иң алдынгы, актив студентка буларак, Габдулла Тукай исемендәге дәрәҗәле стипендиягә лаек була.

Әмма ул – «халык дошманы» кызы... Һәм менә бервакыт аны институт директоры Йосыф Туишев кабинетына чакыртып, тетрәндергеч хәбәр әйтә: «Гөлшат, мин сезне институттан чыгарырга мәҗбүр, НКВД таләп итә». Гөлшатны «халык дошманы» кызы булуда һәм институтка кергәндә, әлеге фактны яшерүдә гаеплиләр. Ике яшьтә әти-әнисеннән аерылуга дучар ителгән ятим бала әтисен бөтенләй хәтерләми. Шуңа карамастан, ул совет власте өчен куркыныч кеше булып чыга.

Бу җан әрнеткеч вакыйганы яшь кыз бик авыр кичерә, әмма югалып калмый. Шунда ук Казан театр училищесына укырга керә. Берничә айдан соң институт директоры Гөлшатны эзләтеп таба һәм яңадан укуын дәвам итәргә мөмкинлек бирә. (Курку белмәс, әхлаклы, бик миһербанлы кеше булган Йосыф ага).

Институтны тәмамлагач (1949 ел), бик җаваплы эшләрдә хезмәт итә Гөлшат апа. Татарстан радиосында 16 ел дәвамында башта әдәби-драматик, соңрак музыкаль тапшырулар мөхәррире була. Биредә ул язучылар, композиторлар, күренекле сәнгать эшлеклеләре белән аралаша, үзе дә иҗатка кереп китә, җыр текстлары, шигырьләр яза. Аннан соң 21 ел Татарстан китап нәшриятында мөхәррир, кадрлар бүлеге башлыгы, язучыларның Тукай клубы директоры.

Матбугат йортындагы китап нәшриятында мөхәррир булып эшләүче Гөлшат апа белән мин 1953 елда, Казан авыл хуҗалыгы институтына укырга кергәч күрештем. Ул чакта алар: кызы Асия, ире Мөхәммәт белән Некрасов урамында ярым подвалдагы бик кечкенә бүлмәдә яшиләр иде. Ә мин якын гына Маяковский урамында якташым Лотфикамал апаларда көн күрәм, Гөлшат апаларга баргалыйм. Бүлмә кысан булса да, киң күңелле апам мине якты чырай, тәмле чәй белән каршы ала, тормышым, укуым белән кызыксына. Кайчак җыелышка китә, мин Асияне карыйм, дәрескә әзерләнәм. Бервакыт химиядән дәрес әзерләп утырганда, 3 яшьлек Асия миннән: «Бу нинди китап?» – дип сорады. «Химия», – дидем. Шуннан соң ул мине «Химия абый» дип йөртә башлады, килгәнне тәрәзәдән күрсә: «Химия абый килә!» – ди икән. Гөлшат апаларга без мәктәптән үк сабакташым, дустым, музыка училищесы студенты Илһам Шакиров белән дә баргаладык, шул танышу алга таба аларның иҗади дуслыгына китерде. Студент вакытта мин Матбугат йортындагы Г.Тукай исемендәге язучылар клубына җомга кичләренә бик теләп йөрдем, Гөлшат апа – аның директоры, үзе чакыра иде.

Бервакыт (1950 нче еллар) Гөлшат апа иҗат иткән «Рамай» пьесасын Язучылар берлегенең драматургия секциясендә тикшереп фикер алыштылар. Ул җыелышка Гөлшат апа мине дә дәшкән иде, кызыксынып тыңлап утырдым. Утырышны күренекле драматург Таҗи Гыйззәт алып барды. Язучылар Мирсәй Әмир, Әнәс Камал чыгыш ясап, әсәрне хупладылар. Башкалар җитешсезлекләрен күрсәтеп, тагын да камилләштерү юлларын атадылар. Гөлшат апа ул әсәрне яңабаштан язып, театр сәхнәсенә менгерде.

Мин 1958 елда институтны уңышлы тәмамлап, дәүләт сортлар сынау участогында мөдир булып эшли башладым. Бәхетемә, ул үз авылыбызда – хәзерге Тукай районы Иске Дөреш авылында иде. Гөлшат апа белән элемтәбез өзелмәде, 1959 елда ул безгә килде. Туган-тумачалары – безнең гаилә белән шатланып күрешкәч, хәл-әхвәл белешкәч, чәйдән соң: «Марс энекәш, басуларыңны күрсәт әле миңа», – диде. Без аның белән тарантаска утырып, басу-кырларга юнәлдек. Август аеның кояшлы, матур көне, игеннәрне урып-җыю бара, кызу эш өсте. Гөлшат апаны бөтен нәрсә кызыксындыра. Уңдырышлы басуларда күкрәп үскән бодайларга соклана, игенчеләрне мактый. Мин әбәткә туктаган комбайнчыларга шаяртып: «Менә, егетләр, сезнең турыда җыр язарга Казаннан шагыйрә Гөлшат Зәйнашева килде, сынатмагыз!» – дим. Бу экскурсиядән ул канәгать калган иде.

1960 нчы еллар башында Гөлшат апа сүзләренә композитор Мансур Мозаффаров кабатланмас моңлы көй язып, консерватория студенты Илһам Шакиров тыңлаучыларның күңел кылларын тибрәндереп башкарган «Менәргә иде Урал тауларына» җырының текстын өлкән язучылар А.Шамов, Г.Әпсәләмов, Ф.Хөсни, Н.Дәүли, З.Мансур нигезсез пессимизмда гаепләделәр. «Урал таулары биек түгел бит, коммунизм төзегән чорда аларга менәргә хыяллана Гөлшат Зәйнашева, менсен!», имеш. Бу исә шигырьне бары тик сәяси караштан гына бәяләү иде. Бу турыда Гөлшат апа ачынып язды: «Менәргә иде Урал тауларына» җырым өчен, йа Хода, күпме эләкте миңа?!» Яшь, хатын-кыз шагыйрәгә ярдәм итәсе урынга коммунизм әкияте каннарына сеңгән олы язучылар аны һәр җыелышта шул бер шигыре мисалында урынсыз теткәлиләр, хәтта матбугатта да усал тәнкыйть итәләр. Өлкән язучы Нәби Дәүли 6 ел шул популяр җыр сүзләренә, аның авторына каршы көрәшә. Әмма Татарстан язучыларының шагыйрә Гөлшат Зәйнашеваны СССР Язучылар берлегенә әгъза итеп алу тәкъдимен караган җыелышында чыгыш ясап, фикере үзгәрүе, ялгышын тануы турында әйтә, шагыйрәне Язучылар берлегенә тәкъдим итүне хуплый.

Гаҗәп һәм сәер бит – тәбәнәк Урал таулары коммунизм төзергә нык комачаулыйлар

икән! Әмма җырны халык җылы, яратып кабул итте, аны һәм шигырь авторын яклаучылар, бу турыда мәкаләләр язып бастыручылар да аз булмады. Нәтиҗәдә, әлеге моңлы җыр әле дә аһәңле, горур яңгырый, чөнки мәшһүр җырчыларыбыз аны бик теләп башкара, җыр сөючеләр исә ләззәтләнеп тыңлый! Шул хәсрәт тәнкыйтьчеләргә багышлап Гөлшат апа:

*«Елмаеп үтик тормышның авыр сукмакларыннан:*
*Саклагыз мине, дусларым, «Тәнкыйть» тукмакларыннан!»*

– дип язды үзенең «Адәм көлкесе» җыентыгында.

Гөлшат апаның консерватория студенты Илһам Шакировка, башка яшь җырчыларга, сәнгатькярләргә ярдәме күп тиде. Матбугатта аның сәләтле җырчылар турында күләмле язмалары, очерклары чыкты, аларга үсү, популярлашу өчен киң юл ачылды. «Гөлсем Сөләйманова» (1957); «Гөлшаһидә җырын кем җырлый?» (Флёра Сөләйманова турында, 1999); «Сагынулы бинийая» (Рафаэль Ильясовка багышланган, 2003) һ.б. һ.б.

Күп хезмәтен, нервларын сарыф итеп, Гөлшат апа мәшһүр композитор Сара Садыйкова турында өч китап бастырып чыгарды: «Сара Садыйкова» (1987), «Сагыналар сине чын дуслар» (1991), «Калфаклы сандугач» (2002).

Күренекле җырчы Әлфия Авзалова язмышы турында язган китабы «Үзем турында үзем» дип атала иде, исемдә, 1996 елда нәшер ителде, авторлыкны әсәр герое җырчыга бүләк итте. Гөлшат апа үзе турында китап язарга уңайсызланды, тыйнаксызлык була, диде. Бик тыйнак, хәтта артык тыйнак зат иде яраткан апабыз. Күңел биреп укысак, аның тормыш юлын иҗат иткән әсәрләреннән белеп була.

Гөлшат апа кинорежиссёр Илмас Үтәгәнов белән «Салих Сәйдәшев» документаль фильмын иҗат иттеләр. Телевидение аны композиторның нәкъ юбилей көннәрендә тамашачыга күрсәтте, уңай бәяләнде. Композитор Сара Садыйкова турындагы «Моңсара» (1996), «Моңнар дөньясына сәяхәт» (2006) документаль фильмнарына сценарийларны Гөлшат апа язды. «Тузган торактан күчкәндә» күп серияле телевизион фильмы аның иҗади җимеше, ул тамашачыларга, беренче Президентыбыз М.Ш.Шәймиевкә дә ошаган, аның исеменнән сценарий авторы Гөлшат Зәйнашевага 50 мең сум бүләк тапшырылды.

Гөлшат апа үзенең фамилиясе нишләп Зәйнашева икән дип гаҗәпләнә, аптырый иде. Әтисе – Хисам, бабасы Хөснетдин бит ләбаса! Бервакыт миңа: «Марс энекәш, борын заманда Казан ханының бер киңәшчесе Зәйнаш исемле булган икән. Минем фамилиям әллә шуңардан килә микән?» – диде. Мин: «Гөлшат апа, әгәр чынбарлыкта шулай булса, Президент Минтимер Шәрипович сиңа мул итеп, персональ пенсия билгеләр, Алла боерса!» – дидем. Апам рәхәтләнеп көлде. Сөйләвенчә, Маһнуй апа аңа: «Зәйнашева фамилиясе бик абруйлы, алыштырма!» – дип әйткән булган. Татарстан язучыларының бер җыелышында Гөлшат апа Сарман егете, шәҗәрәләр төзүче, шагыйрь Дамир Гарифуллинга үзенең гозерен әйтә. Дамир архивларда казынып, шагыйрәнең 7 буынга кадәрге шәҗәрәсен төзи һәм шуны ачыклый: нәселнең Гөлшат апага кадәр булган 5 нче буынында чыннан да 1769 елда туган Зәйнагетдин исемле бик булдыклы, абруйлы зат булган. Авылдашлары аның исемен кыскартып, «Зәйнаш» дип йөрткәннәр икән. Шуннан башланган Зәйнашевлар фамилиясе. Кызганыч, бу турыда Гөлшат апа белә алмыйча, 2005 елда дөнья куйды, чөнки Дамир аның шәҗәрәсен 2013 елда гына эшләп бетереп, кияве Рафаил Шакирьяновка тапшырды. Шәҗәрә Гөлшат Зәйнашева музеенда саклана, күчермәсен без дә алдык.

Гөлшат апа шәфкатьле, мәрхәмәтле, ярдәмчел зат иде. Хезмәттәшләре, иҗат юлында аралашкан сәнгатькярләр, тормыш юлында, ялда, гастрольләрдә очрашкан гап-гади кешеләр, концерт, спектакльләр караган тамашачылар аны гел яхшы яктан искә алып сөйлиләр. Шагыйрәнең башкалар турында кайгыртуы, гамәли ярдәмен раслый торган берничә мисал китерәм.

Гөлшат апа мәшһүр җырчы Әлфия Авзалованың яшь баласы белән, салкын, юеш, башка кеше фатирында яшәвен филармония җитәкчеләренә җиткерә, аңа бер бүлмәле әйбәт торак бирдерә. Гаилә ишәйгәч, өч бүлмәлене алырга ярдәм итә.

Гөлшат апаның авылда урын өстендә яткан, аяныч хаста хәлендә дә язучы, шагыйрь булырга хыялланган Фәнис Яруллинга ярдәме гыйбрәтле һәм мактауга лаек изге гамәл, үзе бер кыйсса. Фәнис Яруллин турында ул 1962 елда «Татарстан яшьләре» газетасыннан укып белгән, күреп таныш булмаса да, аның көчле рухына сокланып, шундук ярдәм кулын сузган. Җылы хатлар язып, язучы булу өчен нинди әсәрләр укырга, кемнән үрнәк алырга һ.б. файдалы киңәшләрен биргән. Күренекле язучыларның китапларын сатып алып, Фәнискә почта аша җибәргән. Соңрак үз әсәрләре җыентыкларын да, җылы автограф язып бүләк иткән. Яшь, башлап язучы күп шигырьләр, пьесалар иҗат иткәч, Гөлшат апа аларны игътибар белән укый, әйбәтләрен уңай бәяли, чиле-пешлеләрен дустанә тәнкыйтьләп, төзәтү, камилләштерү юлларын күрсәтә.

Фәнис җыр шигърияте остасы Г.Зәйнашевадан җыр язу серен ачуын сораган. Гөлшат апаның җавабы: «Җырның меңләгән серләреннән берсе – чын күңелдән, чын йөрәктән язу... Җырда тирән фикер гади генә, табигый генә әйтелергә тиеш... Җыйнап әйткәндә, җыр ул – поэзиянең иң авыр, иң нечкә бер тармагы». Язмыш Гөлшат апа белән Фәнис Яруллинны 1965 елда «Бәкер» шифаханәсендә очраштыра, алар анда бер ай дәвамында дәва алып, ял итәләр. Халык шагыйре Фәнис Яруллин остазы Гөлшат Зәйнашевага олы ихтирамы һәм ихлас зур рәхмәтен «Сөенечләр бүлешү» әсәрендә тәфсилле язып белдерде.

Гомеренең күп өлешен Гөлшат апа кысан, тузган торакларда яшәп үткәрде. Ниһаять, 1990 еллар башында аңа Мусин урамында ике бүлмәле «хрущёвка» бирделәр. Фатирыннан күчәргә җыенып йөргәндә, таныш түгел бер ир кеше килеп, аннан бушаячак бүлмәсен күрсәтүне сорый. Бу кешене район башкарма комитетыннан җибәргәннәр икән, әле генә төрмәдән чыккан. Фатирны карагач, ул: «Юк, мин мондый фатирга риза түгел», – дип чыгып китә. Ә Гөлшат апа үз вакытында бик шатланып килгән иде бирегә.

Күп еллар дәвамында халкыбыз күңеленә хуш килгән олуг һәм күркәм иҗаты белән шагыйрә Гөлшат Зәйнашева инде күптән Г.Тукай исемендәге премиягә лаек иде. Әмма Язучылар берлеге дә, башка оешмалар да ләм-мим, тәкъдим итүче юк. Бу җаваплы, зарури эшкә үзем алындым. Инде 17 ел мин укытучы, доцент булып эшләгән Казан авыл хуҗалыгы институты (хәзер аграр университет) коллективы исеменнән 1990 елда шул мәртәбәле премияне бирү комитеты рәисе мөхтәрәм М.Х.Хәсәновка хат яздык, аны институт җитәкчеләре, укытучылар, студентлар имзалады. Безнең мөрәҗәгатькә нигез, җитди сәбәп бар иде. Чөнки үзенең иҗаты белән Гөлшат апа безнең күпсанлы студентларга, укытучыларга бик таныш һәм якын булды. Ул елларда институт коллективы, студентлар белән очрашуларга, әдәби-музыкаль кичәләргә без язучыларны, артистларны чакыра идек. Гөлшат апа аларга бик теләп килә, кичәне оста итеп, юмор белән үзе алып бара, тамашачыларны көлдерә дә, уйландыра да иде. Ә студентларыбызның күпчелеге авыллардан килгән, мәктәпләрдә татарча укып үскәннәр. Гөлшат Зәйнашева җырларын алар аеруча яратып, үзләре дә җырлыйлар. Безнең тәкъдим бик вакытлы булып чыкты, 1991 елда Гөлшат Зәйнашева ул мәртәбәле премиянең лаеклы лауреаты булды. Җырлар җыентыгы өчен Г.Тукай исемендәге бүләк тапшыру тарихта беренче тапкыр иде!

Гөлшат апа бик бала җанлы кеше иде, кызы Асияне әйбәт тәрбияләп, югары белемле музыкант булырга ярдәм итте. Үзенең һәм туганнарының гына түгел, гомумән, барлык балаларны ихлас яратты, аларга игътибарлы, ягымлы булды. Гимназияләрдә, мәктәпләрдә укучылар белән очрашу кичәләрендә бик тиз уртак тел таба, бергәләп, күмәк җырлауларына, сорау-табышмакларга җавап бирүләренә ирешә, сөендерә, көлдерә. Балаларга кызык кирәк бит, алар шатлана, канатлана. Гөлшат апа балалар өчен 70 шигырь һәм җыр иҗат итте, 10 китап бастырып чыгарды: «Асия» (1973), «Кояш гомере» (1975), «Җырчы миләш» (1982), «Бөҗәкләр концерты» (1984), «Гимназиядә

дуслаштык» (1996), «Әбиемне яратам» (1997) һ.б. һ.б. Казан курчак театрында «И, кызык Шүрәле!» пьесасы күрсәтелде, ул балаларга ошады.

1994–2004 елларда Гөлшат апа һәм композитор Гөлнара Беляева балалар өчен илледән артык җыр иҗат иттеләр. Шулардан утызы, ноталар белән «Көмеш тавышлар» исемле 125 битле китап итеп, 2008 елда, Гөлшат апаның вафатыннан соң нәшер ителде, тиражы 3 мең данә тәшкил итте. Бу дәртле, моңлы җырларны шагыйрәнең кызы, музыка укытучысы, хор дирижёры Асия Зәйнашева үзе оештырган балалар «Айсылу» вокаль ансамбле репертуарына кертте. Режиссёр Нурания Җамали бу ансамбльнең югары сәнгать дәрәҗәдәге чыгышларын файдаланып, «Без – табигать дуслары» исемле күп серияле музыкаль фильмнар, спектакльләр иҗат итте. Татарстан телевидениесе аларны зәңгәр экраннарга чыгарды.

Балалар өчен күп күркәм шигырьләр, җырлар язган Гөлшат Зәйнашеваның тормыш юлы һәм иҗаты «Балачак әдипләре» китабында (2002) һәм «Балачак энциклопедиясе»ндә (2012) әйбәт яктыртылган, фотосурәте дә бирелгән.

75 яше тулган көннәрнең берсендә Гөлшат апаны көчле инсульт аяктан екты, ул ике елдан артык каты авырды. Хастаханәдә, санаторийда дәваланды, әмма табиблар ярдәм итә алмады. Гомеренең соңгы көннәренә кадәр акылында булды, кыенлык белән булса да сөйләшеп ятты. Яныннан кеше өзелмәде, балалары, туганнарыннан тыш, дуслары аның хәлен белергә, кизү торырга килделәр.

Барчабызны тетрәндереп, якыннарын, чын дусларын тирән кайгыга салып, Гөлшат апабыз 2005 елның 1 нче апрелендә арабыздан китеп барды. Ул матәм көнне Татарстан радиосы иртәнге тапшыруларын шагыйрәнең «Китмә, сандугач» җыры (Рөстәм Яхин музыкасы) белән башлап җибәрде һәм кайгылы хәбәрне халыкка җиткерде. Мәрхүм белән хушлашу мәрәсиме Г.Камал театрында узды, театр Гөлшат Зәйнашеваны соңгы юлга озатырга килгән халык белән тулы иде. Гөлшат Зәйнашеваның кабере халкыбызның бөек шәхесләре Г.Тукай, С.Сәйдәшев, С.Садыйкова, И.Шакиров һ.б. белән бер зиратта. Шактый зур гранит һәйкәл-кабер ташына шагыйрәнең васыяте уелган: «Кешеләр, яратыгыз бер-берегезне, ярату озайтыр гомерегезне!»

Гөлшат апабыз арабыздан китте, әмма аның мәңгелек җәүһәрләренә әйләнгән моңлы, күркәм җырлары калды. Мәшһүр шагыйрәнең вафатыннан соңгы елларда аның иҗатын пропагандалау, якты исемен мәңгеләштерү җәһәтеннән шактый күп күркәм гамәли адымнар ясалды. Изге һәм саваплы ул чараларны тормышка ашыруда кызы Асия, кияве Рафаил, туганы Марс Гаитов, дуслары Әзһәр Хөсәенов, Дания Сибгатуллина-Нигъмәтҗанова; иҗатын яратучылар – Сания Минкина, Алия Шәрипова, Рузинә Галимҗанова һ.б. актив, даими эш алып баралар. 80 еллык юбилее вакытында Минзәлә, Тукай, Алабуга һ.б. районнарда «Дулкыннар» дип аталган республикакүләм фестиваль шаулап үтте. Минзәлә районында 2012 елдан башлап Гөлшат Зәйнашева иҗатына багышлап уздырыла торган «Кояш гомере телим мин, Минзәләм, сиңа» исемле әдәби-музыкаль җыен бәйрәм төсен алды. 2013 елның апрелендә Казан федераль университетының Яр Чаллы педагогика институтында узган әдәби-музыкаль кичә бик җылы, истә калырлык итеп оештырылган иде.

Гөлшат апаның бала һәм яшүсмер чагы үткән Югары Тәкермән авылында (Минзәлә районы) шушы төбәктән чыккан өч күренекле шагыйрьнең тормыш юлы, иҗатына багышланган музей булдырылды. Анда шагыйрә Гөлшат Зәйнашева, шушы авыл тумасы шагыйрь Марс Шабаев, Габделхәй Сабитов турында тулы мәгълүмат бар. Авылның бер урамы һәм мәдәният йорты Г.Зәйнашева исемендә. Ул укыган мәктәпләрдә, уку йорты һәм Минзәлә районы музейларында шагыйрәгә багышланган экспозицияләр бар. Бу изге, саваплы гамәлләрне башкаруга район хакимияте башлыгы Айдар Сәлахов, авыл җирлеге җитәкчесе Алия Шәрипова, шагыйрәнең кияве (кызы Асия Зәйнашева ире) Рафаил Шакирьянов нык булыштылар.

Казан шәһәре хакимияте карары нигезендә 2011 елда Казанның бер урамына

Гөлшат Зәйнашева исеме бирелде. Шул елда Татарстан китап нәшрияты шагыйрә турында истәлекләр китабы чыгарды (төзүчеләре Әзһәр Хөсәенов, Рәмзия Шакирова). Гөлзадә һәм Фәйзерахман Камаловларның «Фаиз» киностудиясе 2013 елда шагыйрәнең тормыш һәм иҗатына багышланган «Гөлшат Зәйнашева» дип аталган телевизион фильм төшерде, анда мин дә хатирәләремне сөйләдем.

«Татар энциклопедиясе»ндә (2005), «Минзәлә энциклопедиясе»ндә (2001), «Заслуженные люди Тукаевского района» китабында (2016) Гөлшат Зәйнашеваның тормыш юлы һәм иҗаты турында кызыклы, тулы мәгълүмат һәм фотосурәтләре бирелгән.

2018 елда, шагыйрәнең тууына 90 ел тулгач, Татарстан Мәдәният министрлыгы Татар дәүләт филармониясе концерт залында күренекле җырчы-артистлар катнашында Гөлшат Зәйнашева иҗатына багышланган зур концерт оештырды. Зал тамашачылар белән шыгрым тулды, һәр башкарылган җыр аларның күңеленә хуш килде, көчле алкышларга күмелде.

Казанның Хөсәен Мәүлетов урамындагы 13 нче китапханә мөдире, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, милләтпәрвәр Сания Минкина башлангычы һәм китап укучылар теләге белән 2006 елда биредә шагыйрә, драматург Гөлшат Зәйнашеваның музей бүлмәсе ачылды. Сания ханым – тынгысыз зат. Биш мең укучы йөри торган китапханәне ул татар әдәбияты, мәдәнияте үзәгенә әверелдерде. Биредә әледән-әле әдәби-музыкаль кичәләр үткәрелә, аларга күренекле язучылар, артистлар, музыкантлар, кызыклы шәхесләр чакырыла. Тик 32 ел эшләгән китапханә бинасы инде шактый таушалган, тузган, җитмәсә уку залында кышларын бик салкын, чөнки ул начар җылытыла иде. Сания ханым Минкина әлеге вазгыять турында чаң сугып, күп мәртәбә хакимияткә мөрәҗәгать итте, төзекләндерү зарурлыгын кабыргасы белән куйды. Тамчы тама-тама, таш тишә, ди мәкаль. Ниһаять, 2021 елда Казан мэриясе бинаны төзекләндерү турында карар чыгарды. Шәһәрнең капиталь төзекләндерү һәм реконструкцияләү идарәсе Марат Сәмигуллин җитәкчелегендә 9 айда шактый күләмле бу эшне югары сыйфатлы итеп башкарды. Китапханә 2022 елның май аеннан ялтырап торган матур һәм уңайлы бинада эшли башлады. Шунысы куанычлы: шагыйрә Гөлшат Зәйнашева музей бүлмәсе дә хәзер гаҗәеп күркәм, үзенә тартып тора. Ә китапханәгә аның популяр җырыннан алып, «Сандугач» исеме бирелгән. Төрле заллары, мәһабәт концерт залы булдырылды, китапханәгә яңа китаплар сатып алу өчен шәһәр бюджетыннан 12 млн. сум акча бүленгән. Тирә-ягына декоратив үсемлекләр, агачлар утыртылган, мәрмәр плитәләр җәелгән ишегалды мәйданчыгы күзләрне камаштыра, сокландыра. Шушы елның август аенда без кызым Алсу белән биредә булдык, китапханә мөдире Рузинә Радик кызы Галимҗановага музей өчен шактый күп экспонатлар бүләк иттек. Мөхтәрәм Сания ханым Минкина авыру сәбәпле, үз теләге белән апрель аенда эшеннән киткән, «Сандугач»ны яшь мөдиргә тапшырган.

2022 елның 30 августында – бәйрәм көнне «Сандугач» китапханәсен, Г.Зәйнашева музеен, бинаның тирә-ягын Татарстанның Президенты Рөстәм Нургали улы Миңнеханов карап, канәгать булып китте.

Гөлшат Зәйнашева үзенең күпкырлы, бай иҗаты белән татар теле, татар мәдәнияте һәм сәнгате сагында торды. Милләтебез һәм тарих алдында Гөлшат Зәйнашеваның йөзе ак, вөҗданы пакь булды. Язмышы яралы булса да, Гөлшат апа дөнья ямен, яшәү кадерен белеп, тормышка гашыйк булып гомер итте. Тормыш аны төрлечә, ә кайчакта аяусыз сынады. Әмма ул бөгелмәде, сынмады. Малга, байлыкка кызыкмады. Аның байлыгы – табигать биргән мул таланты, сәламәтлеге, гаиләсе, дуслары, халык мәхәббәте булды, ул бәхетле иде!

**Марс ГАИТОВ,**
*икътисад фәннәре кандидаты, Татарстанның атказанган икътисадчысы, Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Дәүләт премиясе лауреаты.*

# ТАТАРСТАННАН ЧИТТӘ – ТАТАР ГАЛИМНӘРЕ ДИНАСТИЯЛӘРЕ



Төбәктә билгеле, абруйлы шәхес гаиләсендә туып-үсеп, тормышта үз урыныңны табу, алай гына да түгел, зур уңышларга ирешү җиңелме, әллә авырракмы? Читтән күзәтеп торучылар «җиңелрәк» диярләр. Уку, белем алу, үзең теләгән өлкәдә көчеңне сынау өчен – бөтен шартлар, янында киңәш сорарлык акыллы, тормышның сынаулы юлларын узган абруйлы якын кешеләрең булу ни тора! Әмма минем фаразлавымча, мондый язмышка ия кешеләр «авыррак» диярләр! Чөнки алар өчен үзләрен якыннары белән чагыштырып бәяләү планкасы кечкенәдән бик югары куела. Әле гаилә һәм тирә-якта мәшһүр якыннарың алдында эчке җаваплылык та бар бит!

Укучылар белән таныштырасы шәхес шундыйлардан – күренекле галимнәр, фикер ияләре, мәгърифәтчеләр династиясенең вәкиле, Башкортстан Фәннәр академиясе академигы (2016), физика-математика фәннәре докторы (1992), профессор (1994), Башкортстан Республикасының 6 нчы чакырылыш Дәүләт Советы – Корылтай депутаты (2018) Рамил Назыйф улы Бәхтизин. Үзе яшәгән төбәктә билгеле гаиләдәге бердәнбер бала булып үссә дә, әтисе юлыннан китми ул. Болары хакында – соңрак, сүзне баштан башлыйк.

Рамил Назыйф улы 1955 елның 30 мартында Башкортстанның башкаласы Уфада туа. Әтисе – Башкортстан Республикасы Фәннәр академиясенең мөхбир-әгъзасы, үсемлекчелек белгече Назыйф Бәхтизин (1927–2007), Россиядә билгеле шәхес, галим, мәгариф һәм фәнне оештыручы.

Гомумән, Бәхтизиннар – хәзер Башкортстанның Илеш районына кергән җирлектә билгеле нәсел. XIX гасыр башына кадәр Тамбов губернасында яшәгән морзалардан, мондагы Югары Аташ авылы янындагы ялан җирләргә килеп төпләнәләр. Столыпинның аграр реформасы башлангач, җирләрен киңәйтергә исәплэп, 1909 елны алар Яңа Аташ авылына нигез сала. Рамил Назыйф улының әтисе нәселе – менә шушы тармактан.

Шунысы кызык: әнисе нәселе дә Бәхтизиннардан булып чыга аның. Ерак бабасы Мохтарулла Салигаскәр улы Бәхтизин Рус-Япон сугышында батырлыклар күрсәтә, Георгий Тәресе кавалеры була. 1917 елдан соң илдә башланган колхозлаштыру, кулакларны сөрү фаҗигасенә дучар булсалар да, гаилә сакланып кала, Уфага күченеп яши башлый.

Бәхтизиннарның бу тармагында да галимнәр, мәгариф хезмәтен гомерлеккә сайлаган шәхесләр шактый. Әйтик, Рамил Назыйф улының әнисе ягыннан икетуганнары арасында Тәгъзимә Кәрам кызы – юл төзелеше техникумында укыткан, Алия Кәрам кызы – химия фәннәре докторы, профессор, Лилия Кәрам кызы – фәннәр кандидаты, Гөлия Кәрам кызы – фән докторы, Таһирә Таһир кызы – инглиз теле белгече, Наил Таһир улы – комсомол өлкә комитетының беренче секретаре булып эшләгән республика җитәкчесе, Корылтай депутаты, фәннәр кандидаты һ.б.

Әтисе ягыннан нәселнең бер буыны – Яңа Аташка нигез салынган вакытта Оренбургтагы танылган «Хөсәения» мәдрәсәсендә укыган Раян Ханбәк улы Бәхтизин (1880–1927) указ алып, авылга имам-хатыйб булып кайта. Шулай яңа авылга иман нуры керә: мәчет төзелә, аның янында җәдит мәдрәсәдә балалар укыту җайга салына. Раянның хатыны Шәмсиямал кызларга белем бирә. Раян мулла үз авылында мәгърифәт тарату белән чикләнми: газета-журналларга мәкаләләр яза, китаплар бастыра. Кызганыч, ул бик иртә, 47 яшендә бакыйлыкка күчә. Әтисе Раян вафат булып 3 ай узгач, гаиләдә бишенче бала булып, Назыйф дөньяга килә.

Авыр заманнар була бу. 1917 ел алып килгән үзгәрешләр һәр гаиләгә кагыла, әмма руханилар гаиләләренә, морзаларга – аеруча. Әниләре балаларын аякка бастыру, укыту өчен тырыша. Бөек Ватан сугышы башлануга, хәлләр тагын да катлаулана: гаиләдәге ике олы малай – Әгъзам белән Әхмәтназ фронтка китә, икесе дә һәлак була.

Никадәр генә авыр булмасын, әниләре белем алуны беренче максат итеп куя. Шуңа да Иске Дөмәй авылында мәктәпне тәмамлаган Назыйф 1946 елны Башкорт авыл хуҗалыгы институтына укырга керә. Аны бик яхшы билгеләренә генә төгәлләп, бер ел Мораптал совхозында (Куергазы районы) баш агроном булып эшли, аннары остазлары чакыруы белән аспирантурага кайта. Республикада сөрүлек җирләрнең сыйфатын билгеләү мәсьәләләре белән шөгыльләнә башлаган галимнәрдән була ул. 1955 елны көлсу урман-дала туфрагының сөренте катламын эшкәртү мәсьәләләренә караган кандидатлык диссертациясен уңышлы яклап, вузда укытырга кала.

Тырыш, акыллы, киң карашлы белгечне тиз күреп алалар: 1961 елны – фән эшләре буенча проректор, аннары ректор итеп билгеләнә. Илдәге авыл хуҗалыгы вузлары ректорлары арасында иң яше була Назыйф Раян улы. Институтны ныгытуга, укыту һәм фәнни-тикшеренү эшен камилләштерүгә зур көч куя: яңа һәм махсуслаштырылган факультетлар (икътисад, умартачылык, авыл хуҗалыгы белгечләренең квалификациясен күтәрү) оештырыла, кафедралар ачыла, заманча лабораторияләр барлыкка килә, студентлар өчен тулай тораклар төзелә, Уфа вузлары арасында беренчеләрдән булып аспирантурадагы белгечлекләр саны арта, агрономия, зоотехника, инженерлык, икътисад һәм ветеринария буенча профильле яклау Советлары ачыла. Моннан тыш, республиканың ерак районнары өчен кадрлар әзерләүгә аерым игътибар бирелә.

Назыйф Раян улы үзе агрономия факультетындагы үсемлекчелек кафедрасы белән җитәкчелек итә, 1978 елны профессор дәрәҗәсенә лаек була. Ул мавыгып фән белән шөгыльләнә: авыл хуҗалыгы культураларыннан уңыш алуны программалаштыру методикасын эшли һәм уҗым культураларын интенсив технология белән игү системасын гамәлгә куюда башлап йөри. Бу тикшеренүләр галимнең – адаптив үсемлекчелек фәнни мәктәбен булдыруына, республикада исә авыл хуҗалыгы җирләрен зональ эшкәртүгә, адаптив-зональ системаларның урнашуына китерә. Назыйф Раян улы – җир эшкәртү һәм үсемлекчелек мәсьәләләренә багышланган 28 монография, 450дән артык фәнни мәкаләләр авторы. Бу өлкәдәге ачышлары үсемлекчелек буенча укытыла торган китапларда чагылыш таба.

1979 елны аннан Башкорт авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институтын җитәкләвен үтенәләр. Бу чорда институтта эре селекция комплексы (фитотрон) төзелә, институтның матди-техник базасы ныгый, тәҗрибә хуҗалыклары булдырыла, югары уңыш бирә торган көзге арыш һәм бодай, карабодай, җиләк-җимеш культураларының яңа сортлары уйлап табыла. Алар бүген дә Россиянең күп кенә төбәкләрендә игелә. Гомумән алганда, бу чорда институт игенчелекнең туфракны саклау системасын эшләү һәм авыл хуҗалыгы культураларының яңа сортларын барлыкка китерү буенча Россиядә билгеле фәнни үзәккә әйләнә. Шуңа да Назыйф Раян улының үзенә «Республиканың баш агрономы» дигән рәсми булмаган исем иярә. Ул әзерләгән «Игенчелекнең Башкортстан зоналары буенча фәнни нигезләнгән системасы» китабы хуҗалык җитәкчеләре һәм агрономнарның өстәл китабына әверелә. 1991 елны, беренчеләрдән

булып, галим Башкортстан Республикасы Фәннәр академиясенең мөхбир-әгъзасы итеп сайлана.

Әлбәттә, тыныч холыклы, кешеләргә ярдәмгә килергә һәрчак әзер торган, җирне – иң олы байлык дип санаган Назыйф Раян улы турында күп сөйләргә мөмкин булыр иде. Әмма безнең бүгенге героебыз – аның улы икәнен дә онытмыйк.

Бәлки, авыл хуҗалыгы өлкәсендә «Назыйф Раян улы» булып йөрергә теләмәү аларның бердәнбер уллары Рамилне Санкт-Петербург дәүләт университетының механика-математика факультетына китергәндер. Кем белә?! Бәлки әнисе Гөлниса Мәхмүт кызының математик булуы аның да әлеге белгечлекне сайлавына сәбәп булгандыр. Ни генә булмасын, Рамил Назыйф улы әтисе юлы белән китми: һөнәр сайлаганда ук үз урынын башка өлкәдә – математика, нефть һәм газ чыгару, нефть эшкәртү өлкәсендә табачагын ачыклап куя.

1977 елда укуын тәгәлләп туган җиренә әйләнеп кайтып, ул Уфа нефть институтының (хәзер Уфа дәүләт нефть техник университеты, УГНТУ) югары математика кафедрасында эшли башлый. 1995 елда математик модельләштерү кафедрасы оештырып җибәрә һәм шуны җитәкли, 1999-2001 елларда икътисад һәм менеджмент факультеты деканы була, 2001-2011 елларда – уку-укыту эшләре буенча проректор, 2007 елдан математика кафедрасы мөдире булып хезмәт итә. 2015-2020 елларда – ректор. Рамил Назыйф улы бүген – үз институтында «Нефть һәм газны күчерү һәм саклау» кафедрасы профессоры.

45 ел шушы вузда җитәкче урыннарда эшләп, Рамил Назыйф улы университетны үстерүгә зур өлеш кертә. Р.Н.Бәхтизин ректор булган вакыт аралыгында УГНТУ республикадагы югары уку йортлары арасында беренче булып федераль статус – Россиянең терәк вузы исемен ала. Университетның юбилеена «Университетның 70 еллыгына – 70 объект» дигән программа кабул ителә һәм тормышка ашырыла. Ул уку йортының матди-техник базасын заманча югары дәрәҗәгә күтәрергә мөмкинлек бирә. Бу вакытта сафка баскан объектлардан, уфалыларга Космонавтлар урамындагы Аллеядагы скульптур композиция таныш һәм шәһәрнең иң матур урыннарыннан берсе буларак кадерле. Аның идеясе – Рамил Назыйф улыныкы, ташка исә Санкт-Петербургта яшәүче уфалы сынчы Илья Литвинов уйган.

Иң катлаулы, республика бюджетына йогынтылы вуз белән идарә итүдән тыш, Рамил Назыйф улы фәнни тикшеренүләрне дә, җәмәгать эшләрен дә читкә куймый. Ул Башкортстан вузларының ректорлар советы рәисе (2018) вазифасын башкара, Башкортстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе (2001), Россия Федерациясенең атказанган фән эшлеклесе (2015), Башкортстан Республикасының Халыклар Дуслыгы ордены (2020) кавалеры, башка бик күп мактаулы исемнәргә лаек була. Күрәбез, тормыш-көнитешнең бөтенләй үзгә тармагында әтисе уңышларын кабатлый.

Бу казанышларның тамыры бер – туктаусыз хезмәт, тырышлык, белем арттыру, башкаларны да гыйлем юлыннан ияртеп бару! Ул сайлаган фән өлкәсе дә нинди бит – нефть һәм газ сәнәгате!

Билгеле, Рамил Назыйф улы Башкортстанга әйләнеп кайткан 1980 еллар – республикада гына түгел, Идел-Урал төбәгендә кара алтын чыгаруның фәнни нигезләрен заманчалаштыру, бу процессның нәтиҗәлелеген арттыру хакында уйланган вакыт. Рамил Назыйф улын шушы гаҗәеп катлаулы һәм халык тормышын тиз арада яхшыртырга сәләтле өлкә үзенә җәлеп итә. Шуңа егет 1980-1983 елларда М.Азизбеков исемендәге Азәрбайҗан нефть һәм газ институты аспиранты, 1990-1992 елларда – докторанты булып белемен ныгыта. Остазы, мәшһүр галим һәм педагог, җәмәгать эшлеклесе, Азәрбайҗан милли фәннәр академиясе академигы Азат Хәлил улы Мирзаҗанзадә кул астында фән белән шөгыльләнү, Рамил Назыйф улының фикеренчә, аның үз юлын табуында иң зур рольне уйный.

Рамил Назыйф улы фәнни юнәлеш итеп нефть һәм газ чыгаруда, аларны башка урыннарга җибәрү-илтүдә, эшкәртүдә, нефть-газ комплексының икътисадында математик методлар һәм математик модельләштерү куллануны сайлый. Матурлыкны, табигатьне, сәнгатьне яратуы, кеше фикеренең-фәлсәфәсенең тирәнлегенә соклануы белән кечкенәдән аерылып торган татар егете Азат Хәлил улында һәм фәнни, һәм шәхси остаз таба.

Р.Бәхтизинның нефтьне һәм газны башка урыннарга күчерү мәсьәләләрен тикшерү нәтиҗәләре әлеге өлкәдә дәүләти карарлар кабул итү өчен нигез дип табыла һәм Башкортстан Республикасы, Россия Федерациясенең ягулык-энергетика комплексы предприятиеләрендә кулланыла башлый. Моннан тыш, ул скважиналарны җир астында ремонтлау эшенә әзерлек һәм аны башкару өчен җиһазлар комплексы уйлап таба, бу эшләрне башкарып чыгу юлларын тәкъдим итә. Торбада чакта ук сыеклык агымын эшкәртү механизмнарын табу, шулай ук, бу өлкәдә зур алга китеш дип бәяләнә ала. Болар барысы да гамәлгә керә, сәнәгатьтә кулланыла башлый. Нефть үткәргечләрнең технологик режимнарын эшләү, корыч резервуарларның файдаланылу мөмкинлекләрен киңәйтү, электр ярдәмендә җылыту юлы белән нефть продуктларын саклау һәм күчерүнең нәтиҗәлелеген күтәрү, резервуарларны кулланунның куркынычсызлыгын тәэмин итү кебек мәсьәләләр дә профессор Бәхтизин хезмәтләрендә чишелеш таба.

Галим тәкъдим иткән магистраль нефтьүткәргечләрдә капиталь ремонт ясарга әзерлек һәм аны башкарып чыгу, агымнар белән идарә итү технологияләре катламнарның җир маен бирү мөмкинлекләрен һәм нефть-газ эшкәртү сәнәгатенең гомуми социаль-икътисади нәтиҗәлелеген күтәрүгә китерә.

Р.Н.Бәхтизин нефть-газ сәнәгатендәге хокукый-икътисади проблемаларны да урап узмый. Аерым алганда, нефть-газ проектларын тормышка ашырганда инвестор һәм дәүләт катнашының шартларын күзаллау, Башкортстан Республикасы төбәкләре икътисадына инвестицияләр җәлеп итү механизмнарын ачыклау, нефть чималын эшкәртүнең төрле схемаларын куллану вакытында матди агымнар белән идарә итү системасы – шундыйлардан. Ул – үз тематикасы буенча 20 фәннәр кандидаты тәрбияләгән, 380нән артык фәнни хезмәт, 10 монография һәм дәреслек авторы. Һәр ачышы-казанышы диярлек үз өлкәсендә бирелә торган бүләкләргә лаек була: Россия Федерациясе газ сәнәгатенең мактаулы хезмәткәре (1998), һәм Шәрәфле югары профессиональ белем бирү хезмәткәре (2010), Россия Федерациясенең мактаулы нефтьчесе (2019); академик П.Л.Капица (2005), академик А.Х.Мирзаҗанзадә (2016) медальләре, академик И.М.Губкин премиясе (2016), К.Р.Тимергазин премиясе иясе ул.

Бу урында кабат Рамил Назыйф улының остазына әйләнеп кайтырга кирәктер. Мирзаҗанзадә фәнни мәктәбе Башкортстанга 30-дан артык фән кандидаты һәм 20-ләп фәннәр докторы әзерләп бирә. Алар арасында Россия күләмендә танылган галимнәр – А.И.Спивак, А.М.Шаммазов, М.Р.Мәүлетов, А.К.Галләмов, В.Ф.Новосёлов, П.И.Тугунов, М.М. әсәнов, И.Ш.Әхәтов, В.А.Байков, И.Р.Байков, Р.К.Газизов, Р.Р.Газизов, А.Р.Латыйпов һ.б. бар. Гомумән, гаҗәеп шәхес – фундаменталь гыйлемнәрдән тыш, философия белән кызыксына, шәхес психологиясен якын итә, классик музыка һәм балетка мөкиббән кеше була ул! Үзенең укучыларына да, фән белән бергә, рухи үсеш юнәлешләрен күрсәтә, аларны үзе шикелле үк киң карашлы, тормышны һәм кешеләрне яратучылар итеп тәрбияли.

Азат Хәлил улы Башкортстанда нефть һәм газ ятмаларын эшкәртүнең теоретик һәм гамәли мәсьәләләре, механика һәм гамәли математика буенча өр-яңа юнәлешләр формалаштыра. Аның катнашында Уфада югары математика, бораулау, теоретик механика, торбаүткәргеч транспорт, нефть ятмаларын эшкәртү кафедралары ачыла. Ике ел дәвамында ул үзе җәмәгать тәртибендә нефть ятмаларын эшкәртү кафедрасын җитәкли. Ул республикада 1978 елны Әсгать Галимҗан улы Гомәров нигезләгән легендар фәнни мәктәп-семинар белән җитәкчелек итә. Азат Хәлил улы чакыруы

буенча күренекле галимнәр Р.И.Нигъмәтуллин, З.И.Сүнәев, Н.Х.Ибраһимов, М.Ә.Илһамов, З.П.Шульман һ.б.лар Башкортстанга килеп, республика галимнәрен үзләренең эш нәтиҗәләре белән таныштыра. Бу семинарлар йөзләгән яшь галимнәр өчен фәнгә юл ача.

Рамил Назыйф улының Татарстан белән хезмәттәшлеге турында да аерып әйтергә кирәк. Бер мисал: Р.Н.Бәхтизин һәм хезмәттәшләре тарафыннан агымлы аппаратларның төп гидродинамик характеристикаларын исәпләүнең теоретик нигезләре һәм методикасы эшләнә. 1999–2017 елларда Россия ягулык-энергетика комплексының 10 эре предприятиесендәге нефть чыгару һәм нефть эшкәртү объектларында 100 дән артык җилләткеч җайланмалы инновацион болгаткыч гамәлгә кертелгән булса, нефтьне тозлардан арындыру өчен хезмәт итә торган 30дан артык агымлы гидравлик болгаткыч Татарстанда, «Татнефть» нефть-газ чыгару идарәсенең 14 предприятиесендә кулланыла. Әлеге эшләнмәләрне куллануның икътисади файдасы йөз миллион сумнан артып китә.

Гадәттә, мондый технологияләрне чит илләрдәгеләре белән чагыштырып бәяләү кабул ителгән. Россиядәге һәм чит ил аналоглары белән чагыштыру эшләнмәләрнең өстенлекләрен тагын бер кат раслый, бигрәк тә монтажлау һәм хезмәт күрсәтү өчен җиңел булуы; озак хезмәт итү вакыты; хәрәкәтләнүче, әйләнүче өлешләре булмау; электр энергиясе кертү кирәкмәү, куркынычсызлык – шундыйлардан. Алар Россия Федерациясенең 14 патенты белән расланган. Р.Н.Бәхтизин җитәкләгән коллективның (Р.З.Нургалиев, М.М.Алиев, С.А.Трубкин, А.Г.Авзалетдинов, В.Ф.Галиәкбәров, Б.А.Яхин, Г.М.Сидоров) Дәүләт бүләкләре арасында «Нефть һәм нефть продуктларын әзерләү һәм эшкәртү вакытында җилләткеч җайланмалы, агымлы инновацион аппаратларны эшләү һәм киң сәнәгать кулланылышына кертү» дигән проекты өчен 2019 елны бирелгән Татарстан Республикасының Фән һәм техника өлкәсендәге Дәүләт премиясе дә бар. Бүген исә Рамил Назыйф улы, УГНТУ, КФУ, И.М.Губкин ис. РГУ һәм Сколтех бергәләп оештырган консорциум – дөнья фәне югарылыгындагы «Планетаның сыек углеводородлар запасын рациональ үзләштерү» дип аталган фәнни үзәкнең баш гыйльми хезмәткәре буларак, Татарстан галимнәре белән бергәләп яңа проектларны тормышка ашыру белән шөгыльләнә.

Тагын бер өлкәне – Рамил Назыйф улының, уку-укыту һәм фән белән бер үк вакытта 2011-2015 елларда Башкортстан Фәннәр академиясе президенты булуын әйтми китсәк, дөрес булмас иде. Бу еллар республика Фәннәр академиясе тирәсенә көчле галимнәр – интеллектуаль көчләр туплану дәвере булды. Аерым алганда, технологик стартаплар белән шөгыльләнә башлау – академиянең киләчәккә карап башланган зур проекты иде. Фәнне популярлаштыру, яшьләр һәм балалар белән эшләү юнәлешендә дә өр-яңа мөмкинлекләр табыла: Фән һәм сәнгать музее оештырыла, республикага үзенең күргәзмәсе белән З.К.Церетели килә һ.б.

Рамил Назыйф улы бүген УГНТУда – остаз-профессор, диссертацияләр яклау советы рәисе, «Башкортостан Республикасында электрон мәгариф» ассоциациясе рәисе, Башкортостан Республикасы кече нефть компанияләре ассоциациясе рәисе, депутат... Йомшак-хәерхаһлы табигатьле, тыныч-сабыр холыклы галимнең шулкадәр иҗтимагый активлыгына сокланмый мөмкин түгел.

Гомер буе матурлык яратучы, хөр табигатькә мөкиббән булып яши ул. 1980 елларда Кавказ тауларында була, Памирдагы Ленин түбәсенә менә! Соңгы елларда Камчаткада, Ерак Көнчыгышта, Сахалинда, Курил утрауларында, Коль ярымутравында, Таулы Алтайда, Селигер күлендә, Якутия (Саха) Республикасында йөреп кайта. Караш җитмәс киңлекләрне, тын кысылырлык биеклекләрне, гаҗәеп матурлыкларны күрү туган җирләрнең кадерен тагын да ныграк төшендерә булыр: югыйсә әти-әниләре дачасы булган Йоматау турында сайт алып баруын, бу урынга кагылышлы китапларны нәшер итәргә булышуын ничек аңлатыр идең?!

Башкортстанда Рамил Назыйф улының әтисе үстергән гаҗәеп затлы бакча хакында да легендалар йөри. Тамырлары белән җиргә береккән, рухы белән күкләргә омтылган кеше генә шундый гөлбакча үстерә ала торгандыр. Хәер, Рамил Назыйф улы үзе дә 2019 елны туган җире Яңа Аташның 100 еллыгына багышлап, авылда зур бәйрәм оештыра. Анда авылга нигез салучыларга мемориаль комплекс ачыла.

Гаиләсе дә гыйлем һәм сәнгать юлында, аның белән бергә атлый. Хатыны Мила Рәшит кызы – архитектор, фәннәр кандидаты, озак еллар вузда студентларга белем бирә. Яраткан кызлары Алия – математик-икътисадчы, фәннәр кандидаты, шулай ук фән юлын сайлаган. Оныклары Аэлита мәктәптә укый. Бәхтизиннарның яшь буыны да бабалары юлын лаеклы дәвам итәр – монда шик юк. Үрнәк алырлык асыл затлар биргән династия бит бу!

**Дания ЗАҺИДУЛЛИНА,**
*академик, филология фәннәре докторы.*

## *Котлыйбыз!*




Рамил Назыйф улы Бәхтизин Газпромның 2022 ел өчен фән һәм техника өлкәсендәге бүләгенә лаек булды. Бүләккә лаек булган проект нефть һәм нефть продуктларын табу, әзерләү һәм саклау өчен кирәкле технологик җайланмаларны киң сәнәгать җитештерүенә кертү белән бәйләнгән.

Фотода: Бүләкләү тантанасында. Рамил Бәхтизин уңда.

*Фотолар* **Рамил Бәхтизинның** *шәхси архивыннан алынды.*

# МӘХКӘМӘИ ШӘРГЫЯНЕҢ XVIII ГАСЫР АЗАГЫ – XIX ЙӨЗ УРТАСЫНДА ЭШЧӘНЛЕГЕ

XVIII гасыр азагы – XIX йөз уртасы – Мәхкәмәи шәргыядә рәислек вазифасын император билгеләп куйган Мөхәммәтҗан Хөсәенов (1789–1824), Габдессәлам Габдерәхимов (1825–1840) һәм Габделвахит Сөләйманов (1840–1862) башкарган заман. Аларның һәрберсе, нигездә, дини идарәне ныгыту һәм аның авторитетын күтәрү юлында үзеннән өлеш керткән.

## Дәүләт оешмасының үсүе

***Оешманың штатлары.*** Мөхәммәтҗан Хөсәенов Казакъ даласында Коръән сүзе катыштырылган халыкара дипломатиянең Россия хөкүмәте өчен никадәр әһәмиятле булуын, үзенең арадашчылык өлкәсендә алыштыргысыз сәяси эшлекле икәнен яхшы аңлаган. Кыенсынмыйча, императорлардан кат-кат матди ярдәм һәм яклау сораган һәм алган. 1786 елны ул сәүдәгәрләр түли торган салымнан азат ителгән, чыгышы белән сәүдәгәр сословиесендә булса да, Екатерина II Мөхәммәтҗанга башкортларның җирләрен, ә 1793 елда крепостнойлар сатып алырга рөхсәт биргән *(Материалы по истории Казахской ССР. (1785–1828 гг.). Т. 4. М.,Л., 1940. С. 483.)*

М.Хөсәенов үзенә каршы төрле кешеләр тарафыннан ачылган мәхкәмә эшләреннән качу максатында 1811 елда Александр Iдән мөфтигә бәйле низагларны Сенат карарга тиеш дигән рөхсәт ала, мөфтинең дәрәҗәсен күтәрүгә ирешә.

Мәхкәмәи шәргыя оешканда мөфтинең еллык кереме – 1500, өч казыйныкы – 120шәр, сәркатибнеке – 250, тәрҗемәченеке – 120, теркәүче-регистраторныкы – 100, ике канцелярия өстәл башлыкларыныкы – 80шәр, аларның кул астында эшләүчеләрнеке – 50шәр, ике күчереп язучыныкы – 40ар, каравылчыныкы 20 сум дип билгеләнгән. Канцелярия чыгымнарына 150 сум тәгаенләнгән була.

1836 елны штатлар саны һәм хезмәткәрләргә түләү беркадәр арта. Мәхкәмәи шәргыя рәисенә ассигнацияләр белән 2000 сум һәм юл чыгымнарына 1500 сум санала. Казыйларга – 750шәр сум, сәркатибкә, Ранглар табеле буенча XII класс куелып – 1000 сум, тәрҗемәчегә (XII класс) – 600 сум, ике канцелярия өстәлләре башлыкларына (XIV класс) – 600әр сум, архивариуска (журналист) (XIV класс) – 500 сум, дүрт уртача оклад билгеләнгән канцелярия хезмәткәрләренә – 240ар, түбән оклад билгеләнгән канцелярия хезмәткәрләренә 160ар сум дип раслана. Канцелярия чыгымнарына, бинаны җылыту, яктырту һәм каравылчыга түләү өчен һәммәсе 1200 сум бүлеп бирелә.

Габделвахит Сөләймановның гозерен канәгатьләндереп, 1841 елны хөкүмәт Мәхкәмәи шәргыягә өстәл башлыгы һәм ике канцелярия хезмәткәре штатларын өсти. 1855 елны Г.Сөләйманов Мәхкәмәи шәргыя сәркатибен (X класс чины), тәрҗемәче, өстәл җитәкчеләренекен һәм журналистныкын (XI) бер класска күтәрүгә ирешә (*В память столетия Оренбургского магометанского духовного собрания, учрежденного в городе Уфе. Уфа: Типография губернского правления, 1891. С. 37*).

Бер сүз белән әйткәндә, дәүләт мөфтиләргә матди яктан махсус игътибар күрсәтә, ә казыйларга, казна оешмасында эшләүчеләргә һәм канцелярия чыгымнарына акчаны бик саран бирә. Югыйсә хатлар белән мөрәҗәгать итүчеләр, имтихан бирергә

килүчеләр саны арта барган, кәгазь эшен тиешле дәрәҗәдә алып барырга штатлар җитмәгән, түбән хезмәт хакына югары квалификацияле хезмәткәрләр эшкә урнашырга атлыгып тормаган. Казан губернасыннан казыйлыкка сайланып килгән руханиларның да русчалары һәм дини белемнәре чамалы булган. Шулай итеп, тел һәм белем факторлары да тиз һәм нәтиҗәле эшләүгә өстәмә кыенлыклар тудырганнар.

***Казыйлар.*** Архивта М.Хөсәенов мөфти булып торган елларда Мәхкәмәи шәргыя эшчәнлеге теркәлгән журналлар сакланмаган, ә мөфтиятне күзәтеп торган Эчке эшләр министрлыгының архивы 1861 елда янган. Төбәк һәм үзәк империя институтлары архивларында күбрәк М.Хөсәеновның халыкара дипломатик эшчәнлеге хакында, шулай ук җирле хакимият һәм аерым шәхесләр өстеннән үзе язган шикаятьләр яки аңа каршы язылган текстлар гына сакланган.

Мәхкәмәи шәргыя күмәк карарлар кабул итеп эшләргә тиеш булса да, мөфти Казан губернасы руханилары сайлаган казыйлардан берсүзсез үзенә буйсынуларны таләп итә. Күрәсең, ул кабул иткән карарлар арасында хилафлары да булмаган түгел, казыйлар исә, шәригатьчә түгел дип яки шәхси кимсетелү санап, Мәхкәмәи шәргыядә фетнә күтәргәннәр, прокурор тикшерүенә биргәннәр. Бу каршылык дулкыны Казан һәм күрше губерна муллалары арасында таралган, үз чиратында, төрле ризасызлыкларга сәбәп булган.

Г.Габдерәхимов һәм Г.Сөләйманов мөфтиләр дә казыйларның эшчәнлегеннән канәгать булмаганнар.

Эчке эшләр министрлыгында шәригать кануннарын куллану өлкәсендә эксперт булып эшләгән профессор А.К.Казем-Бекның булачак мөфти С.Тәфкилевкә 1865 елның 7 августында язылган хатыннан күренгәнчә, империя хакимияте Мәхкәмәи шәргыядә эшләр барышыннан һич кенә дә риза булмаган. Галим мондый торышны казыйларның эш тәртибен белмәүләре, канцелярия хезмәткәрләре өстеннән күзәтүнең йомшак булуы белән аңлата. Мәхкәмәи шәргыянең еш кына төрле шәхесләр басымнары астында бер-берсенә каршы килүче карарлар кабул иткәнен, мөселманнар һәм муллалар турында кайгыртасы урында, гадел булмаган карарлар чыгарып, аларны кимсетүен ассызыклый (*Материалы по истории Татарии второй половины XIX в. Ч. 1. М.-Л., 1936. С. 187–190.*).

***Мәхкәмәи шәргыянең мәчетен һәм бинасын төзү.*** М.Хөсәеновтан аермалы буларак, Габдессәлам Габдерәхимов Казан губернасы руханилары һәм байлары белән уртак тел тапкан. 1827 елның августында Габдессәлам Мәкәрҗә ярминкәсенә баргач, Казан байлары аңа Уфада мәчет төзүдә ярдәм итәргә сүз бирәләр (*Байбулатова Л.Ф. Оренбургские муфтии и их деятельность в «Асаре» Ризаэддина Фахретдина // История татар с древнейших времен. В 7 т. T.VI. Казань: Институт истории им. Ш.Марджани АН РТ, 2013. С. 1005, 1007*). Чыннан да, Арчаның 2 нче гильдия сәүдәгәре Мөэмин Хуҗасәитов 1830 елда калада – таш мәчет, 1834 елны исә имтихан бирергә һәм үз эшләре белән Мәхкәмәи шәргыягә килгән дин кардәшләренә һәм казыйларга яшәү өчен вакыф йорты төзеп куя. Уфада мәхәллә һәм мулла булмау сәбәпле, җомга һәм гаетләрне Габдессәлам мөфти үзе башкарган, кайбер вакытта бу вазифаны казыйларга тапшырган.

Мәхкәмәи шәргыянең бюджеттан тыш керемнәре 1829 елдан метрикә кенәгәләре өчен җыелган акчадан башлана. Һәр мәхәллә ике данә метрикә кенәгәсе өчен ассигнация белән 50 тиен түли торган була.

1828 елны, муллаларга ике метрикә кенәгәсе тутыру, аның бер данәсен Мәхкәмәи шәргыядә сакларга җибәрү турында Указ чыккач, мөфти хакимият алдында дини идарәгә бина мәсьәләсен күтәрә, аны бергәләп, казна һәм мөселманнардан җыелган иганә акчасына төзергә тәкъдим итә. Губерна хакимияте 1831 елда шәһәрдәге дәүләт биналары исемлеген төзегәндә, Мәхкәмәи шәргыя турында оныта. Мәхкәмәи шәргыянең бик начар шартларда эшләгәнен күргән чиновниклар, мөфтинең 6 ел элек бинаны бергә төзибез дигән сүзләрен искә төшереп, 1834 елны аңа мөрәҗәгать итәләр: Мәхкәмәи шәргыянең акчасы бармы? Мөфти, метрикә дәфтәрләре сатудан

кергән акчага кушып, мөселманнар никахларын теркәгән өчен ассигнация белән 30 тиен (8, 50 тиен көмеш акча) салым җыеп, бина төзү тәкъдимен кертә. Шул рәвешле мөселманнарның никахларын теркәгән өчен махсус салым җыела башлый.

Җыелган сумманы мәхәллә мулласы ел азагында метрикә кенәгәсе белән бергә өяз түрәләре аша Мәхкәмәи шәргыягә җибәрә торган була. Бу җыем «мөселманнарның никах салымы» дип атала башлый.

Яңа мөфти Габделвахит Сөләйманов элегрәк Габдессәлам мөфти әзерләгән бина проекты белән таныша. Бу сызымнан күренгәнчә, таш бинаның уң ягындагы флигель – архив өчен, сул ягындагы флигель – казыйлар яшәү өчен, бина артындагы флигель хезмәткәрләр өчен дип планлаштырылган. Проектның расланмаган булуыннан файдаланып, Габделвахит аңа үзгәрешләр кертә. Төп яңалык – бинаны ике катлы төзеп, икенче катка мөфти фатирын урнаштырырга. Әйтергә кирәк, хөкүмәт раслаган проектта аның бу тәкъдиме исәпкә алына.

Габделвахит, төзелеш эшләре башлангач, 1861 елның 22 маенда яңа тәкъдимнәр белән чыга. Аның фикеренә колак салып, сметага өстәмә эшләр языла: ат абзары, кареталар, ат арбалары һәм чаналары өчен сарай, кер юу урыны булган мунча төзү, казыйлар өчен флигельдә базлар казу һәм ишегалдын таш койма белән әйләндерү. Шулай итеп, Мәхкәмәи шәргыя бинасы бер комплекс буларак корыла *(Байбулатова Л.Ф. Күрс. хезмәт. 1023 б.).*

Төзелеш эшләре 1865 елда тәмам була. Мөселманнарның никах салымы буларак җыелган суммадан җәмгысе 54742 сум акча сарыф ителә. Төзелеш тәмамланганда, Мәхкәмәи шәргыянең Дәүләт банкында әле 10650 сум һәм 619 сум 12 ¼ тиен акчасы калган була. Прокурор тикшерүе акчаның төгәл, дөрес файдаланылганын раслый *(Загидуллин И.К. Финансовое положение Оренбургского магометанского духовного собрания во второй трети XIX в. // Минбар. Исламские исследования. 2018. №11 (1). С. 29–37).*

Шулай да, кайбер казыйлар, гаиләләре белән яшәргә шартлар юк дип, флигельдә яшәүдән баш тарталар. Алардан соң яңа өчьеллыкка билгеләнгән казыйлар да, шушы үрнәккә ияреп, шәһәрдә арендага фатир алып яшәүне өстен күрделәр, дип яза Р.Фәхреддин *(Байбулатова Л.Ф. Күрс. хезмәт. 1023 б.).*

Төзелеш эшләре башлангач та, никахны теркәгән өчен салым җыюны туктату мәсьәләсе калкып чыга. Сөләйманов, салым җыюны дәвам итү кирәклеген раслап, түбәндәге дәлилләрне китерә: яңа төзелгән Мәхкәмәи шәргыя бинасына, аның канцеляриясенә, мөфти фатирына мебель алырга, янгын куркынычсызлыгы страхованиесен түләргә, киләчәктә ремонт ясарга. Хөкүмәт, чыннан да, мөселман никахлары өчен салымны калдыра, ләкин суммаларны губерна идарәсе карамагына тапшыра. Габделвахит мөфтинең никах теркәгән өчен салымны саклап калуы соңрак Мәхкәмәи шәргыя эшчәнлеген оештыруга зур файда китерә.

## Муллалар белән идарә итү структурасы төзелү

Кануннарда мөселман институтларының хокуклары төгәл билгеләнмәгән булу күп мәсьәләләрнең җирле хакимият тарафыннан «кем көчле – шул хаклы» принцибы белән хәл ителүенә китерә. Үз шәхесенең илкүләм авторитеты Мөхәммәтҗан мөфтигә тиз арада Мәхкәмәи шәргыя Ырынбургыяне төзеп чыгарга һәм аны төбәк хакимияте алдында тиешле югарылыкка куярга мөмкинлек бирә. Бер сүз белән әйткәндә, ислам институтларының хокукларын билгеләргә тиешле кануннар өлкәсендәге бушлыкны мөфти муллаларга яңа мәчет төзү яки аны ремонтлау турында хатлар язып, ир белән хатын аерылу, дини китапларны бастыру хакында һәм башка мәсьәләләр буенча фәтвалар биреп тутыра. Алар арасында М.Хөсәеновның 1810 елда Коръәннең «Бәкарә» сүрәсендәге 232 нче аятькә таянып, әгәр никах вакытында киленнең опекуны катнашмаган булса, мондый никахны, киленнең әти-әнисе теләгенә каршы төзелгән дип танып, юкка чыгарырга кирәк дигән фәтвасын атап үтәргә мөмкин *(Кемпер М.*

*Суфии и учёные в Татарстане и Башкортостане (1789–1889). Исламский дискурс под русским господством. Казань: РИУ, 2008. С. 124.)*

М.Хөсәенов – Мәхкәмәи шәргыя округына кергән күпсанлы губерналарда таралып яшәүче мөселман руханилары белән төбәкләрдә идарә системасын нигезләгән мөфти. Ул эшне оештыру өчен ышанычлы кешеләргә ахун дәрәҗәсе биреп, аларны Мәхкәмәи шәргыянең төбәк вәкилләре итеп, «мөфтият – губерна/шәһәр/өяз ахуны – мәхәллә руханилары» идарә моделен булдырырга тырыша. Дөресрәге, элек төбәкләрдә эшләп килгән, авылларда муллалар һәм халык иялнгән һәм губерна хакимиятенә караган ахун институтын Мәхкәмәи шәргыягә буйсындыра. Әйтергә кирәк, бу хезмәт бик мәшәкатьле була.

Мөфти Г.Габдерәхимов, бу сәясәтне дәвам итеп, «ахуннар – өяз дәрәҗәсендә мөселман судьялары» дигән фәтвалар бирә *(Кемпер М. Күрс. хезмәт. 126 б.).* Г.Сөләйманов та ахуннарга таянып идарә итү сәясәтен тормышка ашыра.

Мөфти М.Хөсәенов вакытында бу өлкәдә күп кенә проблемалар килеп чыга. Шуларның берсе – мөфтинең, рус чиновниклары алымнарыннан аерыла алмыйча, мөфтилеккә сәяси вазифа дип карап, эш-гамәлләрендә дини тәкъвалык һәм суфиларга хас динлелек сыйфатларын калкытып күрсәтмәвенә бәйле *(Кемпер М. Күрс. хезмәт. 125 б.).* Киңрәк караганда, бу кыенлыкны ислам институтлары өстеннән дәүләт куйган җитәкче (мөфти) белән Урта Азия һәм Әфганстан мәдрәсәләрендә укып кайтканнан соң Идел-Урал төбәгенә таралган Нәкышбәндия тарикате тарафдарларының – җирле суфи тарикате оешмалары җитәкчеләре булган мөршидләрнең, ишаннарның үзләренең мөридләре (шәкертләре, указ алган муллалар) аша – төбәк мәчет-мәдрәсәләрендә, мәхәлләләрдә үз йогынтыларын булдыру омтылышы арасындагы каршылык дип бәяләргә мөмкин *(Хабутдинов А.Ю. Российские муфтии: от екатеринских орлов до ядерной эпохи (1788 – 1950). Н.Новгород, 2006. С. 13–14.).*

Мисаллар китерик. 1802-1803 елларда Саратов төбәгендә Казан губернасының Царевококшай өязе Ор авылы мулласы Хәбибулла Хөсәенов һәм аның ике мөриде, шушы якның ике мулласы, Саратов, Казан, Сембер, Пенза губерналарында мөстәкыйль дини идарәләр ачарга кирәк дип өндәп, авылдан-авылга йөргәннәр. Әйтергә кирәк, аның тәкъдимен күтәреп алып, Саратов төбәге мөселманнары губернаторны үзләрендә мөселман рухани идарәсе оештырырга күндергәннәр, хәтта бу хакта губернатор башкалага рапорт та җибәргән.

1808 елны Казан губернасы муллалары һәм сәүдәгәрләре шулай ук губернаторга төбәктә мөстәкыйль дини идарә оештыруны сорап мөрәҗәгать итеп карыйлар (*Азаматов Д.Д. Оренбургское магометанское духовное собрание в конце XVIII – XIX вв. Уфа: изд-во «Гилем», 1996.* С. *32-33).* Югарыда яңгыраган тәкъдимнәрне өлешчә мөстәкыйльлеккә омтылу дип тә карарга мөмкиндер.

Мөхәммәтҗан Хөсәеневнең вафаты турында хәбәр килеп ирешкәч, 1824 елның сентябрендә бер төркем Казан губернасы муллалары һәм сәүдәгәрләре халык мәгарифе министрына 1788–1808 елларда Бохарада укыган бик диндар һәм гыйлемле, Казан каласының Олы мәчете ахуны Габделсаттар Сәгыйтов яки Фәтхулла бине Хөсәен әл-Орыви (Ор авылыннан) кандидатураларын мөфтилеккә тәкъдим итәләр *(Кемпер М. Күрс. хезмәт. 113 б.).* Ул да түгел, 1825 елның гыйнварында Ибраһим Хуҗаши җитәкчелегендә бер төркем төбәк ахуннары министрга яңа тәкъдим белән чыгалар – Казан губернасы руханиларына мөфтине сайларга мөмкинлек бирергә! (*Азаматов Д.Д. Күрс. хезмәт. 49 б.*). Бу инициатива – төбәктән дини автономия сорап ясалган безгә билгеле беренче мөрәҗәгать.

## Мөфтиләрнең эшчәнлеге

Мөхәммәтҗан мөфти булган еллар – дини укыту системасы формалашкан, күпләп мәктәп-мәдрәсәләр һәм мәчетләр ачылган, «указлы» руханиларның мәхәллә халкына әхлакый тәрбия, үсеп килүче яшь буынга дини белем бирүгә ныклап алынган, ислам

кануннарының халык көнкүрешенә, мәдәниятенә тамыр җәйгән заман иде. Р.Фәхреддин дә Мөхәммәтҗан мөфтинең яхшы гамәлләре дип, XIX гасыр башында Казан типографиясендә голәмәләрнең дини китапларын бастыру өчен фәтвалар бирүен, Мәхкәмәи шәргыяне ачып, юлга куюын һәм аны рәсми рәвештә хакимият оешмалары тарафыннан кабул иттерү дәрәҗәсенә җиткерүен әйтә (*Фәхреддин Ризаэддин. Асар. 1 том. Казан, 2006. 104 б.*). Шуңа өстәп, хокукый нигез булмаса да, үзе тәкъдим иткән «гадәт» буенча хакимият белән аралашып һәм көрәшеп, мөфти Мәхкәмәи шәргыя һәм муллалар карамагына шәригать кануннары буенча гаилә мөнәсәбәтләрен көйләүне һәм милек/мирас бүлүне беркетә. Соңрак Николай I заманында бу тәртипләр рәсми канун рәвешен ала.

Мөхәммәтҗан Хөсәенов Казанда ачылган типографиядә басылачак дини китапларның цензоры итеп, Иске Татар бистәсендәге агач мәчет имамы Мөхәммәд Әбдрәзәковны тәкъдим итә, чынлыкта нәшер ителә торган китапларга үзе күзәтчелек итә *(Каримуллин А.Г. У истоков татарской книги. От начала возникновения до 60-х годов XIX века. Издание 2-е, испр., и пер. Казан: Татар. кн. изд-во 1992. С.112).* 1802 елда мөфти фатыйхасы белән ислам дине һәм аның йолалары турында сөйләгән «Пиргули китабы» һәм «Устуани китабы» татарча басылып чыга. Башка китапларда мөфти фәтвасы белән басылган дигән сүзләр булмавы бу хезмәтләрне мөфти тәкъдиме белән бастырылган дип әйтергә урын калдыра. Алар татар мәдрәсәләрендә дәреслек сыйфатында файдаланыла.

1803 елда Казанда Коръән 2 өлештән һәм 10 өлештән торган китаплар итеп нәшер ителә. Ислам тарихында Коръәнне шулай ун өлешкә бастырып чыгару практикасы әле булмый. Бу исә, һичшиксез, коммерция максатларында, сату бәясен төшереп, күбрәк акча эшләү өчен башкарылган һәм шәкертләргә арзан бәягә изге Китап текстларын сатып алу мөмкинлеген биргән. Аларны бастыру да мөфти белән килештерелгән булу шик уятмый.

Мөфти, шулай ук, Истанбулдан Мөхәммәд Биргәвинең (1573 вафат булган) гарәп телендә язылган «әт-Тарика-и әл-Мөхәммәдия» китабын бастырырга фәтва бирә. Бу хезмәт мөселманнарны активлыкка һәм эшмәкәрлеккә өнди: милек кешегә бу дөньяда матди кыенлыкларга тармыйча яшәү өчен кирәк, ә акча – Аллаһ биргән игелек, аны дөрес тоту һәр мөселманның ахирәттәге тормышына турыдан-туры йогынты ясый дип ассызыклана. Шуңа күрә китапта акчаны башкалар мәнфәгате өчен сарыф итү – мәдрәсә, мәчет, күпер салу мөһим дигән фикер уздырыла.

Мөхәммәтҗан мөселман җәмгыятенең киләчәген традицион җәмгыятькә кушылып, аны ныгытачак рус урта һәм югары уку йортларын тәмамлаган шәхесләр катламы формалашуга нисбәтле күзаллый. Мөфти беренчеләрдән булып хакимияткә дин кардәшләренең белем бирү системасына реформа кирәклеге хакында хәбәр итә. Аның проекты нигезенә Казанда университет җитәкчелегендә, Оренбургта губернатор карамагында мөселманнар өчен махсус урта белем бирә торган уку йортлары (гимназияләр) ачып, аларны тәмамлаган кешеләргә университетта уку мөмкинлеге булдыру фикере салынган була. Проект кәгазьдә генә калса да, бу документ Мөхәммәтҗанны мөселман җәмгыятенең киләчәген кайгырткан шәхес буларак бәяләргә мөмкинлек бирә *(Кемпер М. Суфии и учёные в Татарстане и Башкортостане (1789–1889). Исламский дискурс под русским господством. Казань: РИУ, 2008. С. 104-106, 217-229)*.

Мөфтиләр Г.Габдерәхимов һәм Г.Сөләйманов Мәхкәмәи шәргыя рәисләре булып торганда, император Николай I дәүләт кануннарына кодификация үткәрә, империя кануннарының тулы басмасын бастыра, шулай ук һәрбер дәүләт оешмасына, төгәл эшләсеннәр дип, төрле инструкцияләр һәм нигезләмәләр әзерләтә. Шушы сәясәт кысаларында Мәхкәмәи шәргыя, ислам институтларына кагылышлы кануннар яисә Эчке эшләр министрлыгы раслаган күрсәтмәләр эшләнә.

Мөселманнарга карата сәясәтнең мөһим вакыйгаларыннан берсе буларак 1826 елны мәхәллә руханиларын сайлау тәртибен рәсмиләштерүне күрсәтергә кирәк. Бу

тәртип буенча мәхәлләдәге ир-атларның 2/3 өлеше җирле хакимият вәкиле катнашында оештырылган җыелышта мулла яки мөәзин сайлау турында җәмәгать карары төзиләр; аларга шулай ук булачак мәхәллә руханиларының дәүләткә түләргә тиешле салымнарын үз өсләренә алу хокукы бирелә. Эш шунда ки, Россиядә өстенлекле катлам вәкиле булып, православие руханилары саналган. Мулла булгач та, аның дәүләт алдындагы крестьян салымы һәм башка бурычлары сакланган.

Габдессәлам мөфти үзенең фәтваларында дини әдәбиятка күп сылтамалар ясаган. Ул, бер яктан, рус хакимияте мөселманнарга боерганнарны үтәү кирәклеген Коръән аятьләренә һәм хәдисләргә, дини хезмәтләргә сылтамалар ярдәмендә аңлаткан, икенче яктан, аның фәтвалары суфилар карашлары белән аваздаш булып, дәвамчанлыклы кабул ителгән.

Әйтик, 1831 елны башкортлар арасында йогышлы авырулар таралу сәбәпле, кантоннардан 10-15 яшүсмерне Казанга, гимназиягә, университетның медицина факультетына укырга җибәрү турында Оренбург генерал-губернаторы П.П.Сухтеленнең боерыгы чыга. Бу хакта мөфти дә үз фәрманын тарата. Әмма Верхнеуральск, Троицк, Чиләбе төбәкләре мөселманнары һәм муллалары, бу адым укырга җибәргән яшүсмерләрне көчләп чукындыруга китерәчәк дип, үзләренең төбәк ахуннарына хатлар юллыйлар, Чиләбе төбәге руханилары бу хакта турыдан-туры императорга хат белән мөрәҗәгать итәләр. Моңа җавап итеп Габдессәлам 1834 елның июлендә медицина – изге Коръән һәм шәригать тарафыннан рөхсәт ителгән гыйлем дип, кайбер коткы таратучыларга карата – кисәтү, кайберләрен вазифаларыннан азат итү турында фәтва юллый (*Байбулатова Л.Ф. Күрс. хезмәт. 1004-1005 б)*.

Г.Габдерәхимов 1833 елда руханиларга атап төзегән нәсихәтнамәсендә мәхәлләләрдә халыкны ислам әхлагы буенча вәгазьләргә, яхшылык кылырга һәм начарлыктан тыелырга өнди, начарлык кылган кешеләрнең догалары кабул булмаячагын искәртергә куша. Ул, шулай ук, исламга кагылышы булмаган, ләкин халык ярата, балалар һәм хатын-кызлар катнаша торган һәртөрле бәйрәмнәрне һәм күңел ачуларны тыярга кирәклеген ассызыклый һ.б. *(Кемпер М. Күрс. хезмәт. 121-123 б.).*

Габдессәлам мөфти вакытында мәхәлләләр өчен Мәхкәмәи шәргыя катнашында чыккан иң әһәмиятле канун буларак, 1835 елның 9 декабре Указын атау дөрес булыр.

Идел-Урал төбәге авылларында мәчетләрнең арта баруы, руханиларның күбәюе империя структураларында борчылу тудырган. Мәчетләр каршында имам-мөәзиннәрнең санын чикләү һәм, гомумән, бу өлкәдә норматив кертү кирәк табылган. Дәүләт советы: «Бер мәчеткә ике яки аннан да күбрәк мулла билгеләп буламы?» – дигән сорау белән Мәхкәмәи шәргыягә мөрәҗәгать иткәч, Уфадан: «Мөселман традициясе буенча, җәмигъ мәчеттә хатыйб, имам һәм мөәзин, биш вакыт намаз укый торган мәчеттә имам һәм мөәзин тиеш, күбрәк мулла булса, мәхәллә халкы арасында низаглар чыгачак һәм халыкның матди тормыш-көнкүрешенә тискәре йогынты ясаячак», дип җавап бирелгән. Шушы кәгазь нигезендә яңа канун кабул ителгән. Ислам традициясе күзлегеннән караганда, бу Указ шактый буталчык яңгырый: теркәлгән мәхәлләдә 200дән артык ир-аттан торган җәмгыять өстәмә мулла сайларга теләсә, аларның саны җәмигъ мәчетендә булган саннан артмаска тиеш, диелгән.

Мөселман илләрендә җәмигъ мәчете фәкать шәһәрләрдә генә булган. Авыл җирендә мәчетләр бишвакыт гыйбадәтханә ролен үтәгәннәр. Шушы Указ нигезендә мөселманнар мәчетләре янына өчәр рухани (ягъни җәмигъ мәчетендәге кадәр) сайлый башлаганнар. Әгәр дә аларның берсе хатыйб булса, ул җомга намазында вәгазь әйтергә хокуклы булган. Шулай итеп, мөселман илләрендә фәкать шәһәрдә генә җәмигъ мәчет төзергә дигән кагыйдә Россия шартларында юкка чыккан. Хәзер мәчет статусы сайланган мулланың Мәхкәмәи шәргыядә тапшырган имтихан нәтиҗәсендә бирелгән дини дәрәҗәсенә бәйле булган: хатыйб икән, мәчет җәмигъ исеме белән аталган, имам булса – бишвакыт намаз укый торган мәчет дип саналган. Бу яңалык, ахыр чиктә, авылларда җәмигъ мәчетләренең һәм руханиларның саны артуга китергән.

Эчке эшләр министрлыгы, мөселманнарның гаилә мөнәсәбәтләрен тәртипкә салуны күздә тотып, мөфтигә дин кардәшләренең никах һәм аерылышу кагыйдәләрен эшләүне йөкли. Габделвахит Сөләймановның мәшһүр хезмәте дип, 1841 елның 21 гыйнварында кабул ителгән никах һәм аерылышу кагыйдәләрен атарга кирәк. Анда никахны фәкать кыз бала тәрбияләнгән мәхәллә мулласы укырга тиешлеге, егет белән кызның Россия кануннары билгеләгән балигълык яшенә җиткән булу зарурлыгы әйтелә. Никахка кадәр кәләш янына кеше җибәреп, мулла аның «риза» булуын ишетү, ягъни кәләшнең ирекле, үз теләге белән тормышка чыгуын тәэмин итү таләбе игътибарга лаек.

Оренбург казак гаскәрендә хезмәт итүче мөселманга никах укыганчы, мулла аның командирыннан рөхсәт сорарга тиеш була. Башкорт яки башка казак сословиесе вәкиле икенче хатын алырга теләсә, муллага үзенең командирыннан беренче хатыны белән аны кимсетми яшәгәне һәм икенче хатынга өйләнү өчен җитди сәбәп булуы хакында кәгазь алып килү мәҗбүри итеп куела.

Рекрут хезмәте 20 ел булу сәбәпле, имамнарга ире солдатка алынган хатынны, мөрәҗәгате булса, аеру хокукы бирелә *(Сборник циркуляров и иных руководящих распоряжений по округу Оренбургского магометанского духовного собрания. 1836–1903 гг. Уфа, 1905. С. 5-10).*

Дәүләт, мәчет төзүне яхшырту ниятеннән, 1829 елны сигез почмаклы үрнәк мәчет проекты раслаган була. Бу проект дүрт яки алты почмаклы бинаның ике кыеклы түбәсенә манара утырту традициясенә каршы килгән. Г.Сөйләманов 1843 елны эчке эшләр министрына 1829 елгы проект буенча мәчет төзү кыенлыклары хакында хат юллый һәм үрнәккә ике җәмигъ һәм ике бишвакыт мәчет планнарын терки. Николай I 1844 елны, мөфтинең мөрәҗәгатен игътибарга алып һәм үз архитекторларыннан сыздыртып, төрле зурлыктагы ике җәмигъ һәм ике бишвакыт мәчетләрнең үрнәк проектларынраслый. Бу яңалык мәчетләр төзүне күпкә җиңеләйтә. Ә 1862 елны мәҗбүри рәвештә үрнәк проектлар буенча мәчетләр төзү практикасы туктатыла *(Загидуллин И.К. Исламские институты в Российской империи: Мечети в европейской части России и Сибири. Казань: Татар. кн. изд-во, 2007. С. 234–245).*

Мөфти булып, Сөләйманов торган заманда руханиларның кайбер хокуклары төгәлләштерелә, бу алар өстеннән контрольне көчәйтү һәм дәүләт кануннарын төгәл үтәтү максатында эшләнә. Тиешле кагыйдәләр еш кына игътибарга алынмау сәбәпле, императорның 1849 ел 21 июнь Указы нигезендә яшьләре тулмаганнарга никах укыган өчен руханиларны 6 айга кадәр төрмәгә утырту тәртибе кертелә. 1855 елны руханиларның вазифага керешү яше билгеләнә: ахуннар – 25 яшьтән, хатыйблар һәм имамнар – 22 яшьтән, мөәзиннәр – 21 яшьтән (*Азаматов Д.Д. Күрс. хезмәт. 128 б.*).

1862 елны хөкүмәт муллаларга мәхкамәгә мөселманнарны ант иттерергә яки төрмәгә тоткыннар янына чакырганда командировка акчасы түли башлый.

Ниһаять, хөкүмәт, төрле мәсьәләләр буенча кабул ителгән указларны тәртипкә салып, 1857 елны Мәхкәмәи шәргыянең Уставын раслап куя. Дини идарәнең һәм руханиларның хокуклары һәм бурычлары турында маддәләрне туплаган бу хокукый актның җитешсезлекләре күп булса да, мөселман җәмгыяте өчен аның әһәмияте зур икәнлеге бәхәссез.

Шулай итеп, Мәхкәмәи шәргыянең XVIII гасыр ахыры – XIX йөз уртасындагы эшчәнлеге аның мөселманнар тормыш-көнкүрешендәге күп өлкәләрне колачлап алырга омтылуы, шул исәптән, күп кенә иҗтимагый-сәяси, мәдәни мәсьәләләрне хәл итәргә алынуы турында сөйли. Әлеге оешма, дини йола-гадәтләрне үтәүгә кагылган тәртипләрне ныгыту белән бергә, хакимият белән халык арасындагы күп кенә аңлашылмаучылыкларны юкка чыгаруга, мөселманнарның көндәлек хәлен яхшыртуга да үзеннән зур өлеш кертә.

**Илдус ЗАҺИДУЛЛИН,**
*тарих фәннәре докторы.*

## 2023 елда дини бәйрәмнәр
## һәм истәлекле көннәр

МӨСЕЛМАН АЙ КАЛЕНДАРЕ БУЕНЧА 1444-1445 ҺИҖРИ ЕЛЛАР

**26 гыйнвар** – Рәҗәб аеның беренче җомгасына каршы кич – Рәгаиб кичәсе дип атала. Мөхәммәд пәйгамбәрнең әти-әнисе Габдуллаһ һәм Әминәнең бергә кушылуын искә алу кичәсе дә.

**17 февраль** – Мигъраҗ кичәсе. Мөхәммәд пәйгамбәрнең Мәккә шәһәреннән Иерусалимга һәм аннан җиде кат күккә – Аллаһы Тәгаләнең тәхете янына кылган могҗизалы сәяхәте. Мигъраҗ уразасы 100 төн ураза тотуга тиңләнә.

**6 март** – Бәраәт кичәсе, ягъни «ләйләтул-Бәраәт». Бәхет һәм һәртөрле уңышлар, изгелекләр иңә торган изге көн. Нәкъ шушы төнне Аллаһы Тәгалә, һәркемнең изге гамәле һәм догаларында ялварып сораган үтенечләрен исәпкә алып, кешеләрнең язмышы турында карар кабул итә.

**23 март** – изге Рамазан ае һәм Ураза башланган көн.

**21 апрель** – Гайдел-фитыр. Ураза бәйрәме.

**21 май** – Идел Болгарстанында Ислам динен рәсми рәвештә кабул иткән көн (310 нчы һиҗри, 922 нче милади ел).

**27 июнь** – Гарәфә көне. Хаҗ кылучылар тарафыннан Мәккә янындагы Гарәфә тавына бару һәм тау итәгендә намаз уку көне.

**28 июнь** – Гайдел-Әдъхә, Корбан гаете. Мөселманнарның иң зур бәйрәме. Ураза тәмамлангач, нәкъ 70 көннән соң башлана торган Корбан чалу бәйрәме, ул 3 көн дәвам итә. Бу көн Татарстан Җөмһүриятендәге барлык календарьларда кызыл төс белән билгеләнгән.

**29, 30 июнь** – Тәшрикъ көннәре. Әлеге көннәрдә мөселманнар, фарыз намазларын укыганнан соң, Аллаһы Тәгаләне мактап, махсус сүзләр әйтәләр.

**19 июль** – 1445 ел, яңа мөселман елы һәм Мөхәррәм ае башланган көн. Бу айда күп итеп хәер (зәкят) бирелә, изге гамәлләр кылына.

**28 июль** – Гашура бәйрәме. Сөнниләр – Аллаһы Тәгаләнең ун пәйгамбәренә күндерелгән изгелекләре хөрмәтенә, ә шигыйлар, Мөхәммәд пәйгамбәрнең оныгы Гали хәлифәнең улы Хөсәенне (626-680) җәзалап үтерү көнен мөбарәк, изге вә хөрмәтле санап, ураза тота.

**26 сентябрь** – Мәүлид бәйрәме. Иң зур бәйрәмнәрнең берсе – Мөхәммәд пәйгамбәрнең туган көне. Әлеге изге бәйрәм нәкъ бер ай дәвам итә. Бу вакытта мәчетләрдә вәгазьләр укыла, хәер, садака (зәкят) өләшенә. Күп кенә мөселман илләрендә факеллар һәм фонарьлар кабызып, тантаналы мәрәсимнәр уздырыла.

**Хаҗи Абдулла ДУБИН** *төзеде.*




*«Казан утлары» хезмәткәрләренең һәм авторларының төрек язучысы Яхъя Акынгөн белән очрашу истәлеге. Фотода басканнар (сулдан уңга): Мансур Вәли-Барҗылы, Тәслимә Сибгатуллина, Гөлзадә Бәйрәмова, Рафаэль Мостафин, Тәүфикъ Әйди, Кояш Тимбикова, Рәдиф Гаташ, Рашат Низами, Шамил Маннапов, Гөлназ Хөснетдинова, Мөдәррис Вәлиев. Утырганнар: Флёра Сабирова, Лилия Гатауллина, Резеда Ганиева, Роза Туфитуллова, Яхъя Акынгөн, Ринат Мөхәммәдиев, Салих Баттал. 1991 ел.*





*Быел «Шура» журналының чыга башлавына 125 ел тула. Ул 1908–1918 елларда Оренбургта бертуган Рәмиевләр нәширлегендә дөнья күргән.*



*Вазыйх Фатыйхов (1958) – шагыйрь.*



*Ямаш Игәнәй (1938–1997) – шагыйрь.*




*Шамил Бикчурин (1928–2012) – язучы.*



*Бер очрашу – бер гомер. Сулдан уңга: Марсель Галиев, Мөдәррис Әгъләмов, Мансур Вәли-Барҗылы, Рәдиф Гаташ. 2000 нче еллар.*




*Редакциядә һәрвакыт эш кайный. Сулдан уңга: Абдулла Сәләхетдинов, Рим Шириязданов, Ринат Мөхәммәдиев, Роберт Миңнуллин, Рәдиф Гаташ, Ләбибә Ихсанова, Шамил Маннапов, Әхсән Баянов. 1980 нче еллар .*



*Мөсәгыйт Хәбибуллин (1927 – 2019) – язучы.*




*Шамил Маннапов (1938–2012) – шагыйрь.*



*Мансур Вәли-Барҗылы (1948) – язучы.*

*Аяз Гыйләҗевнең тууына – 95 ел*

# РУХЫНА, ЙӘГЕЗ, БЕР ДОГА...



Татарстанның халык язучысы Аяз Гыйләҗевнең (1928–2002) тууына 95 ел тулу «Татарстан» радиосында олы бер вакыйга буларак кабул ителде. Бу аңлашыла да, чөнки үзенең иҗаты белән татар әдәбиятында тулы бер дәверне хасил иткән әдип безнең өчен аеруча кадерле. Ул радионы халыкка үз сүзен-фикерен җиткерү өчен үтемле бер корал итеп файдалана белде, безнең коллектив белән иҗади хезмәттәшлектә яшәде.

Язучының юбилее уңаеннан аның иҗатына һәм тормыш юлына багышланган яңа тапшырулар белән беррәттән, радио фондында сакланган язмаларга мөрәҗәгать ителде. Аларны анализлап баксак, Аяз Гыйләҗев биредә иң әүвәл драматург буларак ачыла. Бу табигый, радио хезмәткәрләре аның төрле театрларда уйналган сәхнә әсәрләренә күбрәк игътибар иткәннәр, аларны яздырып алырга тырышканнар – радионың хасияте шундый. Нәтиҗәдә дистәләгән спектакльләрнең язмалары тупланган:

«Көзге ачы җилләрдә» – Г.Камал исемендәге ТДАТ спектакле, 1971 елда сәхнәдән яздырып алынган;

«Кызлар хатлары» повесте буенча радиотамаша. Камал театры артистлары башкара. 1976 ел. Инсценировка авторы – Рим Кәримов;

«Китмәгез, тургайлар» – Г.Камал исемендәге ТДАТ спектакле, 1980 елда яздырылган. Сәхнә режиссёры – Марсель Сәлимҗанов, радиорежиссёр – Госман Әхмәтҗанов, композитор – Алмаз Монасыйпов;

«Көйсезләнгән сәфәр» – Г.Камал исемендәге ТДАТ спектакленең радио варианты. Сәхнәгә куючы режиссёр – Дамир Сираҗиев. 1986 ел.

«Өч аршын җир» – Г.Камал исемендәге ТДАТ спектакле;

«Көлсәң көл, көлмәсәң ела». К.Тинчурин исемендәге ТДДһКТ спектакле;

«Әткәй җырлый да, җылый да...» һәм «Кар астында кайнар чишмә» – Әлмәт ТДДТ спектакльләре;

«Баласын жуйган болан эзеннән» – Минзәлә ТДДТ спектакле магнитофон тасмасына 1998 елда яздырып алынган.

Шулай ук әдипнең проза әсәрләреннән өзекләр архив киштәләрендә шактый урын алып тора. Алар арасыннан «Җомга көн кич белән» (Илдус Әхмәтҗанов укый) һәм «Йәгез, бер дога» (Фоат Галимуллинның кереш сүзе. Ирек Баһманов укый) әсәрләреннән өзекләр безнең көннәрдә дә эфирда актив кулланыла.

2018 елда Аяз Гыйләҗевнең тууына 90 ел тулу уңаеннан КФУда үткәрелгән фәнни-гамәли конференциянең һәм шул ук елда үткәрелгән әдәби-музыкаль кичәнең язмаларын исә әдипнең иҗатына багышланган тулы бер дәреслек дип бәяләп булыр иде.

Ә инде журнал укучылар игътибарына без уникаль бер язма тәкъдим итәргә булдык. Бу – 1986 елда Аяз Гыйләҗевкә 60 яшь тулу уңаеннан әзерләнгән тапшыру. Әдип белән әңгәмәне радионың яшь мөхәррире Зиннур Хөснияр алып барган. Тапшыруның икенче өлешендә әдәбият тәнкыйтьчесе Салих Маннаповның Аяз Гыйләҗев иҗатына багышланган мәкаләсе Инсаф Абдулла укуында бирелә. Язучы биредә шул елларның иң актуаль мәсьәләләренә кагыла һәм, гаҗәп, аның күп кенә фикерләре нәкъ безнең көннәргә атап әйтелгән кебек тоела. Әйдәгез, Аяз аганы тыңлыйк, рухына бер дога булып барсын!

*Илдар Юзеевнең тууына – 90 ел*

# АНЫҢ МОҢЫ БЕЗГӘ ШУНДЫЙ ТАНЫШ



2023 елда «Татарстан» радиосы эфиры Татарстанның халык шагыйре Илдар Юзеевнең (1933–2004) тууына 90 ел тулуга багышланган тапшырулар белән башланып китте. Юбилее көннәрендә әдипнең иҗатын тулырак чагылдыру максаты белән фонд язмалары да хәрәкәткә китерелде. Әлбәттә инде, аның шигырьләренә иҗат ителгән җырларны эфир үзе сорап тора, чөнки «Яшь наратлар», «Кайтам инде», «Бөркет турында баллада», «Мәтрүшкәләр», «Серле чәчәк», «Туган ягым каеннары», «Чит илләргә чыксаң» кебек бик күп җырлары халык күңеленә онытылмаслык булып кереп урнашкан, һәм аларны тыңлаучыларыбыз һәрвакыт көтеп ала.

Юбилей уңаеннан кыш, яз айларында Илдар Юзеевнең берничә сәхнә әсәре тыңлаучылар игътибарына тәкъдим ителәчәк. Әйтик, Шакир Мәҗитовның Илдар Юзеев поэмасына нигезләнеп язган «Резидәкәй» лирик-музыкаль комедиясе (режиссёр – Исламия Мәхмүтова, композитор – Ринат Бикбулатов) февраль аенда эфирга чыга. Аннары «Улыбыз өйләнә, без аерылышабыз», «Кыр казлары артыннан» (режиссёр – Равил Тумашев, композитор – Мәсгуть Имашев) спектакльләре нәүбәт көтә.

Укучылар игътибарына хәзер тәкъдим ителә торган язма исә шагыйрьнең иҗаты һәм тормыш юлы турындагы китапны хәтерләтә. Тарихи тапшыру! 1990 еллар урталарында радиода әдәбият-сәнгать редакциясенең баш мөхәррире, шагыйрь Әхмәт Рәшит каләмдәше Илдар Юзеевне иртәнге эфирга кунакка чакырган. Һәм менә шунда әдип гаҗәеп кызыклы фикерләр әйткән, алар укучыларыбызга бер ачыш булыр кебек. Сез QR-код ярдәмендә журналның сайтына кереп, әлеге тапшыруга колак салырсыз, колак салырсыз да аннан ахырына чаклы аерыла алмассыз. Ә без кәгазьгә әдип сөйләгәннәрнең берничә җөмләсен теркәп куйыйк:

*Әхмәт Рәшит*. Күләм ягыннан синең шигъри иҗатыңның иң зур проценты нәкъ менә поэмалар өлешенә карый торгандыр. Бу нәрсә белән аңлатыла?

*Илдар Юзеев*. Әлбәттә, Әхмәт, иҗат ул спорт түгел, рекорд артыннан кусаң, сыйфатка зыян килер иде. Поэмалар язу алдыннан мин озак еллар шигырь жанрын үзләштердем, берничә пьеса да язып карадым. Шигырь белән драматургияне кушарга теләү дәрте мине шул жанрга тарткандыр, дип уйлыйм мин. Син, Әхмәт, үзең дә күп кенә поэмалар язган шагыйрь буларак, бу жанрның нинди авыр һәм катлаулы икәнен яхшы беләсең. Мин поэманы шигъриятнең иң мөһим жанры дип исәплим. Кол Гали, Кандалый, Тукай, Такташлар нинди гүзәл поэмалар калдырганнар! Үзләре яшәгән чорның тарихы, фәлсәфәсе нинди көчле чагылган аларда! Хәзер, заман кыска жанрларны таләп итә, диючеләр бар. Әйбәт поэма язылса, озынмы ул, кыскамы, аны барыбер укыячаклар...

Әлеге язмада әдипнең әдәбиятка, заманга, шул заманның аерым вакыйгаларына карата фикерләре теркәлеп калган. Үз тавышы белән! Һәм алар безнең көннәрдә дә кыйблабызны эзләгәндә, бер якты маяк булыр дип уйлыйбыз. Тыңлыйк!

*Сәхифәне «Татарстан» радиосының шеф-мөхәррире*
**Нәсим АКМАЛ** *алып бара.*

# МӘҢГЕ ЯШЬ «ЧАЯН»ГА – 100 ЯШЬ!

***1933 ел, 5 нче саннан***

## Төз атарга өйрән!

*(язучыларга карата)*

Гомәр Гали кайда? – Татиздатта,
Саубуллаша шагыйрь кул сузып;
Яшьләр усал, утырталар үзен
Һәрбер
Юлга
Берәр
Сүз
Куеп...

**Ә.Р.**

***

Уңышлардан баш әйләнеп,
Туп итә күрмә, Алиш,
Халтуралы –
«Безнең яз»да
«Безнең сүз»
Үтми торсын,
Юк әле, энекәш,
Шалишь!

**И.Р.**

## Бер эхо!

Биш былтыр бит инде,
Язган нәрсәң
Биш-алтыга тулмый torгандыр,
Их брамат энем,
Шулмы булды инде Туфанлык?

**Ә.И.**

## Туфан!

Туган, кубар туфан!
Басып китмәс борын тузан!

**Р.**

***1954 ел, 11 нче саннан***

## С.Хәкимгә

Уяна кошлар тирәктә,
Таң җиле куя исеп.
Кузгала моңнар йөрәктә,
Язмавың искә төшеп.

**КАРАХМӘТ**

## Г.Гобәйгә

Сакал-мыек басты күптән
«Замана балалары»н.
Тудырды да югалды, дип
Зарлана балаларың.

**КАРАХМӘТ**

## Г.Әпсәләмовка

Роман арты роман бирә,
Ера һәр куелыкны.
Тел ягыннан шомарганын
Күреп булырмы, юкмы?

**З.ЗАМАНОВ**

## Г.Иделлегә

Бернәрсә дә язмый хәзер
Безнең Газиз Иделле.
Аның хәтта каләме дә
Мүкләнә, диләр инде.

**Х.ШАБАН**

## Җ.Тәрҗемановка

Җәүдәт язмый түгел, яза,
Тормышка караштырып.
Кат-кат китабын чыгара,
Исемен алмаштырып.

**Котдус ДӘҮЛӘТШИН.**
*Алабуга районы.*

## Ә.Давыдовка

Секретарьлык итү өлкәсендә
Бик күп, диләр, яхшы якларың.
Бәхәсләшмим, күптер, әмма ләкин
Сагындыра шагыйрь чакларың.

***1954 ел, 11 нче саннан***

## Даллес әфәндегә

Юк абсолют бушлык табигатьтә! –
Философлар шулай сөйлиләр.
Ялгышалар ләкин: димәк, алар
Синең башны әле белмиләр!

## Пакъстан турында

Шундый ил бар – Пакъстан,
Халкы кия ак ыштан.
Ак ыштан да кия алмас,
«Ярдәм» килгәч АКШтан.

***2000 елгы саннардан***

## Р.Фәйзуллинга

Тау өстеннән йолдызлар да якын,
Егылсаң да, кеше күзендә...
Таулар гадел. Ни кычкырса да,
Кайтавазы кайта үзенә!

## Р.Мәннан:

Тауга карап кычкырдым мин бүген!
«Син биек», – дип Тауның үзенә.
Таулар гадел икән:
Кайтавазы кайтты үземә.

***1958 ел, 12 нче саннан***

Б. Старчиков рәсеме.




— Тәки сүземдә тордым бит!

***2020 елгы саннардан***

## Р.Миңнуллинга

Чын «Чаян»чы булган икән,
Нигә безгә язмаган?
Әллә тыелып торганмы,
Әллә Ходай язмаган!
Әллә безләр тиң булмаган
Шигъри киң талантына?
Юкса коенып яшәде
Халык яратуына.

## Гафу итмәслек саташу

Тукай булмаган дип әйткән
Өфөдәге бер галим.
Галим түгелдер ул адәм,
Чынлап, билләһигазим.

**Алмаз ХӘМЗИН**

## М.Әхмәтовка

Татар өчен җаны фида аның,
Тарих әйтер бер көн рәхмәтен.
Туган телне яклар өчен кирәк
Марат Готыф улы Әхмәтов...

**Рашат НИЗАМИ**

*Сәхифәне* **Алмаз ХӘМЗИН** *әзерләде.*

# Ictimagi-mədəni tormışıbızdan
# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ УТЫРЫШЫ

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышында «Татарстан Республикасы Президенты» атамасын «Рәис» дип үзгәртергә тәкъдим ителде.

## БАГЛАНЫШЛАР НЫГЫЙ

Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла Бакуга эш сәфәре кысаларында Азәрбайҗан Язучылар берлеге рәисе Анар Рзаев белән очрашты. Очрашуда ике берлек арасында хезмәттәшлек турында меморандумга кул куелды.

## ӘДӘБИ ЕЛ ЙОМГАКЛАРЫ

Татарстан Язучылар берлегенең Г.Тукай клубында әдәби ел йомгакларына багышланган җыелыш булды. Ул берьюлы өч мәйданчыкта барды: Казанда, Чаллыда, Әлмәттә. Язучыларны Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты җитәкчесе  Данис Шакиров, Татарстан Республикасы мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин сәламләде һәм бер төркем каләм ияләренә бүләкләр тапшырдылар. Җыелышта Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла соңгы елларда эшләнгән эшләргә хисап ясады. Аннары Газинур Морат (шигърият), Камил Кәримов (проза), Галина Зәйнуллина (рус телендәге әдәбият һәм әдәби тәрҗемә), Рафис Корбан (балалар  әдәбияты), Рәдиф Сәгъди (драматургия), Әлфәт Закирҗанов (әдәби тәнкыйть) докладлар белән чыктылар. Фикер алышуларда Рәфкать Кәрами, Наилә Ахунова, Нәҗибә Сафина чыгыш ясады. Соңыннан җыелыш резолюция кабул итте.

## МӘҺДИЕВ УКУЛАРЫ

Арча районы Галиәсгар Камал исемендәге Сикертән мәктәбендә Татарстанның халык язучысы Мөхәммәт Мәһдиев укулары булып узды.  Анда Арча, Балтач, Әтнә, Теләче, Биектау, Кукмара районнары укучылары һәм укытучылары катнашты.  Алар биш номинациядә көч сынашты. Болар: «Мәһдиев – авыл баласы» (3-4 сыйныфлар өчен), «Мәһдиев иҗатында мәдәни мирасның сакланышы» (5-7 сыйныф), «Мәһдиевнең иҗатын беләсеңме?» (8-9 сыйныф), «Мәһдиев иҗатында күтәрелгән проблемалар» (9-11 сыйныф), «Мәһдиев иҗатында публицистика» (укытучылар). Эшләргә махсус комиссия бәя бирде. Комиссиядә Казаннан кайткан язучылар Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Камил Кәримов белән «Казан утлары» журналының баш мөхәррир урынбасары Вакыйф Нуриев та бар иде.

## ЮБИЛЕЙЛАР

Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә Татарстанның халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Рөстәм Мингалимнең тууына 85 ел тулу уңаеннан искә алу кичәсе булды. Анда язучылар Рабит Батулла, Рәдиф Гаташ, Газинур Морат, Мөхәммәт Мирза, Тәлгат Галиуллин, Илсөяр Иксанова, якташлар һ.б. үзләренең истәлек-хатирәләре белән уртаклаштылар. Кичәне Илдар Кыямов алып барды.

* * *

Аяз Гыйләҗев исемендәге Чаллы татар дәүләт драма театрында Татарстанның халык шагыйре, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт, М.Җәлил исемендәге Республика премияләре лауреаты, җәмәгать эшлеклесе Разил Вәлиевнең 75 яшьлек юбилеена багышланган «Бу дөньяның мин бер кыйтгасыдыр» дип исемләнгән әдәби-музыкаль кичә булып узды. Анда шәһәр җитәкчеләре, иҗтимагый оешмалар вәкилләре, язучының каләмдәшләре, якташлары, шигърият сөючеләр катнашты. Кунакларга театр фойесында Үзәк китапханә тарафыннан әзерләнгән  Р.Вәлиевнең тормыш һәм иҗат юлына багышланган күргәзмә тәкъдим ителде. Юбилярны Чаллы шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Рамил Хәлимов, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, аның урынбасары, берлекнең Чаллы бүлеге җитәкчесе Факил Сафин, каләмдәшләре Рәдиф Гаташ, Рабит Батулла, Фоат Садриев, Алмаз Хәмзин, Чаллы шәһәре мэры киңәшчесе Фәйрүзә Мостафина, Бөтендөнья татар конгрессының Түбән Кама бүлеге җитәкчесе Рөстәм Ганиев, Р.Ваһапов фонды рәисе Рифат Фәттахов, төбәкне өйрәнүче тарихчы Айдар Хәмзин һ.б. котлады. Кичәдә шагыйрьнең җырлары, шигырьләре яңгырады. Бәйрәмне Идрис Кәлимуллин, Азат Абитов, Гөлсирин Абдуллина – җырлары, Аяз Гыйләҗев исемендәге Чаллы татар дәүләт драма театры артистлары шигъри композиция белән бизәде.

* * *

Казандагы «Сәйдәш» Мәдәният үзәгендә шагыйрь, прозаик, публицист, җәмәгать эшлеклесе, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Г.Исхакый, Җ.Вәлиди, Һ.Атласи исемендәге әдәби премияләр лауреаты Айдар Хәлимнең 80 яшьлек юбилее уңаеннан «Мәхәббәттән язмыш башлана...» дип аталган әдәби-музыкаль кичә булып узды. Аны шигырьләре белән юбиляр үзе башлап җибәрде. Залда язучының каләмдәшләре, якташлары, укучылары, туксанынчы еллардагы милли хәрәкәт вәкилләре иде. Бәйрәмдарны Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе Данис Шакиров, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, Г.Камал театры артистлары Равил Шәрәфиев, Әзһәр Шакиров, Илдус Әхмәтҗанов, А.Хәлимнең туган ягыннан – Башкортстанның Миякә районыннан килгән вәкилләр һ.б. котлады. Кичәдә К.Тинчурин театры артистлары Зөфәр Харисов, Ирек Хафизов юбилярның шигырьләрен укыдылар, Айдар Хәлимнең кызы Зөлфия Тәхаутдинованың әтисе сүзләренә язган җырлары яңгырады. Аларны Алинә һәм Азат Кәримовлар, Руслан Сәйфетдинов, Сәйдә Мөхәммәтҗанова, Алмаз Хөсәенов, Флёра Талипова-Колахмәтова, Рөстәм Насыйбуллин, Гүзәл һәм Арслан Сибгатуллиннар һ.б. башкарды. Сәхнәдә кич буена Рәсим Ильясов җитәкчелегендәге «Казан нуры» оркестры уйнады. Бәйрәмне Г.Камал театры артисты Фәнис Җиһанша алып барды.

* * *

Татарстан Язучылар берлегенең Г.Тукай клубында шагыйрә, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Абдулла Алиш исемендәге әдәби премия лауреаты Йолдызның (Йолдыз Шәрәпова) юбилей кичәсе булды. Бәйрәмдарны «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте генераль директоры Шамил Садыйков, ТР мәгариф һәм фән министры урынбасары Минзәлия Закирова, Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Илсөяр Иксанова, Буа якташлык җәмгыяте рәисе Ирек Закиров, «Шәһри Казан» газетасының баш мөхәррире Радик Сабиров, каләмдәшләре Хәбир Ибраһим (котлавын җыр белән дә ирештерде), Рәхимә Арсланова, Дания Нәгыйм, Наилә Яхина, галим Альберт Борһанов, дуслары, сабакташлары котлады. Йолдызның шигырьләрен балаларның укуы, улы Сәйдәшнен җырлавы бәйрәмне тагын да ямьләндерде.

### «ЯҢА ТАТАР ПЬЕСАСЫ – 2022»

Г.Камал театрында «Яңа татар пьесасы – 2022» бәйгесенә йомгак ясалды.

I урын – **Әлфис Гаязов** «Картлар күңеле кемнәрдә»;

**Салават Юзеев** «Последние люди»;

II урын – **Артур Ибраһимов** «Бабайның бабасы»;

III урын – **Артур Ибраһимов** «Күрше авыл догалары»;

Кызыксындыру премияләре – **Мансур Гыйләҗев** «Бездә туй – аерылабыз», **Айгөл Әхмәтгалиева** «Пароль – Юк!»;

«Милли классиканы заманчалаштыру өчен» махсус номинациясендә – **Раушан Шәриф** «Ач күзеңне, килен бу»;

ТР Мәдәният министрлыгының махсус премиясе – **Рөстәм Галиуллин** «Күзгә кайтаваз».

### КИТАП ТӘКЪДИМ ИТҮ

Казанда, «ТАТМЕДИА» бинасындагы «Әдәби кафе»да Башкортстанда яшәп иҗат итүче Аида Хәйртдинованың «Кышкы юл озын иде» китабын тәкъдим итү булды. Бу – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте ярдәме белән «Казан утлары» журналы китапханәсе» сериясеннән басылып чыккан уналтынчы китап. Яңа китап бәйрәмендә «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте генераль директоры Шамил Садыйков, «Мәдәни җомга» газетасының баш мөхәррире Вахит Имамов, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе урынбасары Марс Тукаев, язучы Галимҗан Гыйльманов, «Казан утлары» журналының җаваплы сәркатибе Ландыш Әбүдәрова һ.б.чыгыш ясады. Нәфис сүз остасы Айваз Садыйров әсәрдән өзек укыды. Автор үзе видеочыгышын җибәргән иде. Соңыннан Кыш бабай («Казан утлары» журналының шигърият бүлеге мөхәррире Фәнил Гыйләҗев) бәйрәмгә килгән кешеләргә Яңа ел котлавын ирештерде һәм бүләк итеп шушы китап белән «Казан утлары» журналының 100 еллыгына чыгарылган фотоальбомны өләште. Чараны «Казан утлары» журналының бүлек мөхәррире Рафис Корбан алып барды.

### СӘФӘР

«Казан утлары» журналының баш мөхәррир урынбасары Вакыйф Нуриев, шигърият бүлеге мөхәррире Фәнил Гыйләҗев, язучы Рәдиф Сәгъди Марий Эл Республикасының Бәрәңге районы Портянур, Куян авыллары мәктәпләрендә булып, укучылар белән очраштылар, аларга журналлар бүләк иттеләр.

2022 елның 9 декабрендә 83 нче яшендә Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе **Мансур Әхмәтдин улы Шиһапов** вафат булды.

Мәрхүмнең җәсәде Балык Бистәсе районы Яншык авылы зиратында җирләнде.

*Сәхифәне* **Вакыйф НУРИЕВ** *әзерләде.*

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*«Проза и поэзия»: роман Ф.ГИМАЛТДИНОВА «Хан Орды Узбек», повесть Ф.САФИНА «Сухой», рассказ Ш.ЗИГАНГИРОВОЙ «Сколько раз можно любить?»; стихи М.МИРЗЫ, Л.САГИДУЛЛИНОЙ, Ф.ГАБДРАХИМА.*
*«Новые имена»: рассказ Д.ФАРХЕТДИНОВОЙ «Последний подарок судьбы».*
*«Литература родственных народов»: стихи А.САГАТАЕВА в переводе с хакасского языка Ф.ГИЛЯЗОВА.*
*«Юбилеи»: статья Н.ЮСУПОВОЙ. Литературный взгляд на творчество М.МИРЗЫ.*
*«Память»: статья М.ГАИТОВА.*
*«Соплеменники»: статья Д.ЗАГИДУЛЛИНОЙ.*
*«1100 лет со дня принятия Ислама в Поволжье»: статья И.ЗАГИДУЛЛИНА.*
*Религиозные праздники и памятные даты в 2023 году.*
*«Бесценные голоса»: статья к 95-летию А.ГИЛЯЗЕВА и статья к 90-летию И.ЮЗЕЕВА.*
*Рубрику ведет Н.АКМАЛ.*
*«Страницы юмора»: К 100-летию журнала «Чаян». Рубрику подготовил А.ХАМЗИН.*
*Из архива журнала.*
*Дневник общественно-культурной жизни.*
*На наших обложках: главная ёлка в Казани.*

# IN THIS ISSUE:

*«Prose and Poetry»: novel by F.GIMALTDINOV «Khan Uzbek», story by F.SAFIN «Hard», story by SH.ZIGANGIROVA «How many times can you love?»; poems by G.BATTAL, M.MIRZA, L.SAGIDULLINA, F.GABDRAKHIM.*
*«New Names»: story by D.FARKHETDINOVA «The Last Gift of Fate».*
*«Literature of Kindred Peoples»: poems by A.SAGATAEV translated from the Khakas language by F.GILYAZOV.*
*«Anniversaries»: article by N.YUSUPOVA. Literary view on the work of M.MIRZA.*
*«Memory»: article by M.GAITOV.*
*«Tribemans»: article by D.ZAGIDULLINA.*
*«1100 Years since the Adoption of Islam in the VolgaR»: article by I.ZAGIDULLIN.*
*Religious holidays and memorable dates in 2023.*
*«Priceless voices»: article on the 95th anniversary of A.GILYAZEV and article on the 90th anniversary of I.YUZEEV.*
*The rubric is led by N.AKMAL.*
*«Pages of humor»: 100th anniversary of the journal «Chayan». The rubric is led by A.KHAMZIN.*
*From the magazine's archive.*
*Diary of social and cultural life.*
*In our covers: the main tree in Kazan.*

---

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Казанның төп чыршысы. *И.АБРАМОВА фотосы.*